ISSN 0206—4185

# КАЗАН УТЛАРЫ

5.1990



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ЖУРНАЛЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

**1990**

**5**

**(811)**

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР


И. ЮЗЕЕВ. Өзелгән тәсбих. *Нәүрүзләр, тәкбирләр* . . 3
Т. ӘЙДИ. Елан угы. *Роман* . . . . . . . . . . . . . . . . .12
Ә. ГАДЕЛ. Заһидулла Яруллин — сабан туенда. *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . . . 87
С. ХАФИЗОВ. Гомерем фасыллары. *Повесть* . . . . 91


ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ


И. ХӨСНИ. Җырлар иле. *Шигырьләр* . . . . . . . .130
Т. ШӘМСУАРОВ. Дөнья. *Шигырьләр* . . . . . . . .132
Х. КАСЫЙМОВ. Өлкәннәр. *Шигырьләр* . . . . . . .134


ПУБЛИЦИСТИКА


М. ГАЛИЕВ. Яшәү белән үлем арасында . . .136
В. ЮНЫСОВ. «Әс-Сабру мифтах әл-фараҗ» . . . . .147


ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


Тукайлар рухы *(язучы Н. Фәттах белән тәнкыйтьче М. Вәлиев әңгәмәсе)* . . . . . . . . 153
К. МИҢЛЕБАЕВ. Хәзинә алмашканда . . . . . . . .158
Л. КӘШФИЕВА. Гамил Афзал көлүе . . . . . . . .162


ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ


Р. ӘМИРХАНОВ. Төзәтмикче Тукайны . . . . . . .166


КИТАП КҮЗӘТҮ


И. ХӘЛИУЛЛИН. Сәхифәләр калка тарихтан . . 169


ТАТАР ХАЛКЫ: ТӨРЛЕ ТӨБӘКЛӘРДӘ, ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘ


Ф. ШӘРИФУЛЛИНА. Касыйм татарлары . . . . 172


ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ


А. ВӘЛИУЛЛИН. Табылдык хатлар ни сөйли? . 176


МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА


С. ӘХМӘТЕВ. «Кыйссаи Йосыф» асылташлары . 178

Р. ВӘЛИЕВ. Монгол яуларына кадәрге чорда Болгар иле белән Русь арасында сәүдә элемтәләре . . . . . . . . . . . . . . . . 181

ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕ

Сигезенче дәрес . . . . . . . . . . . . . . . . . 185

Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре . . . . . . . . . . . . . . . . 187

Котлыйбыз . . . . . . . . . . . . . . . . 189

Мәдәният тормышы көндәлеге . . . . . . . . . . 190

Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*

РАВИЛ ФӘИЗУЛЛИН

*Редколлегия*

ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘЖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙПОВ
*(җаваплы секретарь)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек редакторы)*
МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘУФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек редакторы)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият,
очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: продолжение романа Т. АЙДИ «Жало змеи», повесть С. ХАФИЗОВА «Мгновения судьбы». Новые стихи И. ЮЗЕЕВА, А. ГАДЕЛЯ.
«Творчество молодых»: стихи И. ХУСНИ, Т. ШАМСУАРОВА, Х. КАСИМОВА.
«Публицистика»: М. ГАЛИЕВ «Между жизнью и смертью»; статья-размышление В. ЮНУСОВА о проблемах современности.
«Литературная критика»: Беседа критика М. Валиева с писателем Н. ФАТТАХОМ; статьи К. МИННИБАЕВА о проблемах художественного перевода и Л. КАШФИЕВОЙ, посвященная особенностям юмора Г. Афзала.
В рубрике «Острая проблема»: Р. АМИРХАНОВ ставит вопрос о неурезанной публикации творческого наследия Г. Тукая.
«Татарский народ: в различных регионах страны и мира»: Р. ВАЛИЕВ «Касимовские татары».
«Библиография»: Рецензия И. ХАЛИУЛЛИНА на книгу Н. Фаттаха «Поющие стрелы».
Письма читателей: А. ВАЛИУЛЛИН о новой повести К. Тимбиковой «Тайна найденных писем».
Статья кандидата геологических наук С. АХМЕТОВА «Драгоценные камни поэмы «Киссаи Юсуф».
Р. ВАЛИЕВ. «Торговые отношения Великого Булгара с Русью в домонгольский период».
Уроки татарского языка
Навыки чтения на основе арабской графики. Отмечается 60-летие Р. Валиевой и М. Хузина.
Хроника культурной жизни;
На наших обложках — деревянное зодчество татарского народа. Портрет известного писателя Ахсана Баянова.

*Бүлек редакторлары* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Редакторлар* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рашит Әхмәтҗанов.
*Техредакция*: Р. Вафина, Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина.

Производствога бирелде 5.03.1990 ел. Басарга кул куелды 26.04.1990 ел. ПФ 05241. Офсет ысулы белән басылд.
Кәгазь форматы 70×108. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 83044. Заказ Д-118. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1990 ел.

ШИГЪРИЯТ

## Илдар Юзеев

# ӨЗЕЛГӘН ТӘСБИХ

НӘҮРҮЗЛӘР, ТӘКБИРЛӘР

## Беренче тәсбих: нәүрүзләр

*Бу заманда онытылган*
*Гадәт-йолага кайтып,*
*Өйдән өйгә йөрмәк булдым*
*Шигырь, җыр, бәет әйтеп...*

### Ач ишегең, керәмен

Нәүрүзче мин... Ният изге.
Куркышып бикләнмәгез,
Өйләрне талап йөрүче
Сукбай дип шикләнмәгез!
    Ач ишегең, керәмен,
    Нәүрүз әйтә киләмен!
Нәүрүз аенда бабайлар
Келәне дә элмәгән,
Матур теләк әйтүчегә
Этләре дә өрмәгән.
Таныш миңа һәрбер нигез,
Чит-ят итмәгез алай,
Мин һаман шул: көйгә салып,
Шигырь сөйләүче малай.
Якты йөз белән нәүрүзне
Көтә торган сәгатьләр...
Нигә ачылмый ишекләр?
Кердеме ят гадәтләр?
Кайсы нигезгә барыйм да
Кайсы капкадан керим?
Таң алдыннан үз-үземә
Мин нәүрүз әйтеп йөрим:
    Ач ишегең, керәмен,
    Нәүрүз әйтә киләмен!

---

Илдар ЮЗЕЕВ *(1933) — шагыйрь, драматург. Татар, рус, башкорт телләрендә дөнья күргән кырыкка якын китап авторы. ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт һәм М. Җәлил исемендәге комсомол премияләре лауреаты. Казанда яши.*

## Җиде кыз бәете

Килгәннәр, кергәннәр,
Актарып йөргәннәр,
Янәсе, чын йөзен яшергән.
«Хөкемгә тартылган»,
Өзгәләп атылган
Сәйләне таралган, чәчелгән...

Дошман дип күргәннәр,
Мулланы сөргәннәр,
Җиде кыз язмышы билгесез...
Нигезләр таралган,
Шәҗәрә каралган,
Кайларда йөрисез инде сез?

Көтәм мин юллардан,
Эзләре югалган,
Язмышның юлларын кем белгән?
Сабира — Себердә,
Сәгыйдә — Сембердә,
Саҗидә — Самарда күмелгән.

Йөрсәң дә эзеннән,
Гомерләр өзелгән,
Күзләрем — тузанлы юлларда.
Җәмилә — көньякта,
Камилә — төньякта,
Шамилә, Гамилә — Уралда...

Бабагыз акланды,
Шәҗәрә сафланды,
Тик менә кабере билгесез...
Җыр юллыйм мин сезгә,
Таралган нигезгә,
Оныклар, кайтыгыз инде сез!

Таралды болытлар,
Кайтыгыз, оныклар,
Бабагыз нигезен тоярбыз,
Хәтерләп яшьлекне,
Таралган тәсбихне
Бергәләп-бергәләп җыярбыз...

Дәшмисез, дәшмисез нигә сез?..

## Авылыбызның асыл бер егете

Кызлар кер чайкыйлар басмада.
Авылыбызның асыл бер егете
Өзелеп-өзелеп җырлый... тасмада:
Моңайтырбыз әле,
Бер кайтырбыз әле,
Утлар сүнсә сүнәр учакта...

Суынсагыз бездән,
Кайтырбыз да тиздән
Җылытырбыз кайнар кочакта.
Кызлар кер чайкыйлар басмада.
Авылыбызның асыл бер егете —
Рәсеме кайтты кара тасмада:
Моңайтырбыз әле,
Бер кайтырбыз әле,
Утлар сүнсә сүнәр учакта...
Кызлар кер чайкыйлар басмада.
Һәлак булды егет чит җирләрдә,—
Тавышы гына кайтты тасмада:
...Суынсагыз бездән,
Кайтырбыз да тиздән
Җылытырбыз кайнар кочакта.
Тавышы гына кайтты тасмада.
Өзелгәнне ялгап, уйчан кызлар
Өзелеп-өзелеп җырлый басмада:
Моңайтырбыз әле,
Бер кайтырбыз әле,
Утлар сүнсә сүнәр учакта...
Суынсагыз бездән,
Кайтырбыз да тиздән
Җылытырбыз кайнар кочакта...
Нәүрүз котлы булсын!
Ачык ишекләрегездән
Кара кайгы кермәсен,
Әфган фаҗигасе янә
Кабатлана күрмәсен!

## Югалган шәҗәрә

Ачлык елны ташлап киттем,
Бер сынык икмәк эзләп...
Үзем — татар,
Ирем — таҗик,
Балалар — үзбәк.
Кайттым туган авылыма
Шәҗәрә очын эзләп...
Үзем — татар, ирем — таҗик,
Балалар — үзбәк.
Әнкәй каберендә — сукмак юк...
Ничекләр кирәк түзмәк?!
Үзем — татар,
Ирем — таҗик,
Балалар — үзбәк.
Оныкларым — русча гына...
Чабабыз сүзлек эзләп,
Үзем — татар,
Ирем — таҗик,
Балалар — үзбәк.
Тапмадым әнкәм каберен,
Йөрсәм дә үксеп — эзләп...
Оныклар — рус,
Ирем — таҗик,

Балалар — үзбәк.
Адашып йөрим зиратта,
Әнкәм туфрагын эзләп...
Оныклар — рус,
Ирем — таҗик,
Балалар — үзбәк...
Үзем кем соң?
Шәҗәрәмне
Кем йөрер эзләп?

## Үтәлмәгән әманәт

Әллә инде монда җир тетрәгән,
Узган мәллә давыл?
Беркем җавап бирми. Кайда соң син,
Әти туган авыл?
Яфракларын селки, ят итәдер
Бабам яткан зират...
Кайда чишмә юлындагы кызлар?
Кырлардагы ир-ат?
«Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз»,— диеп,
Әти җырлап киткән.
Язмыш аны фашист коллыгына,
Аннан читкә илткән.
Атам нәүрүз әйтә-әйтә кергән
Ишекләрне тапмыйм,
Әманәтен җиткерергә теләп,
Урам буйлап атлыйм.
«Үтә, улым, диде, минем шушы
Соңгы әманәтне:
Таратмасын иде авылдашлар
Минем яманатны.
Илгә хыянәт тә итмәдем мин,
Сатлык җан да түгел.
Тормышлар — мул, балалар да разый...
Әмма әрни күңел.
Өлешемә тигән көмешемдер,
Язмыш шулдыр инде...
Соңгы сулышымда авылым мине
Бәхилләсә иде.
Авылымның тәмле суын сагынып
Сырхауладым тәмам.
Бер йотым су биреп җибәрегез...
Өзелеп көтеп калам»...
Рәнҗемәссең, әти, башны иеп
Зират буйлап үтәм.
Авылыңнан синең әманәтне
Үти алмый китәм.
Әле дә шөкер, җир дә тетрәмәгән,
Кагылмаган давыл.
Сулар агулангач, туган җирен
Ташлап киткән авыл...
Югалган авылга карап,
Башны иям дә тынам.
Туксан тугыз нигез иде

Мөбарәк тәсбих сыман...
Нәүрүз артыннан нәүрүз бу,
Сәйлән артыннан сәйлән...
Кулларымда — бар дөньяга
Сибелгән өзек бәйләм...

## Икенче тәсбих: тәкбирләр

### Картлар әйткән тәкбир

И аллам, син гали, син бөек,
Сорыйбыз ялварып, баш иеп.
«Адәмнәр бозылды, азалар»,—
Диеп син китермә казалар.
Илаһым, ташлама адәмне,
Китермә гомуми әҗәлне!
Акылны дәһшәткә фән җигә,
Җир, һава, суларда — фаҗига.
Тын җитми иркенләп суларга,
Агулы ризык та, сулар да...
Илаһым, син гали, син бөек,
Сорыйбыз ялварып, баш иеп.
Күбәйде имансыз адәмнәр —
Рухсыз вә җансыз да калганнар.
Укыдык мең дога, мең аять —
Кимеми фахишлек, җинаять.
Асылын югалтты бу бәндә:
Төзәтми җәза да, төрмә дә...
Булса да бик түзем, бик сабыр,
Вөҗданлы кешегә бик авыр.
Илаһым, ташлама адәмне,
Китермә гомуми әҗәлне!

...Һәрбер диннең таңресе — бер,
Бар минем дә үз аллам:
Ул — Шигърият! Мин аңардан
Фатиха һәм сүз алган.
Китми күз алдымнан һич тә:
Өзелгән тәсбих ята.
Чәчелгән, таралган дисбе
Җанда әрнү уята.
И Шигърият, күңелемдә
Илаһи бер көй сизәм,
Изге сүзләр бәйләменә
Дисбе-шигырьләр тезәм.
Кол Гали, Тукай һәм Такташ —
Пәйгамбәрләрем минем,
Фатиха-киңәш алмасам,
Тәсбих тезәлмәс идем.
Күп вакытта аерылсак та
Уйларда, бәйрәмнәрдә...
Әлбәттә, шагыйрь булгандыр
Мөхәммәт пәйгамбәр дә.
Күк йөзе — чиксез, куркыныч...

Серлелек артып тора,
Мәңгелек сер шагыйрьне дә
Күкләргә тартып тора.
Аксакаллар, сез дә, мин дә
Илаһи биеклектә:
Карашыбыз бик еш кына
Очраша зәңгәр күктә.

## Мәчет нигезендә әйтелгән тәкбир

*Урамнан урамга йөрим,*
*Тәкбир әйткән картлар күк:*
*Шигъри сүзем авылым рухын*
*Дога булып саклар күк.*

Аксакаллар, сез сабыр, сез түземле,
Ишетегез минем шигъри сүземне.
Иске мәчет авылның күрке иде,
Тирә-юньгә нур-иман бөрки иде.
Бабамнар күккә сер сөйләгәннәр,
Күк телендә догалар көйләгәннәр.
Ник шул кадәр шашканбыз, тилергәнбез,
Иске дип, мең еллык рухны җимергәнбез.
Без, нәниләр дә, тотындык арканга,
Олыларга көч өстәдек тартканда.
Чукынсын, имеш, иске заманасы:
Гөрселдәп ауды мәчет манарасы!
«Кеше Галәмнән дә өстен!» дип кычкырдык,
Җирдән дә без, Күктән дә без ычкындык.
Каргадыгыз кечесен һәм олысын:
«Манара аударган куллары корысын!...»
Телә йөрәкне әйткән тәкбирләрегез,
Өзә үзәкне сүзләр — тәгъбирләрегез.
Куллар, корымаса да, шәфкатьле эшләргә кыскарды,
Алар гел җимерергә остарды.
Соң булса да, аңладым йөрәк ярагызны,
Кичерегез каргалган балагызны.
Гүр иясе инде күпләрегез,
Телә йөрәкне әйткән тәкбирләрегез...

## Болгар җирендә әйтелгән тәкбир

*И татарларның кәгъбәсе,*
*Мәккәсе — шәһри Болгар!*
*Мин генәме, сәҗдә кылып,*
*Карашын сиңа борган...*

Ташлар гүя тәкбир әйтә,
Тыңлап торам тын калып:
«Бармы җирдә безнең нәсел?
Онытмагыз: без — А Л Ы П!»
Мин дә кушылам бу моңга,
Сискәнеп, уйга талып...

Без — Тукайлы, Җәлилле дә...
Тик... хәзер нинди халык?
Ташлар гүя тәкбир әйтә:
«Сез хәзер нинди халык?
Безнең рухны таптарсызмы
Изге җырларга салып?
Онтырсызмы Алыплыкны,
Телсез-тарихсыз калып?»
Мин дә кушылам ташларга
Тәшвиш-борчуга калып:
«Бездә м е ң ел югалырмы,
Уллы-оныклы халык?
Кемнәр барыр киләчәккә
Алыплар рухын алып?»

## Утка карап әйтелгән тәкбир

Сак бул, Кеше, сискәнүең
Юкка түгелдер бер дә:
Залимнәр үсеп чыгалар
Галимнәр янган көлдә.
Аң бул, Кеше, зәһәр утны
Явыз кулларга бирмә:
Залимнәр үсеп чыгалар
Шагыйрьләр янган көлдә.
Рәхимсезлек, шәфкатьсезлек
Буш җирдә тумый бер дә:
Имансызлар үсеп чыга
Коръәннәр янган көлдә.
Әче йөзем исе килә
Диңгездән — төтен-җилдә...
Ни үсәр — җирсез калганнар
Үзен яндырган көлдә?..

## Тәкбиргә кушып әйтелгән нәләт

*Дивардан диварга барам,*
*Тәкбир әйткән картлар күк.*
*Нәфрәт хисем диварларда*
*Нәләт булып шартлар күк!*

Нәҗес куллар тарафыннан
Язылган күпме әләк.
Яла яткан ул кулларга —
НӘЛӘТ! НӘЛӘТ! НӘЛӘТ!
Залим, җәллад төрмәсендә
Асыллар булды харап...
Залимнәргә, җәлладларга —
НӘЛӘТ! НӘЛӘТ! НӘЛӘТ!
Адәмнәрне гелә түгел,
Халыкны юкка санап,
Иленнән сөргән тиранга —
НӘЛӘТ! НӘЛӘТ! НӘЛӘТ!

Каберләрен табалмыйча,
Ташка-туфракка карап,
Кабатлыймын бер үк сүзне —
НӘЛӘТ! НӘЛӘТ! НӘЛӘТ!
Җир астыннан, диварлардан
Аваз килә — аманәт:
«Исән йөргән залимнәргә —
НӘЛӘТ! НӘЛӘТ! НӘЛӘТ!»

## Милләтара бәрелешләрдән соң картлар тәкбире

Җиһан шундый зур, түгәрәк,
Һәммәбез дә сыябыз...
Тукта, туктагыз, туганнар,
Ник җаннарны кыябыз да
Ник каннарны коябыз?
Асыл туганлык тәсбихен
Йөз-мең еллар җыябыз...
Туган ил — бердәм оябыз,
Ник тәсбихне коябыз?
Гел бергә җыйган тәсбихнең
Өзелгәнен тоябыз...
Йөрәкләрнең, үзәкләрнең
Өзелгәнен тоябыз,
Үч-нәфрәтне тыябыз да
Бергәләшеп җыябыз!
Һәрбер өзелгән өлешен
Үз урнына куябыз!
Җиһан шундый зур, түгәрәк,
Һәммәбез дә сыябыз...
Дөнья — ул мөбарәк тәсбих,
Акылыбызга уябыз,
Тәсбих бер таралса әгәр,
Җыеп булмас, юкка чыгар
Җир шары — үз оябыз...

Хуплап, тәсбихемә тездем
Картларның теләк-уен,
Тәкбир дә көчсез шул... сизәм:
Уртак сүз табу кыен.
Һәр халыкның үз иманы,
Үз җире, горурлыгы,
Милли җанына чәчелгән
Гасырларның орлыгы.
Тигезлек даулап, тел-милләт
Чыга корыч кысадан.
Ил-йорт — тузынган, аерган
Умартага охшаган.
Залим астындагы коллык,
Узган гомер кызганыч...
Гаделлек өчен көрәш бу,
Ирек өчен кузгалыш!
Җитте тел яшереп яшәү,
Авыз йомып тын тору!
Бу — милләтнең сүнгән рухын

Янартырга омтылу!
Бер-береңнең омтылышын,
Хәлен аңларга вакыт,
Һәр милләтнең үзенә бөек
Телен санларга вакыт!
Ызгышудан, таркалудан
Белмим туктату серен...
Берләштерсә, безне бары
Тигезлек берләштерер!..

## Атом станциясе афәтеннән соң картлар тәкбире

Кодрәтле вә мәрхәмәтле Аллабыз,
Үзең коткар, ни күрербез алда без?
Куркытып та калтыратып яшәтмә,
Тотма безне өметсезлек, дәһшәттә!
Гыйлемгә өмет багълады адәмнәр,—
Ә ул алып килде мәхшәр, әҗәлләр.
Алчы бу Җирдән, галимнәреңне ал,
Дөньяны харап итәчәк залимнәреңне ал!
Ашар ризык, һава, сулар — агулы,
Тәнгә ниләр кирәк — шулар агулы.
Китте Җирдән миһербанлык, бәрәкәт,
Юлда, суда, күктә — үлем, һәлакәт.
Җәзала да гөнаһлыны, яманны,
Китермәче безгә ахыр заманны!
Пәйгамбәрең юлла — бу газап китсен,
Мәһди[1] безне коллыктан азат итсен!

Кыйтгадан кыйтгага йөрим,
Тәсбих тарткан картлар күк,
Шигъри «догам» Кешелекне
Юк булудан саклар күк.
Туксан тугыз сәйләп эзләп,
Сүзләр тәкрарлап атлыйм.
Иң кирәкле, иң хәлиткеч
Йөзенче сүзне тапмыйм...
Җиһанда — гауга, хәрәкәт:
(Куркып, басылып яткан),
Кемдер — җирен, кемдер — илен,
Кемдер — телен югалткан.
Гаепләне табалмагач,
Уртага — хәнҗәр чыга...

Бир сабырлык һавасыз һәм
Сусыз калган юлчыга!
Юлларда — атом тузаны,
Җанда — радийлы давыл.
Дөнья — гүя шәҗәрәсен
Эзләгән сусыз авыл.
Кыйтгадан — кыйтгага йөрим,
Узып милли чикләрдән:
Ишекләр, ник ачылмыйсыз,
Ычкынмыйсыз бикләрдән?!
«Дөнья — ул мөбарәк тәсбих»...
Йөрим илләр буйлата,
Алларымда — өзгәләнгән,
Таралган тәсбих ята...

*1989.*

[1] Мәһди — дини риваятьләрдә: ахыр заман җиткәндә соңгы пәйгамбәр — Мәһди күренәчәк, шуннан соң Җир йөзендә гаделлек патшалыгы урнашачак, дип фараз ителә.

Чәчмә әсәрләр

**Тәүфикъ Әйди**

# ЕЛАН УГЫ

РОМАН

19



Кәрвансарай капкасы төбендә көтеп торган иптәшләренә корал чыгарып биргәннән соң, Фарукҗан хәрби комиссариатка шалтыратты. Сөйләшү кыска булды һәм каефне кыра торган рухта тәмамланды. Аңа хәрбиләрчә чатнатып:

— Иптәш Шиһабетдиновның йомышчысы Рахманкол кичә үк шәһәрдән чыгып китте,— диделәр.

— Кая юнәлде? — дип сорады Байкучатов.

— Каршы ягына.

— Нинди эш белән?

— Белмибез. Аны бездән Ревком сорап алды. Ә сез кем буласыз?

— Чекадан бу. Егетне анда ничә көнгә җибәргәннәр икән?

— Әйтә алмыйбыз. Сез кем буласыз соң?

Фарукҗан җавап бирүдән тыелып, трубканы куярга ашыкты. Койрыгына теләсә кем басмый торсын әле!

Рахманколны аулакта күрергә һәм нығытып сөйләшергә ашыкмавы Симиниевләр белән бәрелешүдән саклану аркасында гына түгел иде. Фаҗиганең бердәнбер таныгы нәкъ менә шушы кеше генә булу шикләндерде аны. Әгәр гаепле икән, бу артык гади һәм күзгә төшәр дәрәҗәдә сәер ләбаса. Әйтерсең лә, кемдер шикне юри шуңа төшерү һәм саташтыру өчен алдан ук хәйлә корып куйган. Тукта! Әгәр Рахманкол мөрит кенә икән, нигә аның белән бәйләнеш тотучыларны эзләмәде соң әле ул? Менә бусы инде башсызлык, тәҗрибәсезлек галәмәте. Шул ук Гарипов электән шәхсән танышмы икән аның белән? Рахманкол якын-тирәдә йөргәндә аны астыртын гына күзәтү бөтенләй җиңел эш иде ләбаса! Полициядә дә хезмәт иткән бәндә булгач, нинди генә сер сыймас егеткә. Их син, тавык мие эчкән нәрсә! Хәвефле Бохарадан бөтенләй үк табан ялтыратмаса ярый инде. Иргәш тә әйле-шәйле генә фикердә ич аның турында. Ләкин... ләкин ул чакта аңа нигә баштан ук юкка чыкмаска иде соң?

Дәвамы. Башы 4 нче санда.

Күңелен төрле уй талаган Фарукҗан, хәзер инде нәрсә генә майтарырга мөмкин икән, дип ике тәүлек эчендә эшләгән эшләрен күз алдыннан кичерә башлады. Дөрес, ул бу вакыйганы тикшерүгә җавап бирми, хәтта аннан бөтенләй читләтелде. Бәлки нәкъ менә үзбаш эзләнергә керешүе һәм шуның белән кемгәдер ошамавы аркасында Ташкентка командировка бирелүе дә растыр.

Газәли мәхәлләсендәге чәйханәнең соңгы вакытта төнге клуб сыман үзәккә әйләнүен, анда төрле этрәк әләм җыйналып гәп куертуын Байкучатов инде атна-ун көннәр элек үк ишеткән иде. Яңа танышлары ул ояны Бохараның бер кызык җире сыман итеп сөйләделәр. Әмма Шиһабетдинов вакыйгасына кадәр Фарукҗан аны бар дип тә белмәде. Артык өметләнергә ярамаса да, сүз капчыгын селкегән җирдә колак салып торуның үзенә зыян китермәячәген ул бик яхшы чамалый иде. Комиссар юкка чыгу кеше теленә кермәслек вакыйга түгел, кичә үк аяк басарга кирәк иде инде анда.

Тагын бер ачыклыйсы нәрсә — Зөһрәгөл хәбәре. Кемнәр чекист муенын борып атарга җыена икән соң? Ни өчен? Нәкъ менә шушы вакыйгадан соң — Фарукҗанның фаҗигане җентекләбрәк тикшерергә теләге барлыгы сизелгәннән соң, аңа теш кайрый башлаулары бәлки очраклы хәл түгелдер? Монда нидер бар, моны ачыкламый ярамый. Әмма аннан да кирәгрәге, мөгаен, Шиһабетдиновның Каганнан ары китеп өлгермәгән хатларыдыр: йомгакның очы яки шуңа берәр ишарә менә кайда күренүе мөмкин. Тик ул хатларга күз салу насыйпмы икән Байкучатовка? Симиниевнең мөнәсәбәте мәгълүм, Чека председателе генә ярдәм итмәсә...

Фарукҗан коридорга чыгып, Әминев кабинетына сугылды — бикле иде. Шуннан соң кире үз бүлмәсенә әйләнеп кереп, ишекле-түрле йөренә башлады. Аннары Каган вокзалында язып алган адресны исенә төшереп, күнегелгән хәрәкәте белән унатарын барлый-барлый тимер-күгенә чыгып атланды һәм, якташы Шәмгунне эзләп табарга дип, шәһәр үзәгендәге мәхәлләләрнең берсенә чаптырып китте. Тик ул аны өендә дә, партия Үзәк Комитетында да очратмады. Шәмгун Аксолтанов, суга төшкәндәй, кайдадыр юкка чыккан иде. Чека председателе күрергә киңәш биргән, Фарукҗан уенча, аның йомышы хакында Әминев тарафыннан инде кисәтеп куелырга тиешле Кәрим Хәкимев нииндидер комиссия утырышын уздыра — сөйләшергә ул да буш түгел иде. Шуңа күрә Байкучатов бераздан янә Чекага әйләнеп кайтырга мәҗбүр булды. Монда ул, төрле агымнар көрәшен яхшырак төшенер өчен, җирле матбугатны караштырырга кереште.

«Бохара әхбаре»» газитен актарганда ул хәзер үзен кызыксындырган исемнәрнең икесен — Шәмгун Аксолтанов белән Кәрим Хәкимевне барларга тырышты. Ташкентта партия мәктәбен тәмамлаган һәм монда аның белән бергә килгән иптәшләреннән, аннары Бохарада танышкан кешеләрдән ул инде бу ике шәхес турында кайбер нәрсәләрне ишеткән иде. Әмма Фарукҗан андый имеш-мимешләр нигезендә генә Аксолтанов белән Хәкимевнең тоткан юлларындагы аерымлыкны, бигрәк тә Бохара Компартиясе Үзәк Комитеты постыннан беренчесенең төшерелүе һәм аның урынына икенчесенең сайлануы сәбәпләрен юньләп ачыклый алмаган иде. Аның исәбенчә, Шиһабетдиновның дусларын һәм дошманнарын чамалау өчен бу беренче чиратта кирәк, хәрби комиссарның монда килгәч кемнәр җырын җырлавын һәм кемнәргә каршы чыгуын якташларына мөнәсәбәттә билгеләү җиңелрәк булырга тиеш иде.

Фарукҗанның белүенчә, Шәмгун Аксолтанов Казан губернасында туган, башта авылда, атасы мәктәбендә, аннары Казан мәдрәсәсендә укыган, заманында кадимчеләргә каршы чыккан, дөньяви белем алырга тырышкан кеше иде. Яшьли шигырьләр язарга керешкән. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, патша хезмәтеннән качып, Бохара

әмирлегенә килеп урнашкан. Монда ул мамык тазарту заводында. Кызыл түбә тимер юл станциясендә, соңра Каган типографиясендә эшләгән, шушында большевиклар белән танышып, революцион хәрәкәткә тартылган. Яшь бохаралылар программасының демократиграк таләпләр куюына йогынты ясарга тырышкан, аннары Бохара коммунистлар партиясенә нигез салуда катнашкан иде. Ләкин Бохара мәмләкәтендә инде байтактан яшәсә дә, җирле халык телен әле һаман яхшы үзләштермәгән иде. Кайберәүләрнең мыскыллап көлүенчә, аңа үзбәк телен өйрәнүне марҗа хатыны тыя, имеш! Билгеле, бу хәбәрне Фарукҗан чынга алмады. Бохара шартларында марҗага өйләнү һәм шуның белән бергә гомер итү, әгәр ул хәбәр дөрес булса, үзе генә дә зур кыюлык, икенчедән, кыюлык кына да түгел, күпчелек мөселманнарның ачуын китерә торган бер эш иде. Аның Бохара компартиясе Үзәк Комитеты секретарьлыгыннан төшерелүендә дә нәкъ менә шушы ягы хәлиткеч роль уйнамады микән? Шиһабетдинов нигә дус итте икән соң Шәмгунны? Ярлылар хакын яклап көрәшкә күтәрелүе, кулына корал алып, хатыны белән бергәләп әмир өнен штурмлауда катнашуы өченме? Бәлки Шәмгунның сүзе эшеннән аерылмавы, искиткеч кыю һәм тәвәккәл булуы Баһаветдинны әсир иткәндер? Бәлки Аксолтановның шагыйрьлек шөһрәте дә күңеленә ошагандыр? Тик... шул арада белеп өлгердеме икән соң әле ул дустының шигырьләр язуын?

Фарукҗан «Бохара әхбаре» гәзитен актарганда һәм таныш исемнәрне күздән кичергәндә, әнә шушылар турында уйлады, үзе элек белгәннәргә нәрсә дә булса яңаны өстәргә тырышып утырды. Әмма «Бохара әхбаре»ндә ул күбрәк Гарипов исеменә юлыкты. Сан саен! Коралларны тапшыру, элек төрле идарәләрдә вазифа башкарган хезмәткәрләрне гафу итү һәм эшкә алу, фаэтоннарны һәм атларны мәмләкәт милкенә әйләндерү турындагы һәм бүтән боерыкларга Ревком исеменнән нәкъ менә ул кул куйган иде. Фарукҗан бу әмерләрнең берсенә аеруча игътибар итте. Әмир кул астында эшләгән түрәләрне кичерү ике яклы лабаса. Бу күрсәтмә яңа идарә сафларына үтеп керү өчен дошманнарга киң юл ачмый микән? Хәер, боерык астында Гариповныкы белән бергә Халык Комиссарлары Советы рәисе Хуҗаев исеме дә тора торуын. Кумәк хәл ителгәндер бу. Эш алып бару өчен тәҗрибәле, укымышлы кешеләр кирәклеге ачык. Ләкин саклык белән сайлау хаҗәт аларны. Үтә саклык белән. Шулай эшләнәме икән соң ул?

Таҗик телендә басылган мәкаләләрне искә алмаганда, Фарукҗан гәзитләрне тулысынча караштырып чыкты. Бохара революциясенең максатларын аңлаткан язмалар да, яңа хөкүмәт боерыклары һәм игъланнары да аны әллә ни кызыксындырмады — боларның күпчелеге белән Байкучатов эш барышында ук танышкан иде. Кызыл Гаскәргә язу, укытучыларны теркәү, иске китапларны саклау әмерләренә дә ул күз йөгертеп кенә узды. Әмир өерен җиңүгә шатланып язылган «Көн тугды», «Котылдык» шикелле мәкалә, шигырьләргә дә, дөнья хәбәрләренә дә озак туктални — рухын ачыклаганнан соң ул бүтәнәренә күчте. Әмма таныш исемнәрне аларында да очрата алмады. Революцион халык вәкилләренең Беренче Бөтен Бохара корылтаена гәзит зур гына урын биргән. Тик анда ни Аксолтанов, ни Хәкимев чыгышы күренми иде. Хивадан, Гыйшыкабадтан тәбрик телеграммалары бар, ләкин бәйсез Бохара Халык Совет Республикасын игълан иткән шушы съездда РСФСР хөкүмәте исеменнән сөйләгән Кәрим Хәкимевнең котлау нотыгына урын табылмаган. Гаҗәп! Дөрес, Фарукҗан аның корылтайда ниләр сөйләгәнен болай да яхшы белә.

«Барыннан да әүвәл шуны әйтергә кирәк,— ди анда Хәкимев,— элек, царизм вакытында, рус хезмәт ияләре белән бергә башка халыклар да изелеп килде. Хәзер һәр милләт үз язмышын үзе хәл кыла».

Корылтайда РСФСР вәкиленең җылы чыгыш ясавын, җитмәсә аның һәркемгә аңлаешлы итеп үзбәкчә «гәперүен», халыкның азат Русия вәкилен алкышларга күмүен күпләр әле дә бик яхшы хәтерли иде.

Ә нигә РСФСР хөкүмәте исеменнән съездны нәкъ менә Кәрим Хәкимев тәбрикләде икән? Аның Оренбург губернасы һәм Татарстан республикасы ревкомнары члены, Төркестан компартиясе Вакытлы Үзәк Комитеты секретаре итеп билгеләнүе, болардан башка тагын шактый җаваплы урыннарда эшләве хак. Әмма баш күтәргән Бохара халкын котларга бүтән күренекле партия эшлеклеләре аз идемени? Әйтик, бу көннәрдә шушы якка килеп чыккан Фрунзе, Куйбышевлар! Тик алар, әлбәттә, Урта Азия хезмәт ияләре арасында Хәкимев шикелле озак еллар буе кайнамаган, Канибадамдагы кебек шахталарда кәйлә белән күмер чапмаган, үзбәк, таҗик ярлылары белән кара эштә дәвамлы рәвештә иңгә-иң тир түкмәгән, Караянтаг шикелле кышлакларда аларның балаларын укытмаган, Фирганәдә солдат шулпасын эчмәгән, кыскасы, Бохара халкының фәкыйрь катлауларына хас тирәлектә, аларныкы кебек шартларда бергәләп тормыш итмәгәндер, шуңа күрә гади дийканнар, эшчеләр һәм чабаннар белән яңа Русия исеменнән сөйләшүне дә аларның телен генә түгел, ничек сулыш алуын да тоя һәм белә торган кешегә тапшырганнардыр.

Байкучатов берьюлы «Бохара әхбаре»ндәге Фәйзулла Хуҗаев, Габделкадыйр Мөхетдинев мәкаләләре белән дә танышып чыкты, аннары гәзитләрне шкафка алып куеп, тагын Әминев кабинетына кагылды — Чека председателе әле һаман әйләнеп кайтмаган иде. Шуннан соң ул кизү торучы иптәшен кисәтте дә шәһәрнең бердәнбер шифаханәсенә юнәлде. Анда башы сызлавыннан, хәле китүеннән зарланып, докторга күренде, аңардан дару юнәтергә рецептлар, эш урынында күрсәтергә дип чирләве хакында аерым белешмә яздырып алды. Әлбәттә, ул даруханәгә баруны уйлап та карамады, бу бары тик Ревком әмереннән тайчану өчен хәйлә генә иде.

Менә шуннан уралганда Фарукҗан бая үзе бик очратырга ашкынган кешесенә тап булды. Ул аны күреп алу белән җитез генә каршысына чыгып исәнләште дә:

— Ә мин сезне, Шәмгун абый, бүген генә өегезгә эзләп барган идем әле,— диде.

Тузан кунган киемнәренә һәм шактый әлсерәгән кыяфәтенә карaганда, Аксолтанов ерак юл узган кешегә охшаган иде. Бу күрешү аны әллә ни шатландырмаса да, ул туктарга мәҗбүр булды һәм Байкучатовка карап:

— Нинди нужагыз төште соң миңа, якташ? — дип көлемсерәде.

— Сез бүген Таштимер абыйны очратмадыгызмы?

— Андый бәхетне ходай язмады шул әле. Мине ул эзләтте мени?

— Юк ла.

Фарукҗан, әгәр алар очрашкан булса, дусларча гәп барышында чекистның Кагандагы эзләнүләрен дә бизмәнләп карарлар, шунлыктан аңа Шәмгун абыйсыннан кызыксынган нәрсәләрен сорашу да җиңеләер, дип өметләнгән иде. Аксолтановның җиңелчә шаярып җавап бирүен һәм якташының йомышын тыңларга бер дә атлыгып тормавын күргәч, Фарукҗан басынкылана калды. Тик ул бу юлы ялгышты. Аксолтанов нәкъ менә Тураевны бүген көндез күргәнлектән һәм аның белән кайбер хәлләр турында фикер алышырга өлгергәнлектән генә, бик сусаган һәм арыган булса да, Байкучатовның сәламен алып, туктап калды һәм, күләгәгә елышыбрак, аның сүз башлавын көтте.

— Мин сезгә үз йомышым белән сугылган идем,— диде Фарукҗан яңадан телгә килеп.

— Нинди йомыш икән соң ул?

— Әлеге Шиһабетдинов турында инде. Мин ул һәлакәтне үзбаш тикшерә башлаган идем. Кайберәүләр моны хупламаса да.

— Нигә мондый хаҗәт эшне хупламасыннар икән?

— Чөнки аны ачыклау Чеканың яшерен-оператив бүлеге башлыгы иптәш Симиниевкә тапшырылган иде.

— Ә ул баш тарттымы?

— Юк...

Байкучатов һәлакәт урынын карау хәлләрен, үзендә бу уңайдан туган шик-шөбһәләрне, фаразларны, томанны таратыр өчен ясаган беренче адымнарын, шуннан соң көне белән башланган сәер аяк чалуларны һәм астыртын янауларны телгә алып, бер җепкә тезәргә кереште. Аның сүзләренә колак салып торган Аксолтанов көлемсерәвен бик тиз сүндерде, йөзе җитдиләнде. Ниһаять ул:

— Сез моны миңа ни дип сөйлисез соң? — дип сорады.

— Иптәш Шиһабетдиновның дусты булганга.

— Кем әйтте?

— Иптәш Әминев. Ул сезне миңа булышыр дип юраган иде.

— Үзе ярдәм итәме соң?

— Тели шикелле, әмма...

— Нәрсә «әмма»?

— Әллә ничек шунда, аягы-кулы бәйләрәк төсле тота үзен дип әйтимме? Әллә миңа ышанып бетмәве генәме — тәмам аптырадым инде. Эзләнүемә теләктәш тә шикелле.

— Аңлашыла,— диде Аксолтанов.— Тыңлап-тыңлап торам да, сезнеңчә шик уята торган кешеләрнең иң беренчесе Рахманкол булып чыга бит әле?

— Әйе шул, минем дәлилләрем гел шуны раслап тора.

— Ә сез партиягә керү өчен рекомендацияне Рахманколга Баһаветдин үзе бирүен беләсезме?

— Булмас!

— Була шул, якташ,— диде Аксолтанов.— Мин ул язуны үз күзем белән күргән кеше.

Аксолтанов тәмәке төреп кабызды һәм әңгәмәдәшенә дә янчыгын сузды. Аннары тәмәкесен тирән-тирән итеп суырды да, Фарукҗанны күзәтә-күзәтә, төтенен читкә өрде.

— Үҗәтләнеп үз юлыгыздан атлавыгыз ошый миңа, сез буш егет түгел икән,— дип дәвам итте ул аннары.— Әйбәт бу, әйбәт. Чынлап та, өйгә кагылыгыз әле сез, кайбер четерекле нәрсәләрне аяк өсте генә сөйләшеп бетереп булмый. Күрсәтәсе бер язу да бар шикелле. Менә шунда гәпне дәвам итәрбез, ә?

— Кайчан килсәм, сезгә уңайлырак булыр икән? — диде Байкучатов.

— Бүген кичке тугызлар тулгач мөмкин. Кыенсынып тормагыз, мин соң ятам.

— Иртәгә ничек булыр икән?

— Калган эшкә кар ява, якташ. Аннары мине тагын очрата алмый тинтерәвегез ихтимал.

— Аңладым. Планлаштырган бер эшем бар иде, шуның аркасында кичексәм дип кенә соравым. Бушауга киләм алайса.

— Килештек.

Алар икесе ике якка аерылып киттеләр. Фарукҗан шәһәрне чыгып, су буенда үскән бер агач ботагына кесәсендәге бер гәзит кисәген элеп куйды да, кулын күнектерер өчен, шуңа әүвәл илле, аннары йөз адымнан атып карады. Мәргәнлеген тикшергәч, пуляларын бушка әрәм итмәвенә шатланып, колакларын шәмрәйткән тимер-күген сыйпый-сыйпый, кире калага борылды.

Чека председателе аны күңелле хәбәр белән каршы алды.

— Егетләрегез турында сораштым,— диде ул.— Авыз суы корытуың бушка түгел икән, әйбәт яктан телгә алдылар.

— Әйттем ич мин сезгә!

— Амантай Туктаровны милициягә күчерергә булдык. Ревком сагында торыр. Иргәш Мирәхмәтев үзебезгә кулайрак шикелле.

— Киресенчә эшләп булмыймы соң аны, Галимҗан абый?

— Ярамый,— диде Әминев.— Безнең эш җаваплы, четерекле. Иргәшнең сугышларда сынау узарга өлгергән булуын онытмыйк. Ышанычлырак. Аннары укымышлырак та, таҗик телен белүе дә бар. Туктаров чыныга төшсен әле.

— Анысы да дөрес. Хәзер сез Иргәшне кем карамагына билгелисез инде?

— Яшерен-оператив бүлекне ныгытасыбыз бар. Симиниев җинаятьләрне ача алмый, дип сукранасыз ич.

Фарукҗан үзе тәкъдим иткән кешеләрне теркәү бүлегенә беркетмәсләрме дип өметләнгән, инде алдан ук шул ихтимал ярдәмчеләре белән һәлакәтне тикшерү эшләрен көчәйтергә хыяллана башлаган иде. Чека председателенең нияте шуңа күрә аны бик үк сөендермәде, ләкин Симиниев тирәсендә киләчәктә үз кешесе булачагын игътибарга алып, ризасызлык күрсәтмәскә ниятләде. Бары тик:

— Мин Иргәшне Нурморатовка кушасыздыр дип уйлаган идем әле,— диде.

— Нигә?

— Аңа агентлар җитми торгандыр, йөремсәк Тураевны күзәтер өчен генә дә күпме көч кирәк ләбаса.

— Тураевны күзәтүен кайдан белдегез?

— Хәбәрләр минем аша да уза ич. Дөрес, таҗикча язуларга тешем үтмәгәнлектән, мин элек аларга игътибар бирми идем. Тик вакыйгалар болай куерып киткәч, таштан юкә суыыбыз да гаҗәп булмастыр.

— Кызык. Тураевны кайсы агент күзәтә соң?

— «Ябалак». Хатларына таҗикча «Бум» дип кул куя. Сезнең әмерне үтидер ич ул?

— Алай ук дип әйтмәс идем,— диде Әминев.— Моннан соң аның рапортларын туп-туры үземә кертеп тапшыра барырсыз. Бу хакта Нурморатовка ләм-мим, аңладыгызмы?

— Әлбәттә, Галимҗан абый. Симиниев хәрби комиссар «эш»ен яптымы инде?

— Кичә үк. Тагын берәр яңалыгыгыз бар идеме әллә?

— Ул сезгә Каган почтасыннан алып кайткан Шиһабетдинов хатын күрсәттеме?

— Юк.

— Анда хәрби комиссарның үзенә килгәнне дә кулга төшергән икән ул. Танышасы иде шул хатлар белән!

— Ә сез моны төгәл ачыкладыгызмы?

— Почта хезмәткәре раслап тора.

— Ярар, мин бу хакта Симиниевтән үзем сорармын.

— Галимҗан абый,— дип инәлде Фарукҗан.— Эзләмәгән табылмый, без һәр вак-төяккә игътибар итәргә тиеш.

— Ярар, энем. Башка йомышыгыз юкмы?

Фарукҗан доктордан алган белешмәне Чека председателенә сузып:

— Командировканы кичектерәсе иде,— диде.— Кәеф тә юграк. Әминев кәгазьне алып укыды да:

— Күз алдында үсәсез сез, Байкучатов,— дип көлемсерәде.— Белешмә эшне җиңеләйтәчәк, билгеле, иртәгә юлга чыгып тормассыз болай булгач. Үзегез әфсенләгән язу гына түгелме бу?

— Юк, юк, бөтен шартын китереп күрендем табипка. Аннары тагын бер үтенечем бар иде әле...

— Тыңлыйм.

— Бездә оператив эшләр барышында тотылырга тиешле аерым мая юкмы ул? Мин үз эшемә Иргәш белән Амантайны да тарткан идем, бүген кичен бер чәйханәгә күз салырга кирәк иде. Анда ашамыйэчми утыруыбыз кешедә шик уятмагае дип куркам.

Чека председателе сейфен ачып, үз хәзинәсеннән Фарукҗанга бераз акча бирде.

— Чеканың бик мулдан түгел монда, чамалап кына йөрегез,— диде ул шуннан соң.— Иптәшләрегезгә әйтерсез, отряд командирлары кисәтелгән, иртәгә иртән башта миңа күренсеннәр. Теләсәләр, яңа урынга күчкән арада бер-ике көн ял итеп алырга мөмкин... Аннары... үзегез дә аңлыйсыздыр, ул егетләргә сез күз-колак булырга тиеш.

Белеп торам. Чекага бик мач киләчәк кешеләр алар,— диде Фарукҗан.— Изүчеләргә каршы нәфрәт каннарына сеңгән.

Сүзен түгәрәкләп чыгып китәргә җыенганда гына Әминев аны ишарә белән туктатып, йомышчысына Симиниевне чакырырга кушты.

Яшерен-оператив бүлек мөдире озак көттермәде, ниндидер кәгазьләр тотып, эшлекле кыяфәттә килеп керде дә, чекист иптәшенә кырын күз генә салып, түргә узды. Әминев үз алдында яткан папкадан башын күтәреп:

— Монда Шиһабетдиновның хаты теркәлмәгән икән ләбаса, Юлтай,— диде.

Симиниев:

— Нинди хат? — дип гаҗәпсенде.

— Кичә Каган почтасыннан алганыгызны әйтәм. Кайда ул?

Чека председателенең үзенә төбәлүен, Фарукҗанның да кызыксынулы карашлар ташлап алгалавын абайлап, Юлтай бүтән сорау бирмәде, иң гадәти нәрсә хакында сүз барган шикелле:

— Ә-ә, менә кайсысын барлыйсыз икән сез,— диде.— Безгә ярардай сер тапмагач, мин аны адресатына кире җибәрдем.

— Кемгә салынган иде соң ул?

— Хатынына.

— Ә Шиһабетдиновның үзенә кем язган иде?

— Ниндидер дусты шунда, Верныйдан. Чүп савытына тондырган идем, җыештыручы чыгарып түкмәгән булса, шундадыр ул.

— Әйдәгез карыйк әле без аны. Байкучатов, сез дә иптәшегезгә булышыгыз!

Әмма Симиниев кабинетындагы чүп әрҗәсе гомумән буш иде.

— Сейфегезне ачыгыз әле,— дип боерды Әминев.— Бәлки сез оныткансыздыр, хатлар шунда гына ятадыр?

Яшерен-оператив бүлек башлыгы бу әмерне дә чыраен сытмаска тырышып үтәде, әмма аның үзен киеренке тотуын тәҗрибәле күз сизми кала алмый иде. Кул астындагыларны игътибар белән күзәткән Әминев:

— Сейфне Байкучатов тикшерсен, ә сез, Юлтай, өстәлләрегезне, шкафларыгызны карагыз,— диде.— Энәсеннән җебенә кадәр! Шиһабетдинов хатын үз кулым белән почтага илтеп салдым, дисезме әле?

— Аны башка эш кәгазьләре белән бергә курьер җибәрергә тиеш иде.

— Курьерга калгач, ышаныч тагын да кими инде. Караштырыгыз, кара!

Фарукҗан сейфне, Юлтай өстәл тартмаларын актарганда, Чека председателе ишекле-түрле йөри-йөри бүлмәне һәм егетләрнең казынуын күзәтте. Боерыкка каршы төшмәсә дә, кысылган иреннәре һәм дуамал хәрәкәтләре Симиниевнең җан тынычлыгы югалуы хакында сөйли иде. Әминев исә аның саен басымны арттырып:

— Сез кесәләрегезне дә капшагыз әле, Юлтай,— дип куйды.— Кайчакта ялгыш та тыгыла ул.

— Юу-у-ук, анысы булмас, хәтерлим ич мин.

Фарукҗан сейфнең астын өскә китерсә дә, кирәкле хатны таба алмады. Хәзер инде шкафын актарырга керешкән Симиниев:

— Артык мәшәкать кенә бу, билләһи, исемдә ич инде минем,— дип үпкәләгән кыяфәт ясады.

Шулвакыт өстәлгә ябылган көрән постауны күтәреп караган Фарукҗан, таң калгандай, сызгырып җибәрде. Анда бернечә бит язулы кәгазь, шул исәптән, Җәркәндкә, Шиһабетдинова Шаһикамалга адресланган конверт та ята иде. Әминев конвертны күреп алып:

— Алай да хәтер сездә, Юлтай! — дип көлемсерәде.— Ә без сейф актарып азапланабыз, кул астында гына булган икән ич хат.

— Гаҗәп, ничек кергәндер ул анда...

Күзенә ут капкан кабинет хуҗасын тынычландырып, Әминев:

— Борчылмагыз, безгә адресы табылуы кыйбат,— диде.— Комиссар гаиләсенә ярдәм итәргә тиеш ич Чека. Әйдәгез, Байкучатов, мәрхүмнең хатынына салырга билгеләнгән әйберләрне бирим сезгә.

## 20

— Сине анда пәрәнҗә бөркәнгән бер хатын-кыз сорый.

Савыт-саба юу белән әвәрә килгән Балҗан башта үзенә эндәшкәнне ишетмәде, аннары һаман яныннан китмәгән шәфкать туташына аптырап күз салды. Тегесе әлеге сүзләрен яңадан кабатларга мәҗбүр булды.

— Минеме?

— Сине инде, сине,— диде ак халатлы кыз елмаеп.— Ишек төбендә көтеп тора.

Ике-өч тапкыр Амантай килеп чакырып чыгаруын исәпләмәгәндә, хәрби госпиталь кухнясында эшләргә тотынган Балҗанга читтән бер кешенең дә әлегә кадәр йомышы төшкәне юк иде. Менә ни өчен аның эче жу итеп, башына кергән беренче уй да ире турында булды. Әллә соң берәр бәлагә тарыганмы, шуңа күрә Иргәшнең апасы эзләп килгәнме икән аны?

Ул кулларын тиз-тиз тастымал белән корытты да кабалана-сөртенә тышка йөгереп чыкты. Әмма аны көтеп торган кеше Балҗанга һич тә таныш түгел иде.

— Сез сорадыгызмы ул мине?

Ят хатын-кыз, чачванын ачып тормастан, болдырга чыгып баскан Балҗанга таба атлады һәм:

— Әйе, мин,— диде.— Менә син нинди сылу икән, балам!

Аяк битенә кадәр җиткән чуар балаклы ыштан һәм озын итәкле күлмәк, аның өстеннән ак халат кигән, җиңнәрен сызганган Балҗан бу минутта үтә дулкынланган кыяфәттә басып тора иде. Җаенке битләре алсуланган, шомырт күзләре очкынланган, берәр хәвефле хәбәрне ишетүгә, чытыр чабарга әзер. Әмма бөтенләй ят кешене күргәч, ул сәерсенеп:

— Сез кем соң? — дип сорады.

— Эшнең җае минем кем булуымда түгел, балам, кеше гозерен тыңлап, хәбәрне сиңа китереп җиткерүемдә.

— Нинди хәбәр соң ул, апа?

— Бик күңеллеләрдән түгел шул әманәтем. Бер аулаграк җир юкмы соң монда, бигрәк ир-ат оясы икән гәспител дигәннәре, энә төртер урын да калмаган.

Балҗан шунда гына ни үзенең болдырдан аяк атламаганлыгын, ни пәрәнҗәле хатынны бина эченә керергә чакырмаганлыгын абайлап алды һәм баскычтан төшә-төшә:

— Әйдәгез бакчага керик алайса, кухняда кысанрак шул безнең,— диде.

Йокы сәгате җиткәнлектән, яралылар бүлмәләренә кереп киткән, куләгәдәге урындыклар һәммәсе дә буш иде. Пәранҗәле хатын шуларның берсенә килеп утырды да Балҗанга карап:

— Шушында кяферләр арасында буталасыңмыни? — дип эндәште.

— Монда мөселманнар да күп. Шәфкать туташлары арасында нугай кызлары байтак.

— Барыбер шәригатькә сыя торган шөгыль түгел инде бу,— диде пәранҗәле хатын.— Ят ирләр тирәсендә чуалу хәрам безгә.

— Мине монда ирем үзе урнаштырды,— диде Балҗан.— Хатын-кыз дип берәү дә җәберләгәне юк әле. Сезнең йомышыгыз ниндирәк соң?

Кунак аны ишетмәгән төсле үзенекен бөгүне белде:

— Шушы ристан хезмәтенә мөкиббән алайса? Кышлакны, анда адәм рисвае булган ата-анаңны да оныттың инде, ә?

— Рисвай? Ни өчен?

— Аны син үзең аңлатырга тиештер инде, балакай. Никахлы ирең: «Кызыгыз өйдән качып китеп, бер ят ир белән хәзер зина кылып йөри, шуңа күрә мәһәремне кире үземә кайтарыгыз», дип ата-анаңны казыйга чакырттыруын беләсеңме? Картларның калымны кире кайтарып бирерлек рәте юк, табыннары болай да такы-токы гына. Шул сәбәпле, анаң түшәккә егылган, атаң көтү көтеп тапкан бөтен малын, аның өстәвенә киләсе еллар өчен хезмәт хакына тиясе сарыкларны да хуҗасыннан ялвара-ялвара алдан алып, кияү ягын бәхилләтергә тырышкан. Хәзер инде энеләрең-сеңелләреңә хәер сорап җан сакларга гына калган анда. Газизләреңне кара кайгыга саласыңны уйладыңмы син, балам? Лачынны чыпчыкка алыштыруыңны төшенәсеңме?

Бу сүзләр Балҗанның җанына бик тиз килеп тиде. Пәранҗәле хатынга ышанмый хәле юк, чөнки ул үзенең яшьлек чәчәген коючының каты күңелле, нәфесле бәндә булуын, кешенең актык әйбередер бу, дип беркайчан да тукталып калмавын җитәрлек сынаган иде. Шундый бәндәне лачынга тиңләү, аның уенча, тәмамысы киртәне җимерү иде. Үзе шапырынса бер хәл, әмма белә ич ул аның түбән җанлылыгын? Бәгыре өзгәләнгән көннәре әле дә исендә. Гыйждуванда чакта булды ул зар елаткан вакыйгалар. Нинди уңай беләндер кунаклар җыйган иде «лачыны». Ярдәмгә чакырылган ашчылар ишегалдында көне буе казан кайнатты — ләгъман, пылау, мәнте кебек тәгамнәр пешерде, тандыр тутырып нан — төче тәбикмәк салды. Балҗан үзе ит, суган турап, камыр басып, табак-савыт һәм җиләк-җимеш юып хәлдән тайганчы бөтерелде, аннары, кайчан таралыр икән инде бу мәҗлес, дип сулу алырлык бер аулак почмак эзли башлады. Күңел ачучылар исә ярты төн узгач кына таралышты. Анда да кунакларның берсе — бәк хәзрәтләре куна калган булып чыкты. «Лачыны» бер кулына шайтан суы тутырылган кувшин, икенчесенә шәм тоттырып, Балҗанны кунак бүлмәсенә урын җәергә дип кертеп җибәрде. Тик анда инде барысы да әзер икәнлеген яшь хатын идәнгә түшәлгән киез-ястыкларга абына язгач кына аңлап алды. Шәмен югары тотып кергәнлектән, мендәргә таянып кырын яткан ир-атны — майлы күзләрен елтыраткан мыеклы кунакны да, үзе шук тавыш белән: «Йөзеңне күрсәтеп, күңелемне алдың, алып күңлемне, утка мине салдың», дип шигырь әйтеп телгә килгәч кенә, абайлады ул. Бу шулкадәр көтелмәгәнчә булды ки, Балҗан кулындагы әйберләрен нишләтергә белми аптырады. Аннары күзләрен шар ачып арты белән чигенә башлады, тик гаҗәп ки, әле генә кергән ишеге шул арада тыштан бикләнгән булып чыкты. Кырын яткан ир-атның аягына торып басуын һәм, «Дәрьяның уртасында сал һәм каек, авылыгызда кыз бармы безгә лаек?» — дип көйли-көйли үзенә таба якынла-

шуып күргәч, капкынга эләккән куян төсле, йөрәге кысылган Балҗан, аягы белән ишекне кыйный башлады, аннары аһ орып, шәмне идәнгә атып бәрде. Бүлмә дөм караңгылыкка чумса да, бәк хәзрәтләре наян җырын туктатмады, култык астыннан түргә шуып үтеп киткән хатынны кулына эләктерергә тырышып. «Авылыгызда кыз булса безгә лаек, кияү булам, каршы ал кочак җәеп!» — дип такмаклый-такмаклый капшанырга кереште. «Ширбәт» чөмереп нәфесе азган, күзе кызган бәкнең гөнаһсыз шаяру белән генә чикләнмәячәген җаны-тәне белән тойган Балҗан, тавышын ишетеп тә һичкем коткарырга ашыкмавына исе китеп, аэәрлекләүдән котылыр өчен, әле сулга, әле уңга ташланды, аннары сулышы буыла башлавын сизеп, кайнар канлы җырчыга җан ачуы белән шайтан суы тутырылган кувшинны тондырды. «А-а-а!» Үкергән калын тавышка шундук ишек ачылды, аннан: «Нимә булды, әкәҗан, нимә булды?» — дип «лачыны» атылып керде. Балҗан исә, ыгы-зыгыдан файдаланып, бүлмәдән йөгереп чыкты да, мал абзарына кереп, күз яшьләренә ирек бирде. Ире аны шушында эзләп тапты һәм: «Син нимә кылдың, тинтәк баш?» — дип нәгъръэ орды. «Ул бәдбәхет миңа кул сузмакчы иде». «Сузса соң? Бәк орынган җирең тәмугта янмас иде». «Ә шәригать? Гөнаһсын мин кая куяр идем?» — диде Балҗан үкси-үкси. «Әгәр бәк мине иртәгә хезмәтемнән куса, нимә кылабыз хәзер? Башың ярылса, бүрек астында кү, нимә була иде сиңа? Бер юньле эшкә ярамаган холкың белән бар, теләгән әтрафыңа олак хәзер, имансыз!»

Балҗан бу бәрелешне гомергә исендә калдырды. Алдан уйлап «урын җәяргә» җибәргән икән ләбаса аны ире! Үзен ялчылар белән бергә кара эштә эшләтүгә, алар белән бергә ашатуга ул әле бик үпкәләми, моны иренең укымышлы һәм бай булуына, зур урында эшләвенә, үзенең исә кияүгә бирнәсез генә китүенә сылтый иде. Ничек кенә каксалар да, ул әлегә кадәр, «Мин барыбер шундый кешенең хатыны ич әле», дип үзен юата иде. Әмма бәк ясаган тамаша аның ире йортындагы чын бәһасен ачыклагач, киявенә карата сакланган хөрмәт хисе үзеннән-үзе юкка чыкты. Киләчәктә суынуы тагын да көчәйде, чөнки ире аны гарьләндереп, рәнҗетеп кенә калмады, җәберләү, кыерсытуларын да арттыра барды. Кайдан килеп лачын булсын ди инде шундый мәкерле мескен җан?

Балҗан уйларыннан аерылып, әңгәмәдәшенә төбәп карый-карый:

— Лачын дигәнегез көчек кенә иде шул,— диде. Бәк табынынннан калган сынык-санкыны көтеп, арт аягына басып ялагайланучы, аның һәр пычрак теләген койрык болгый-болгый үтәргә атылучы әнчек. Ә чыпчык дигәнегез — баш бармактай егет, аны теләсә-нинди капъйотка тиңләү урынсыз.

— Чү, чү, балам, телем ачылды дигәч тә ул кадәр... Алай бик булдыклы егет икән, йөзеңне ачар өчен нигә кышлагыгызга бер кайтып килми соң әле ул? Тиешле мәһәрен чыгарып салса, бәлки атаанаң да суган суы суырудан туктар иде.

— Ә сез, апа, безнекеләр хәлен кайдан ишеттегез?

— Кодаларым аркылы. Исәнлеккә туймаган анаң минә шуларга, баламның кайда икәнлеген белмим, күзләрем йомылганчы күләгәсен күрерменме икән, дип яшь түккән.

— Амантайның хезмәтеннән бушарга мөмкинлеге юк шул әле,— диде Балҗан көрсенеп.

— Һич югы үзең генә булса да хәлләрен белеп килергә иде сиңа картларның. Икегез дә мал табасыз, бераз кучтәнәчегез дә аларга бик ярап куячак. Баланың күңеле сукыр, диюләр рас шул, онытасыз сез аналарыгыз имезгән хәләл сөтне...

— Хатын-кыз башым белән ялгызым ничек юлга чыгыйм мин?

Сүзе үтә башлавына җанланып киткән пәрәнҗәле хатын:

— Балакаем, мин монда телем кычытканга гына килмәдем ич инде, бер изгелегем тисен, дип аяк киендем. Кышлагыгыз ул хәтле җиде җир чите түгел, халык гел йөреп тора. Әле менә үз картым да кызымны алып кодаларга китәргә җыена. Теләсәң, шулардан калма.

— Кайчан юлга чыгалар?

— Иртәгә таң сызылганда. Тик, ниятләсәң, хәзер үк җыенырга кирәк сиңа. Кышлакта торабыз, соңыннан безне эзләп табуың икеле.

Көн инде кичкә авышкан. Балҗанның хәрби госпитальдәге эш вакыты тәмамланып килә иде. Шуңа күрә ул чын-чыннан алмасарлана калды. Хәзер аның аягын тышаулаган бердәнбер нәрсә — Амантайның Каганда булмавы гына иде. Чөнки ул соңгы вакытта туган кышлагы турында үзе дә еш уйлана, иренең Байсын ягына чыгып китәчәге беленгәч, эшкә бөтенләй кулы бармый башлаган иде. Нишләр ул монда бер ялгызы калып? Калканнары — хәрби комиссар да һәлак булгач... Җиде ятларны бер нәни куышына сыйдырган Иргәшнең апасы кем инде аңа? Бәлки ил-көн тынычланганчы, ире гарасаттан исән-имин әйләнеп кайтканчы, ата-анасы янына юл тоту хәерлерәктер? Моны Амантай да хуплар, ләкин ул үз фикерен белдергән чакта соң булыр. Билгеле, кышлакта охшашы күрелмәгән бер вакыйгага әйләнәчәк аның атасы йортына шушылай уралуы, әмма...

Балҗан бер карарга килеп:

— Апа, мин эшемнән рөхсәт сорап чыгыйм әле,— диде.— Сез мине шушында көтеп тора аласызмы?

— Юк, картымны барлый торырмын мин, балам. Бакзалда очрашырбыз, шунда килерсең, без сине үзебез кереп алырбыз. Әмма тизрәк, балам, юл кешесенең юлда булуы хәерле.

— Тик менә иремнең юклыгы гына...

— Әйтеп китсәң, кулы бушагач, үзе үк артыңнан куа кайтыр әле,— дип тынычландырды аны пәрәнҗәле хатын.— Кышлагыгыз бер, юлы таныш.

Балҗан йөгереп диярлек кухняга, аннан госпиталь башлыгына кереп китте. Үзбәкчә ярыйсы сукалаган Мартьянов аның каударланып аңлатуларын тыңлап-тыңлап торды да:

— Ашыкмагыз әле, сеңелем,— диде.— Хәл-әхвәлегезне сөйләп, күз-колак булуымны үтенеп урнаштырдылар монда сезне. Кинәт пәйда булган ят хатынны үзем дә күрим әле мин, әйдәгез карап керик әле бергәләп.

Әмма алар вокзал тирәсендә күпме генә әйләнсәләр дә, әлеге пәрәнҗәле хатынны очратмадылар. Амантай кайтканчы сабыр итәргә киңәш биреп, Мартьянов шуннан соң кире госпиталенә кереп китте, Балҗан исә, түшәккә яткан бичара анасын уйлап, юл уңаендагы кибеткә кагылды да әзрәк чәй-шикәр һәм күлмәклек бер арзанлы тукыма сатып алды. Иртәме-соңмы, тиздән барыбер кышлакка сәфәр чыгарга туры киләсенә ул инде хәзер бер дә шикләнми иде. Шуңа күрә өенә кайткач та юлга җыенуын дәвам итте. Аннары хуҗаларын кисәтте дә тагын вокзал тирәсен күздән кичерергә юнәлде. Бу юлы ул әлеге хатынның нәкъ өстенә килеп чыкты.

— Балам, кайда югалдың болай, сине көтеп соңга калдык лабаса инде,— диде ул.— Әңгер төшә башлавын күрмисеңмени?

— Сез әле башта Бохарада туктала торгансыздыр ич?

— Менәтерә, анда ниебез калган? Кала эченә бөтенләй кереп тә тормабыз әле. Картым дөяләрен сугарып, әллә кайчан җыенып бетте ләбаса.

Моннан соң инде Балҗан бүтән икеләнеп тормады, тиз генә күчтәнәчләре белән юл ризыгы төйнәлгән бөктәрен кайтып алды да вокзалдан ерак түгел бер чәйханә янында әлеге юлаучыларга килеп

кушылды. Озынча йөзле, кара сакаллы, кашлары чыршы ботакларын хәтерләткән абзый кеше, алар өркәчләр арасына урнашып бетүгә, үзе дөяләрнең алдагысына менеп атланды һәм, офыкка шәфәкъ кызыллыгы җәелгәндә, кечкенә кәрван Каганнан чыгып китте.

Алар бу төнне шушы кәрванчының өендә уздырырга тиешләр иде. Ләкин юлаучылар ул кышлакка исән-имин барып җитә алмадылар, караңгылык тәмам куера башлаганда гына әллә кайдан берничә җайдак килеп чыкты һәм, кәрванчылар ни дә булса уйлап өлгергәнче, Балҗанны әсир иттеләр — аяк-кулларын, күзләрен бәйләп, атка атландырдылар да «ә» дигәнче нәмәгълүм тарафка чаптырып китеп тә бардылар.



## 21

«Полковник Штеннелгә.

Хөрмәтле сэр, күрсәтмәләрегез буенча, Бохара әхвәлләрен ачыклауны һәм кайбер ашыгыч чаралар күрүне дәвам итәм.

Яңа хакимият ярлы диһканнарны, эшчеләрне оештыра, урта катлауларны үз ягына аударырга тырыша. Бу җәһәттән Фәйзулла Хуҗаев иярченнәре аеруча тынгысыз.

Хуҗаев яклыларга Үзәк Русиядән җибәрелгән фанатик мөселман большевиклары гадәттән тыш зур ярдәм күрсәтә. Алар арасында җирле халыклар гореф-гадәтен, телен яхшы белүче Аксолтанов, Хәкимев, Шиһабетдинов кебек үтә көчле оештыручылар байтак. Аталганнарның соңгысы, мәсәлән, әмир чирүенә һәм тышкы дошманнарына каршы көрәшер өчен, хәзер Бохара Кызыл гаскәрен җыя башлады, бу эштә аңа якташлары һәм Төркестан коммунистлары ярдәмгә килде.

РСФСР вәкилләре булышуына таянган Хуҗаев өерен зәгыйфьләндерер өчен суллар белән уңнарның һәр икесеннән файдалану, алар ярдәмендә Ревком һәм хөкүмәт аппаратына үз тарафдарларыбызны урнаштыру мәгълүм нәтиҗәләр бирә башлады.

Тиздән Бохарада политик хәлне тотрыксызландыра торган вакыйгалар башланачагына ышанам. Киләсе почта белән ун маузер һәм патроннар җибәрүегезне үтенәм.

Капитан Блеккер. Бохара, унынчы октябрь.»

«Бохара Халык Совет Республикасы Тышкы Эшләр назыйры Фәйзулла Хуҗаевка.

...Бөек Әфганстан Дәүләте күршелек мөнәсәбәтләренең иң беренче дәвереннән хәзерге көнгә чаклы, Бохараның эчке һәм тышкы мөстәкыйльлеге эшкә ашуы намена, теләсә нинди ярдәм күрсәтүдән һәм таяныч булудан һич тә баш тартмады, анда ислам канат җәйсен өчен биниһая хезмәт куйды...

Сезнең тарафтан илчеләр алмашу һәм ике дәүләт арасында дуслыкны арттыру теләге белдерелгәнлектән, хөкүмәтебез Мөкатдәс Бохарага якын көннәрдә килеп җитәчәк Габделһадихан җитәкчелегендә Гадәттән тыш Илчелеген җибәрүен белдерәбез. Илчелек килеп җиткәнче, Хөкүмәтегез каршында Әфганстан ватандашлары эшен яклауны шәхсән Габделшөкерханга йөклибез, соңра барлык гомуми мәсьәләләрнең хөрмәтле дустыбыз Габделһадихан һәм Дәүләтебезнең Гадәттән тыш Илчелеге әгъзалары ризалыгы белән хәл кылынуын тәкъдим итәбез.

Бөек Әфганстан Дәүләте әмире Амануллахан.
Кабул шәһәре, 1920 елның октябре».

«Капитан Блеккерга.

Агентура мәгълүматларына караганда, Әфганстан хөкүмәте Бохараның яңа хакимнәрен танырга һәм, күчермәсе кулыгызга керәчәк махсус хат белән илчелек җибәреп, дипломатик мөнәсәбәтләрен яңартырга җыена.

БХСР юлбашчыларының политик хыялларын уяту, нәфесләрен кыздыру, РСФСРга басым ясау ягыннан акылга ярашлы булса да, тулаем алганда, бу адым безнең мәнфәгатьләребезгә туры килеп бетми.

Шуңа күрә, муафыйк эшлекләләр аркылы РСФСР вәкилләренә Әфганстанның хәзерге хөкүмәте панисламизм байрагын күтәрүен, бу адымның Бохара мөстәкыйльлегенә генә түгел, бөтен Туран, Идел-Урал, Кавказ, Кырым мөселманнарының Русиядән аерылып чыгу хәрәкәте көчәюенә хезмәт итәчәген искәртегез. БХСР җитәкчеләренә исә Әфганстанның басмачыларга булышуын хәтерләтү кирәк. Шул ук вакытта Бохарадагы

Әфган сәүдәгәрләрен, бигрәк тә телгә алынган Габделшөкерханны ике мәмләкәт арасын бозарлык берәр күңелсез маҗарага тартып кертү акланачак.

Бохарадан җибәргән ике хәбәрегезне алдык, эшне уңышлы башлап җибәрүегез әйбәт фал. Фикерләрегез дөрес, ниятләрегез өметле, БХСР җитәкчелеге арасына чөй кагуны дәвам итегез.

Коралларның өстәмә партиясе әзерләнә, бу әмер белән бергә, яңа чыгымнарыгызны каплар өчен, утыз мең Бохара таңкасе җибәрелә.

Полковник Штеннел. Мәшһәд, уналтынчы октябрь».

## 22

Шиһабетдиновның сөйгән кызына язган хатында да йомгак очын сүтәрлек исемнәр аталмаган. Байкучатов фикеренчә, нәкъ менә шуңа күрә генә Симиниев тарафыннан юк ителмәгәндер. Шулай да ул хатны тагын бер кат җентекләп укып чыкты.

«Сандугачым Шаһикамал!»

Сагындырган хәбәрләрең инде күптән килмәсә дә, мин менә тагын сиңа хат язарга утырдым. Революция давылы җаныеңны уттан алып суга, судан алып утка салды — Баһаветдинның бүген сайрар кошлар оя типкән яшел тугайлы Җидесудан бик еракта — сары барханнары арасында чаяннар белән ташбакалар гына шуышкан Караком сахраларында йөри. Игенче белән бакчачыларның, көтүче белән һөнәрчеләрнең сыртын каезлап, аларның җелеген суырып рәхәт чигүчеләр Җидесуда гына түгел, монда да бик ишле икән. Бохара хезмәт ияләре безне менә шуларга каршы иңгә-иң торып көрәшер өчен ярдәмгә чакырды. Ул көрәшнең ничек баруына тукталып тормыйм, Җәркәнттәге канлы бәрелешләр буенча син аны үзең дә яхшы чамалый аласың.

Җәркәнт дигәннән, Бохара каласы аңардан күпкә зуррак, күпкә матуррак икән. Мондагы әмир сарайлары, мәчет-мәдрәсәләр теләсә кемне таң калдырырлык. Арада бик борынгылары, сәяхәтчеләр махсус килеп карый торганнары да байтак. Исмәгыйль Саманый төрбәсен мин дә бик яратып тамаша кылдым. Мең ел элек салынган булса да, аның әлегә чаклы бер генә кирпече дә кителмәгән. Челтәрләнгән ишек уемнары, ул уемнарның гөмбәз сыман башлары, корылманың сырланган кәрнизләре һәм дүрт почмагындагы дүрт баганасы шулкадәр нәфис, аларның үлчәмнәре шулкадәр килешле, мин ирексездән, Бохара төзүчеләренең ата-бабадан ук үтә зәвыклы һәм оста куллы булуларына иман китердем...

Шаһикамал җаныем, мин соңгы вакытта үзбәк дусларымның җырларына колак салырга һәвәсләндем бит әле. Алар, Җәркәнттәге уйгырлар шикелле, сузып-сузып көйли башласа, мин әүвәл ятсына, сүзләрен дә төшенеп бетми, моңнарын да сәеррәк күрә идем. Хәзер инде әллә күнегә төштем, әллә көне-төне араларында кайнагач, тормышлары да, уй-хисләре дә аңлашыларак барамы, берәрсенең җыру әйтүен тансыклап көтеп кенә торам. Җәркәнттә уздырган бәхетле минутларны сагынып моңлануданмы икән әллә бу? Кайчак мин үзем дә сине күз алдыма китерә-китерә, шуларга кушылып китәм:

Өрек-өрек күзеңнән, өрек-өрек,
Янамын да көямен, төштә күреп.
Яндырганчы син болай төшкә кереп,
Утырсайдең янымда чәчең үреп!

Бик сагындым шул үзеңне, сандугачкаем! Тик әлегә мин сине монда чакырып китерергә кыенсынам. Бохара республикасында, кая карама, тышкы һәм эчке дошманнар мыжгып тора. Шуларның сыртын сындырырга тырышып, мин тәүлегенә унсигезәр сәгать аяк өстендә бөтереләм. Килсәң дә, мөгаен, туйганчы иркәләнеп, сайрашып утырырлык вакыт тиз генә табылмас иде.

Бу арада күп йөгереп бераз суырылдым, ахры, әмма кәефем әйбәт — сугышчан! Барлык туганнарга чуктыйн-чук сәламнәремне тапшыр, үз хәлләрегезне белдереп, җавап яз, яме, Шаһикамалым? Суга төшкәндә дә, утка кергәндә дә сине онытмаучы Баһавың.

Бохара, унсигезенче октябрь».

Әйе, хатта хәрби комиссарның теге дөньяга китәргә һич тә ашыкмавы, киресенчә, «кәефем әйбәт, сугышчан», дип дошманнарына үзе һөҗүмгә күчәргә җыенуы бик ачык белдерелгән иде. Аның «намуслы егетләребезгә яла ягып, үрмәкүч тозагы корып» маташучыларның эзенә төшүе дә хәбәр ителгән Фарукҗанны да нәкъ менә шул соңгы мәсьәлә буенча чакырган булгандыр ул. Әмма «болганчык суда балык тотучылар» үзләренә янаган хәвефне шулай ук сизгән, күрәсең, бөркет-

не тозакка төшерүне ашыктырулары күз алдында. Монда инде хәрби комиссар әле танып бетермәгән, шуңа күрә ышанып караган берәр сатлык җан астыртын тырышкандыр. Шиһабетдинов эч серләрен йомышчысы белән уртаклаштымы икән? Юк. Фарукҗан йөкне ялгыз кешегә генә аудара алмый әле хәзергә. Намуслы егетләргә тозак коручы ике-йөзле бәндәләрне киңрәк даирәдән эзләү хәерле. Халык кайнаган җирләргә күз салырга кирәк, әлбәттә.

Байкучатов сөйләшенгән чәйханәгә менә шундый уйлар эчендә юлга чыкты. Күгәрчен көтүендәге карга шикелле чекрәеп тормас һәм чалбар каешына кыстырып куйган унатарын белгертмәс өчен, ул үзе дә өстенә үзбәк чапаны, башына чиккән түбәтәй киярг онытмады. Шундый ук киемле Амантай аны ишек төбендә байтактан көтеп тора иде инде.

Алар чәйханәгә караңгы коридор аша килеп керделәр. Бүлмә уртасындагы биек түшәмгә эленгән бер генә лампа янганлыктан, күз иярләшүен көтеп, Фарукҗан башта ишек төбендә тукталып калды. Каралып, ысланып беткән чәйханә шактый иркен эчке әйваннан гыйбарәт булып, аның түре тоташ стена белән буйга бүленгән иде. Уң ягындагысының ике сөям чамасы калкыбрак торган җир идәненә палас түшәлеп, уртасына бер генә озын җәймә җәелгән, аның тирәсенә әлегә дүрт-биш кенә кеше урнашкан, табын әлегә түгәрәкләнеп бетмәгәнгә охшый иде. Сул якта исә сәкеләр куелган, аларның ишек катындагылары бөтенләй буш, түрдәгеләрендә, кәвешләрен идәндә салып калдырып, аякларын бөкләп утырган ирләр күренә. Теләгәндә алар арасына да сыеп була иде.

Чәйханәнең Фарукҗаннар кергәненнән тыш, тагын ике ишеге бар иде. Ризык исләре бөркелүгә караганда, аларның сул ягындагысы кухняга чыгарга тиеш иде. Ә түр сәкеләр арасындагысы...

Фарукҗан, менә шуны ачыкларга теләп, кыю гына алга таба атлады һәм әлеге ишекне ачып, тышка килеп чыкты.

— Ишегалды, ахры, бу,— диде аңа ияргән Амантай.

Байкучатов җавап бирергә өлгергәнче, каршысында кулына чәйнекләр тоткан бер егет пәйда булды. Ул дәшми-тынмый яннарыннан узып, чәйханәгә кереп киткәч, Фарукҗан алга таба атлавын тагын дәвам итте һәм ишегалдының арткы дувалындагы капканы ачып, ниндидер буш җиргә килеп чыкты. Моннан шактый ук тирән чокыр башланып китә, аның ярында чәй эчеп утыручы ир-ат төркемнәре шәйләнә иде. Үзләренә ачык һавада уңайлы аулак урын эзләүчеләр алардан башка да җитәрлек булганлыктан, Фарукҗаннарга берәү дә әһәмият бирмәде. Шуңа күрә Байкучатов ялкау адымнар белән түбәсе ябулы бер тар тыкрыкка килеп җиткәнче, аннары шуның буйлап күрше мәхәлләгә аяк басканчы, тирә-якны җентекләп тикшереп чыкты. Бары шуннан соң гына үзеннән бер адым да калмаган иптәшен:

— Амантай, әгәр андый-мондый хәвефле хәл була калса, бу юлны исеңдә калдыр,— дип кисәтте.

Чәйханәнең бердәнбер кечкенә тәрәзәсе түрнең сәкесез ягтысыннан шулай ук чокырлы ялан белән чиктәш ишегалдына карап тора, ул шар ачык һәм аннан, морҗадан чыккан шикелле, тәмәке төтене саркыла иде.

Хәзер инде өченче ишекне ачып, аннан әләгергә мөмкин җирләрне карап чыгасы калды, ләкин бусагада ике кулына икешәр чәйнек тоткан кырык-кырык биш яшьләрдәге хуҗа белән йөзгә-йөз очрашкач һәм аның:

— Мәрхәбә, миһманнар, хуш киләсез, кунаклар! Тыныч кына утыра бирегез, хәзер сезгә дә чәйне үзем алып киләмен,— дип эндәшүен ишеткәч, ирексездән чигенергә туры килде.

Фарукҗан залның һәр тарафын да яхшы күзәтә, төрле төркемнәрдә кузгалган гәпне ачык ишетә алырлык җиргә утырырга теләде. Шун-

лыктан, алача күлмәк өстеннән шундый ук буй-буй сырган чапан кигән, түбәтәй кырыена аксыл чалма ураган ике егеттән итагатьле генә рөхсәт сорап, уртадагы сәкегә — алар табынына килеп утырды. Чәйханәдә халык торган саен арта, әңгәмә авазлары да көчәя бара иде. Яңа килүчеләрнең кайберсе чәйнек белән касәләрне кулына төшерүгә, ачык һавага — яланга чыгып китә, кайсылары түр идәндәге олы табынга кушыла иде. Бер-берсе белән җанлы исәнләшүләренә караганда, монда даими йөрүче кунаклар да шактый иде, күрәсең. Фарукҗан бу якларда пәтер дип аталган кондәлек ризыкны — көлчәләрне сындыргалап Амантай белән икесе арасына җәймәгә таратып салды да касәләргә чәй койды һәм күршеләренә бөтенләй игътибар итмәгән төстә, сусын кандырырга керешә. Туган якларында бер чынаяк белән чикләнүче егетебез Бохарада чәйнең тәмен белә торган кешегә әйләнеп килә иде. Үзе белән генә мавыккан булып кыланса да, ул сәкедәгеләргә дә, иркен олы табынга утырган кунакларга да, алар арасына борын тыккан Иргәшкә дә күз йөгертергә, бигрәк тә колак салырга онытмый иде.

— Юк, юк, тәкъсыйр, аслан килешә алмыйм. Мөхәммәт пәйгамбәр балачагында үзе дә сарыклар, кәҗәләр көтә, үсә төшкәч кәрван йөртүче байларга яллана, шуңа күрә ул фәкыйрьләргә һәрвакыт теләктәш була.

— Аның аксөякләр нәселеннән икәнлеге «Сирәт рәсүлаллаһ» хәдисләрендә ап-ачык әйтелгән. Аннары үзегез уйлап карагыз әле: пәйгамбәребез нигә Мәккәнең атаклы байбикәсе Хәдичәгә өйләнә соң? Калган хатыннары да — сәүдәгәр кызлары. Минемчә, аның малга кызыгуы, байгуралар белән генә әҗе-гөҗе килүе, шуларны гына кайгыртуы бәхәссез.

— Көфер сүз ычкындырудан сакланыгыз, тәкъсыйр! Эшләре уңышлы барганда сәүдәгәрлеген кем ташлый? Мөхәммәт пәйгамбәр! Әгәр Мәккәдән аны сәүдәгәрләр куып җибәрүен дә искә алсак? «Әлҗәмыйг әс-сәхих»не укысагыз...

— Җыйган хәдисләренең күпчелегенә әл-Бохари үзе дә ышанмаган, әфәндем. Бинаән галәйһи, ягъни, шуңа нигезләп, сукырларча бәхәс кылуыгыз гаҗәп. Болай булса, озакламый Хуҗаев белән Мөхетдиневләрне дә ярлы дип танытуыгыз ихтимал.

— Ярлымы, баймы,— әмир золымын юкка чыгару хәрәкәтенә нәкъ менә шулар җитәкчелек итте ич инде, тәкъсыйр.

— Ышану кыенрак шул моңа, әфәндем. Шундый кан дошманы икән, әмир галиҗәнапләре Фәйзулла Хуҗаевка ник җил-яңгыр тидермәде соң?

— Кайчан?

— Әйтик, унсигезенче елның мартында. Нәмаешка чыккан Мирбаба белән Гайниләрне җитмеш бишәр таяк белән сыйлады, ә Фәйзулла әкәгезне затлы фаэтонга утыртып, Каганга озатты. Карга күзен карга чукымый, дигәндәй, әллә сәүдәгәр Хуҗаевны кәсептәше Мөхәммәт пәйгамбәр саклаганмы икән?

Фарукҗан табындашларының дини бәхәсе үтә дә дөньяви төс алуына гаҗәпләнеп, колакларын торгызды, әмма чыраендагы битарафлыкны тамчы да үзгәртмәстән, чәй эчүен дәвам итте. Әле яңа гына Мөхәммәт пәйгамбәрне ярлылар тарафдары итеп күрсәтергә тырышкан шәкерт исә кызып-кызып Хуҗаевны якларга тотынды.

— Хакыйкатьне аслан белмибез икән, тәкъсыйр,— диде ул кайнарланып.— Яшь бохаралылар оештырган нәмаешка каршы кадимчеләр, әмир яклы бәдбәхетләр күтәрелде ләбаса ул чакта. Фәйзулла әкәне әмир түгел, без үзебез коткарып калдык.

— Каһарманлыгыгызны да сурәтләп бирерсез бәлки?

— Көлмәгез, тәкъсыйр, чыннан да бик хәтәр минутлар кичердек без ул чакта. Яшьләр нәмаешын әмир канга батырырга җыенуын

бер карт килеп әйтте. Тик ул арада карагруһлар төркеме Фәйзулла әкәләр өен чолгап алырга өлгергән иде инде. Ярый әле алардан яһүд мәхәлләсенә яшерен җир асты юлы казылып куелган иде. Фәйзулла әкәнең менә шул юлдан качып кына котыла алуын мин үз күзләрем белән күреп тордым. Яһүд мәхәлләсендә аны без — өч кораллы егет каршы алдык, аннары биржа ямчысы арбасына яшереп утырттык та Намазгаһ капкасы аша көч-хәл шәһәрдән чыгып качтык.

— Бохара — куәти ислами дине хәят,— дип елмайды шәкертләрнең икенчесе.— Шәһәребез ислам диненең тераге икән, хак юлда йөрүчеләрне дә ходай үзе саклагандыр, күкрәк кагарга ашыкмагыз.

Шулвакыт тыштан шау-шу, тамбур чирткән тавышлар ишетелә башлады. Һәм күп тә көттерми, каерып ачылган ишектән шат күңелле егетләр төркеме ишелеп керде. Чапан чабуларын билбавына кыстырган, чалмасын кыңгыр чалган җыйнак гәүдәле тамбурчы, тавышын юри нечкәртеп:

> Аяжан, ая
> Башгинам агрийди-я,—

дип сузуын дәвам итте.

Аңа каршы иптәшләренең берсе шундый ук шаян рухта, иңнәрен-кулларын уйната-уйната хатын-кызлар шикелле бии-бии:

> Башгинандан аяң айлансин,
> Нимәләргә агрийди-я? —

дип сорау бирде.

Фарукҗан бер дә көтмәгәндә, бу тамашага кухня ягыннан кувшин, касәләр тотып чыккан хуҗа да кушылды. Калын, әмма ягымлы тавыш белән ул:

> Чәйханәдә булар икән,
> Кувшиннарда торар икән,
> Ана шуни аты ширин ширбәт,—
> Ушаңа агрийди-я,—

дип җавап бирде һәм касәләрен берәм-берәм кунакларына сузып, эчемлек сала башлады.

Моңа барысы да җанланып:

— Бәрәкалла!

— Гомерегез ашулә-җыр белән узсын, әкә, чәйханәгезгә бәрәкәт иңсен! — дип шат авазлар яңгыратты.

— Амин, миһманнар, түргә узыгыз, дәстәрханга рәхим итегез, кунаклар!

Күңелле төркем залның палас җәелгән җир идәненә, зур табын тирәсенә утырышты. Хуҗа аларга чәй тулы чәйнекләр өләшеп чыкты. Егетләр касәләренә авыз тидереп алгач, чиртүен туктаткан тамбурчыга:

— Уйный бир, дускай, хөррият заманасында рәхәт чигик әле,— дип үтенделәр.

— Чүлдә каңгырып йөргән әмирнең йөрәге янсын!

— Галиҗәнап хәзрәтләрен дә кызганырга кирәк,— диде аларга Фарукҗанның күршесе.— Безне кяферләр һөҗүменнән саклап килүче изге каһарман шул түгел идемени?

Шәкерткә олы табыннан да кушылучы табылды.

— Дөрес, кардәшкәем, әмир хәзрәтләре ил-көнне кайгыртучы иде. Гүзәл Ситтәрәи Маһи-һуса сараен салдыру дисезме, кая барса да, без укымышлыларга хөрмәт күрсәтү дисезме, фәкыйрьләргә миһербанлы булу дисезме...

— Миһербанлы?

Ачык коңгырт төстәге чикмән кигән, шактый ук купшы чалма чал-

ган очлы иякле, озынча йөзле. маңгаеның уң ягында яра эзе беленеп торган картның бу чәнечкеле сорауга исе китмәде.

— Әйе, миһербанлы иде әмир хәзрәтләре.— дип кабатлады ул.— Бервакыт галиҗәнап базардан узып бара икән. Күрә, яңа өлгергән кавын саталар бер чатта, ә шуның янында гына хуш исле җимешкә кызыккан, әмма сатып алырга акчалары булмаган дәрвишләр басып тора икән. Кесәләрен капшап караса, әмир хәзрәтләре акча тыгып чыкмаган, пулы бөтенләй юк имеш. Шуннан соң ул дәрвишләргә чапанын салып тоттырган да: «Сәүдәгәрдән менә шушының бәрабәренә тигән кадәр кавын алыгыз!» — дигән. Сәүдәгәр бер генә кавын биргән. Әмир хәзрәтләре аны үз кулы белән телемләп дәрвишләргә өләшкән, үзенә хәтта авыз итәргә дә калдырмаган.

— Һа,— дип кашын җыерды егетләрнең берсе,— алырсыз эт авызыннан сөякне! Әйтерсең лә, әмирнең беренче комсыз әрвах, азгын хайван, канәчкеч әшәке җан икәнен белмибез.

— Әмир хәзрәтләре үзе гадел, үзе намуслы иде,— дип дәвам итте озынча йөзле карт.— Бәкләре, казыйлары гына аның әмереннән чыгып...

— Агачына күрә алмасы дигәндәй, әмирнең якыннары да нәкъ үзенә охшаган иде,— дип бүлделәр аны.— казыйлары — ачкүз вә ришвәтче, рәисләре — сатлык уйнашчы, мирбашлары — эчкече вә беренче карак иде!

Бәхәс кыза башлагач, тамбурчы уен коралын кулына алып, аның кылларын чиртә-чиртә, тавышлар тына төшүен көтте һәм берәүгә дә атап эндәшмәстән, яхшы ук кинаяле рәвештә Гомәр Хәйям робагыен көйли башлады:

Дөньяда акыл-уйга мәнсез бул син,
Сөйләнсә җиһан җае, өнсез бул син.
Колагың, күзең, телең сау чакта да
Сукыр бул, саңгырау бул, телсез бул син!..

Ләкин, революция күпләргә тел ачкычы биргәнгәме, бу искәртүгә берәү дә җитди колак салмады, тамбурчы киңәшен чичәнлек үрнәге сыман гына кабул иттеләр, башланган гәпләр бер минутка да өзелмәде. Зур табындагы сүзгә кушылучылар арасында Иргәш тә бар иде.

— Әгәр сугару хакында үтенеч бирсәң, әмир хозурыннан җавап елгада су бетеп, арык төпләре кибеп яргалангач кына килә иде,— диде ул ачу белән.— Бичара диһкан кыйбатка төшкән ул мәгънәсез кәгазь кисәген ертып атырга гына мәҗбүр була иде.

— Безне талап җилкә симертүче әнә шундый әрәмтамакларны тукмар өчен Кызыл Гаскәр барлыкка китерелә дә инде.

— Хәрбия назыйрының үзен тәгәрәткәннәр ич әле әнә,— диде әмирне яклаучы карт.

— Нәрсә ул хәрби комиссар? — диде тамбурчы уенын-чынын бергә кушып.— Шул төнне һөнәрче Хушмәмәтнең өч чүлмәген ватканнар, менә анысы ичмасам вакыйга!

— Ха-ха-ха! — дип шаркылдады шәкертләрнең берсе.— Хушмәмәт әкә казасын сөйләп, бөтен базарны сасытты инде. Син аңа хәрби назыйр харап булган дисең, ә ул һаман үзенең чүлмәкләрен колагыңа тукый.

— Ни хәл итәсең,— диде аңа каршы иптәше,— адәм баласыннан аңа ходай бирмәгән гакылны өмет итеп булмый.

— Кичерәсез,— дип эндәште Фарукҗан күршеләренә,— сүз Яңа Базар мәхәлләсендәге Хушмәмәт турында барамы?

— Юк-юк, бу байгыш Чархараста яши.

Байкучатов чүлмәкчене генә түгел, хәтта әлеге мәхәлләләрне дә юньләп белми. Яңа Базарны күршеләренә бары иплерәк мөрәҗәгать итәр өчен генә атаган иде. Кирәк җавапны ишеткәннән соң, бераз күз буяу ниятеннән, шул ук вакытта үзенең дә бик үк төшеп калган бәндә

түгеллеген сиздерер өчен, сүзен шәкертләрчә хикмәтле очларга тырышты.

— Килешсез бию, моңсыз җыр, мәгънәсез гәп,— бу дөньяда әнә шундый өч күңелсез нәрсә бар инде.

— Тугры. Хушмәмәт әкәнең чүлмәк кыйссалары да шуңа иң кәттә мисал, әлбәттә.

Аннары Фарукҗан игътибарын янә дә зур табынга юнәлтте. Мәҗлеснең каефле баруына, уен-көлке, сүз көрәштерүләрнең бер дә басылып тормавына караганда, анда яхшы ук шомарган чичәннәр, хәйран гына укымышлы һәм хәбәрдар кешеләр җыйналган иде. Башына өлгергән кәбестә сыман ак чалма өеп куйган, өстенә бикасәб (ефәк) чапан кигән шома йөзле, үткен карашлы егет бигрәк тә дикъкатьне тарта иде.

— Борадәрләр, яңа себерке чамадан тыш каты себерә ич әле,— дип дәвам итте ул.— эшләр киләчәктә дә болай барса, байтак асыл егетләребезнең партиядән сөрелүе ихтимал. Бохара өяз-кала комитетында яңа хуҗа һәр унның җидесен чыгаруны таләп иткән.

— Бигрәк әйбәт, андый дәһриләр партиясе кирәкми дә безгә! Фәйзулла коткысына бирелеп кенә кушылдык без коммунистларга, хәзер менә шул хатаны төзәтү хәерле.

— Фәйзулла әкә шикелле зирәк сәясәтчене хөкем итмик,— диде кәбестә чалма,— ул кайсы юлдан барырга кирәклекне күпләрдән алда чамалаган.

— Ә Госманхуҗа әкәнең борыны ис тоймыймыни? — дип кабынып китте атлас чапан кигән кабартма яңаклы ир-ат.— Аның башы эшләмимени? Минемчә, Хуҗаевлар нәселенең җыенысын бергә укмаштырсагыз да, бер Госманхуҗа Булатхуҗаев әфәнде килеп чыкмаячак.

— Эш анда түгел, туган,— диде кәбестә чалма,— юкка тартышмыйк, ике күгәрчен сугышса, карчыга бәйрәм итә. Хәзер партиядән чыгу җитәкчелектән читләшү дигән сүз ул. Әмир золымын биш бөртек бәлшәвик имәс, нәкъ менә без — Яшь бохаралылар фиркасе юк итте. Шушы көрәш юлында йөзләгән-меңләгән юлдашларыбыз хәләл малын гына имәс, газиз башын да корбан кылды. Тәнебез зинданнарда кандалаларга азык булды, каныбыз Регистан мәйданын комач төсенә кертеп елга шикелле акты. Ә хәзер без революционерлар түгел, имеш.

— Хуҗаев, Мөхетдиневләр нәрсә карый соң?

— Менә шушы чәйханәдәгеләр шикелле, алар да үзара тарткалаша — итәк кисеп җиң ялгыйлар. Ә Хәкимевкә шул гына кирәк, бәрәм-бәрәм һаман үз планнарын алга сөрә. Каты куллы.

— Бәлки ул да хәрби комиссар артыннан олагыр? — диде кабартма яңак.

— Чыкмаган кояшта кызынмыйк,— диде кәбестә чалма,— моныcын юлдан яздыру өметсез. Үткен, хәйләкәр, мәдрәсәдән соң әллә ниткән гимназияләр тәмамлаган, сөйләшә башласа, теленә хөҗе төкергән. Таштимер Тураевлар гына имәс, бүтән кәттә егетләребез дә шул иблиснең авызына гына карап тора. Менә шуннан файдаланып суячак та инде ул безнең кайбер оешмаган җаннарыбызны. Хәтәр бу, эшләребез таманысы хөрти.

— Куегызчы, безнең Госманхуҗа әкәләр шуңа бирешер дисезме? Партиядән берне куса, аның урынына ун яңаны алырга кирәк, шуның белән уңмаганның бөтен тырышлыгы сүтеләчәк.

— Ә бәлки партиядән залимнәргә койрык болгаучыларны гына сөрмәкчеләрдер? — дип тавыш бирде Иргәш.— Хәзер сүздә халык өчен җан атучылар күбәйде, гомер буе җелегебезне суырып яшәгән соры кортлар да революционерга әйләнде!

Фарукҗан, монда байбәтчәләр, төшемле урын сагалап еллар буе мәдрәсә хөҗрәсендә аунап яткан пишкадәмнәр ишле икәнлеген чама-

лап, иптәшенең сүзгә катнашуына пошынмый булдыра алмады. Иргәш ялгыз калмады, аңа да кемдер куәт өстәде. Искереп беткән сыргган кара чапанын биленнән яулык белән буган, яланаягына чи тиредән тегелгән башмак элэктергән ир беренчеләрдән телгә килде.

— Дөрес, үкәм-энекәшем,— диде ул.— партия дигәннәренә хәзер лаегы да, түгеле дә кереп тулды. Арада түрә булуны гына кайгыртучылары да шактый. Андыйлар әмир яклыларны фаш итәргә уйлап та карамый. Мәркәз идарәсе карарларын да санга сукмый, тәртип дигәнне инде бигрәк тә танымыйлар...

— Тәртип? — дип чәчрәп чыкты кабартма яңак.— Хәрби назыйр Шиһабетдинов әнә тәртип дип йөреп, үзе дә Ревкомга буйсынмый башлаган иде. Сәүдәгәрләрнең кәсеп итеп тапкан хәләл малын ярлыларга бүлеп бирергә, шәригатьне бетерергә, хөкүмәткә фәкыйрьләрне генә менгереп утыртырга теләгән иде — барып чыкмады. Әлифне таяк дип белмәгән диһкан ничек мәмләкәтне идарә кылсын инде? Дөнья шулай бара алса, мәктәп-мәдрәсәләр дә кирәкмәс. Коръән шәрифне уку да артык булыр иде!..

Әңгәмә-бәхәсләр әнә шулай кызганнан-кыза барды, хәзер инде бөтен чәйханә тоташ табынга — уртак мәҗлескә әйләнгән, монда һәркем үз сүзен кыстырырга тырыша иде.

— Һа! — дип нәфрәтләнде купшы чалма ураган бер карт аеруча кайнарланып.— Болай булса, мөселманлыкның тамырын корытырга да мордар булып җәһәннәмгә олагырга гына кала инде безгә!

— Ашыкмагыз, әкә,— диде аңа яшьрәк бер егет.— мөселманнар бу дөньяда бер без генә түгел. Әле менә хәрби комиссар үлеменә дә...

Егет соңгы сүзләрен пышылдап кына әйткәнлектән, Фарукҗан аны ишетеп җиткермәде. Олы табындагылар исә җанланып:

— Йомышчысы Рахманколмы? Шуны Габделшөкерхан янында күргәннәрме?

— Габделшөкерхан? Әфган сәүдәгәрен әйтәсезме?

— Сәүдәгәр генә түгел, әмир куылганчы күрше мәмләкәтнең рәсми вәкиле дә иде кү,— дип шаулаштылар.

Тик әлеге егет баягы сүзләрен тагы да ачыклап тормады шикелле, бары тик:

— Дөньяда хак мөселманнар да күп кү, бохаралылар базмаса, алар кыюрак кү,— дию белән чикләнде.

Әмма Байкучатов моны инде мыегына урамый калмады. Димәк, әмир заманында ук Әфганстан вәкиле булып килгән Габделшөкерхан — басмачылар таяныч таба торган шикле кешесе белән Шиһабетдиновның йомышчысы таныш булганнар, дип уйлады Фарукҗан. Кызык! Чит ил карчыгасына гына мохтаҗ иде ул бу вакыйганы тикшергәндә. Тик шул чак чәйханәгә кергәннән бирле шым гына утырган иптәше Амантай, терсәге белән орынып, аның фикер агышын бүлде һәм ишеккә таба ымлап:

— Кунаклар ишәя! — дип елмайды.

Байкучатов яңа пәйда булган берничә ир-атның кухня дип фараз ителгән бүлмәгә кереп югалуларын, җитмәсә, алар арасында көндезен Каган вокзаланда күзгә чалынган озынча йөзле, кара сакаллы, чыршы кашлы бәндәнең дә булуын күргәч, ул тарафка элегрәк борын тыгып карамавына пошынып куйды һәм шул хатасын төзәтергә омтылып, урыныннан кузгалды. Тик олы табындагы кәбестә чалмалы, шома йөзле егетнең дә кухняга таба юнәлүен күргәч, ирексездән беравыкка тукталып калды. Әмма Фарукҗан Яшь бохаралылар партиясе өчен әле дә җаны өзелгән, халыкны Коммунистлар партиясен тазартуга каршы котыртып маташкан бу егеттән күз язырга һич тә җыенмый иде. Шуңа күрә аның артыннан әлеге ишек ябылуга, Амантайны бераздан шулай ук кухня ягына күз салырга кисәтте дә сәкедән купты.

Байкучатов килеп кергән караңгы коридорда янә ике ишек шәй-

ләнә, аларның берсе ябылып бетмәгән һәм аннан чынлап та таба чыжлаган тавыш, кыздырылган ит, суган исләре килә иде. Икенчесенә колагын куеп тыңлап торгач кына, Фарукҗан баягы кунакларның шунда икәнлекләрен чамалады. Тик алар бер дә шау-гөр чыгармый, әңгәмәләре дә тын гына, ипле генә ага, коридорга ишетелми диярлек иде. Байкучатов анда керергә ашыкмады, башта сүзнең ни хакында баруын аңларга тырышты.

— Сәетморат бәк Каратаудан китәргә теләмәйде,— диде кунакларның берсе.— Безнең ата-бабалар әлмисактан бирле шушында яшәгән, ди.

— Кызыл ләшкәр килсә, нимә кылады? Юллар якын, яшеренергә җае бармы?

— Каратауга өметләнәде.

— Кешеләре күпме?

— Анча күп имәс. Корал китерсәгез, ишәячәкбез, ди. Пулемет сорады.

— Сәетморатны беләмен, сүзенә хуҗа адәм,— диде карлыккан тавыш.— инкыйлапчылар сайлаткан яңа түрәне бик тиз тәүбә иттергән, теле озынайган аксакалларның янә берсен акылга утырткан, иманга килмәгән яшь этәчләрне исә әрвахлары янына озаткан!

— Бәрәкалла! Мондый каһарманның сораганын бирәек, җәмәгать.

— Йөз мылтык, пулемет, патроннарны каракүлгә алмашып алсын,— диде карлыккан тавыш.— Бер-ике тәүлектән кәрван килеп җитәр. Багбан коесы янында көтеп торсыннар...

Кухня ягыннан кемнеңдер якынлашуын тоеп, Фарукҗан ялт артына борылды һәм караңгырак почмакка тайпылып, билбавына кыстырган унатарын барлый-барлый иданәгә чүгәләде. Ике кулына икешәр буш чәйнек тоткан хуҗа иде бу. Бәхеткә, ул уңга-сулга күз салмастан, туп-туры зур залга атлады. Шулвакыт коридордагы аяк тавышына аулак бүлмәнең дә ишеге ачылды, ләкин яктыдан караңгыга башын сузган адәм Фарукҗанны шулай ук абайламады, хуҗаны артыннан танып тынычландымы, кире эчкә кереп югалды.

Байкучатовка хәзер инде аеруча сак булырга, тиздән кире әйләнеп киләчәк хуҗаның күзенә төшми, хәлне катлауландырмый гына Амантай янына сызарга кирәк иде. Әмма ул үзен тагын бер мәртәбә аулак бүлмәдәгеләр гәбенә колак салудан тыеп кала алмады.

— ...Залда чекист утыргач, тикшерми хәлең юк,— диде карлыккан тавыш.— Иснәнеп килгәнме ул монда, әллә адашып кына әләккәнме — ходай бирсен.

— Аны моннан бөтенләй биздерү дә зыян итмәс иде.

— Караңгы почмаклар җөдә күп, борадәрләр, күңелен күрү кирәк!

Фарукҗан сүзнең үзе турында баруын чамалагач һәм бу карлыккан тавышлы бәндәне Каган вокзалында хәтерләп калган картка юрагач, колагын шундук ишектән алырга мәҗбүр булды. Шулай, ат типмәс димә, эт капмас димә. Баксаң, мондагылар чаялыкта бер дә аңардан ким түгел икән ләбаса, күзләре очлы, колаклары чос, сүзне җилгә ташлаучыга да охшамаганнар шикелле. Инде аны барыбер беләләр икән, югалтыр нәрсәсе калмаган, башны юләргә салып, өсләренә басып керергә дә һич югы танып калырга иде бәдбәхетләрне. Бүтән эш чыгара алмас ул чәйханәдә, вакыты да, шарты да шуннан арыга ирек бирми.

Уйлаган эш — беткән эш, дигәндәй, Байкучатов тәвәккәл генә әлеге ишекне ачты да мул яктыртылган, иданенә яхшы келәмнәр түшәлгән җыйнак кына бүлмәгә килеп керде. Тәбәнәк түгәрәк өстәл тирәли тезелеп утырган биш-алты ир-атның һәммәсе дә дәррәү башларын күтәреп һәм гаҗәпләнеп көтелмәгән кунакка текәлделәр. Фарукҗан аларның барысын күздән кичергәч,

— Кичерәсез, хуҗа монда имәсмени? — дигән булды.
Чыршы кашлы, кара сакаллы таныш карт йөзен яшерергә ашыкты, калганнары беравыздан диярлек:
— Аш өе анавы якта, шундадыр ул.— дип җавап бирде.
— Рәхмәт, кичерәсез.
Фарукжан аларга тагын бер кат күз йөгертеп алгач кына, кечелекле тәстә баш иеп, бүлмәдән чыгып китте. Коридорда йөзгә-йөз килеп бәрелгәч, хуҗа аңа үзе гаҗәпләнеп:
— Сезгә нимә кирәк иде? — дип эндәште.
Артындагы кунак бүлмәсенең ишеге шыгырдап куюыннан Байкучатов үзләренә колак салучы җан пәйда булуын чамалады һәм шактый табигый рәвештә әйтте:
— Әкәҗан, бераз тамакка кабасы диеп идек. Берәр кайнар ризык булса...
— Пылау бар кү, күңелегезгә якса...
— Җөдә яхшы булыр иде. Ике адәмгә, әкә!
— Хәзер китерәмен, утыра торыгыз.
Фарукжан Амантай янына әйләнеп килгәч тә фикерен бер юнәлештә туплый алмый аптырады. Аулак бүлмәдәгеләрне кулга алырга ымсынса да, моңа ни дәлилле сәбәбе, ни көче җитәрлек түгеллеген, чөнки олы залда да аларның тарафдарлары барлыгын чамалап өлгергән иде инде. Шуның өстенә, монда китергән максаты да бүтән ич әле, тәҗрибәсез иптәшләрен дә куркыныч астына кую ярамас.
— Дускай, миңа хәзер сыпыртырга туры килә,— диде ул аннары Амантайның колагына.— Хәзер хуҗа пылау китерер, сез Иргәш белән сыйлана-сыйлана, мондагыларның һәр сүзенә колак салып утырыгыз. Бигрәк тә хәрби комиссарга кагылсалар. Иртән мине кәрвансарайдан эзләп табарсыз.
— Хуп, булады.
Фарукжан шуннан соң чәйханәдә озак юанмады, Амантайга хуҗаны бәхилләтерлек акча тоттырды да урыныннан кузгалды — яландагыларга тагын бер мәртәбә күз салып узар өчен, арт ишектән чыгып китте.
Тышта салкынча һәм караңгы иде. Әмма монда һава сафрак, тел астына кыстырган насвайны теләсә кайсы якка төкерергә, касә төбендәге чәй түбен күзең караган тарафка чайкап түгәргә уңайлы иде. Аннан да бигрәк монда үзеңә охшаганрак урын табып, ят колаклар ишетер дип куенсынмастан, әшнәләрең белән тәмләп әңгәмәләшергә, төрле-төрле планнар корырга мөмкин иде. Күктә йолдызлары чекрәеп торган аяз кичләрдә генә түгел, болыт баш очын тәмам каплаган чакларда да монда хозур, күңелдә ерак яланга чыккан кебек бер хис пәйда була иде.
Менә шуңа күрә Фарукжан ашыкмыйча, тирә-ягына карана-карана, ишетелгән гәпләргә колак сала-сала кичте яланны. Түбәсе ябулы тар тыкрыкка әнә шулай килеп җиткәнче гадәттән тыш берни дә шәйләми атлады ул, бары күрше мәхәлләгә аяк басар алдыннан гына, ату тавышыннан сискәнеп, бер кырыйга тайпылды һәм унатарына үрелде. Икенче пуляның аңардан кул сузымы җирдә дувалга килеп тиюенә караганда, кемгә һөҗүм итүләре ачык иде, шуңа күрә ул бер дә икеләнми утка ут белән җавап бирде. Бу тирәне начар белсә дә, наган тавышына чамалап ата-ата, үзе дувалга сыенып алга таба йөгерде. Бәхетенә, аны эзәрлекләүче бәндә дә караңгыда юньләп төзи алмады, ахры, аннары урам бормасында корбанын бөтенләй күздән югалтты. Шул арада мышкылдап чыккан Фарукжан туктап сулышын басты һәм, караңгылыкка төбәлеп, тыңлап торды — артта аяк тавышлары бүтән ишетелмәде. Ул арада янә наган атылды, аннары тагын, гаҗәбе — аларның гөпелдәве икесе ике җирдән яңгыраган шикелле тоелуда иде. Бераздан ату тавышы тагын кабатланды, аннары бик

тиз якынлашып килгән аяк дөпелдәве ишетелде — дуамал чабуына караганда, бу дошман әзәрләүче кеше йөрешенә бер дә охшамаган иде. Шунлыктан Байкучатов коралын әзер тотып, дувалдагы ишек уемына елышты. Әлеге җан иясе аның янында җил кебек җитез йөгереп узып киткәч, карачкының хәрәкәтен чалымлап алган чекист:

— Амантай! — дип кычкырды.

Ераклаша барган шәүлә туктады һәм ерактан гына:

— Фарукҗан әкә? — дип тавыш бирде.

— Мин бу, мин.— диде Байкучатов, иптәшенә таба атлап.— Кая болай җир җимертеп элдертәсең?

— Сине куып җитмәкче идем.

— Мине?

— Әйе. Тизрәк тайыйк моннан, Фарукҗан әкә,— диде Амантай каударланып.— Ишләренең әзәрлекли килүе бар, мин анда берәүне чүкедем бугай.

— Ничек?

— Син бусагада күздән югалуга, карыйм, кухня ягыннан чыккан кәбестә чалмалы ир-ат иплэп кенә койрыгыгызга тагылмасынмы. Күңелем сизенде. Иргәшне кисәттем дә тегенең артыннан иярдем.

— Күзегез очлы икән тагын.

— Чәйханә биләмәсеннән ераклашканчы песи кебек кенә барды-барды да бер заман гөрс револьвердан. Син җавап бирә башлагач, артына борылып: «Басмачы-ы-ы!» — дип аваз сала-сала йөгерә бит әле, төнлә туган! Шуннан соң мин дә сыйларга булдым ул акыллы башны.

— Тидерә алдыңмы?

— Белмим, ни өчендер урам уртасында тәгәрәп калды шунда.

— Тыйнак, тыйнак!

— Бу тирәдән ычкыныйк без, Фарукҗан әкә, атышка чәйханәдәге бөтен халык тышка агылды бугай.

— Иргәш анда ялгызы гына бәлагә тарымасмы соң?

— Сират күперен кичкән каһарман ич ул, алдатмас.

Әмма Фарукҗан ашыкмады, иптәше белән бергә тар урамнар буйлап әйләнә-тулгана торгач, яңадан әлеге чәйханә янына килеп чыкты. Аның таныш караңгы коридоры аша узып, зал ишеген саклык белән бераз гына ачты да хасил булган нәни ярыктан эчкә күз салды. Анда хәзер барысы да урыныннан купкан, дулкынланган, күз алларында дип әйтерлек йөз биргән шау-шулы вакыйганы берсен-берсе бүлә-бүлә тикшерергә керешкәннәр иде. Әмма Фарукҗан ят халыкка әз генә дә игътибар итмәстән, бөтен чәйханәне күздән кичереп, үзенә генә таныш йөзне эзләде һәм аны әлеге кайнап торган төркем эчендә исән-имин, хәтта үзенекен тукый-тукый сүзгә катнашкан хәлдә күргәч, тынычланды, коридордан тавыш-тынсыз гына кире чыкты да, Амантайны ияртеп, кайту юлына төште.

## 23

Аксолтановларга килеп кергәч, Фарукҗан:

— Ничектер сәеррәк: капкагыз да, ишегегез дә бикләнмәгән икән,— дип гаҗәпләнде.

— Кунакны шулай көтәргә тиешләр дә.

— Төнге кунакларның нинди булмас дисез, хәтәр түгелмени?

— Шәмгун абзагызны бәләләр монда, утка керергә атлыгучыларны тиз генә таба алмассың.

— Ә миннән курыкмыйлар,— диде Фарукҗан күңелсез генә.— Кеше күз алдында тәгәрәтә яздылар, көчкә качып котылдым.

— Чекист башың беләнме?

Аксолтанов аны кечерәк бер бүлмәгә алып керде дә керосин лампасының тонык яктысы төшкән түрдәге тәбәнәк өстәл янына утыртты. Фаруқҗан өстәлдә таралып яткан ниндидер кулъязма китапка игътибарсыз гына карап алганнан соң, әле яңа гына чәйханәдә һәм аның тирәсендә булып узган хәлләрне кабат хәтерендә яңартып, берничә сүз белән үзенә ничек атуларын сөйләп бирде.

— Үзең соң нәрсә авыз ачып тордың? — дип сорады Аксолтанов.

— Шау-шу куптарып күзгә бәреләсем килмәгән иде.

— Һәй, туган, кубасы купкан инде, димәк, кем икәнлегеңне барыбер белгәннәр.

— Аның каравы иптәшләрем куләгәдә калды сыман. Козгыннар оясына юлны бикләү, киекләрне өркетү акланмый, аларга колак салыр өчен иң уңай урын ул.

— Белмим, мин үзем дошманнан качып котылуны хупламыйм. Табан ялтыратудан һөҗүм итү яхшырак.

Фарукҗан бәхәскә кереп тормады, үзен күбрәк кызыксындырган мәсьәләгә күчте.

— Шәмгун абый, Рахманколның әфган сәүдәгәре Габделшөкерхан белән танышлыгы нәрсәгә нигезләнә икән?

— Вәкил әфәндене әйтәсеңме?

— Нәкъ шуны.

— Алар таныш икәнлеген төгәл ачыкладыңмы?

— Әйе.

— Кызык бу. Рахманкол хәрби комиссар әмере буенча да элемтәгә керергә мөмкин, билгеле. Сәүдәгәр белән базар алышбиреше дә булырга мөмкин. Тик син, мөгаен, алар бәйләнешеннән берәр мәкер, сүз берләшү эзлисеңдер инде?

— Әфганстанның әле кайчан гына Бохара әмире белән хәрби килешү төзегән булганлыгын истә тотсак...

— Нигез юк түгел, ахры, үзе.

— Аның койрыгына басу гына кыен хәзер. Вакытын чамалап юкка чыккан күренә.

Хәрби комиссар йомышчысы башта ук шик уятып, соңыннан әллә кая китеп баруы белән Фарукҗанны тәмам аптырашта калдырса, Шәмгун Аксолтановның моңа бөтенләй исе китмәгән шикелле тоелды. Хуҗа кеше, мин хәзер чәй генә алып керим әле, дип бүлмәдән чыгып киткәч, Байкучатов ирексездән өстәлдә яткан кулъязма китапны актара башлады. Бохара әмирләрен сурәтләгән ниндидер тарихи трактат иде бу.

Ул арада Аксолтанов табын кирәк-яраклары, ризык алып кереп, бизәкле касәләргә чәй ясады һәм үзе дә өстәл янына аякларын бөкләп утыргач:

— Әйдә, якташ, җитеш! — дип эндәште.

Фарукҗан кулъязманы урынына куеп:

— Боларның барын да үзегез укыйсызмы? — дип гаҗәпләнде.

— Әйе.

— Кайсы әмирнең ничә кәнизәге булуын белү бик мөһиммени хәзер?

Аксолтанов аның фикерен дәвам итеп:

— Шушындый революция кайнаган, җыен дөнья актарылган чакта, ә? — дип көлемсерәде. Аннары җитдиләнеп дәвам итте: — Кирәк шул, якташ, кирәк. Ничә кәнтәе, нинди мал-мөлкәте булуын, галиҗәнапнең ничек көн уздыруын белү дә файдалы. Гыйбрәтле.

— Билгеле, сезгә... кызыктыр инде.

Фарукҗан «шагыйрь кешегә» дип авыз ача башласа да, вакы-

тында тыелып калырга өлгерде һәм чаен йотып куйды. Аксолтанов исә аны тулысынча төшенгән шикелле:

— Әйе, аны уку миңа бик кызык,— диде.— Миңа гына түгел, бу трактат белән танышу бүтәннәргә дә зыян итмәс иде. Кыю, зирәк, җаны сызлаган кеше язган аны. Әхмәт Даниш. Ишеткәнең бармы?

— Юк.

— Кызганыч, бу әсәр китап булып басылмаган. Аны укырга миңа кем киңәш бирүен беләсеңме? Шиһабетдинов! Хәер, сине ниндидер трактат түгел, хәрби комиссар йомышчысы кызыксындыра ич әле.

— Нишләп инде? — диде Фарукҗан үзгәрә башлап.— Трактат та кызыксындыра. Кызыксындырырга тиеш!

— Минә бусы бөтенләй башкача,— диде Аксолтанов елмаеп.— Даниш бабаң ханлыкның хәл-әхвәлен биш бармагыдай белгән, аның бөтен чирен ачып салган һәм әнә шулай Бохара революциясенең тарихи ихтыяҗ икәнлеген дә исбатлаган. Әмир өеренә каршы уңышлырак көрәшер, кайберәүләрнең күзен ачар өчен бу трактат үзе бер кыйммәтле табылдык.

— Халык аннан башка да үз хәлен чамалагандыр инде. Салым түләп тинтерәсен дә...

— Алай гына уйлама. Язмыш дип, кеше малына кызыгу хәрам дип, баш катЫручылар һәрчак ишле булган монда. Трактатның бездәй читтән килүчеләргә Бохара каршылыкларын, мондагы төрле бәйләнешләрне аңларга ярдәме зур. Югыйсә, карбыз, мамык кырларына, йөзем, өрек бакчаларына хозурланып йөреп, әмирлектә күплэрнең гомер буе ач-ялангач яшәүләрен күз алдына да китермәскә мөмкин. Илдә үзегезнең хуҗалык нык идеме соң?

— Уртача. Безнең әнкәй баштта малай арты малай тапкан. Имана ишәйгәч, балалар үсә төшкәч, бераз баш-күз алганбыз. Кешегә ялланып эшләп, әткәй атлы булуга ирешкән, аннары иген игәргә, терлек, кош-корт асрарга керешкән. Әмма сугыш чыгу, абыйлар белән минем дә фронтка китеп баруым аны тагын аяктан екты.

— Габделхәмит Гарипов белән Бохарага килгәнче үк таныш идегезме?

— Сорау алуга охшап китте әле бу, әллә миңа ышанмыйсыз инде, Шәмгун абый?

— Э син чекистлар гына төпченергә тиеш дип уйлыйсыңмы? — дип көлемсерәде Аксолтанов.

— Юк та соң, әллә ничек килеп чыга: уртак эшне җигелеп тартасы урында, чәйләп, мич башына да качмый торган нәрсәләрне телгә алып вакыт уздырабыз. Мин болай да кая барып бәрелергә белми баш ватканда...

— Гарипов булышмыймыни?

Фарукҗан хуҗа кешенең әле һаман сынап каравын абайлап, аның соравына төгәл җавап бирергә мәҗбүр булды.

— Гариповны мин беренче мәртәбә менә шушында килгәч кенә күрдем. Ул Шиһабетдиновның үзен-үзе үтерүенә ышанган, җитмәсә, минем мөстәкыйль казынуымны да өнәми икән.

— Сине нигә Чекага урнаштырды соң ул?

— Белмим. Тәтештә чакта ук шунда бераз эшләп алуымны әйткән идем.

— Барыбер табышмак.

— Нигә?

— Йә ул алданган, йә син хәзер бүтән кеше булып кыланасың. Һәр очракта ут белән уйныйсың син, энекәш.

— Берни дә аңламыйм,— диде Фарукҗан чын күңелдән.

— Озакламый барыбыз да аңларбыз, кояшны иләк белән каплап булмый. Э хәзергә менә таныш әле шушы кәгазь белән.

Аксолтанов сузган язуны укырга керешкәнче үк, Фарукҗан андагы имзага игътибар итте. РСФСР һәм Коминтернның Бохара республикасындагы вәкиле Куйбышевка адресланган русча хатка хәрби комиссар үзе кул куйган иде.

«Хөрмәтле Валериан Владимирович!

Бохара революциясе коммунистлар кулы астында киң катлам халык тарафыннан ясалса да, монда Республика җитәкчелегенә сәүдәгәрләр, вак буржуа эшлекләре оялау аркасында, хезмәт ияләренең өмете әле һаман акланмады. Демократик үзгәрешләр ярты юлда тоткарланды, социаль тигезлеккә гамәлдә ирешәсе урында, хөррият хакында буш сүз куертулар өстенлек алды. Тыштан үтә революцион күренгән Яшь бохаралылар Коммунистлар партиясенә кереп тулды да Ревкомда ныгырга, яла ягу, ришвәт бирү шикелле бер генә алымнан да чирканмастан, Кызыл Гаскәрдә, Чекада тамыр җибәрергә мөмкинлек тапты, хәтта йомышчымны сатып алу омтылышы да ясалды. Революциягә менә шулай хыянәт ясалган шартларда без, Бохара хезмәт ияләренә булышырга дип читтән килгән большевиклар, нишләргә тиеш? Бурычыбызны үтәгән санап, ватаныбызга кайтып китәргәме, әллә сыйнфый ят көчләрне тар-мар итеп, чын социалистик революция ясаргамы? Шушы мәсьәләгә Коминтерн мөнәсәбәтен ачыклавыгызны һәм тиешле күрсәтмәләр бирүегезне үтенеп, РКП(б) әгъзасы Баһаветдин Шиһабетдинов.

1920 елның унбишенче октябре».

Хатны укып чыккач, Фарукҗанның башына килгән беренче уй тагын Рахманкол турында булды. Шуңа күрә Аксолтановка:

— Димәк, йомышчысының дошманнар белән элемтәгә керүен хәрби комиссар белгән? — диде.

— Дөресрәге, йомышчысы тирәсендә үрмәкүчләр ятьмә үрүен сизгән. Бары шулай гына. Әгәр Рахманколның гаебе булса, Баһаветдин аны шунда ук урынына утырткан булыр иде.

— Мөгаен өлгермәгәндер.

— Монда эшләр шактый катлаулырак шул, энекәш. Аерым җинаятьчене эзләү белән мавыкмаска кирәк сиңа. Астыртын политик көрәш көчәйгән заман, бөтен бер чылбырны күздә тотарга иде.

— Рахманкол әфган сәүдәгәре Габделшөкерхан белән бәйләнештә булгач, контрларның кайдан үрелүе билгеле инде.

— Анысын да онытырга ярамас, әмма дөнья болгатырлык көчләр Бохараның үзендә дә җитәрлек. Шиһабетдинов шуларга бик нык аяк чалган, күрәсең.

— Мин дә нәкъ менә шулай уйлыйм.

— Бик әйбәт. Әмма Чеканың эше хәрби комиссарга кул салган ялгыз җинаятьчене тотып алып җәзага тарту гына түгел, әнә шул үтерүче аркылы сыйнфый дошманнарыбызны барлау, шуларны халык алдында фаш итү.

— Әйе, шул. Тик, карагыз әле, Шәмгун абый, Шиһабетдиновның бу хаты ни өчен сезнең кулда соң?

— Сүзне алдан ук менә шуннан башларга кирәк иде дә инде, энекәш,— диде Аксолтанов тәмәке кабызып.— Баһаветдин РСФСР вәкиленә язган мөрәҗәгатендә чын революционерларның байтагын борчыган иң җитди мәсьәләне күтәргән иде. Ләкин ул хат адресатына илтеп тапшырылмады. Тагын бер кат үзара киңәшкәч, без яңа фикергә килдек.

* * *

Ревком ханәләренең берсендә шау-шулы бәхәс куерүын ишетеп, Аксолтанов барган җиреннән ирексездән туктап калды. Бераз колак салып торуга, үгет биргән сыман сөйләүче юмакай тавышны да таныды — бу, әлбәттә, җәдитчеләр «аксакалы» Госманхуҗа иде. Истанбулда акыл җыеп кайткан хәйләкәр төлке ниләр бы-

тылдый икән? Бохарада кайбер җитди мәсьәләләр рәсми утырышларда түгел, нәкъ менә шушындый мәҗлесләрдә алдан ук хәл ителеп куелуын искә алганда...

Шәмгун, кеше күзенә артык чалынмаска тырышып, мыштым гына бүлмәгә барып керде дә арткы сафтагылар янына чүгәләргә ашыкты, тик аңа барыбер, Фәйзулла Хуҗаев түргә узарга ишарә ясаганнан соң, шундук алгарак узарга туры килде. Таштимер Тураев, Баһаветдин Шиһабетдиновлар да исәнләшеп баш какты, әмма бу аларга тыныч кына кыяфәттә Госманхуҗаны тыңларга да комачауламады.

— ...Элек бар нәрсәне әмир үзе генә хәл итә, бәкләр, вәзирләр һәммәсе дә аның җырын җырлый иде,— дип сүзен дәвам итте Госманхуҗа.— Бәхеткә, без ул мәгънәсез залимнән мәңгегә котылдык, мәмләкәтебез язмышын кайгыртуны халык үз кулына алды. Хәзер Бохараны Саманыйлар дәверендәге шикелле куәтле вә шөһрәтле дәүләткә әверелдерү дә, әмир Мозаффар заманындагы шикелле, бәйсезлеген югалтып, бичара хәлгә калдыру да шушында утырган мөхтәрәм җәнапләргә бәйле. Аерым алганда, партияне тарту комиссиясенә, РСФСРга җибәреләчәк миссиягә кемнәрне билгеләү дә Бохараның киләчәк язмышына зур йогынты ясаячак...

— Госманхуҗа әкә,— дип бүлдерде аны Таштимер.— без бөтен дөньяда социаль революция ясарга ашкынганда нинди Саманыйлар шөһрәте ул? Әллә сез шулай итеп комиссиягә диһканнарны сайларга өндисезме?

Шиһабетдинов мыек астыннан гына елмаеп, Аксолтановка күз кысты, аннары тагын җитди төскә кереп, сүз көрәштерүчеләргә колак салырга кереште. Госманхуҗа исә Таштимернең юри бөгештерүен бөтенләй сизмәгән төсле:

— Мин диһканнарны билгеләүгә каршы имәсмен,— диде.— Тик җаваплы урынга куелачак кешенең укымышлы, мәмләкәт күләмендә уйлап эш итәрлек акыл иясе булуы лязим.

— Дамелла,— дип сүзгә кушылды Фәйзулла Хуҗаев.— фикерегез тугры, намуслы укымышлыларны идарә хезмәтенә тарту хаҗәт. Сез үзегез тагын кемнәрне җәлеп кылынмаган саныйсыз соң?

— Сәләтле егетләребезне теләсә ниндигә түгел, лаеклы вазифага тәгаенләү мөһим,— диде Госманхуҗа.— Ерак барасы юк: сез үзегез мин элек тә телгә алган киң мәгълүматлы, эш җаен яхшы белә торган әйбәт энекәшләребезнең берсен гади уку өе мөдире итеп тотасыз лабаса.

— Әбдиевне әйтәсезме?

— Әйе. Җөдә йөгерек фикерле бала. Әле бүтән әйбәт яклары өстенә, Рәсәйне белә, урыс телен белә. Минемчә, РСФСРга барачак миссиягә менә кемне дә кертү артыгы белән акланыр иде.

— Тугры, дөрес кү,— дип хуплаган тавышлар яңгырады.

— Әмир оясын штурмлауда катнаштымы соң ул?

Госманхуҗа, Баһаветдин соравына җавап бирмәстән, үзенекен тезә бирде:

— Яки менә Латыйфханны алыйк. Безнең хәрәкәттә күптәннән катнашып килә. Хәрби комиссариатка әллә кайлардан командирлар эзлибез, борын төбендәге егетләрне күрмибез. Комиссар булырга ярамаган икән, нигә шуны урынбасар итеп куймаска? Бохараның үз кешесе анда да эш башында утырырга тиеш имәсме?

— Бохаралыны кую язык булмас булуын, әмма ни өчен сугыш кырыннан качкан адәмне калкытырга? — дип аваз салды Тураев.— Аны Чекада тотканга рәхмәт әйтегез әле. Тапкансыз каһарман!

— Кызмагыз әле, Таштимер,— дип бүлде аны Госманхуҗа.— Ул чакта тәкбир әйтү бер Латыйфханны гына имәс, күпләрне аптырашта калдырды.

— Башка чакта рәхәтләнеп тулы Коръән чыга торган бәндәләр-

неме? — дип мыскыллы көлемсерәде Тураев.

— Иңгә-билгә патронташлар урап, икешәр наган, кылыч асып утка ташлануыгызны беләбез,— диде Госманхуҗа юмаларга тырышып.— Тик сезнең калада бүленеп калган энегезне коткарырга омтылуыгыз да сер имәс иде.

— Борадәрләр, кардәшләр,— диде Фәйзулла Хуҗаев.— Юкка кылыч болгамыйк. Таштимернең кыю солдат булуына шикләнмибез. Әмма берәүнең сәләте сугышта, икенченең тынычта ачылуы да хак.

— Тугры,— дип җөпләде аны Госманхуҗа.— Бәлки Латыйфхан парткомиссия эшенә кулайрактыр? Әллә без андый җиргә Бохара халкын кайгыртучыларны имәс, бөтен дөнья революциясе дип ахух килүчеләрне генә сайлыйбызмы? Әгәр бу шулай икән, бәлшәвикләрнең милли тигезлек, үзбилгеләнү дигән нәрсәләрен үзебез үк аяк астына салып таптамыйбызмы соң?

— Госманхуҗа әкә, үзбилгеләнү шигаре хезмәт ияләренең азатлык өчен сыйнфый көрәшендә киртәгә әйләнергә тиеш түгел,— дип каршы төште Шиһабетдинов.— Милли мин-минлекне кабартып, байларның ярлыларны изүен, башта мәнә шуны бетерергә кирәклекне онытмыйк. Милли изү — буржуйларның сыйнфый өстенлеге нәтиҗәсе. Социаль тигезлек алу милли изүне дә юкка чыгара. Вакытыннан элек үзбилгеләнү исә хезмәт ияләренең буржуйларга каршы берләшүен зәгыйфьләндерә.

— Теләсәгез ни әйтегез, борадәрләр, тик мин Баһаветдинов тәкъдим иткәнчә, көнчыгыш чигебезне РСФСР гаскәрләреннән саклатуга да, Бохарада аның акчасын йөртүгә дә каршы. Моңа юл кую бәйсезлекне җуюга бәрабәр!

Госманхуҗаның бай сәүдәгәр икәнлеген һәм ниндидер ярлы диһканнар хәленә беркайчан да җаны сыкрамаячагын Аксолтанов яхшы белә иде. Шәмгунне чынлыкта ул түгел, аны кемнәр һәм ничек яклаячагы күбрәк кызыксындырды. Шиһабетдинов исә Бохара эшлекләре белән әле юньләп танышып җитмәгән, кеше сынап артык вакыт уздырырга да теләми иде, ахры, гадәттәге кайнарлыгын тоймастан, милли каһарман өстенә очып кунды:

— Беләсе иде: сез бик каты үстерергә теләгән Әбдиев, Нурморатовлар да шулай уйлыймы икән?

— Миңа аларның чын Бохара егетләре булуы гына ачык...

— Бохара егетләре? Сөйлисез дә инде. Хөрмәтлем, бу әле әз, бик әз шул. Югары вазифага билгеләнер өчен баш күтәргән халыкка тугрылыклы кеше булу кирәк. Сезнең шикелле РСФСР ярдәмен кире кага башласалар, әмир башкисәрләре монда бик тиз килеп җитәчәк, һәм, беренче эш итеп, шуларның ук муенын борып атачак. Әллә сез шуңа сусап торасызмы? Бәлки күңелегезгә бүтән мәмләкәт ярдәме ошыйрак бирәдер?

— Англия булышырга ашкына диләр үзе!

Тураев репликасы болай да кыза башлаган һавага очкын шикелле чәчрәде, әмма Фәйзулла Хуҗаев ялкын кабынуга ирек бирмәде.

— Җәмәгать,— диде ул.— Бохара революцион хөкүмәте империалистлар атаманы Англия белән беркайчан да дуслашмас. Гареп пролетариаты белән Шәрык хезмәт ияләренең хөррият өчен көрәше Бохара халкын Совет Русиясе белән берләшергә чакыра. РСФСР безгә үз гаскәрләребезне тизрәк аякка бастырыр өчен ярдәмен кызганмый.

— РСФСРның булышуы әйбәт,— диде зур чалма ураган ир-ат.— Тик мин бернәрсәне төшенмим: хәрби назыйр Шиһабетдинов киләчәктә Бохара Ревкомына буйсынмаячак, турыдан-туры Төркестан фронты әмерчесе белән генә эш итәчәк имеш, диләр. Хакмы икән бу сүз?

Бүлмәдәгеләр әле Фәйзуллага, әле Госманхуҗага күз йөгертте.

РСФСР белән БХСР арасында вакытлы сәяси-хәрби килешү әзерләнүен Аксолтанов та ишеткән, әмма аның нинди булачагын болай ук тиз арада күпләр белеп алыр һәм тикшерә башлар, дип һич тә башына китермәгән иде. Бу юлы Тураев та, Шиһабетдинов та ләм-мим авыз ачмады. Госманхуҗа да гөнаһсыз карашын Хуҗаевка төбәде. Бик теләмәсә дә, шуңа күрә Фәйзуллага җавап бирергә туры килде.

— Борадәрләр, безнең хәзерге хәлебез бик киеренке,— диде ул.— Байсын ягында әмир өере көч җыя, башка тарафларда да басмачылар тернәкләнә. Мондый шартларда барлык куәтебезне бергә туплау, аны бер әмерчегә буйсындыру котылгысыз. Ә революцион Бохараның махсус хәрби әзерлекле үз юлбашчылары юклыгын һәммәгез дә беләдер. Минемчә, эш кемнең кемгә буйсынуында имәс, бу берләшкән көчләрнең канәчкеч әмир өерен туздыруындадыр. Шулай имәсме?

Ни хуплап, ни ризасызлык белдереп эндәшүче күренмәгәч, Хуҗаев сәгатенә карап алды да:

— Тәнәфесне бетерергә вакыт икән,— диде.— Гәп яхшы яхшысын, әмма ул эшне калдыра. Кемнең хаклы икәнен гамәлебез генә күрсәтә алады кү...

* * *

Республика хәрби комиссары казага очраганга ике тәүлек тулып килә, тик фаҗига сере ачылудан әле һаман ерак иде. Байкучатов, Аксолтановны бөтен игътибарын биреп тыңласа да, ул сөйләгәннәрдән ачык кына бер мәгънә чыгара алмый баш ватты.

— Бу гәп куертулар күптән булдымы, Шәмгун абый? — диде ул.

— Бер атна чамасы элек. Шул көннең иртәгәсен өч дус тагын очраштык та яңадан әлеге мәҗлесне искә төшердек. «Менә шундый инде ул безнең изге Бохарабыз,— диде Таштимер.— Революциягә без җан өрдек, ут эченә дә үзебез ургылып кердек, ә хөкүмәткә Госманхуҗалар кереп тулды! «Баһаветдин аны: «Әмир түрәләрен, комсыз бәкләр, фанатик руханиларны кысрыклау да зур җиңү», дип юатты. Шулай фикер алышкалап бер-ике мәхәлләне узгач, Баһаветдин безгә РСФСР вәкиле исеменә язган хатын күрсәтте. «Минем бу постка билгеләнүемә теш кайраучылар барлыгын элек тә сизә идем,— диде ул.— Кичә Госманхуҗа әкә таш аткач, бу бигрәк тә нык ачыла төште». «Сәүдәгәр ни кузгатмас? — диде Таштимер.— Аңа бөтен җирдә үз кешеләрен утырту кыйбат». «Сәүдәгәрне аңларга мөмкин,— дидем мин,— әмма бүтәннәр нигә авызларын йомып торды икән анда?» «Бүлмәдә Госманхуҗа иярченнәре иште иде,— диде Таштимер.— Кайберәүләрне үз ягына аударып өчен, аның юри авырткан чуанга кагылуын үзегез дә күрдегез ич. Беркатлы җаннар ышанып та куя сафсатага. «Димәк, мин бу хатны бик вакытлы язганмын?» — дип сорады Баһаветдин. «Беләсезме нәрсә? — дип эндәште Таштимер,— әйдәгез юлдаш Куйбышев янына өчәүләп барабыз?» Бу тәкъдим барыбызга да ошады һәм без, озак уйлап тормастан, туп-туры РСФСР вәкиллегенә юнәлдек.

...Көн инде күптән кичкә авышкан. РСФСРның Бохарадагы гадәттән тыш вәкиле Валериан Владимирович Куйбышев, көндезге эшләрен тәмамлап, бүтәннәренә тотынганчы дип һавага чыккан һәм ишегалды түтәлендәге чәчәкләргә су сибә башлаган иде. Ул чәчәкләр ярата, бу якларда октябрь азагында да хуш ис таратып утыруына сөенә һәм, моннан җанга рәхәт һәм мәгънә табып, авыз эченнән:

ТӘУФИКЪ ӘЙДИ ◆ ЕЛАН УГЫ ◆

дип көйли иде. Капкадан килеп кергән кунакларны ул менә шул хәлдә күтәренке күңел белән каршы алды.

— Бөтен бер гвардия рәхим итүен генә күрегез әле,— диде ул җанланып.— Ул-бу килеп чыкмагандыр ич?

— Юк-юк.

— Әйдәгез өйгә узыгыз, иптәшләр!

— Без озакка түгел, Валериан Владимирович,— диде Шиһабетдинов.— Бакчада сөйләшсәк тә ярый.

— Юк инде, кадерле кунакларга безнең вәкиллектә бер касә чәй эчү язык булмас. Залга рәхим итегез!

Моңа кадәр дә көн саен эшлекле һәм гади итеп сөйләшеп йөргән бер кешенең хәзер шул кадәр олпат, әмма бер үк вакытта кечелекле һәм кунакчыл хуҗага әверелүен күрү җанга рәхәт иде. Тик Шиһабетдинов моңа карап кына бик онытылмады, озакка сузмый үзен борчыган нәрсәләр турында сүзгә кереште. Соңгы көннәрдә шаһит булган вакыйгаларга тукталганнан соң, ул:

— Валериан Владимирович, әмир өерен туздырганчы Бохара революционерлары үз алларына ярыйсы ук сугышчан бурычлар куйган иде,— диде.— Ә хәзер алар шуны җиң сызганып тормышка ашырасы урында, кире чигенә башлады. Мин соңгы вакытта кайберәүләрнең чын революционер булуына да шикләнеп карарга мәҗбүрмен.

— Нинди гөнаһларын ачтыгыз икән аларның? — диде Куйбышев шаярткан сыман.

— Республика җитәкчеләренең байтагы ярлы халык турында уйлап та карамый. Чөнки алар үзләре бай катлаулардан.

— Сәүдәгәрләрдән ни көтәсең инде? — диде Тураев.— Алар хәзер бишкә алып унга сатуны гына кайгырта.

— Кыскасы, мин Бохарада берни дә аңламыйм,— дип дәвам итте Шиһабетдинов.— Төркестанда бар да ачык иде.

Куйбышев кунагы белән килешеп:

— Монда эшләр чыннан да катлаулырак шул,— дип раслады.— Бохара кузгалышы Шәрыкта феодаллыкка каршы беренче аграр революция. Анда коммунистлар зуррак роль уйнаса һәм хакимлек Совет рәвешендә урнашса да, буржуаз-демократик үзгәрешләр генә күздә тотылды. Сәүдәгәрләр әмир башбаштаклыгыннан котылу, диһканнар авыр салымнардан арыну, әмир һәм бәкләр җирен үзара бүлеп алу өчен көрәште.

— Хәзер инде ул революцияне тирәнәйтергә, гомум демократик башлангычтан социалистик баскычка күчәргә вакыт,— диде Шиһабетдинов.— Завод-фабрикаларны эшчеләр кулына, сәүдәне дәүләт карамагына бирергә кирәк. Югыйсә кан коюларыбызның мәгънәсе дә калмый, сәүдәгәрләрне тәмам аякка бастыру, шәригать дип лаф оручыларны үсендерү өчен генә тырышып йөргән булабыз лабаса.

— Матди, рухи шартлар өлгереп җитмәгән шул әле,— диде Куйбышев.— Мондый хәлдә революцияне дәвам итү коммунистларны күпчелек тәшкил итүче диһканнар, һөнәрчеләрдән аерып, урта һәм вак буржуазиянең алдынгы өлешен, укымышлыларны бездән тулаем биздерер иде.

— Әгәр җир бүлеп бирсәк, диһканнар безнең белән булачак,— дип үз фикерен белдерде Аксолтанов.— Тик хәзерге җитәкчеләр бу эшкә бер дә ашкынмый.

— Бохарада урта гасырчылык хөкем сөрә, сыйнфый катламлану җитми,— диде Куйбышев.— Халыкка руханилар тәэсире көчле икәнлеген үзегез дә беләсез.

— Әмма җир бирсәк, сугаруны яңача оештырсак, ярлы дихканнар бераүгә дә корал булмаячак.

— Димәк, безгә хәзер нәкъ менә шул эшләрне көчәйтү генә файдалы? Ревкомны шуңа этәрсәк, РСФСР булышса...

Куйбышев Шиһабетдиновны игътибар белән тыңлаган арада бүтән кунакларын да күздән кичерергә онытмады. Аны бигрәк тә Тураев фикере кызыксындырды. Һәр өчесенең дә бер сүздә булуын ачыклагач, ул:

— РСФСРның бары тик хезмәт ияләренә генә теләктәшлек күрсәтүе кемгә дә сер түгел,— диде.— Аның нәкъ менә шуларга булышачагын мин һич тә кыенсынмый белдерә алам. Әмма Бохара революционерлары беренче чиратта үз халкына таянырга тиеш. Кышлакларга ешрак чыгыгыз, үз карашларыгызны киңрәк таратып, күпчелекнең яклавына ирешегез. Чын коммунистлар өчен бу — бердәнбер көрәш юлы.

— Менә күрдеңме? — диде Тураев тантаналы төстә Шиһабетдиновка.— Ә син Бохарадан таярга да әзер идең.

— Таярга? — дип сорады гаҗәпләнгән Куйбышев.

— Валериан Владимирович, җитәкчелектә миңа кырын караучылар хәтсез, шуңа күрә...

— Минемчә, Фәйзулла да астыртын гына дөнья болгата монда,— диде Тураев кыза башлап.— Беләм инде аны, йомшак җәеп катыга утыртырга дисәң, Хуҗаевка гына куш. Сәүдәгәрләр әшнәләренә юл куеп, үз хәлен ныгытмакчы, юха.

— Ашыкмагыз, Таштимер,— дип туктатты аны Куйбышев.— Хуҗаев хәленнән килгәннең барын да эшли. Кайбер бай җәдитчеләрнең җәмәгатьчелек ышанычына керүенә ул түгел, үзегез гаепле. Сәүдәгәрләр басымы астында чигенү хурлык. Киресенчә, диһканнар, һөнәрчеләрнең — Республика халкының уннан тугыз өлешенең аңын уятып, үзегез байларны кысрыкларга тиеш!

* * *

Төн уртасы якынлашса да, Фарукҗан әле һаман Шәмгун абыйсын тыңлавын дәвам итте. Хәзер аңа Бохара хәлләре тирәнрәк ачыла төште, әмма бу вакыйгаларның хәрби комиссар язмышына конкрет тәэсире бик үк аңлашылып җитмәгән иде. Шуңа күрә ул, хикәяне дәвам иттерергә теләп:

— Шәмгун абый, сез шуннан соң Госманхуҗалар белән бәрелешкә кердегезме? — дип эндәште.

— Әйе, дисәң дә, юк, дисәң дә ярый. Чөнки без шушы сөйләшүдән соң кышлакларга таралдык һәм халыкны әмир ялчыларына каршылык күрсәтергә, җир-су өчен көрәшкә оештыра башладык. Баһаветдин исә калада Бохара Кызыл Гаскәрен тупларга керешә. Шул эш барышында революциягә чын күңелдән бирелгән егетләрне барлауга, Госманхуҗалар тәкъдим иткән кешеләрне ачыклауга да күңел салды. Минемчә, аның нәкъ менә шушы эшчәнлеге дошманнарның ачуын кабартты һәм аларны авантюрага этәрде булса кирәк. Ә без ул чакта кышлакларда йөргәнлектән, дустыбызга янаган хәвефне вакытында күрә дә, кисәтә дә алмый калдык.

Аксолтанов төти башлаган лампаның филтәсен басып, касәләргә тагын чәй ясады. Аннары:

— Шундый алтын егетнең харап булуы Бохара ярлылары өчен бик зур югалту,— дип көенде.— Талканы коры иде Баһаветдинның, дошманнарына күз буарга ирек бирми, койрыкларын тиз кисә торган иде. Син кайгы митингысында иптәш Куйбышев чыгышын тыңладыңмы?

— Туры килмәде.
— Ул Шиһабетдиновны бик югары бәяләде.
— Алай югары бәяләгәч, нигә җинаятьне ачырга омтылмыйсыз соң сез? — дип сәерсенде Фарукҗан.— РСФСР вәкиле һәлакәтне нигә ныгытып тикшертми?
Аксолтанов бераз уйланып торгач:
— Әй син, җанкисәгем, нигә шундый уйга килдең әле? — дип елмайды.— Һәр нәрсә күзгә төртелеп тормый. Кайберәүләр: «Очын шәп яшердек тә котылдык», дип тик уйлый бирсен! Без мүкләнгән таш түгел, әүвәл хәлиткеч мәсьәләләрне кайгыртыйк әле, аннары... Беләсеңме, Шәмгун абзаң бүген ничә чакрым юл узарга өлгерде? Өч йөзне. Шуның алтмышын — атта. Ышана аласың: эт куып кына йөрмәдем анда. Шуңа карамастан, синең белән күрешүдән дә баш тартмадым.
— Гафу итегез, сез бик арыгансыздыр алайса?
— Зарар юк. Ә тансыклаган Рахманколыңны иртәгә Зыятдин станциясендә очратырга мөмкин. Тик сузма, беренче поезд белән үк юлга чык. Әгәр нәрсәнедер капшый алсаң, уртак эшебезгә керткән өлешең булыр.
— Шәмгун абый...— Табарга атлыккан кешесенә Аксолтанов әнә шулай зур әһәмият бирми генә юл ачканнан соң, Фарукҗан нәрсә әйтергә дә белми төртелеп калды. Рәхмәт хисе, үзенең булдыксызлыгыннан гарьләнү тойгысына аралашты, ахры. Хуҗа кеше исә сүзнең дәвам ителүен көтеп:
— Йә-йә? — дип үсендереп куйды.
— Иртәгә яки берсекөнгә Багбан коесы янына басмачылар өчен корал китерелергә тиеш. Мин шуны сагаларга ниятләгән идем әле.
— Бик әйбәт.
— Әйбәт тә соң, әле ул коены табасы да бар ич.
— Каратау ягында булырга тиеш ул, сораш. Чөнки Багбан кышлагы шул якта, Зыятдиннан ерак түгел. Болай булса, берьюлы ике куян тотуың ихтимал, тик анда саграк бул.
— Хәтәрмени?
— Сәетморат бәк басмачылары шул тирәдә котырына. Ышанычлы иптәшләр алырга онытма!
Фарукҗан сүзне беткәнгә хисаплап, аягына торып басты.
— Шәмгун абый,— диде ул саубуллашканда,— мин болай ук җитди ярдәм күрсәтерсез дип көтмәгән идем. Рәхмәт!
— Ә син киләчәктә күз алдындарак йөр, югалма.
Хуҗа аны капка төбенә кадәр озата чыкты. Урамда күзгә төртсәң күренмәслек караңгы иде. Тик Фарукҗан әле һаман Чекага юнәлмәде, атын Чархарас мәхәлләсенә таба борды. Мондый төндә анда чүлмәкче Хушмәмәтне эзләп табу, әлбәттә, бик икеле иде. Хәер, ул моңа исәп тә итмәде. Аксолтановтан ишеткәннәрне тагын бер кат аң иләгеннән или-или саф һавада озаграк кына йөрисе килде, шуңа урау юлны сайлады бугай. Тынып калган бормалы урамнар һәм буш мәйданнар буйлап узуны. Шул юл буендагы өйләрдә хәләл көче белән көн күрүче меңнәрнең татлы өметләре хәзер йолдыз булып күккә атылырга көч җыя, кара эчле бәндәләрнең мәкерле хыяллары баш очында кара болыт булып куерырга әзерләнә. Фарукҗан шикелле егетләрнең кырыс ихтыяры исә, төн карасын ертып алга атлаган ярсу аргамак шикелле, революция иминлеге сагына баскан иде. Шәмгун абыйсының нәрсәнедер әйтеп бетермәве, әмма даулы Бохарадагы астыртын көрәшнең сәбәпләрен, кайбер каһарманнарның шул көрәштә тоткан урынын яктыртуы Байкучатовка үзен ышанычлырак тоярга, дөрес юлдан атлавын белеп, канатланырга ярдәм итте. Шуңа күрә ул хәзер Чархараска таба кыю һәм гайрәтле төстә юртты. Төрле уйлар эчендә барганлыктан, үзе артын-

нан мыштым гына ияргән җан иясенең аяк тавышын ишетмәде.

Бер-бер артлы теркелдәгән ике кулэгә әнә шулай шактый җир узды, аннары тымызык һаваны сискәндереп револьвер шартлады. Бәхетенә, сукыр пуля бу юлы да Фарукҗанга тими дувалга килеп кадалды. Чырае качса да, чекист чамасыз каушап төшмәде, секунды белән маузерын тартып чыгарып, билгесез дошманына ут ачты. Аннары йөгәнне кулыннан ычкындырмый гына Тимеркүгеннән сикереп төшеп, коймага елышты да, тирә-ягына колак салып, баскан җирендә тораташтай катып калды. Таштимер дөрес кисәткән икән, бүген инде икенче мәртәбә колак төбеннән пуля сызгырып узгач, Фарукҗан үзен чын-чыннан әзәрлекли башлауларына ышанды. Шактый вакыт шым гына торса да, бүтән ят тавыш-фәлән ишетелмәде. Байкучатов исәбенчә, ул хәзер Чархараска, чүлмәкче Хушмәмәт яши торган мәхәлләгә килеп җиткән иде. Бәлки һөнәрченең чүлмәкләрен дә башка берәүгә төбәлгән пуля челпәрәмә китергәндер?

Аңа бу юлы да кире борылып һөҗүмгә ташланудан һәм әнә шулай ят җирдә кемгәдер мәрә булудан сакланырга, биек дуваллар-га ышыклана-ышыклана юлын ары таба дәвам итәргә туры килде. Бормалы тар урамнар Байкучатовны бераздан Чека урнашкан кәрвансарайга алып чыкты.

## 24

Аякларына чүпрәк ураганмыни, атлар елдам гына чапса да, тояк тавышлары бик яңгырамый иде. Кыр буйлап элдертәләр, дип уйлады Балҗан. Тик кайсы якка? Юлдан сул кулга юнәлделәр, ахры, кеше күзеннән аулак җирләр аша узаргадыр исәпләре. Нинди афәт соң бу? Юлбасарлармы, хатын-кызларны мыскыл итеп кызык табучы азгыннармы, яисә аларны сатып кәсеп итүче пычрак җаннармы Балҗанны әсир итүчеләр? Очраклы әләктеме имансызлар кулына, әллә алдан уйлап корылган тозакка төштеме? Дөяләргә асылган төенчекләрне онытып, нигә аңа гына ташландылар? Әллә соң юлдашларын талаганны миңгерәгән Балҗан күрергә генә өлгермәдеме? Карт белән карчык ни өчен ай-һай салмады? Ул чырылдап-тиберченеп каршылык күрсәткәндә, нигә ярдәмгә килмәделәр икән? Дөрес, Балҗан үзе дә кинәт ясалган һөҗүмнән, карчыга алдындагы чебештәй, куркып, аптырап калды, әмма озын тормыш юлы узган кәрванчы карт үзен тәрерәк, батыррак тотарга тиеш иде кебек...

Атлар әле һаман җитез чапканлыктан, Балҗанның артка каерып бәйләнгән кулларын җеп кисә, уңайсыз рәвештә утырганлыктан, аның гәүдәсе ватыла, үзе менә-менә җиргә тәгәрәп төшәр сыман тоела иде. Әммаияр ат аркасына ипле урнаштырылган һәм аның бавы яхшы тартып бәйләнгән, өзәңгеләр таман кыскартылган, әсир нык «тышауланган», шуның өстәвенә, җайдаклар аны уяу күзәтә, димәк, явызлар кулыннан үзеннән-үзе котылу мөмкинлеге бөтенләй юк иде.

Бер сәгать чамасы бик кызу барганнан соң, төркем адымын әкренәйтте һәм Балҗанның колак төбендә диярлек:

— Өлгергән җимеш кебек, өзеп алуны гына көткән икән чибәркәебез! — дигән тавыш яңгырады.

Аңа икенчесе үтә хирес рәвештә авызын чәпелдәтеп:

— Уша казакъ кызлары җәдә ширин булады кү,— дип җавап бирде.— Ходай язган булса...

— Йә-йә! — дип кырыс кына тыйды аны беренчесе.— хәрәмгә бикәр күз кыздырмыйк.

Боеручан төстә сөйләшүенә караганда, кырыс тавышлысы төр-

кем башлыгы иде, ахры. Ул өченче җайдакны йомыш кушып каядыр ашыктырып җибәргәч, нәфесе кузгалган егет тагын телгә килде.

— Ир азыгы белән бүре азыгы юлда имәсме? — диде ул шаярткан сыман.— Нәзир әкәнең барыбер аңарда күңеле юк.

— Каенатасы чая кеше булмаса, беренче хатынын да бик күптән күңеленнән чыгарыр иде инде ул.

— Гомер иткән бикәчләре кинәт нигә артыкка әйләнгән соң әле? Шундый чибәрләр дә ярамагач...

— Аның күз аткан былбыл кошы тагын да асылрак сөяк шул,— диде кырыс ир.— Нәзир дамелла шуңа өйләнер өчен...

— Алайса нәкъ вакытында гына юкка чыккан аяклы каза белән нигә булаша соң ул?

Балҗан үзен әсир итүчеләрнең һәр сүзенә шым гына колак салып бара иде. Баш басмачы җавабы егеттән битәр аны күбрәк кызыксындырганлыктан, ул хәтта сулыш алырга да куркып, туктап калды. Тирә-як тын, салкынча, атлар ышанычлы һәм җиңел атлый иде. Аны-моны дәшми бераз баргач кына, ирләрнең өлкәне, тел астына салган тәмәкесен җиргә төкергән шикелле, кыска гына итеп:

— Шулай кирәк! — диде.

— Ни өчен?

— Дошманына бушлай бүләк иткәнче, түләгән калымын төрекмәннәрдән кайтарыр ичмаса. Монда кирәкмәгәнне сайрап, дамелланың данын сатып та йөри алмас.

— Без юкка тегеләрне иректә калдырдык,— диде аңа иптәше.— Карт-корының теле шулай ук дилбегә буе.

— Син нәрсә, аларны чынлап та очраклы юлаучылар дип белдеңмени? — дип көлде өлкәне.— Дамелланың башы шуңа да җитмәгән дип уйладыңмы?

Төн карасын ертып барган җайдакларның беразга сүзләре өзелде. Басынкы гына сулкылдауны ирләр ишетмәде, Балҗан исә тавышын тизрәк үз эченә йотарга ашыкты. Кем кулына эләгүен, үзен кая алып баруларын вакытыннан алда белгәнлеген һич тә сиздерергә ярамый иде. Кайларга ризык тартадыр инде, дип рухы төшү шунда ук өмет белән алышынды. Төрекмәннәргә кадәр ара ерак, бәлки әле яхшы күңелле кешеләр дә очрап куяр, я булмаса Амантайлар эзгә төшәр. Ахыр чиктә басмачыларның кайнар канлы комагаен сынап, юри уңаена сыйпап карарга да була!

Балҗан бикле өйдән хәйлә белән чыгып качып, үзенең ничек итеп ялгызы гына Каганга килүен һәм Амантайны эзләп табуын исенә төшерде. Нәзирнең нишләтүен белгәч, сөйгәненең йөзе кара янып чыгуы әле дә хәтерендә. Кызык та соң инде бу ир-атлар. Әйтерсең, Балҗан шуңа кадәр әлеге зобаныйның никахлы хатыны булып ике ел гомер кичермәгән иде. Бәлки Амантай аның үзе белән кушылганчы тормышын игътибарга алырга, үткәнгә дәгъва белдерергә хаксыз булуын төшенгәндер? Инде үзенекенә әйләнгәч... Юкка гына мылтык атарга өйрәтеп маташмады лабаса. Киләчәктә безне тагын нинди бәла көтмәс, дип хәнҗәр әзерләве дә тикмәгә генә түгел иде!

Ул өзәңгегә киерелебрәк басып, кәвеш олтырагы астындагы тимер катысын яхшырак тойгач, кайнарланып: «Юк-юк, бу юлы мин ерткычлар иркенә җиңел генә бирелмәм»,— дип пышылдады һәм яңадан Амантаен күз алдына китереп, үзен аңардан аеручыларга карата йөрәгендә нәфрәт һәм үч кайный башлавына, бу хисләрнең бөтен барлыгына чыдамлык һәм гайрәт өстәвенә сөенде.

Җайдаклар бер юыртып, бер сикертеп чаба-чаба билгесез караңгылык эченә, алга, киләчәккә савылып керүен дәвам итте. Үз ихтыярыннан мәхрүм Балҗан исә бу вакытта күңеленнән кирегә, үткәнгә китеп бара иде.

Дөрес, анда да караңгылык җитәрлек, аның иң куесы, иң чирканчыгы — Нәзир белән аулакта калган төн иде. Шәрабтан, хайвани теләктән исергән тылмач аңа, җәйранга ташланган чүл бүреседәй ыргылды һәм мәхәббәт минутларын әллә ниләр хыялланып көткән кызны, ерткыч шикелле, дуамал комсызланып ботарлады да җиңүчән кыяфәттә түшәккә тәгәрәп төшеп, бик тиз гырылдап йоклап та китте. Ул төнне Балҗан таңга кадәр елап чыкты. Шәрыкның бер хикмәт иясе: «Урынсыз сүз, моңы юк кешенең җыры, җаның тартмас кеше белән мәхәббәт уены — дөньяда иң күңелсез өч нәрсә менә шулар»,— дип юкка гына әйтмәгән икән!

Амантай белән Бохарада очрашканда һәм аңа ияреп Каганга килгәндә ул инде, чәчәкләре күптән тапталган болын шикелле, нурсыз һәм боек иде. Каган урамында бер дә уйламаганда каршысына килеп баскач, Балҗан аңарда әле кайчан гына үзенә яшертен сокланып, нәрсәдер көтеп, ымсынып караган егетне түгел, тәмам бата башлаганда тартып чыгарып сау калдырырлык танышын — атасының элекке ярдәмчесен генә күрде, мәгәр яңадан араларында якты җеп сузылыр дип һич тә башына китермәде. Никах укылганнан соң бер юрган астына кереп сыенгач исә Амантай аны бигрәк тә шаккатырды. Ул аңа шактый озак орынмыйча ятты. Балҗан инде кимсенә, мендәрне шыпырт кына күз яшьләре белән чылата башлагандa гына, кыяр-кыймас кочаклап алды. Ялгыш кагылып китеп, егетнең кул аркасы тоташ тирләп чыгуын тойгач, ул аның халәтен, җиһанның сигезенче могҗизасына тап булгандай, дулкынланып күзаллады һәм йөрәгенә тула башлаган шатлыктан кайнар күз яше янә бәреп чыгуын сизми дә калды. Лаек идеме соң ул мондый ихлас, пакь күңелле, әле беркайчан да кыз куенын күрмәгән егеткә? Кеше икәнлеген, үзенә бик кадерле икәнлеген тоярга форсат биргән юмарт җанга тиешенчә түли — лаек пакьлек, ихласлык, матурлык бүләк итә ала идеме соң ул? Бәхеттән исергән Балҗан бу турыда ни шул төнне, ни соңрак үзенә-үзе хисап кылмады бугай. Бары хәзер генә ул бу таш табаннарның үзен кемнән, нәрсәдән мәхрүм итәргә җыенуларын бик ачык төшенде. Юк инде, дип уйлады Балҗан нәфрәт белән, мин хәзер Амантайдан аерылуга алай бик җиңел, күндәм генә риза булмам. Пычрак хәшәрәтләрнең дөнья тоткасыдай кукраеп йөрергә хаклары юк. Аларга үзләренекедәй мәкер, көчне генә каршы кую аклана.

Һәркайсы үз уйларына чумган өч җайдак күпме юл узгандыр — Балҗан моны тәгаен генә һич тә әйтерлек хәлдә түгел иде. Күзләрен бәйләгән яулыкны чишеп алуларына караганда, таныш җирләрдән шактый ераклашкан булсалар кирәк. Басмачылар саклыгы көлке һәм мәгънәсез — төн караңгылыгында пәрәнҗә аша болай да ни аера ала инде тоткын? Ниндидер кое янына килеп туктауларын да ул бары су өслегенә чупылдап төшкән чиләк тавышыннан гына чамалады. Атларны сугаргач, алар юлны тагын дәвам иттеләр һәм, таң атып кояш шактый югары күтәрелгәч кенә, хуҗасыз көтүчеләр торагына очрап, ял итәргә туктадылар.

Җир өстеннән, укмашкан балчык өемедәй, түбә сырты гына калкып торган һәм, тәмам якынлашканчы, барлыгы да беленмәгән базкуышның ишеге биксез иде. Иярен чишеп, атын тышаулап җибәргәч, басмачыларның өлкәне калган эшнең барысын ярдәмчесенә йөкләп, ерак китмичә генә хаҗәтен үтәде дә, мылтыгын, юл төенчеген алып, куышка кереп китте. Комагай егет исә, әллә арыганлыктан, әллә юри әкрен кыймылдаганлыктан, иплән кенә башта үзенекен, аннары Балҗан атланган атны тышаулады. Сахрада икәү генә калгач, каймак күргән мәче төсле, хатын тирәсендә бөтерелеп:

— Байбичә, юл өшәндермәдеме? Әле авызыгыз кипмәдеме? — дип сайрый башлады.

Аяк-кулларын бәйдән бушаткан арада бете котырган басмачы аңа чамадан тыш сыланып әрсезләнсә дә, Балҗан чыгымламады, хәлдән тайган кеше сыман, бөтен күкрәге белән аның өстенә үзе ишелеп төште. Егет аны бик рәхәтләнеп кочаклап алып, елдам гына йомшак җирләрен капшый-капшый, пәрәнҗә читен күтәрде дә:

— Вай-вай, ни булды сезгә? — дип эндәште.

Балҗан, иркә бала кебек назланып, җавап урынына үзе сорау бирде:

— Килеп җиттекме инде?

— Кая?

— Сез мине үзегезгә кәләш итеп урламадыгызмыни?

Егет, муенына асылынган хатынны чәчваны ачылып киткәндә майлы күзләре белән ялмап, ике дә уйламастан:

— Без хәзер гомергә кавыштык инде, өрек җимешем,— дип авызыннан бал тамызды.— Без хәзер...

Балҗан, кайнарланган комагайга ышанган шикелле, күзләрен тутырып тагын бер карап алды да, сокланган дай:

— Сез нинди кыю! — дип пышылдады.

Аннары басмачы кочагыннан кинәт шуып чыгып, оялган һәм каушап калган кыяфәттә үзе атланып килгән юрганың арт санына сукты да базкуыштан читкә таба атлап китте.

— Сез кая болай?

Ташы кызган егет җавап көтеп тормады, әсир хатын артыннан ташланды һәм ике сикереп, бер атлап куып җитте дә кочаклап алды. Чәчванын ачып, шашып үбә башлагач, Балҗан нәфрәттән тетрәнеп, каты бәрелүдән үзен көчкә генә тыеп:

— Сез нишлисез? Әле без никах укыттырмаган ич! — дип терсәкләрен тырпайтты.

— Без барыбер бергә булабыз кү.

— Алайса юлдашыгыз ял итә торсын, ә без монда тукталып тормыйк, кузгалыйк.

Егет бер генә минутка икеләнә калды, әле атлар, әле базкуыш ягына күз йөгертте, әмма җиңелчә мавыгуыннан, шул ук вакытта иптәше алдындагы җаваплылыктан арына алмыйча, нәфесен уятучыны тагын шунда ук кысрыкларга кереште. Эшнең үзе уйлаганча барып чыкмаячагын күреп, Балҗан карыша башлады һәм уңаен туры китереп, сиздерми генә кәвеше эчендәге хәнҗәрен суырып алырга тырышты. Ләкин әүмәкләшү бөтенләй көтелмәгәнчә тәмамланды. Ул, күлмәге ертылып, терсәкләре сыдырылып, чарасыз калганда гына, ярдәмчесенең куышка озак керми торуын ошатмаган кырыс башлык тышка килеп чыкты һәм аны әтәч кебек хәлдә күреп алуга, йөгереп килде дә наган түтәсе белән бар көченә юлдашының чигәсенә сылады.

— Сиңа шәригать кагылмыймыни?!

Комагай егет көлтә кебек җиргә тәгәрәде, мышкылдап чыккан Балҗан аягына торып басуга, киемнәрен төзәтә башлады.

— Ә син нигә кычкырмадың? — диде үксегән хатынга кырыс басмачы.

— Буып үтерер, дип курыктым.

— Бар, базкуышка кер!

Чигәсеннән шаулап кан аккан яшь басмачы бер-ике тапкыр ыңгырашып, күзән җыерган шикелле тартылып куйды да, җаны чыккандай, хәрәкәтсез калды. Агарынган Балҗан, эсселе-суыклы булып, арты белән көтүчеләр торагына таба чигенде, аннары өлкән басмачының сәер карашын тоеп, аңа аркан борылды.

Куышның түрендә сәке, ишек төбендә сулы чүлмәкләр, кечкенә казан, турсык, тагын кайбер көнкүреш әйберләре күренә иде. Димәк, хуҗалар кайдадыр шушы тирәдә генә көтү көтә. Бу уй аны бераз

тынычландырса да, Балҗан сәкегә килеп утырырга кыймады, аулакта хәнҗәрен олтырак астыннан алып, ычкыр бавына такканнан соң, почмакка барып сөялде. Озын итәк каплаган корал һич тә беленерлек түгел иде. Караңгыга күзе ияләшкәч, ул ишек катындагы почмакка сөялгән мылтыкны да күреп алды. Аны сафтан чыгарырга кирәклеген аңласа да, моның юлын белмәгәнлектән, һаман шул көе терәлеп торуын дәвам итте. «Иптәшенең башына житте, ахры, бу зобаный»... Басмачы ишектә озак күренмәгәч, ул бераз батыраеп, мылтыкка үрелде, аның корулы икәнен ачыклап, сак кына пулясын чыгарды һәм аны көтүче кирәк-яраклары арасына яшерде.

Басмачы башта аңа әллә ни игътибар итмәде, кечкенә казанны тышка алып чыгып чәй кайнатты, аннары юл төенчегеннән пәтер, каклаган ит, хәлвә чыгарып, тамак ялгарга кереште. Көтүче чыныягына чәй ясап, табынга токтынын да чакырды һәм ризыкка житешергә боерды:

— Тамак ялгап ал, аннары безнең юл озын булачак әле.

Аның юмартлыгыннан өреккән әсир:

— Иптәшегезне чакырмыйсызмыни? — дип авыз ачты.

— Аны алыштыра алмас, дип куркасыңмыни?

Бер басуда үскән тигәнәк икән болар, дип хәвефләнде Балҗан. Басмачы исә аны бөтән кыстап мәшәкатьләнмәде, үз милкенә күз салгалап алучы хуҗа шикелле генә караштырып, ризыклануын белде. Шулай хәтсез ургач, сусын кандыргач, дога кылып, азык-төлеген җыйнады да:

— Хәзер эссе басылганчы бераз ял итеп алабыз,— диде.

Токтын әле һаман әлек килеп сыенган почмагында посып утыра иде. Басмачы аңа сөзеп карап торды да:

— Йә, сәкедәге түшәккә барып ят! — дип әмер бирде.

— Ә сез?

— Сәке киң, мин дә шунда сыярмын.

— Юк, юк...

Дөньяга баш иярга җыенмаган Балҗан, басмачының аны ипкә китерергә тәвәккәлләвен тоеп, түргә елышырга мәҗбүр булды. Ишек эчтән бикләнгән, әмма ул ачык булган хәлдә дә мыек кабарткан бәндәнең озын кулларын читләтеп тышка атылу һич тә мөмкин түгел иде. Аның хәрәкәтен сүздән чыкмау дип кабул итеп, басмачы тыныч кына кәвешләрен һәм чапанын салды, наганын чапан астына шудырды, аннары мутланып:

— Хатыннарның ирләр кагылган җире тәмугта янмавын беләсеңме, киленчәк? — дип эндәште.

— Сезгә оят имәсме, әкә? Шәригать...

— Ә-әй, куйчы, куй, шәригать — тегендә баргач, бүгенгә син монда минеке генә, киленкәем! — диде басмачы күзләрен майландырып.

Түргә таба якынлашкан алып гәүдәле табак битнең теләгенә ирешер өчен бернидән дә тайчанмаячагын, бая ярдәмчесенә кешене бәладән коткарыр өчен түгел, үз өлешенә нәфесен сузганга гына ут капкандай ашыгып ябырылуын Балҗан хәзер инде бик ачык төшенде. Аның күз алдында әле уйнашка кымырҗыган басмачының җирәнгеч азгын йөзе, әле Амантаеның ачынып сытылган чырае бии башлады. Битләре ут янган хәлдә ул стенага килеп терәлгәнче чигенде дә, кайнар кочакка эләгүен тоюга, итәк астыннан мыштым гына булат хәнҗәрен чыгарды һәм, үзе бер яккарак тайпылып, аны җан ачысы белән дошманының кендек астына батырды. Кочак бераз бушауга, хәнҗәрен суырып алып тагын бер кадады, аннары чапан астындагы наганны кулына төшерде.

— Ах син, талак фетнәсе! Җәлә...

Хәзер инде Балҗан зәһәр сүгенүне, аның соңында теле көрмәк-

ләнгән ерткычның аһылдавын колагына да элмәстән, «ә» дигәнче куыш ишеген каерып ачты да абына-сөртенә сахрага ыргылды. Калтыранган кулындагы канлы ханҗәрен комга сөртеп кынына салганнан соң, тышаулы атларның якындагысын кабалана-кабалана иярләде һәм, яшь басмачының аяк астында дип әйтерлек аунап яткан өр-яңа мылтыгын бар дип тә белмәстән, күз ачып йомганчы юртакка менеп атланды. Үкчәләре белән төюгә карамастан, аты бер дә алдырып китмәгәч кенә, сәбәбен чамалап, кире иярдән сикереп төште һәм тышауны ханҗәре белән тураклап атты.

Бахбайны ул бертуктаусыз көнчыгышка таба куалады. Әгәр якын арада берәр кышлак-мазарга тап булмаса, ахыр чиктә Сәмәркәнд-Чарҗуй тимер юлына килеп төртелү иде исәбе. Аннан инде кичә кояш баеганда алны-артны юньләп уйламыйча ашыгып чыгып киткән Каганга — Амантае янына әләгү кыен булмаска тиеш иде.

Әмма бәхетсезлек потлап килә, мыскыллап кына китә шул!

## 25

Ничек кенә арымасын, Фарукҗанның йокысы уяу булып чыкты — ул уянганда сәгать әле алты да тулмаган иде. Аксолтанов кисәтүен хәтерләп, кояш җелекне киптерә башлаганчы, башта ул Каганга барып җитәргә җыенды. Аннары ниндидер эчке сиземләүгә буйсынып, ниятен үзгәртте дә Чархарас мәхәлләсенә юл тотты. Үзенә төнлә нәкъ менә шул тирәдә атулары да тикмәгә генә түгел сыман тоелды. Бу мәхәлләнең шәһәр читендәрәк урнашуы һәм пайтәхетне тышкы дөнья белән бәйләп торган капкаларның берсенә орынган булуы да игътибарга лаек иде. Бигрәк тә шунда яшәүче Хушмәмәт останың чүлмәкләре тиктомалдан кырыла башлагач. Беренче карашка мәзәк, даулы заман өчен исә шактый гадәти тоелса да, һөнәрченең телгә керүе Фарукҗанны сагайтып җибәрде.

Офыкта пәйда булган бакыр шар алтынсу төскә манылгач кына, ул кәрвансарайдан кузгалды. Иртә матур, һавасы саф һәм беркадәр салкынча иде. Ерак кышлаклардан базарга килүчеләрне исәпләмәгәндә, шәһәр урамнары әле һаман, агачлары кисеп атылган бакча шикелле, шыр иде. Фарукҗан көндезге ыгы-зыгыдан, шау-гөрдән ял итеп яткан мәйданнар һәм урамнар буйлап елдам гына узып, Чархараска якынлашты. Шул мәхәлләгә аяк баскач, чүлмәкчене сорашыр өчен беренче очраткан кешесенә мөрәҗәгать итте һәм аның ярдәмендә бик тиз Хушмәмәт останы эзләп тапты. Һөнәрче инде аяк өстендә — ишәген җигеп базарга китәргә әзерләнә иде. Исәнләшеп үзенең кем икәнлеген һәм ни өчен килүен аңлаткач, Фарукҗан:

— Хушмәмәт әкә, әлеге чүлмәкләрегез кайда торганда ничек ватылды соң? — дип сораулар бирә башлады.

Хуҗа аны төп йорттан бер читтәрәк салынган лапас сыманрак корылма янына алып килде. Аның ишегалды тарафы ачык булганлыктан, эчтәге шүрлекләргә тезеп куелган эреле-ваклы чүлмәкләр әллә кайдан ук күренеп тора иде.

— Менә шушындагыларның өчесен харап иттеләр,— диде хуҗа.— Билгеле, чүлмәк кенә түгел, адәм башлары да исәпсез-хисапсыз тәгәрәтелгән хәтәр заманда минем югалту әллә ни имәстер. Шулай да, әгәр алар ватылмаган булса, акчасы кесәмне тишмәс иде.

— Ничек ватылды икән соң алар?

— Үз күзем белән күрмәдем, йоклый идем,— диде Хушмәмәт.— Мылтык шартлауга сискәнеп уянган гына идем, чүлмәкләрем челпәрәмә килү тавышы янә дә һушымны алды.

— Аларга нәрсә, кем зыян китерүен чыгып карамадыгызмы?

— Мин әйванда ята идем, кеше-кара керсә, күзгә чалынмый кал-

мас иде. Таш атсалар, иртән табылган булыр иде.

— Димәк, пуля тигән?

— Башыма төшкән бәла инде, ходайның язганы...

Фарукҗан чүлмәкченең күндәм кыяфәтенә бер генә күз сирпеп алды да ишегалдын, лапасны тикшерә башлады. Урам ягы коймасы ике метр биеклегендәге дувал булганлыктан, лапастагы чүлмәкләргә килеп тигән пуля, димәк, шактый биектән атылырга тиеш иде. Ат өстеннән яки... Урамның каршы ягында — икенче катында балаханәсе булган бер генә йорт күренә, ул Хушмәмәтләрдән хәтсез сул кулдарак иде. Фарукҗан ватылган чүлмәк урыныннан шул якка күз салды һәм канәгатьләнеп тамак кырып куйды. Балаханә түбәсеннән монда бик иркен ут ачарга була иде. Билгеле, Хушмәмәтнең үз өе түбәсеннән дә мөмкин, ләкин анысы инде башка сыймый. Ә тегеннән...

— Сәгать ничәләрдә аттылар? — диде ул хуҗага.

— Төн уртасы җитмәгән иде әле. Бәлки уникенче яртылар гына булгандыр.

— Сез моны ничек белдегез соң?

— Әтәч бар ич безнең. Күршеләрнең дә...

— Ә, әйе, әйе, дөрес. Хушмәмәт әкә, сез нәрсә, шуннан соң үзегезгә зыян китерүчеләрне барлап карамадыгызмы? Әйтик, урамнан?

— Төне дөммә-дөм караңгы иде. Аннары әчемә шөр дә йөгерде. Үземә гөпелдәтмәсеннәр тагын, дип каушап калдым.

— Шуннан? — Чүлмәкченең икеләнүен күреп, Фарукҗан аңа ныграк басым ясарга омтылды: — Бернине дә яшермәгез, әкә, без бу вакыйганы тикшерергә алынганбыз икән, күршеләрегездән дә сорашачакбыз, бүтән чаралар да күрәчәкбез. Ышаныгыз, без капчыкта озак ятмас.

— Егет сүзе бер булыр,— диде ниһаять Хушмәмәт оста, үзе өчен нәрсәнедер хәл иткәндәй.— Барын да булганча гәперәм. Чүлмәкләрем тәгәрәп вәйран килгәннән соң, койма артында, урамда шундук ниндидер кыштырдау, аннары ыңгырашу тавышы ишеттем...

— Шулай дип уйлаган идем аны! Йә-йә, дәвам итегез.

— Шуннан соң миңа да җан керде. Торып чапанымны бөркәндем дә дувал буена бүкән алып барып, урамга күз салырга кузгалдым. Бәлки ярдәмгә мохтаҗ яралы ыңгырашадыр, дип уйладым. Тик шулчак мине ат пошкыруы туктатты. Аннары таза-сау кешенең сүгенүе ишетелде. Нугайча. Мин, билгеле, басып торган җиремдә катып калдым да шым булдым.

— Тышка үрелеп карамадыгызмы?

— Карадым, тик соңрак, әлеге ике җайдак урынынан кузгалгач кына,— диде Хушмәмәт.

— Төн кошларын танымадыгызмы?

— Юк. Алдасам — гомеремнән бәрәкәт тапмыйм. Төне җөдә караңгы булганлыктан, болар күзгә ике күләгә кебек кенә шәйләнде. Икесе дә эре сөякле. Тик миңа шунысы бик сәер тоелды: янәшә барган җайдаклар бер-берсенә янтайган шикелле иде. Мин әле: боларның берсе икенчесен тотып бармыймы икән, дип тә уйлап куйдым.

— Башка берни дә күрмәдегез, ишетмәдегезме?

— Аның тагын бар кызыгы да шунда инде. Болар күздән югалырга да өлгермәде, артларыннан янә ике җайдак узып китте. Аралары ерак имәс иде, димәк, ату тавышын алар да ишеткән булырга тиеш. Ләкин шуңа да карамастан, соңгылар вәкарь белән генә атлый, алдагыларны куып җитәргә һич тә ашыкмыйлар иде.

— Җайдаклар кайсы якка китеп югалды? — дип сорады Фарукҗан.

— Каршы капкасына таба.

— Аннары сез яңадан йокларга яттыгызмы?

— Юк. Урамда әле һаман хәрәкәт тынмавын күргәннән соң, миңа да гайрәт керде,— дип көлемсерәде Хушмәмәт.— Бераз колак салып тордым да, бүтән ят тавышлар ишетмәгәч, шәм кабызып, бая ыңгырашу тавышы яңгыраган койма буен барып карадым. Җирдә кан тамган урыннар каралып, беленеп тора иде. Таптана торгач, арырак тагы да гаҗәбрәк бер нәрсәгә күзем төште.

Хуҗа кешенең тынып калуын күреп, Фарукҗан:

— Нәрсәгә? — дип сорады.

— Хәзер күрсәтәмен.

Хушмәмәт оста шулай диде дә өенә кереп китте һәм тиздән кулына уч төбе кадәрле генә затлы көзге тотып, кире ишегалдына чыкты. Фарукҗан табылдыкны күреп, гаҗәпләнә калды, чөнки ул мондый хатын-кыз әйберен түгел, револьвер, хәнҗәр ише берәр корал яки фуражка, кулъяулыгы шикелле нәрсә көтә иде.

— Көмеш, ахры, бу.

— Әйе, көмеш, җитмәсә, бизәкле. Әйбәт оста сырлаганга охшый. Кызым аңа бик сөенде инде.

Көзге артындагы, «Гүзәллеге арта бара һаман аның, шул гүзәлгә корбан булыр, ахры, җаным», дигән шигырьне укыгач, Фарукҗан:

— Тик моны сездән алып китәргә туры килер шул,— диде.— Җинаятьне ачарга булышуы ихтимал.

— Ала бирегез. Мин инде аны ватылган чүлмәк әҗере дип кенә күңелемә сыйдырган идем.

— Бүтән нәрсә күзегезгә чалынмады инде ул чакта? Әйтик, пуля?

— Юк, күрмәдем, ходай шаһит кү.

— Көзге яткан урынны чыгып карыйк әле.

Алар капка төбеннән сул кулга борылып, урам буйлап койма тирәләрен караштырдылар. Фарукҗан иелеп бармаклары белән җирне дә капшап матаашты. Тик кан табы әллә кайчан кибеп, туфракка аралашып беткән, дуваллдагы эзләрне дә, бусы фәләннән калган, дип өзеп кенә әйтерлек түгел иде.

— Соңрак бу тирәдә берәр шикле адәм әйләнеп-тулганып йөрмәдеме? — диде Байкучатов.

— Күрмәдем. Аннары капка төбен каравылларга вакытым да юк лабаса. Чүлмәкләрне шәһәр тышында яндырам.

— Ә теге балаханәле йортта кем яши?

— Бер сәүдәгәрнең өлкән хатыны. Айдан артык туган кышлагында сыйланып ята инде ул, йорт-җиренә күршеләр генә күз-колак булып тора.

— Ире, балалары монда тормыймыни?

— Балаларын үзе белән алды. Сәүдәгәрне беләсездер инде, ярты гомере юлда уза. Күршебезнең базарга якынрак җирдә тагын бер өе бар, ул күбрәк шунда яшь хатыны белән әвәрә килә. Бу йортын сатачак икән, дигән сүзләр дә йөри.

Фарукҗан күз-колак булучы күршеләрне һәм Хушмәмәтне ияртеп, үзендә шик уяткан утарны карап чыкты, баскыч таптырып, балаханә түбәсенә менәргә дә иренмәде. Йортның урам ягына тәрәзәләр уелмаганлыктан, түбәгә ул аеруча игътибар итте. Аннары хуҗаның исемен, яңа адресын язып алды һәм үзенә ияргән ир-аттан әлеге төнге ату турында сорашканнан соң, «биш былтыргыны кем хәтерли инде», дигән җавантан бүтәнне ишетмәгәч, кире чүлмәкче ишегалдына әйләнеп кайтты да:

— Хушмәмәт әкә, сез ватылган чүлмәкләр тирәсендә пуля-фәлән тапмадыгызмы? — дип мөрәҗәгать итте.

— Юк шул, тәксир. Хәер, мин аны эзләмәдем дә, кургашын кисәген табудан һөнәрчегә ни файда?

— Шул вагыйгадан соң лапасны себердегезме соң?

— Туры килде, билгеле.

— Чүпне кая түктегез?

Фарукҗан башта чүлмәкләр тезеп куелган шүрлекләрне күздән кичерде, аннары, тавык шикелле, чүплектә казына башлады. Озаклямый ул хуҗаны гаҗәпсендергән шатлыклы аваз белән:

— Менә уңдым! — дип кычкырды.— Инглиз винтовкасыннан атканнар. Монысын көтмәгән идем мин, монысы — табышмак!

Байкучатов Чархарас мәхәлләсеннән Башта Тураевларга юнәлеп, анда бикле ишеккә очрагач, Аксолтановларга да сугылды. Якташы иртәләгән кунакка сәерсенүен сиздермәде, эшлекле төстә өйгә чакырды.

— Шәмгун абый,— диде Фарукҗан, әлеге табылдык көзгене чыгарып,— узып тормыйм, менә бу әйберне ачыклар өчен генә кагылуым. Сезгә таныш түгелме ул?

Аксолтанов көзгене, бигрәк тә аның артындагы язуларны һәм бизәкләрне кат-кат карагач:

— Кайдан алдың моны? — дип эндәште.

— Анысы инде Чека сере, сез башта үзегез әйтегез әле.

— Кара син чукынмышны,— дип елмайды Аксолтанов,— әле миннән дә сер яшерәсеңмени? Әйтсәм әйтим инде алайса: көзге артына мәшһүр Җәми шигыре сырланган.

— Ю-ук, мине шигырь кызыксындырмый, көзгесе таныш түгелме дим, Шәмгун абый?

— Аһ, шулаймыни? — диде Аксолтанов шаяртып.— Ә мин тагын шигырь язучыны ачыкларга телисең дип торам. Өеннән алып чыккан идеңме моны?

— Кемнең?

— Шиһабетдиновның.

— Алайса бу көзге аныкы?

— Шиксез. Көзгене хатынына бүләк итеп җибәрергә җыенган иде ул. Мин аңа шигырь астына үз исемен дә өстәргә киңәш иткән идем.

— Ә ул?

— Шигыре төчерәк, диде. Соңыннан риза булып, хәнҗәр очы белән «Б» хәрефен яза башлаган иде, булдыра алмады. Менә бу нәни сызыкны күрәсезме?

— Күрәм.

— Баһаветдин сызды инде аны. Эше пешмәгәч, көмешчегә яздырырга ниятләде. Тик өлгерә алмаган икән шул мәрхүм.

— Сез мине генә үртәмисезме, Шәмгун абый?

— Шулай иза чигәсем генә калган инде.

Аксолтанов аңа житди карашын төбәп, бүтән берни дә эндәшмәгәч, Фарукҗан көзге табылу хәлләрен бер-ике авыз сүз белән сөйләп бирде дә:

— Ярый, мин сезгә соңрак иркенләп бер сугылырмын әле,— дип саубуллаша башлады.— Хәзер ерак юлга җыенасым бар.

— Болай булгач, Бохараның үзендә генә казынсаң, күбрәк уңмассыңмы икән?

— Белмим. Тик мин Рахманкол белән сөйләшми тынычлана алмам, ахры.

Фарукҗан кәрвансарайга яшерен почтаны укыр өчен генә кайтты. Әмма яңа килгән ике хатка аның бу юлы да теше үтмәде. Чека председателе кисәтүен онытмаганлыктан, ул аларны тотып, шундук Эминев янына ашыкты. Ят кешеләр чыгып китүгә, аның кабинетына җилле генә килеп керде дә, кәгазьләрен селкеп:

— Галимҗан абый, көймәм тагын комга терәлде,— диде.— Әллә юри таҗикча гына яза инде болар?

— Кемнәр?
— «Бум» белән «Биһуш»ны әйтәм.
Әминев хатларга бераз күз йөгерткәч, «Биһуш» язмасын бик тиз кире Фарукҗанга сузды.
— Монысыннан ботка түгел, өйрә дә пешерә алмабыз.
«Бум» хаты кызыклырак иде, ахры. Чека рәисе аны кат-кат караштырды һәм шул арада берьюлы Байкучатовны кичәге эше хакында хисап та бирдертте, аннары тагын агент язмасына төбәлде.
— Туры килә кебек бу,— диде ул аннары көлемсерәп.— Бер яшь әтәч турында хәбәр бирә «Бум». Хәтәр кош икәнлеген, кирәкмәгәннәрне белүен, теләсә кая тыкшынуын, тозакка эләкмәвен искәртә. Чәйханә һәм урамдагы төнге бәрелешкә ишарә ясый.
— Минем турыдамы?
— Күрәсез ич. Таҗикчагызны шомарта төшәргә кирәк. Бохарада ансыз уңышлы эш алып бару кыен.
— Бәлки безгә эчкерле «Бум»нардан тизрәк арыну хәерледер? Мондый агентларга таянган Нурморатовтан да...
— Юк инде, сайрый башлаганда гына киек кошларга кизәнмик әле,— диде Әминев.— Бөтен яшерен почтаң шушы гына идеме?
— Әйе.
— Менә бусы начар. Бу кайберәүләр арасында бары тик яңа элемтә юлы көйләнә башлавын гына расларга мөмкин. Без, мөгаен, аларны вакытыннан элек өркеткәндер.
— Ихтимал.
Хатларда Шиһабетдинов үлеменә баглы яңа мәгълүматлар булмавын ачыклагач ук, Фарукҗан Чека рәисе кабинетыннан тизрәк чыгып ычкынуны гына карый башлады. Шуңа күрә ул сүзне тагын хәрби комиссар йомышчысына, Иргәшләр кышлагындагы хәлләргә күчерде, үзенең ниләр майтарырга теләве белән таныштырды һәм Әминевтән ниятләрен тормышка ашыру өчен ризалык алды.
— Поезд белән китсәгез, атларыгызны Каганда калдырып торыгыз,— диде Чека председателе.— Зыятдин станциясендә кечерәк бер гарнизон бар, булышырлар.
— Яхшы.
— Кышлакка барган хәлдә корал белән уйнаудан сакланыгыз. Революция максатларын аңлатып, халыкның безне яклавына ирешү әһәмиятлерәк.
— Беләбез инде, Галимҗан абый, сез нәрсә.
— Сукыр тавыктай, тозакка барып капмагыз, алны-артны карап кына йөрегез!
Фарукҗан Каган юлына чыккач та Әминев киңәшләренә елмаеп барды. Аннары җитдиләнеп, эченнән: «Ә бәлки аңа кайгыртуы өчен рәхмәт әйтергә кирәктер?» — дип уйлап куйды. Кайбер аумакайларны кысыбрак тотарга, идарәгә сырышкан көя күбәләкләрен дә тизрәк фаш итәргә иде. Юкка гына борсаланмый ул, шушы һәлакәтне ачыклау кайберәүләрнең канатын бик нык көйдерер әле. Бәлки нәкъ менә шуннан өркеп аяк чала башлаулары дыр да инде аңа.
Тирә-якны уяу күзәтеп барганлыктан, Байкучатов каршысына чаптырып килгән дусларын ерактан ук танып алды. Амантай белән Иргәш исә, сүзгә мавыгыпмы, аны күрми узып китә яздылар.
— Кая ашыгасыз болай, егетләр?
Җайдаклар, таныш тавышны ишетеп, шундук тезгеннәрен тарттылар, атлары кинәт туктый алмый үрә сикереп кешнәп җибәрде. Юл кырыенарак кагылып биргә баш кушкач, гадәттәгечә исәнлексаулык сорашырга да оныткан Иргәш Мирәхмәтев:
— Бәла, Фарукҗан әкә,— диде.— Сезне күрергә чаба идек әле. Тагын Балҗан юкка чыккан!
Байкучатов йөзе караңгыланган Туктаровка:

— Кая кузгалган, ни булган? — диде.

— Кышлакка. Амантай мине ташлап барыбер басмачыларга каршы китәргә җыена, ул яуларны туздырып кире әйләнеп кайтканчы, әниләр янында торып торырмын, дип әйтеп калдырган үзе.

— Соң алайса нигә өнегез алынды?

— Алдан кисәтмичә кинәт урыныннан кубуы шикле,— диде басынкыланган Амантай.

— Аннары госпиталь башлыгы Мартьянов күңелгә шом салды,— диде Иргәш.— Ул Балҗанның кемгә ияреп юлга чыгачагын күреп, белеп калырга теләгән. Әмма дустыбызның хатынын әгъвалаган юлаучы алар эзләгәндә генә җир йоткандай юкка чыккан. Ул да булмый, Мартьянов киңәшен дә тотмастан...

— Госпиталь башлыгы сабыр итәргә кушканмы? — дип сорады Фарукҗан.

— Әйе шул, ирең кайтканны көтеп тор, дигән Мартьянов уртак.

— Җитмәсә, дөяләргә атланып кичкырын кузгалганнар,— диде Иргәш.— Сәер. Ил даулы чакта юл басучылар азмыни хәзер?

Фарукҗан китек күңелле дустын:

— Анысы аңлашыла инде, эсседә әлсерәп хәлдән таймас өчен тырышулары булгандыр,— дип юатты.— Адәм баласы инә түгел, табылыр. Кайсы юлга төшкәннәр?

— Шушыңа,— диде Амантай.— Тик Каганнан чыгып киткәч, аларны инде беркем дә күрмәгән.

— Кышлагыгыз кайсы тарафта әле?

— Гыйҗдуваннан арырак.

— Һәй, болай булгач бигрәк тә уңай инде,— диде Байкучатов.— Мин үзем дә сезне шул якларга алып китәргә дип уйлап бара идем әле. Балҗан дөядә кайтып җиткәнче, без әллә кайчан поездда элдереп, төп эшебезне үтәрбез дә аны каршыларга юнәлербез.

— Әгәр бу тылмач оештырган явызлык булса?

Фарукҗан үзе дә нәкъ менә шуннан хәвефләнә иде. Әмма моны Амантай теллләп әйтеп биргәч, егетне тынычландырырга ашыкты:

— Мәгънәсезгә баш ватмыйк, дускай. Күп азынса, явызның эзенә төшәрбез дә кикриген бик тиз шиңдерербез. Ә хәзер тиз генә Зыятдин станциясенә барып җитүебез кирәк.

Егетләр берсүзсез аңа буйсынып, атларын Каганга таба борды. Бу юл Бохараны Сәмәрканд, Чарҗуй, Каршы шәһәрләре һәм бөтен тышкы дөнья белән дә бәйләгәнлектән, хәрәкәт шактый җанлы, монда кара җәяүле, атлы, ишәкле, дөялене — барысын, барысын да очратырга мөмкин иде. Мамык кибәннәре төялгән ике күчәрле арбалар гына түгел, затлы тарантаслар һәм тирә-якның тынлыгын алып, төтен бөркеп уза торган берәм-сәрәм машиналар да шушыннан тәгәри. Әмма Фарукҗан кат-кат чалма чалган чуар чапанлы ирләргә, җете төсләре күзне камаштырырлык күлмәкләр кигән һәм аның өстеннән пәрәнҗә бөркәнгән хатын-кызларга, күзге байлыгы белән күңелне хушландырган табигать манзарасына — иген кырларына һәм җимеш бакчаларына, юл буендагы биек, еракган караганда җиргә кадап куелган каз каурыен хәтерләткән байтирәкләргә күз төтеп озак онытылмады, Амантайны берәз алга уздырды да, үзе Иргәш белән тигезләнгәч:

— Я, кичә чәйханәдә бездән соң берәр кызыклы нәрсә күрә-ишетә алдыңмы? — дип эндәште.

— Кесәсе калыннарга хозур анда. Ияк биетеп, күңел эретеп утыра бирәсең.

— Ә сез, алай иркенләп китеп, гәп куертучыларга колак салырга онытмадыгызмы соң?

— Колак салу гына имәс: бәхәскә дә керә башлаган идем әле, кисәтүле карашыгызны абайлагач кына, телемне тыйдым.

Фарукҗан өнәмәгәндәй башын селкеп:

— Сезне шул кадәр кызып китәр дип уйламаган идем,— диде.

— Кызарсың анда. Әмир куштаннары караны ак дип таныта башласа... Сез чикмән кигән, маңгаенда яра эзе беленеп торган берәүгә игътибар иткән идегезме?

Фарукҗан юри ваемсыз рәвештә:

— Әллә тагын,— диде.— Анда чалмалылар чалмасыздан күбрәк иде кебек.

— Монысы озынча йөзле, очлы иякле, кара сакаллы, сөйләнергә җөдә оста бер карт иде.

— Йә, йә, шуннан?

— Хәрби назыйр һәлакәте аны бик сөендергән шикелле күренде. Менә шул яралы маңгай сезнең арттан ук яланга чыгып китте.

— Ә арткы бүлмәдән миңа ияргән җан булмадымы?

— Юк. Атыш яңгыраганчы, аннан һичкем дә яланга аяк атламады. Әмма безнең яктагы атлас чапан кигән кабартма яңаклы, кысык күзле ир беравык шунда кереп югалып торды, аннары шулай ук ашыгып сез киткән якка йомылды.

— Ә теге чикмәнле картыгыз?

— Яралы маңгаймы? Ул атыштан соң ыгы-зыгы басылгач кына пәйда булды, сый өчен түләргә хуҗаны эзләгән шикелле, туп-туры арткы бүлмәгә кереп китте. Бераздан андагылар зур залга чыгып утырды, берсе минем белән гәп тә корып алды әле.

— Нәрсә турында?

— Мине бу чәйханәдә беренче мәртәбә күрүен әйтеп, кем булуымны сораша башлады.

— Кара син аларның уяулыгын, кызы-ы-ык!

— Безне дә юкәдән ишмәгән. Базарга килүемне әйттем дә савыт-саба, кием-салым кыйммәтлеге хакында лаф ора башладым.

— Егет! Атыш ишетелгәч, чәйханәдәгеләр нишләде соң?

— Мәхшәр купты! Кыюраклар тышка чыгып, мылтык шартлаган якка таба йөгерде. Бераздан кире әйләнеп кергән әлеге атлас чапанлы, кабартма яңаклы мөртәт: «Шарт та шорт котны алдылар. Чекистлар әмирнең бер уңмаган түрәсен тоткан икән»,— дип халыкны тынычландырды. Бик шома адәмгә охшаган иде ул.

— Мәҗлес тагын озак дәвам иттеме соң?

— Йокы баса башлагач, мин төнге өчләрдә өйгә кайтып киттем.

— Якшы, без ул «шомаларның» койрыгына басарбыз әле. Ә хәзер сезнең туганнар очраган хәлләргә күчик.

Каганга барып җиткәнче, калган юлда Фарукҗан Иргәштән Каратау ягы, андагы кышлаклар, чүлдәге коелар һәм соңгы вакытта баш күтәргән, ил тынычлыгын алган басмачылар турында сорашып барды.

## 26

— Мин хәзер энекәш белән тиз генә базарга барып киләм,— диде Нәзир.— Чәеңне кайната тор, кунаклар килергә тиеш. Кечтеки кара мыеклы, тәбәнәк буйлы бер хәрби ишек шакыса, арткы бүлмәгә узсын да көтеп торсын. Тиздән кайтып җитә, диярсең.

— Ярар.

— Бохарада «хуп, мәйле» диләр. Бу сиңа Нугайкорган кышлагы имәс, күптән өйрәнергә вакыт.

Зөһрәгөл каршы эндәшмәде. Иренең соңгы вакытта сылтау табып җелеккә үтәргә тырышуы беренче мәртәбә генә түгел иде инде. Әлбәттә, бу бары тик аның Булатхуҗаевларга ешлатуы, шулардан яшь кәләш ярәшеп йөрүе нәтиҗәсе генә. Күрәсең, үзенә бөтенләй

бүтән хатын кирәклеген исбатларга маташуыдыр. Яшь кәләштән бигрәк аның шанлы туганнарына күзе төшүен, шуларның юан муенына асылынырга омтылуын яшерүедер. Белә ич инде: шалкан бәясе генә кеше булса да, үзенә кирәклеген ачыкласа, Нәзир аны көйләргә иренми. Хаҗәте бетсә, бәясе төшкән мал шикелле генә күрә.

Менә шундый арзанлы мал хәленә калды, ахры, хәзер Зөһрәгөл: ире әллә нинди эшләр артыннан чытыр чаба, өйгә кайтып керсә дә, юньле киңәш-табышы, иппе сүзе сирәк. Әллә кайлардан ләх булып уралып, хатынына тузга язмаган гаепләр өяргә, сүгенергә дигәндә аны куш — шундый оста, шундый юмарт!

Аулактан файдаланып, кызларының күлмәк-ыштаннарын юганда да Зөһрәгөл менә шулар турында уйлады. Ата-анасы сүзен тотсаң, бу күп дигәндә дә нибары табак-савыт шалтырау гына. Ир кеше шулай гайрәтле була инде ул. Дөнья куа, мал таба, аның бөтен бу кәсеп итүләре гаиләсе өчен. Әгәр өйгә кайткач бераз чебенләп ала икән, чәпчемә: ир — баш, хатын — муен!

Әмма Зөһрәгөл шактый белем алырга, замананың вакытлы матбугаты белән танышып барырга өлгергән, күзе ачыграк бер хатын-кыз булганлыктан, мондый үгет аның бер колагыннан керә, икенчесеннән чыга. Нәзир янында ир һәм тамак колы — өй кошына гына әйләнеп яшәү аны канәгатьләндерми иде. Казанда уку шактый тирән эз калдырганлыктан, бигрәк тә Фатих Кәриминең «Төрек ханымнары» китабы белән мавыкканлыктан, үз көчен гаиләдән читтә сынап карау, әлеге китап каһарманнары кебек, шөһрәт казану теләге, көл астындагы күмердәй, әле һаман күңелендә көйри иде. Бу омтылышы бала тапкач азрак басылып торса да, Нәзирнең башкаларга нәфес сузуы, аннары Бохара революциясе башлану Зөһрәгөл йөрәгенә тагын тынгысызлык уты салды. Иренең бер дә уйламаганда баш күтәрүчеләргә кушылуы һәм үз биләмәсендә уку йорты ачтыруы аның өметен бигрәк тә үрләтеп җибәрде. Алдынгы карашлы кеше данын чыгарырга теләвеннәнме, әллә ниткән йомышлар белән әледән-әле кышлакларга китеп югалып торуы аркасындамы, Нәзир чыннан да уку өе эшенә хатынын да аралаштырырга мәҗбүр булды. Уку өенә килгән һәр хатын-кызны Зөһрәгөл тансыклап каршы алды, аларга нәрсәдер аңлатырга сәләте җитүенә сөенде. Нәзирнең бу эшкә исе китмәвенә дә көязләнмәде, бары тик иренең кайберәүләр белән генә гәп коруына, сөйкемле сөякләрен еш кына кунакханәгә алып кереп серләшүенә генә сәерсенде. Җитмәсә, Нәзиренең андый сердәшләре уку өендә «агартуга» мохтаҗ кешеләргә тамчы да охшамаганнар иде.

Капка шакылдауга, юеш кулларын тастымалга сөртә-сөртә, Зөһрәгөл тышка чыкты. Ире тасвирлаган кара мыеклы, тәбәнәк буйлы хәрби килеп җиткән икән. Шактый көяз, җитез хәрәкәтле һәм кыю холыклы кунак, кичә генә аралашкан кешедәй, татарча исәнләште дә, сораудан бигрәк раслауга охшатып, үгезне мөгезеннән эләктерде:

— Димәк, Нәзир иптәш юкка чыгарга да өлгерде инде?

Ире кушканча җавап биреп, Зөһрәгөл мосафирны арткы бүлмәгә уздырды да юана торырга уку өе ягыннан иске татар журналлары китереп бирде. Әмма кунак аларга күз дә салмастан:

— Чамасыз тамак кипте, якташ,— диде.— Бераз су бирсәгез, тау кадәр рәхмәтләр яудырыр идем.

— Хәзер чәй дә кайнап чыгачак.

— Анысы — соңыннан, хуҗа кайткач.

Зөһрәгөл бары шунда гына кунагының шактый ук тузанга батуына игътибар итте. Озын юл узган күренә иде бу ир-ат. Үзен иркен һәм ышанычлы тотуына караганда, аның Нәзирне генә түгел, Зөһрәгөлне дә алдан ук яхшы белеп килүенә шикләнмәскә мөмкин.

— Юынып алырга теләсәгез, комган әйванда.

— Рәхмәт, бик урынлы булыр, колакларга шалкан чәчәрлек бугай инде.

Кунак аңа ияреп юынырга чыкканда:

— Уку өегез ничек соң, халыкка аң таратасызмы? — дип кызыксынды.

— Әлегә бик ук мактанырлык түгел. Ирем кышлак юлыннан кайтып кермәгәч, безгә аяк басарга кыенсынуларымы шунда, килүче-китүче сирәк. Хатын-кызлар гына.

— Бәлки халык аңа мохтаҗлык тоймыйдыр? Революция ясалды ич инде. Идарәгә гадел җитәкчеләр сайланды. Монда бака туе ясап ятудан ни файда хәзер?

— Чәйханәләрдә гәп куертулар бер дә тыйлыкмый ич, кыза гына бара.

— Чәйханәдәме? Анысы аңлашыла,— диде кунак көлемсерәп һәм иреннәрен ялап.— Анда кереп сусын кандыруга мин үзем дә каршы түгел.

Зөһрәгөл, сүз мондый борылыш алгач, табын хәстәрләвен тизләтергә мәҗбүр булды. Олы тәлинкәгә карбыз кисеп куйды, хәлвәсен, пәтерен, касәләрен дә кунакханәдәге эскәтер җәелгән тәбәнәк өстәл өстенә тезде. Уку өе эшенә бармак аша гына каравын сизгәч, юлаучыны сыйларга болай да ташып тормаган һәвәслеге, кичкә авышкан көндәй, сүрелде, билгеле. Хәтта орчык буйлы егеткәйнең үзен, сабантуйда бүләк алган кешедәй, бик иркен, ышанычлы тотуын да эрсезлеккә саный башлады. Ләкин аңа бу хакта күп уйланырга туры килмәде. Янә капка ачылган тавыш ишетелде һәм өйалдына инде аңа электән таныш яңа кунак килеп керде. «Бум»!

Төнлә бер генә мәртәбә күреп калган булса да, Зөһрәгөл аны шундук таныды. Чыршы кашлы кешенең киләсен Нәзире бер дә искәртмәгән иде. Димәк, аларның ниндидер эшләре пешереп җитмәгән. Бу кунакларны бер-берсе белән очраштырырга ярыймы икән? Хәер, ник чәнчелешеп бетмиләр шунда!..

— Әссәламе галәйкем!

— Вәгаләйкем әссәлам.

— Нәзир иптәш өйдәме?

— Хәзер кайтып җитәр ул. Узыгыз, менә монда ял итә торыгыз.

Зөһрәгөл «Бум»ны шулай ук уку өе ягына кертеп җибәрде. Аннары йокыдан уянган кызлары янына, балаханәгә менеп китте. Аларны киендерде, ишегалдына алып төшеп юындырды, ашарларына бирде. Үзе шул арада әле урам ягына, әле аскы каттагы юлаучылар утырган бүлмәләргә күз-колак салырга да онытмады. Чөнки ул хәзер Нәзиренең «Бум» һәм ят телдә сөйләшүче теге төнге кунак белән ниләр серләшүен исенә төшерми булдыра алмады. Көтеп-көтеп тә бүген Фарукҗаннан бер төрле хәбәр дә килмәү шулай ук аның зарыккан йөрәген талады. Язган хатында үзләренә бүтән аяк басмаска кушса да, кичә көне буе күңеле алгысынды. Чөнки Фарукҗан аерылышканда үзе: «Мин әле сезгә кагылырмын!» — дигән иде түгелмени? Хатын-кызның гади әдәп саклаудан, тыйнаклыктан һәм назланудан гына да, «бүтән килеп йөрмә», дип риялануы ихтималлыгын нигә башына китермәсен икән ул? Әгәр бигрәк тә, «бу якларга юл тотуыма син генә сәбәпче булдың», дигән сүзләре чын булса...

Зөһрәгөл фикеренчә, Фарукҗан аңа нинди дә булса хәбәр бирми калырга тиеш түгел иде. Килә алмаса, һич югы кош теле кадәр берәр язу-фәлән җибәртеп. Әмма көн узды, төн узды, кышкы кояштай тансык егетнең үзе түгел, шәүләсе дә күренмәде. Әллә хатны аңа тапшырмадылар микән? Эш белән Бохарадан берәр якка китеп баруы да ихтимал ич аның. Ләкин Зөһрәгөл кисәтүен тыңлап, моннан бөтенләй кузгалуы, ай-һай... Таш ярырлык тәвәккәл, үҗәт егет ич ул, бар-

мак янауга тугарылып бетә торган мәхлук түгел. Күңеле төшкән кешесеннән генә өметен өзмәсә...

Зөһрәгөлне иң куркытканы да нәкъ менә шул уй булды. Ул әле йөзгә-йөз килгәндә элекке кайнарлыгы белән сөйләшсә дә, соңыннан аек акылга буйсынып... Әйе, әйе, аның барын да бизмәнләп карамавы, чыннан да, мөмкин түгелдер инде.

Зөһрәгөл баскычтан төшкәндә үк аста кемнәрдер мыдыр-мыдыр сөйләшкәнне ишетте һәм башта, Нәзир кайткан икән ләбаса, дип уйлады. Әмма капка тавышы килмәгәнлеген хәтерләгәч...

Ул игътибар белән колак салып, сөйләшү яңгыраган уку өе бүлмәсенә, тычкан сагалаган мәчедәй, шыпырт кына якынлашты һәм әле бая гына икесе ике бүлмәдә калган кунакларның серләре килүен төшенде.

— ...Шундый уңайлы аулак урында кире беткән бәндәне кулдан ычкындыруыгыз башка сыймый,— дип өзгәләнә иде хәрби.— Шундый урында...

— Җыясы ризыгы бетмәгәндер инде аның,— дип акланды «Бум».— Аннары, күккә корым яккандай, караңгы иде.

— Юлыгызга фонарьлар элеп куярга онытканбыз шул, кичерегез. Мәми авызлар!

«Бум» исә юмалау ягын карады.

— Белеп торам,— диде ул.— Фарукҗаныгыз иптәшенә ярдәм итәргә, теге этрәк әләм Иргәшнең якыннарын бәладән коткарырга ашкына. Минем кеше Байкучатов әшнәләре сайравына колак салып йөрде анда. Багбанга барсалар, өчесе бергә капкынга килеп кенә кабарлар, безнекеләр сагалап торачак.

— Теге әнчеген җыештырдыгызмы соң инде?

— Анысы шундый шома килеп чыкты, ха-ха-ха, әмир үзенең хәрәмен кайгырткан шикелле кайгыртачаклар чәчбине. Балҗаныгыз кочактан кочакка...

Зөһрәгөл шулчак капка шапылдавын ишетеп, ирексездән артка чигенде. Аллы-артлы асынып болдырга килеп кергән каенесе аны күреп алуга:

— Баедык, җиңги! — дип шәрран ярды. — Итебез дә, кавын-карбызларыбыз да мулдан бүген.

Ире исә беренче эш итеп:

— Килдеме кунак? — дип сорады.

— Инде күптән сезне көтеп утыра.

— Әйдә җәлт кенә чәеңне әзерлә. Аннары шартын китереп пылау пешерергә керешерсең.

Хуҗа тавышы яңгырауга, уку өендә серләшеп утыручылар дәррәү коридорга килеп чыктылар. «Бум» белән шактый тәкәллефсез, кояз хәрби белән исә үтә ягымлы күрешүенә караганда, Нәзир өчен, һичшиксез, кунакларның икенчесе абруйлырак иде. Ул аларны шунда ук аулаграк бүлмәгә алып кереп китте. Чәй пешеп җитүгә, чәйнекләрне дә үзе чыгып алды. Зөһрәгөл уенча, бу, әлбәттә, кунаклары белән бүтән кешене аралаштырырга теләмәве билгесе иде. Башка вакытта ирләр табынын әзерләү эшенә хатынын катнаштырасы килмәсә, энесен җигә торган иде. Тик бу юлы ул аның барлыгын да исеннән чыгарды бугай.

Зөһрәгөл бу кунакларның юньлегә йөрмәүләрен гапләренә колак салу белән чамалады. Хәзер инде ул, аларның кара ниятләрен мөмкин кадәр тулырак ачыкларга теләп, кунак бүлмәсе тирәсеннән ерак китмәскә тырышты. Тиз-тиз генә пылаулык ит турагач, казан асуны каенесенә тапшырды да, иренең уяулыгы бераз йомшаруга, яңадан серле ишек төбенә якынлашты.

— ...Блеккер әфәнде ашыгырга куша, — дип сөйли иде Нәзире. — Түшәмнән алынган хәбәрләр белән генә ызгыштырып булмый, арада

чын гауга куптарырга, тимерне кызуында сугарга кирәк, ди. Аманулла хан БХСР хөкүмәтенә уңай җавап бирергә өлгергәнче.

— Габделшөкерхан нәрсә белән сәүдә итә әле? — дип сорады көяз хәрби.

— Кызыл мал сата, — дип телгә килде «Бум».

— Соң, җилкә кашып азапланасы юк, кызыл малга кызыл әтәч җибәрү бигрәк килешәчәк инде, — дип кеткелдәде хәрби. — Базарда аның үз кешеләре куна калмыйдыр ич?

— Калмаска тиеш, — диде Нәзир.

— Алайса бүгенге төннән дә кичектерергә ярамас.

Тыштан килеп кергән каенесенең «җиңги!» дип сөрән салуы, аннан да бигрәк җиңгәсен кунакханә ишеге катында шикле хәлдә терәлеп торуын абайлавы Зөһрәгөлне ирексездән иренә эндәшергә мәҗбүр итте.

— Атасы, атасы!

Елдам гына коридорга килеп чыккан Нәзир:

— Нәрсә? — дип каш җыерды.

— Мендәр тышларын салдырып алыйм, дигән идем, юасы бар.

— Соңыннан да өлгерерсең. Син нәрсә, монда кунаклар утыруын оныттыңмыни? Балаханәдәге кызларың нишли анда? Дөбер-шатыр киләләр, берәр нәрсәне ваттылармы әллә? Бар, шуларга күз-колак бул әле син.

Өске катта тавыш-тын ишетелмәсә дә, ире боерыгына буйсынган кыяфәттә Зөһрәгөл коридор буйлап эшлекле генә атлап китте. Хәзер инде каенесе шөбһәләнсә дә, абыйсына аны әләкли алмаячак иде.

— Җиңги дим, пылауга ничә баш суган әрчим соң? — диде әле һаман җавап ишетмәгән үсмер.

— Беләсең ич: гадәттәгечә, унны.

Ул җилле генә балаханәгә менде һәм курчак уйнап мәш килгән кызларына бер генә күз сирпеде дә әйванга чыгып утырды. Нәрсә җитми икән бу адәм балаларына? Әле үтерү, әле яндыру — уйларында ник бер изгелек ятсын. Юк, аларның агулы елан шикелле зәһәр чәчүләрен болай битараф күзәтеп тору ярамый. Гаепсез җаннарга, бигрәк тә саф күңеленә беренче якты очкыннар салган Фарукҗанга бу зәхмәтләр чын мәгънәсендә кыргый ау оештырганда.

Зөһрәгөл токмач шикелле вак-вак итеп кишер тураганда да, ят кара бөртекләрне чүпли-чүпли дөге юганда да һаман бер үк уйлар белән әвәрә булды. Ул әнә шулай ишегалдында, казан тирәсендә бөтерелгәндә «Бум»ны озата чыккан иренең тавышын ишетте.

— Ходай ярдәмчегез, фәрештәләр юлдашыгыз булсын! — дип теләк тели иде Нәзир.

— Мәйле, шулай булсын. Пылауның гына пешеп җитмәве үкенеч, — дип җавап бирде аңа «Бум».

— Язган ризык теш сындырып керә, диләр. Әле сыйланасыларыгыз алда, бурычны үтәгәч, иркенләбрәк сугылырсыз.

— Хуп мәйле, ходай язган булса, озак көттермәмен кү.

Зөһрәгөл сулыш алырга да базмый аларга колак салып торды. Ниһаять, мәкерле «Бум» үз юлына китеп барды, Нәзире исә ян ишекне каерып ачып:

— Ничек анда синең, өлгерәме инде пылавың? — дип кычкырды.

— Хәзер, суы гына очып бетсен инде.

— Утын өстә, көне буе көтеп утырырга вакыт юк!

Зөһрәгөл учакка яңа ботак-агач өстәде һәм пылавын болгата башлады. Үзе һаман Фарукҗанны уйлап кыйналды. Бу зобаныйларда иман да, рәхим-шәфкать тә юк, аларга кеше ни дә, чыпчык баласы ни — җан кыйганда куллары калтырамаячак.

Төрле уйлардан тәмам башы каткан Зөһрәгөл нишләвенә хисап бирмәслек хәлдә пылавын пешереп җиткезде һәм аны бизәкле зур

тәлинкәгә салып, үзен ишек төбендә каршы алган иренә китереп тоттырды. Аннары балаханәдәге сәкегә менеп кунаклады да, кыйнап ташланган кешедәй, ихтыярсыз һәм алҗыган кыяфәттә бер ноктага төбәлеп оеды. Кызлары аңа килеп сарылып, «әни, әни», дип нидер сөйләнде, нидер сорады — ул аларны бар дип тә белми, өнсез утыруын дәвам итте. Бары тик әлеге көяз хәрби тамак чылатудан һәм майлы пылау белән сыйланудан соң хәйран кәефле хәлдә шау-гөр килеп әйванда саубуллашканда гына аңа җан кергән шикелле булды.

Кунагын озаткач ук ире дә юлга җыена башлады. Атын иярләп менеп атлангач, ул хатынына:

— Ревком әмере буенча кышлакка барасым бар, бүген кайтып җитә алмавым да ихтимал, — дип кисәтте.

Аның артыннан каенесе дә мәдрәсәгә киткәч, аскы кат бөтенләй бушап һәм тынып калды. Зөһрәгөл, кызларын кунак бүлмәсенә алып төшеп, сүзсез-нисез генә тамак ялгатты, аннары житез генә табынны җыеп, кашаякларны юып куйды. Кызганулы карашын балаларына йөгерткәндә ул инде кискен бер карарга килгән иде. Өстенә кешелек киемнәрен кигәч, Зөһрәгөл үзен, дөнья эшләренә ходайдан фәтва көтү урынсыз, дип дәртләндерде. Дөнья эшләре адәм балалары ихтыярында. Ул эшләр исә йә ак, йә кара гына булырга мөмкин. Соңгысына исә ул һич тә катнаша алмас иде. Кара пәрәнҗә бөркәнеп йөрсә дә...

Тәвәккәлләп Чекага килеп кергәч, Зөһрәгөл шактый кыю рәвештә Фарукҗанны сорады. Кизү торучы чекист:

— Байкучатов йомыш белән каладан чыгып китте, — дип җавап бирде. — Бәлки йозерегезне безгә дә әйтә алырсыз?

— Сезгә?

Зөһрәгөл, нишләргә белми аптырап, яшь кызыл гаскәригә күз йөгертте. Ул, әлбәттә, Фарукҗанны гел Чекада гына утырадыр дип исәп итмәгән, мәгәр бу юлы аны бик тә шушында очратырга өметләнгән иде. Ихтимал, ул үзенең нинди козгыннар оясында яшәвен, икейөзле иренең әшнәләре белән бергәләп нинди астыртын хыянәтләр әзерләвен йә шушы, йә бүтән бер чекистка ачып та биргән булыр иде. Әмма кизү торучы кызыл гаскәри ят хатын-кызның икеләнүен күреп:

— Алайса Юлтай иптәшкә керегез, — дип тәкъдим итте. Ул арада урыныннан сикереп торып, янәшә тезелеп киткән ишекләрнең берсен барып ачты да хәрбиләрчә катгый тоста: — Иптәш Симиниев, монда берәүне кабул итәргә кирәк иде, — дип мөрәҗәгать итте.

Ишектә Симиниев дигәннәре күренгәч, Зөһрәгөл аң-таң булып, баскан урынында тараташтай катып калды. Чөнки бу Чека хезмәткәре әле яңа гына үзләрендә Бохара революциясенә һәм аның сакчыларына каршы хәтәр планнар корып утырган көяз хәрби иде!

Зөһрәгөл артка таба чигенгәндә, ярый әле пәрәнҗә бөркәнгәнмен, дип кенә уйлый алды. Симиниев исә ягымлы елмаеп:

— Тыңлыйм сезне, кардәш. Кыенсынмагыз, йөрәклерәк булыгыз — дип аны дәртләндерергә тырышты.

Ул арада күрше бүлмәдән өлкәнрәк яшьтәге янә бер ир-ат килеп чыкты. Зөһрәгөл, әлбәттә, монысының Чека председателе икәнлеген башына да китермәде. Ул:

— Сез мине көтәсезме, иптәш? — дип эндәшкәч исә, кырт борылды да кире урамга атылды.

Чекистлар, бу пәрәнҗәле хатын-кызның тора салып табан ялтыратуын нәрсәгә юрарга да аптырап, бер-берсенә карашып алдылар да кире үз кабинетларына кереп киттеләр. Эминевнең нәкъ менә шул кирәкле мизгелдә генә болдырга чыгуы Зөһрәгөлне Юлтай Симиниев төпченүеннән һәм шуның нәтиҗәсендә ахыры озак көттермәячәк хәвефле хәлләрдән саклап калды. Чамадан тыш дулкынланган хатын,

әлбәттә, үзе моны белмәде. Чекадагы очрашу исә аның күңеленә яңа тәшвишләр, яңа шөбһәләр һәм борчулар гына өстәде. Фарукҗан өчен хәвефләнүе, тау башыннан һаман ишәебрәк һәм куәтләнебрәк төшеп килә торган ташкын шикелле, аның йөрәген тагын да ныграк кысылырга мәҗбүр итте.

## 27

Иптәшләре атларны урнаштырган арада Фарукҗан почтага кагылды. Бу юлы аңа таныклыгын күрсәтеп торырга туры килмәде — кичәге күрешүне онытмаган элемтә бүлеге башлыгы, эндәшкәнне дә көтмәстән, Чекага адресланган телеграмма һәм хатларны үзе китереп тоттырды.

— Вакытлы кердегез, әле адресатларга илтергә өлгермәгән идек, — диде ул.

Телеграммаларның берсе Байкучатовны аеруча дулкынландырды һәм шатландырды. Дөрес, аның эзләнүләренә ни җавап бирми, ни ачыклык кертми иде ул. Телеграмма бары сорау рәвешендә генә иде. Шулай да Фарукҗан аны кат-кат укыды, бугазына кайнар төер тыгылып, күзе дымлана башлагач, күңеле нечкәрүен сиздермәс өчен, күпмедер вакыт тәрәзәдән урамга карап торды.

«Бохара Чекасына. Ашыгыч.

Икенче полк кызыл гаскәриләре үзләре аеруча яхшы белгән һәм яраткан Совет эшлеклесе — комиссар Шиһабетдинов үлеменә чын күңелдән кайгыралар. Һәлакәт сәбәбен тиз арада хәбәр итүегезне үтенәләр.

Полк командиры Мансуров, хәрби комиссар Әбүшәяхмәтов.

Җәркәнд, егерме икенче октябрь».

Димәк, бу фаҗигане шыпырт кына йомып калдырырга мөмкин булмаячак. Тулаем бер полк хыянәтнең фаш ителүен көтә, дошманнардан үч алырга ашкына. Хәзер менә кемнәргә дә таяна алачак икән Байкучатов!

Бөтен рәсми хатлар гадәттә барыбер аның кулыннан үткәнлектән, Фарукҗан Чекага җибәрелгән конвертларны почтада ук ачып карарга булды. Аларның берсе шулай ук игътибарны тартырлык иде.

«Хөрмәтле Чека юлбашчылары!

Әмир тарафдарлары Бохара халкы арасында астыртын гына коткы таратуын шушы көнгәчә дәвам итә. Алар егетләребезне басмачыларга кушылырга өнди, яшертен рәвештә корал туплый, Совет хакимиятенә каршы казына. Арада аеруча зәһәр икейөзлеләрнең берсе — әфган сәүдәгәре Габделшөкерхан. Чынлыкта ул күз буяр өчен генә сату итә. Асыл максаты, барча тырышлыгы исә тәмам үзгә — дошманнарыбызны берләштерү, көчәйтү. Мондый нәгъләтләрне тиз көннәрдә җөдә кылмасак, бу дөньяны үзгәртергә тырышкан арада дөнья үзе безне бөгеп куяр. Яңадан-яңа фаҗигаларга тарымас өчен, уяулык, тагын бер мәртәбә уяулык хаҗәт. Бигрәк тә Чекага!

Хәтәр заманда яшәгәнлектән, исемнәребезне теркәмибез. Химаягызга мохтаҗ бер төркем Яшь бохаралылар.

Егерме беренче октябрь».

Байкучатов, тиз генә киңәшеп алырга теләп, Чека председателенә шалтыратты, әмма Галимҗан Әминев телефоны җавап бирмәде. Кизү торучы чекист та аңа кирәкле кешесен табуда ярдәм итә алмады. Сүз ахырында ул бары:

— Иптәш Байкучатов, монда сезне әле генә бер хатын-кыз эзләп килгән иде, — дип хәбәр бирде.

— Хатын-кыз?

— Әйе.

— Кем иде соң ул?

— Белмим. Ничек кинәт килеп кергән булса, сез юклыкны ише-

түгә, шулай ук капыл гына үкчәсен күтәрде. Исемен сорап калырга да өлгермәдек.

— Нindирәк кеше иде ул?

— Яшь, сылу иде, ахры. Хәер, пәрәнҗәсен салмагач...

— Йомышын әйттеме соң?

— Юк шул.

Фарукҗан уенча, аны атап эзли килерлек хатын-кыз Бохарада берәү генә иде. Бары Зөһрәгөл генә! Иске танышын ут капкандай йөгертерлек нәрсә булды икән? Юк-бардан гына тора салып купмаска тиеш ул. Димәк, йөрәгенә төшкәннәр. Фарукҗанны ут йоттырырга дигәндә сәбәбе дә табылып тора тагын: әле Балҗаны, әле... Хәер, үзен эзләүченең Зөһрәгөл икәнлеген тәгаен белми белүен. Моны хәзер үк ачыклый да алмый. Бик тели, әмма кире борылырга, яңадан Бохарага элдертергә мөмкинлеге дә, хакы да юк. Амантай белән Ир-гәш өметен дә акларга кирәк ләбаса!

Байкучатов, күңеленә таракан кергән хәлдә, госпиталь тарафына атлады һәм монда иптәшләре телгә алган Мартьяновны эзләп тапты. Аңардан дәртсез, рухсыз гына рәвештә кичәге хәлләр, Балҗанның мондагы танышлары турында сораша башлады.

— Дөрес, Каганны мин үзем дә белеп бетермим әле, — диде ул. — Менә Верныйның кешеләрен генә түгел, һәр ташын, һәр куа-гын таныйм!

— Шул исәптән, комиссар Шиһабетдиновны да күргәләгән иде-гезме? — дип сорады Байкучатов.

— Һәй, мин аның комиссар чагын гына түгел, бүтәнен дә хәтерлим әле. Атаклы «Гасыр» кинематографына кем генә килми иде! Менә шунда бер заман кассир булып эшләде абзагыз.

— Шиһабетдинов хатын-кыз белән чуалырга һәвәс идеме?

— Уен-көлке ясарга иренми, әмма үтә вөҗданлы, итәгатьле иде. Буйга-сынга килешле, төскә-биткә дә шәп, кызларны үзенә тарта торган магниты бар иде. Верныйда апалы-сеңелле Фира белән Лида Баһауга икесе берьюлы гашыйк булды ич, кәләшсез кала яздым, билләһи. Лидам, миңа кияүгә чыккач та, аны гел искә төшергәли иде. Монда бер-ике тапкыр йомыш белән янына да барып килде әле. Медик ул, госпитальгә дарулар кайтартуын үтенде.

— Соңгы тапкыр кайчан күрештеләр?

— Унтугызында. Мин дә барган идем, озаклап гәп сатарга вакыты гына булмады Баһауның.

— Кайда очраштыгыз?

— Әмирнең җәйге сарае Ситтәрәи Маһи-һусада.

## 28

Вокзалда поезд көтүчеләр торган саен арта бара иде. Бохара тормышындагы кискен үзгәрешләр монда бигрәк тә күзгә ташлана: каршындагы мәйданда да, перронда да бәкләр-морзалар, әмир түрәләре урынын хәзер яңа хәрәкәткә килгән гади халык алган. Сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр белән бергә кызыл гаскәриләр дә төркем-төркем шушында әйләнеп тулгана. Кышлаклардан сәфәр чыккан игенчеләр, бакчачылар мылтыклы солдатны ятсынып читтән генә күзәтсә, кала халкы инде аларга күнеккән, әллә ни игътибар итми, бала-чаганың гына кылыч, наган кебек кораллар таккан кешеләр тирәсендә бөтереләү һәвәслеге әле һаман кимемәгән иде.

Байкучатов иптәшләрен мәйданның вокзал янындагы бер почмагыннан эзләп тапты. Иргәш аңа кычкырып сүз кушарга ирек бирмәде, бармагын иреннәренә аркылы куеп, шыпырт, дип ишарә ясады.

— Фарукҗан уртак, — диде ул пышылдап, — багана янындагыларны күрәсезме? Кичә Газәли мәхәлләсендә күңел ачучылар. Чәй-

ханәдәге купшы чалма белән атлас чапан. Икесе дә чыкылдап торган контр!

— Теге чикмәнлене әйтәсеңме? Очлы иякле, озынча йөзлене?

— Әйе инде. Маңгаеның уң ягында яра эзе дә бар.

— Таныдым, дөрес чамалыйсың. Атлас чапан дигәнең кабартма яңаклысыдыр инде?

— Тугры. Ул безгә арка биреп баскан адәм белән гәп сата, ахры.

— Анысына да юньләбрәк күз салыйм әле, сез шушында гына утырып торыгыз.

Фарукҗан, читтән урабрак, әлеге яралы маңгай белән кабартма яңак тарафына юнәлде. Әмма бу юлы үткенлек күрсәтәсе урында ул үзе янды: сердәшләрнең өченсесе — Чеканың агентура бүлеге башлыгы Латыйфхан Нурморатов, кисәк борылып, шундук хезмәттәшен абайлап алды да, ялгыз вакыт уздырып ялыккан һәм каршысында басып торган юлаучыларга бөтенләй мөнәсәбәте булмаган кешедәй, аңа:

— Ә, Фарукҗан үкә[1], яхшысызмы, Ташкентка китеп барасызмы? — дип эндәште.

Кайдан белә ул Байкучатовның шунда юлга чыгарга тиешлеген? Килеп каптыңмы, егеткәем? Фарукҗанның чирләмәвен, кушылган җиргә китеп бармый, Каган тирәсендә генә болгануын фаш итсә, чыгачак икән әле монда гауғалар!

— Үзегез исән-саумы, Латыйфхан абый? Кәефләрегез яхшымы? Әңгәмәгезне бүлмәдемме?

Кабартма яңак белән яралы маңгайның, үзе якынлашуга, Нурморатов тирәсеннән елдам гына койрык болгауларын күреп торды Фарукҗан. Хезмәттәше исә бигрәк тә сынатырга уйламый иде.

— Хуҗа Насретдин бер мәҗлескә баргач, үзалдына тып-тын утыра икән, — дип елмайды ул. — Берәүне дә тыңламый, берәүгә дә мөрәҗәгать итми. «Хуҗа, нигә болай өнсез калдың?» диләр икән. «Мин акыллы кешеләр белән генә гәпләшергә яратам. Шунлыктан эчемнән серләшәм әле», дигән имеш. Мин дә, күрәсең, шулай үз-үзем белән әңгәмә корырга һәвәс!

— Юлга җыендыгызмы, Латыйфхан абый?

— Юлга, юлга. Адәм баласына исән чакта тынгы бармыни? Менә сез әллә кайдагы Идел буеннан монда кадәр килеп җиткән ич әле. Баксагыз, туган-үскән илегездә дә яшь алыр идегез. Ике кулыгызга бер эш, гаделлек өчен көрәшергә бер мәйдан анда да табылган булыр иде. Шулай кү?

— Дөрес. Әгәр мине партия...

— Әйе, сез дә, Юлтай әкә дә безне кайгыртып килгәнсез, рәхмәт, — диде Нурморатов. — Бохара халкы моның кадерен белеп бетерми әле. Ул, тамагы ачмы-тукмы, өсте бөтенме-ялангачмы, һаман бер көе көндәм генә яши бирә, бәхет эзләп читкә чыгып китүне башына да кертә алмый. Шуңа күрә сезнең шикелле затларны ул аңламый, аларга хәтта шикләнебрәк тә карый. Һәркем, начармыяхшымы, үз илендә яшәргә, шунда үз тормышын үзе көйләргә тиеш, дип саный. Ничек уйлыйсыз: бу аның чикләнгәнлегеме, әллә...

Фарукҗан күңелендә Нурморатовка карата өнәмәү, яратмау хисе куера башлавын тойды. Үзен тыштан дустанә тотса да, нидер суктырып, тешләп сөйләшә бит ул. Я иптәшенең сүзен бүлә, я үзенекен әйтеп бетерми — һәр кыланмышында киная, икейөзлелек, мәкер. Тукта, дип шул ук вакыт сабырлыгын, салкын акылын тупларга тырышты Фарукҗан, аңа бәйләнергә хакың юк. Ул, билгеле, Бохара халкы дигән булып, «килмешәкләргә» карата үз фикерен белдерә. Рәхмәт әй-

---

1 Үкә — энекәш.

түе саташтырыр өчен генә, чынлыкта безне җене сөйми бугай. Ялгызы гына тарланса, ник шартламый абзыкай. Әгәр менә башкалар да шулайрак уйласа? Зөһрәгөл дә искәртте ләбаса. Димәк, кызма, чамасын тоеп сөйләшкән кешенең генә сүзе асыл!

— Белмим, — диде Байкучатов туры җавантан качып. — Бәлки Шиһабетдинов фаҗигасендә дә сез әйткән әнә шул «шикләнеп караучыларның» кулы уйныйдыр?

— Менә монысы — комнан аркан ишү инде. Комиссия ап-ачык кылып белдерде ләбаса: хәрби назыйр үзен-үзе аткан! Сез әле һаман шул тирәдә казынасызмыни?

Фарукҗан:

— Ю-у-ук, — диярга ашыкты. — Сез әйткәннәр күңелгә очкын салудан гына икеләнүем бу.

— Ә-ә.

Нурморатов тирә-якка карангалап алды да кинәт сүзен башкага борып җибәрде:

— Без менә үзебез күтәрә алмаслык әллә нинди зур йөкләргә килеп ябышабыз да иң кирәк гади эшләрне онытабыз. Ташкентка сәфәр чыкканда бераз тормыш ягын көйләүне дә кайгырттыгызмы соң?

— Нинди көйләүне?

— Чекист кеременә яшәү кыен лабаса, айлыгы ташка үлчим. Бохарада ризык ягы кыйммәтләнеп киткәч, бигрәк тә. Ташкентка бераз тансык мал алып барып авыш-тәвеш китәрсәгез, кесәгезне тишмәс иде.

— Нәрсә алып барырга мөмкин соң?

— Менә Хуҗа Насретдин, — дип көлеп җибәрде Нурморатов. — Шуны да белмисезмени?

— Мин сәүдәгәр түгел ич.

— Куегыз, яшәргә тырышмасагыз, дөнья бабаң өйрәтә ул. Безнең егетләр ерак сәфәргә буш кул чыгып китми. Йөзләп каракул сатсагыз, Русиядән килүчеләр шактый хак түли аңа. Латыйфхан әкәгезгә ышаныгыз, сезне коры нан — тәбикмәк белән ширчәйдән коткарачак ул алыш-биреш. Әгәр малны Оренбургка ук илтеп сатсагыз, тагы да уңачаксыз. Русиядә кыш җөдә суык, туны да, бүреге дә кирәк.

— Ул каракүлне башта үземә ничек булдырырга соң? Нинди акчага?

Нурморатов дустанә рухта елмайды:

— Кардәшебезне мохтаҗлыкка ташламабыз инде, сөйләшербез, берәрсе әҗәткә биреп торыр. Бәлки файдасын уртагыннан килешербез?

— Кызыктырдыгыз, Латыйфхан абый, — диде Фарукҗан. — Тәкъдимегездә мән бар, рәхмәт. Тик бу юлы барып чыкмас инде, сәфәрем ашыгыч. Өйрәнә торырга, сәүдә эшенең җаен караштырырга бик мөмкин, өйләнмәгән егеткә мәһәрлек мая да тупларга кирәк ич!

— Тугры. Ташкенттан әйләнеп кайткач, үзегез искә төшерерсез әле бүгенге гәпне. Булышырмын.

Нурморатов перрон ягына китеп күздән югалгач, Фарукҗан аның тәкъдимен төрле яктан бизмәнләп карады. Чын Бохара кешесе өчен алыш-биреш ясау, сәүдә итү чаялык, булдыклылык кына санала үзе. Ләкин моңа чекистны да тарту шәпме икән? Нинди максатны күздә тотып эшләнергә тиеш бу? Яхшылык теләпме, әллә бәйле хәлгә төшерергә тырышыпмы? Буярга омтылыпмы?

Нурморатов Ширбәдәндә үзен сәеррәк тотмаса — Шиһабетдинов һәлакәте хәлләрен куралэтә бутарга омтылмаса, Фарукҗан болай баш та ватмас иде. Билгеле, дусларча тәкъдим иткән очракта да сәүдәгә килешмәячәк ул, бу хакта уйлыйсы да юк. Тик моны нигә

хәзер үк шәрран яра белдерергә? Кем әйтмешли, телең биктә тотгыл — тешең сынмас! Тартып-сузып бүтәннәрне сайрат, бәлки шуңа серләре дә ачылып куяр.

Фарукҗан, Амантай белән Иргәш янына әйләнеп килгәч, яралы маңгайның кем белән гәп корып торуын аңлатты.

— Егетләр, без аларны киләчәктә дә күздән җуймаска тырышыйк. Шикле таныштар! Әмма үзебез күләгәдә калырга өйрәник. Берәүгә дә кая һәм нинди максат белән юл тотуыгызны ычкындырмагыз. Андый сорауларга җавап бирү — минем эш...

Поезд кузгалды һәм тиз арада Каган корылмалары артта калды. Тимер юл янәшәсеннән барган олау — тәгәрмәчләренә кадәр агач борыслардан кадаклап ясалган, шыгыр-шыгыр арлы-бирле янтаеп менә-менә таралып китәр сыман тоелган галәмәт зур арба да күздән югалгач, тирә-якта көмеш таңкә сипкән шикелле ялтырап яткан дала — тозлак кына каршыга йөгерә башлады. Баш очындагы күк чынчынлап иксез-чиксез иде. Ул зәңгәр кочагын киң ачып, бөтен офыкны иңләп алган. Аның иркен йөзендә ел буе дип әйтерлек болыт әсәре күренми, диләр. Караком белән Кызылком сахралары Зәрәфшән оазисына ике яктан ком давыллары җибәргәндә дә, тузан пәрдәсе аша күк зәңгәрлеге барыбер беленеп тора икән. Бүген исә ул аеруча аяз.

Фарукҗан күңеле дә шундый булсачы! Юк шул, эче тулы уй, бара торган юлын билгесезлек томаны каплаган. Аны Төркестанга ашкындырган өмет тә сүнде — Зөһрәгөл инде тормышын бүтән берәү белән бәйләгән булып чыкты. Язмышлар аерылуда Фарукҗанның үз гаебе дә барлыгы ачыклангач, йөрәге бигрәк тә сыкрап типте, әмма эш узган иде инде. Әгәр Зөһрәгөл, Балҗан шикелле, Балҗан шикелле... Юк, юк, — дип бу уйларын куды, — кирәкми, ул үзе барыбер, Амантай кебек, яшьлек мәхәббәтенә күпер сала алмаячак. Өйләнмәгән, әле юньләп кызлар да үпмәгән-кочмаган егет башы белән ике балалы хатынга багланыргамы? Нәселләрендә булмаганны! Хәер, Зөһрәгөл үзе дә, барын җуеп, аңа таянырга җыенмый ич. Гаиләсе бөтен, тормышы җитеш. Яшьлеген сагынуы, бәлки кайчандыр чыннан да үз итеп йөрүен онытмавы аркасында гына, Фарукҗанның иминлеген кайгырта торгандыр ул.

Байкучатов болай уйлавына бераздан үзе дә гаҗәпләнде: күр, ничек җиңел хәл итә егеткәем! Әйтерсең лә, Зөһрәгөлне бер дә яратмаган, яшьлек мавыгуы гына кичергән ул. Бәлки көтеп алмавы өчен әле һаман аңа үпкәсе язылып бетмидер? Гарьләнүе, ачуы бүтән хисләрен күмә, зиһенен томалый торгандыр? Әллә соң Чекадагы эше барлык көчен һәм сәләтен суырып, дөньяда мәхәббәт барлыгын да, адәм баласының таң атуын, арыктан сулар агуын, гөлләрнең чәчәккә бөреләнүен яки күбәләкләр очуын күзәтеп тә зәвыкланауын, кызык табуын оныттырамы? Җиһанны әнә шулай гел икегә — дусларга һәм дошманнарга, фикердәшләргә һәм бүтәнчә уйлаучыларга гына бүлеп карарга ярыймыни?! Байкучатов, уян, тирә-ягыңа киңрәк караш ташла!

Поезд исә вак-төяк разъездларны бар дип тә белми алга йөгерде дә йөгерде, тәгәрмәчләр көйгә салып, армый-талмый рельсларны санавын дәвам итте: дык-дык, дык-дык. Бертуктаусыз кабатланган әнә шул дөбердәү һәм вагонның уңга-сулга чайкалып тирбәлүе тәэсирендә Фарукҗан, үзе дә сизмәстән, калгып китте. Бераздан иптәшләрен дә йокы басты, — Амантай белән Иргәш шулай ук, тез башларын кочаклап һәм маңгайларын беләкләренә терәп, күзләрен йомдылар. Ихтимал, алар шулай өчесе тиң оеп байтак барыр, бәлки әле кирәкле станцияләрендә төшеп тә кала алмаслар иде — ниндидер бер сихри өн әле һаман башын тезенә куеп барган Фарукҗанның колагына килеп эленде дә аны кинәт күзләрен ачарга мәҗбүр итте. Йом-

шак, ягымлы, йөрәк өзгеч таныш авазлары белән күңелне назлый, аңның әллә кайсы күзәнәкләренә язгы ташкын кебек ургылып кереп, хәтернең тирән катламнарын актарып ташлый торган бу көч тальян гармун моңы, туган як җыры иде. Байкучатов, иңгә-иң терәлеп утырган Амантайны терсәге белән төртеп уятты да, йокыдан айнып җитмәгән иптәшенең сораулы карашын күреп:

— Ишетәсеңме? — дип сорады.

Аларның поезды кечерәк бер станциянең запас юлында туктап тора, янәшәдән исә Фарукҗаннарны куып җиткән пассажир поезды узып бара иде. Шуның тәрәзәләреннән, ахры, тәгәрмәч дыкылдаулары күмеп, әлеге моң тарала. Ул көчәя-көчәя якынлашты да, иң куе, иң ачык ноктасына менеп җиткәннән соң, ераклаша, тоныклана башлады. Байкучатов җырның бөтен сүзләрен ишетеп бетермәде, хәер, моның инде хәзер әһәмияте дә юк иде, чөнки ул ишеткән кадәресеннән үк нинди җыр җырлануын да, аны кемнәр сузуын да аңлап алды: бу, әлбәттә, әмир ныгытмасын штурмлауда катнашкан Татар бригадасының Фирганәгә китеп баручы соңгы рота, соңгы взводлары иде. Нинди оешкан, нинди күркәм рәвештә! Фарукҗан әле һаман колагында яңгыраган, аны сокландырган һәм рухландырган җырны тагын да бер мәртәбә эченнән кабатлады:

Сандугачлар да сайрамый
Сез булмаган җирләрдә!

Күзләрен шар ачкан Иргәш гаҗәпләнеп:

— Нугайча ашулә әйтәделәр кү! — дип тел шартлатты.

Фарукҗан аның сүзләрен, гүя, ишетмәгәндәй:

— Их, егетләр, былбыл сайрауларын бер тыңларга да зар ич мин монда! — дип уфтанып куйды. — Безнең илкәйне барып күрсәгез икән сез: бөтен тарафлары зөбәрҗәттәй ямь-яшел! Тау асларыннан ширбәттән дә тәмлерәк, күз яшеннән дә сафрак, салкын сулы чишмәләр тибеп чыга: аның хуш исле печәне, билдән ашкан болыннары, аның колач җитмәс агачлар үскән урманнары, аның Ситтәрәи Мәһиһуса сараедай зур, хәтта аннан да мәһабәтрәк кораблар йөзеп йөри торган киң вә тирән сулы дәрьялары, сихерле көзге шикелле ялтырап яткан күлләре, бар терекләкне иркәләп лепер-лепер яуган шифалы җылы яңгырлары, таң алдыннан әрәмәлеккә куныП, тирә-якны моңга коендыра, кешенең бөтен җанын эретә торган сайрар кошлары һушыңны алачак! Күз күреме киңлектә җәелеп яткан алтын сары иген кырлары, каймак кебек куе ак томаннары, туйга бизәнгән кәләштәй, барлык төсләре белән балкып офыктан күтәрелгән, бәйрәмчә көлеп торган салават күпере дә бар ич әле аның... Ком сахрасында ыгы-зыгылар басылгач, берзаман мин дә илкәемә кайтып китәрмен, сезне кунакка чакырырмын әле.

Байкучатовның болай ачылып утыруына гаҗәпләнгән һәм сүзләренә ышаныргамы, юкмы икән, дип икеләнгән Амантай белән Иргәш, соңгы вәгъдәне ишеткәч, җанланып киттеләр:

— Кызык, тәкъдиребезгә шундый нәрсәләр дә язылганмы икән?

— Тәкъдирне без хәзер үзебез язачакбыз, — диде Байкучатов ышанычлы тоста. — Юкка гына бәк-морзаларга каршы көрәшмибез ич!

## 29

Зыятдин гарнизоны фәрманчысы аларны кат-кат кисәтеп:

— Инде кич җитеп килә, бәлки юлга караңгы төшкәндә чыкмассыз? — диде. — Мин сезгә ун кеше генә бирә алам. Станция тирә-

ягын саклау да безнең өстә, көчләребез исәпле.

— Басмачылар шулай нык азынамыни?

— Төнлә хәтәррәк, тимер юлны сүтәргә омтылалар. Сез барасы Багбан кышлагына да ышаныч юк. Сәетморат бәк башкисәрләре анда гел кагылгалап торганлыктан, ярлы агай-эне дә, безгә булышасы урында, үзләре яклау көтеп яши.

— Менә шуның өчен анда ашыгыч баруыбыз кирәк тә инде, — диде Фарукҗан.

Байкучатовның вакытлыча оешкан сугышчан төркеме Зыятдиннан үзбәк чапаны киеп, башларына чалма чалгач, җирле гади халыктан аерылмас кыяфәткә керде. Аркаларына аскан мылтык, бер запас атка урнаштырылган пулемет белән патрон тутырылган тартма буенча исә аларның кемлеген чамалау мөмкин түгел, димәк, басмачыларның күз-колагы аларны вакытыннан элек ачыклый алмаска тиеш иде. Гарнизон фәрманчысы, мыекларын бөтерә-бөтерә, бәрелешләрдә чыныккан солдатларны гына бирүен искәртеп:

— Мин сезгә үзбәк, казакъ егетләрен махсус сайлап алып куштым, — диде. — Унбашы мәргәннәрнең дә сирәк очрый торганы. Үткен, ышанычлы.

— Рахманколны куып җитә алмавыбыз гына кызганыч. Димәк, ул кире Бохарага китте?

— Әйе. Ревкомнан телеграмма суктылар. Алар әмере буенча, агитатор иптәшләре белән ике сәгать элек кенә станциядән кузгалдылар. Үзем озатып калдым. Бохара юлы өстендәге кышлакларда җыелышлар уздырып, егетләрне Кызыл Гаскәргә керергә өндәячәкләр икән. Комиссар Шиһабетдинов эшен дәвам итмәкчеләр.

— Нәрсә, Рахманкол шулай шапырындымыни? — Фарукҗан үзенең кирәкмәс сүз ычкындыруын чамалап, өстәп куйды: —— Кыен эш ич ул, алдан җиңел-җилпе лаф орып оятка калуың да мөмкин.

— Хәрби комиссардан тәҗрибә җыеп калгандыр инде, озатып йөрде, ибен-җебен беләдер.

Зәрәфшәнне алар гарнизон егетләре белгән бер аулак сайлыктан чишенеп кичте. Әмма елга монда да шактый ук тирән, агым көчле, суы салкын иде. Йөзә белмәгәнлектән, гаскәриләрнең күбесе дәрьяга, кием-салым, кораллар һәм иярләр төягән кечкенә салга ике яктан ябышып кына керделәр. Фарукҗан аларны ашыктырып торды. Ком диңгезендә генә коенып үскән, киң елгадан шулай ук өреккән атларны җитәкләп йөзеп чыгарга булышты. Аннары тиз генә киенеп, аркаларына кадәр юешләнгән бахбайларына менеп атландылар да инде игене урып-җыелган кырлар буйлап көньяк-көнбатышка чаптылар. Кыр үрдәкләре, челән, ләкләкләр бакылдашып-кыңгылдашып яткан Зәрәфшән дәрьясы бик тиз артта калды. Бу тирәләр инде таныш булганлыктан, туган җирен тансыклаган Иргәш Фарукҗан янәшәсендә — җайдаклар төркеменең башында юл күрсәтеп бара иде. Хәзер атасын, энесен һәм җәберләнгән бүтән авылдашларын якларлык көч барлыгын тою аны алга ашкындыра, бу минутларда ул үзен шушы якларның җәйрәнедәй җитез, бөркетедәй үткен күзле, пәһлеванныдай гайрәтле хис итә иде.

Монда арыклар әле ботакларын аска игән еламсар таллар яки куппы тут агачлары астыннан уза, әле кояш нурларына коенган зөбәрҗәт кырларга килеп чыга. Кайбер басуларда зәңгәр, сары, кызыл күлмәкле диһканнар мамык җыя, нидер кәтмәнли. Якты нурлар арык буйларында үскән куе ябалдашлар аша үтеп, юлларга яфрак күләгәсе, бизәкләр шәүләсен төшерә. Кышлаклар арасында тозлы туфрак киңлекләре дә ялтырап ята.

Алар кышлакка кояш баер алдыннан килеп җитте. Иргәш, кеше күзенә мөмкин кадәр чалынмаска тырышып, ялгызы гына хәлне ачыкларга алынды — ышанычлы авылдашларының берәрсен күреп,

Багбанда басмачылар барлыгын-юклыгын да, бай җәза биргән кешеләрнең кая ябылуын да тиз арада белешеп, зират артында яшеренеп торган иптәшләре янына әйләнеп кайтты. Шуннан соң кораллы җайдаклар төркеме туп-туры мәчет янындагы мәйданга барып керде. Намазга җыелган ир-ат әле таралмаган, башкалар белән бергә Нурморат бай да үтә тикъвә кыяфәттә хәзрәтнең вәгазен тыңлап утыра иде.

Фарукҗан авылның хәвефлерәк Каратау очына сак куйгач һәм кызыл гаскәриләренең янә берсен сөрән салырга — кышлак халкын мәчет янына җыелышка өндәргә җибәргәч, калган иптәшләренә аттан төшәргә, мәйдан тирәли кырыйга сибелеп басарга боерды.

Башта мәчет янына бала-чага, аннары егет-җилән аяк басты. Гадәттән тыш ыгы-зыгы тавышлары намазлык өстендәгеләрне дә тиздән урамга чыгарга мәҗбүр итте. Кораллы ят ирләрне күргәч, барысы да сагайды. Хәзрәт тә, аңа ияргән күпшы чапанлы байлар да ни әйтергә аптырап, туктап калды. Үзе әле һаман аттан төшмәгән Фарукҗан:

— Хөрмәтле иптәшләр, тынычланыгыз,— дип мөрәҗәгать итте.— Без — Бохара революциясе сагына баскан кызыл гаскәриләр. Арабыздагы Иргәшне таныйсыздыр. Без аның шикелле ярлы-ябагайны үзе эшләп көн күрүчеләрне яклар өчен кулга корал алып, Бохара мәмләкәте хезмәт ияләренең канын кандала кебек суырып, иреген буып яшәгән залим әмирне, аның үзе кебек шәфкатьсез, комсыз түрәкарасын тар-мар итеп, гадел яңа тормыш корырга керешүчеләр...

Күпләр кызыксынып колакларын торгызды, байлар төркеменең исә йөзе караңгыланды, алар ничек тә мәйдан уртасыннан читкәрәк шылу ягын карый башладылар. Иргәш ымлап күрсәткән кешене күздән җуймаган Фарукҗан тезгенне шунда ук җыя төште:

— Иптәшләр, әмирне, аның күп кенә яраннарын илдән сөрдек, әмма бөтенесен дә түгел. Сәетморат бәк, Нурморат бай шикелле, якында гына яшеренеп ятучы яки әле һаман зәһәрен таратучы кайберләре гаделлек урнаштыруга аяк терәп каршылык күрсәтә, баш күтәрүчеләрне куркытып-өркетеп, асып-кисеп, күпчелекне элеккечә үк буйсындырып тотарга, аларны әүвәлгечә үк талап, сыгып яшәргә маташа. Ләкин дошманнар шуны яхшы белеп торсын: моннан соң андый этлекләргә, вәхшәткә юл куелмаячак. Җәбер, золым чәчүчеләрнең һәммәсе дә тиздән җинаяте өчен җәзасын татыячак. Әйе, тулысынча татыячак. Ишетәсезме, Нурморат бай?

Ике ягына ике кызыл гаскәри килеп баскач, болай да шомлана башлаган бай абзый бу сорауга җавабын ничек тә сузарга тырышты.

— Нурморат бай, ишетәсезме, килегез әле мондарак!

Мәйдандагы халык икегә аерылып юл ачты. Авылдашларының күпчелеге теләктәшлек күрсәтмәгән, киресенчә, астыртын дошманлык белән күзәткән, хәтта, якыннары да аны якларга базмаган, күзләрен яшергән хәлдә, Нурморат бай Фарукҗан басып торган түргә атлады. Әлеге ике кызыл гаскәринең күкрәкләре белән диярлек арттан этеп барулары аркасында, ирексездән!

— Халык хакимиятенә сез ни өчен каршы?

Мәйдан кырыендагы кызыл гаскәрләрдән күзен алмаган бай:

— Мин каршы имәсмен, — диде.

— Алайса яңа сайланган аксакаллар шурасы ихтыярын ник санга сукмыйсыз?

— Нинди шура? Нинди ихтыяр? Һич ишеткән нәмәләрем имәс, белмәймен.

— Ишетмисез, күрмисез, белмисез, ә үзегез шул аксакалларны һуштан язганчы кыйнатасыз, зинданга ябасыз, ә?

— Андый эшләргә аслан катнашым юк кү, нахак бу!

— Алайса аталы-уллы Мирәхмәтевләрне кем җәберләде?

— Сәетморат бәк ләшкәре...

— Мирәхмәтевләр үстергән мамыкны да ишегалларыннан Сәетморат бәк ләшкәре тәяп чыктымы?

— Бирәсе бурычлары бар иде кү. Шуны бәхилләтү хисабына...

Фарукҗан, байның үз гөнаһын танудан әнә шулай баш тартачагын алдан ук белгәнгә, тынып калган халыкка мөрәҗәгать итте:

— Җәмәгать, сезнең кышлакта әҗәтне ун мәртәбә, хәтта, аннан да арттырып түлиләрмени? Шулай итү гадел саналамыни? — диде.

Мәйдандагылар эндәшмәде. Бу тынлыктан рухланып киткән Нурморат бай янә телгә килеп:

— Мин ун бәһа түләтмәдем, мамык сату хисабына бер капчык дөге, бер сарык та бирергә килештем, — диде. — Сүземне хәзрәт тә раслый ала.

— Әйе, әйе, җәмәгать, алыш-биреш шәригатьчә ясалды, — дип җөпләде мулла абзый.

Шул чак кызыл гаскәриләр мәйданга ялангач аркалары күгәргән, кара янып чыккан ике карт белән бер егетне алып килделәр. Әле генә караңгы баздан ирекккә чыгарылган тоткыннарның йөзләре агарынып, сулып киткән иде. Кыяфәте үзенә тартым карт белән егетне Иргәш барып кочаклап алгач, Фарукҗан аларның кемлеген чамалап, шулай ук атыннан төште, тоткыннарның һәммәсе белән кул биреп күреште. Аннары калын гәүдәле, чиртсәң, кан тамарга торган кызыл чырайлы хәзрәткә төбәлеп, мыскыллы рәвештә:

— Бу кешеләрне зинданга ташлау да шәригать кушканча эшләндеме? Гөнаһларын фаш кылсагызчы! — дип мөрәҗәгать итте.

Мулла да, Нурморат бай да дәшми калуны яхшырак санадылар. Фарукҗан, атына менеп атланганнан соң, мәйданга күз йөртеп:

— Җәмәгать, бу бичараларның гаебе бармы? Аларны җәзаларга кем фәтва бирде? — дип сорады.

Мәйдан телгә килергә кыймагач, Иргәш уртага чыгып:

— Уртаклар, мин сезнең Сәетморат бәктән, аның башкисәрләре җәбереннән куркып кына дәшмәвегезне беләм, — диде. — Курыкмагыз. Бәкнең көннәре санаулы. Әгәр без бердәм каршы чыксак, арагыздан намуслырак, гайрәтлерәк егетләр Кызыл Гаскәр сафына басса, бәк чирүе тагын да тизрәк тар-мар кылыныр, гаделсезлекләргә тәмам чик куелыр. Әйтегез әле, бу тоткыннар гаепleme? Әллә...

Шул чак яңа гына ирекккә чыккан картларның берсе:

— Минем һичбер гөнаһым юк! — дип аваз бирде. — Уртагыннан үстергән мамыктан үз өлешемне югарырак хак түләүчегә үзем сатарга, бурычны аннары кайтарырга теләгән идем, бай әйткән бәягә күнмәгән идем. Нурморат мине шуның өчен нахак гаепләп, зинданга яптырды. Мондый золымы өчен ул ходай алдында кыямәт көнне җавап бирер әле. Каһәр төшсен аңа!

Хәзрәт картны туктатырга омтылып:

— Кешегә яманлык теләүне китап мактамый, — диде.

Өлкән Мирәхмәтев муллага нәфрәт белән:

— Алайса нигә үзегез яманлык телисез? — дип кычкырды. — Безнең мамыкны, «Нурморат байга хәләл», дип сез фәтва бирдегез, шуның өчен ул мәлгуньнән бүләккә чапан алдыгыз. Шул гаделсезлек аркасында без канлы яшьләр түктек, газиз балаларыбыз зар елады, әмма сез — бозыклар — зарларыбызга колак салмадыгыз.

Ниһаять халык арасыннан:

— Тугры!

— Байның гидай-ярлы өчен җаны көймәде, — дигән тавышлар килде.

Фарукҗан мәйданда җанлана төшкәннәргә рух өстәргә ашыкты:

— Ләкин Бохара туңкәреше мәмләкәттә гаделлек урнаштыру, фәкыйрь игенчеләрнең, терлекчеләрнең дә хокукларын яклау өчен ясалды, — диде ул. — Без моннан соң байларның башбаштаклыгына

юл куймаячакбыз. Салган зыяны өчен Нурморат бай да, башкалар да җавапка тартылачак. Әгәр алар алдап-йолдап, куркытып, бурыч түләү хисабына дип, авылдашларыннан түбән бәядән җыйнап алган мамыкны, җимешләрне кире ияләренә кайтарып бирмәсә, мөлкәтләреннән, гомумән, мәхрүм ителәчәк, үзләре кулга алыначак. Моны барыгыз да мыекка чорнап куегыз!

Мәйданда җанлану көчәйде. Багбан игенчеләренең күпчелеге, гөж килеп, Байкучатов белдерүен хуплавын төшенү кыен түгел иде. Фарукҗан аларга бераз колак салып торды да:

— Хәзер, алыш-бирешләрегезнең гадел үткәрелүен анықлау өчен, бай куйган бәяне азсынган, әмма шулай да быелгы уңышын ирексездән тагын аңа биргән хуҗалар якынрак килегез, язып алыйк әле, — дип тәкъдим итте.

Иргәш авылдашларыннан кемнең кайсы байга никадәр бурычы булганын, шуны түләргә күпме мал китүен терки башлады. Алыш-бирештән риза булмаган егермеләп кеше, алар янына килеп, зарын түкте. Әмма күпчелек, гаделсезлеккә рәнҗегән, нәфрәтләнгән хәлдә, капчык төбен селкергә ашыкмады. Алданган хуҗаларның кышлакта күп икәнлеген, бәк өере каныгуыннан хәвефләнеп кенә дәшми торуларын Иргәш күптән чамалый иде. Бар кешегә берьюлы гайрәт кертү мөмкин түгел шул, егермеләп авылдашым тәвәккәлләүгә дә шөкер итәргә кирәк хәзергә, дип уйлады ул.

Фарукҗан бу көннәрдә мамыкның, киптерелгән җимешләрнең чын бәясен иптәшләреннән сорашып, җирен уртагыннан файдаландырган байның авылдашларын күпмегә алдавын анықларга омтылды. Әмма Зыятдинда хезмәт итүче кызыл гаскәриләр сәүдә эшен аслан белми торган яшьләр иде. Иргәш белән Амантай да бер фикергә килә алмады.

Багбан коесы янына килергә тиешле кәрванны кулдан ычкындырмас өчен, кышлактан тизрәк кузгалу хәерле иде. Дөресен әйткәндә, Каратау ягында чын гаделлек урнаштыру Сәетморат бәк басмачыларын туздырганнан соң гына мөмкин, шунсыз Нурморат кебек ачкүзләрне авызлыклау да тормышка ашмаячак иде. Моның өчен исә кызыл гаскәриләрнең санын арттыру, революцион көчләрне ныгыту, халыкның аңын уяту хаҗәт. Багбандагыдай гаделсезлекләр Бохара Совет Республикасында атлаган саен очрый. Көрәшнең каты, дәвамлы булуы ихтимал.

— Иптәшләр, безгә кушылырга теләүчеләрне бүген үк ияртеп китәчәкбез, — диде Фарукҗан. — Хәзер үк! Киләчәктә мөлкәтебез имин, тормышыбыз хәвефсез булсын, һәммәбез хөррият җимешен татысын дип теләсәк, яңа тормыш өчен көрәшүчеләр сафына басыйк!

Әмма мәйдандагы халык арасыннан алар янына чәчрәп килеп баскан егетләр күренмәде. Шунлыктан, Иргәшнең эше тәмамлануга, Фарукҗан исемлекне күздән кичерде дә, җыелышка килүчеләргә революция ачкан мөмкинлекләрне, аларны ничек файдалану кирәклеген тагын бераз аңлатканнан соң:

— Дәгъваларыгызны Зыятдиндагы яңа җитәкчеләр өйрәнер, сезгә ярдәм кулын сузар, — диде. — Бер нәрсәне исә хәзер үк өзеп әйтә алам: Советлар Рәсәе белән сәүдә җайга салынгач, Бохарада мамык, җиләк-җимеш бәяләре инде шактый күтәрелде. Моның файдасы тиздән сезгә дә, һичшиксез, тиярга тиеш. Шушы мәсьәлә хәл кылынганчы, авылдашларын талап баеган, гөнаһсызларны җәберләп күңел тапкан ике байгурагызны кулга алабыз. Алар революция кануннары буенча хөкемгә тартылыр.

Язмышлары көтмәгәндә хәтәр борылышка очравын бик тиз тойган Нурморат бай белән аның әшнәсе, бәладән котылырга талпынып:

— Аксакаллар, авылдашлар! — дип мәйдандагыларга эндәште. — Сез ачлыкка, мохтаҗлыкка тарыганда, азык-әүкатен, кием-

салымын уртаклашучы без имәс идекме? Сәдакасын да, ярдәмен дә һәрвакыт кем бирүен онытмаңнар!

— Ашка таш белән атмаңнар, безне яклаңнар! Ят кызыл гаскәриләр килер дә китәр, без — әлмисактан бирле бергә көн күреп килгән кардәшләрегез, моны истән чыгармаңнар!

Аларны яклаучылар чыннан да табылды. Башта хәзрәт, аның артыннан янә берничә куштан телгә килде:

— Могтәбәр затларыбызны кулга алырга аслан фатиха юк!

— Шушы шәфкатьле җаннар юмартлык күрсәтмәсә, ачлыктан кырылмас идекме?

— Бирмик ил агаларын!

Әмма гөбедән чыккандай бер калын тавыш шулчак аларны күмеп китте:

— Таштан юкә суючы агалар безгә нәрсәгә? Алардан башка да кышлак үчмәс, иншалла.

Фарукҗан исә мәйдандагыларны:

— Җәмагать, кышлагыгызга Сәетморат бәк козгыннары килеп керсә, аларга ярдәм бирүдән, үзара ачу тотып, бер-берегезне әләкләүдән сакланыгыз, — дип кисәтте. — Без капчыкта ятмый, бүтәннәргә баз казучы кеше дә иртәме, соңмы беленәчәк, һәм ул, Нурморат байлар кебек, җәзага тартылачак. Яхшылык өмет итүче беренче нәүбәттә үзе яманлык кылмасын — тигәнәк чәчкән беркайчан да йөзем җыя алмаячак!

Әйтеләсе сүзләр әйтелде, ниятләнгән эш эшләнде, хәзер инде авылдан тыныч күңел белән чыгып китәргә мөмкин иде. Халык мәйданнан тарала башлаганда, байларга дәгъваларын теркәткән аксакаллар кызыл гаскәриләрне, урап алып, чәйгә чакырды. Иргәш, авылдашлары кунакчыллыгын куәтләп, Фарукҗанга:

— Хөрмәттән баш тартмыйк, сахрада чәйханәләр юк, — дип мөрәҗәгать итте. — Тамак ялгар чак та җитте.

Байкучатов монда күп вакыт югалтудан куркып сорады:

— Озакка сузылмасмы соң бу эш? Табын әзерләгәнче...

— Ул әзер инде, — диде Иргәш. — Мин бая разведкага килгәндә үк биш-алты хуҗага хәбәр бирүләрен үтенгән идем.

— Әүкат даяр.

— Боерыгыз! — дип картлар бертавыштан Иргәш җавабын раслап куйды.

Иптәшләрен йорт башына икешәр-өчәр кешедән таратыр алдыннан, Байкучатов:

— Ярты сәгатьтән шушы мәйданда җыйналабыз. Кичекмәгез! — дип кисәтте.

Иргәш Фарукҗан белән Амантайны үзләренә алып китте. Гаиләләрендә ир-атның һәммәсе бер дә көтмәгәндә туган нигезгә җыйналудан шатлык бөркелүе сизелә иде. Ишегалдына су сибелгән, өйләре җыйналган, кунак бүлмәсендәге тәбәнәк өстәлгә бар кадәренчә ризык тезелгән — пәтернан, хәлвә, көзге байлыктан тәлгәш-тәлгәш йөзем. Мирәхмәт карт үзе егетләрне түргә чакырып:

— Канә, мәрхәмәт кылың! — диде. — Углымның дуслары — безгә кадердан миһманнар.

Иргәш касәләргә үзбәкчә яртылаш кына тутырып чәй ясый башлады. Китек борыны калай белән ямалган юан корсаклы зур фарфор чәйнекне, чатнаган касәләрне күреп, бүлмәдә юньле-башлы җиһазның булмавын абайлаган Байкучатов эченнән: «Әйе, тормышлары мактанырлык түгел боларның, — дип уйлады. — Мондыйларны ни вөҗдан белән таларга мөмкин икән?» — Иргәш ул арада зур җамаякта дөге боткасы алып кереп, өстәл уртасына куйды.

— Әйдәгез, бары белән ризыкланыйк!

Чәй эчкәннән соң, ул атасына:

— Болар минем иң якын дусларым, — диде. — Амантай белән Каган мамык тазалау заводында ук бергә михнәт чиктек. Фарукҗан әкә Чеканың каттә юлбашчысы, ул безне Байсын ягына җибәрелә торган кызыл гаскәриләрдән аерып, Бохарада, үз хозурында алып калды.

— Ата-анагыз, гаиләгез бармы, углым? — дип сорады Мирәхмәт абзый.

— Бар, — диде Фарукҗан кыска гына.

Иргәш аның кемлеген атасына тәфсилләбрәк аңлатырга керешге:

— Гаиләдә, безнең кебек, өч ир, өч кыз бала үскәннәр икән. Фарукҗан әкә Казанның гали мәдрәсәсендә укыган, ярманнарга каршы сугышкан. Шуннан соң ак патшаны тәхетеннән төшерүдә катнашкан, аның яраннарын акылга утыртып йөргән. Хәзер менә безнең хөрриятне якларга килде. Ул җәдә белемле, гаярь адәм, бәк-морзаларның, түрәләрнең берсеннән дә курыкмый...

Сөйләгәне юк лабаса, кайдан белгән боларны иптәше? Фарукҗан, ишек вазифасын үтәгән чаршауның аз гына ачылып һәм тирбәлеп куюыннан, Иргәш сүзләренә эчкәредәге хатын-кызлар да колак салып торуын чамалап:

— Йә, куйчы, бүтән сүз беткәнмени сиңа, — дип иптәшен тыйды, — Яхшысы, аулакта Мирәхмәт абзыйдан кышлак хәлләрен сорашыйк без.

Хуҗа аның бу сүзләрен ошатып:

— Углыма, безгә калкан булуыгыз өчен каттә рәхмәтләр яусын, балам, — диде. — Бәлки ул имансызлар, безне дә яклаучылар барлыгын күргәч, инсафка килер?

— Килмәсәләр китерербез, — диде Фарукҗан ышанычлы төстә.

— Бәрәкалла! Ата-анаңа, балаларыңа игелек яугыры, безнең хәер-догабыз...

— Фарукҗан әкә әле өйләнмәгән егет, дәдәм, — дип Иргәш атасын бүлде.

— ...кардәшләреңә безнең хәер-догаларыбыз барып җитсен, амин!

Байкучатов табыннан беренче кузгалып, ишегалдына чыкты. Ашау-эчү килешкән, маңгаена тир бәреп чыккан иде. Ул, изүен ычкындырып, беләкләрен сызганып, фуражкасы белән битен, муеннарын җилләтеп торганда, эчке яктан пәрәнҗә бөркәнгән бер хатынкыз килеп чыкты. Хәрәкәтләре җиңел, гәүдәсе сылу, кулына кувшин белән сөлге тоткан.

— Әкәҗан, юлга чыкканда салкын су белән юынып алыгыз, — диде ул.

Фарукҗанның белүенчә, Бохара хатын-кызлары ят ир-атка сүз кушмый иде. Ләкин ул гаҗәпләнүен сиздермәде, фуражкасын дувал өстенә куеп, кувшинга үрелде.

— Үзем салып торамын!

Монысы инде, гомумән, кардәшенә, якын кешеңә генә күрсәтә торган хөрмәт иде.

— Рәхмәт. Сез Иргәшнең сеңлесеме?

— Әйе.

Фарукҗан, суны бик чәчрәтмәскә тырышып, иелеп, кулларын, аннары битен, муенын юды, билен турайтканда инде ул чынлап торып таң калды — кызыкай, чәчванын ачып, елмаеп аңа караган да суын һаман коя иде. Кашлары калын, күзләре карлыгандай кара, битләре алмадай алсуланган. Бер учма чәче маңгаена сибелеп төшкән.

Фарукҗан сузылган сөлгене дә алырга онытып, үзенә төбәлгәч, кызыкай бик тиз керфекләрен төшерде һәм назлы тавыш белән:

— Әкәҗан, безнең кышлакка сез янә дә киләчәксезме? — дип сорады.

— Дусларымны якларга кирәксә — әлбәттә.

Өйдән чыгып килүчеләрнең аяк тавышлары ишетелгәч, кызыкай җитез генә чәчванын төшерде. Фарукҗан ашыгып:

— Ә сезнең атыгыз кем? — дип эндәште.

— Анар.

Ирләр тышка чыкканда кызыкай бакча ягына китеп югалган иде инде. Байкучатов сөртенергә өлгерә алмый калды. Хәер, ул моны кирәк дип тә санамады, әле генә сөйләшенгән бер-ике авыз гәп, аралашу аның уйларын башка эзгә кертеп җибәргән иде.

Кызыл гаскәриләр караңгылык куера башлаганда авылдан чыгып китеп, Зәрәфшәнгә кадәр өзлексез юртып барды. Елганы кичкәч, аның ике сугышчысы, кулга алынганнарны илтер өчен, станциягә борылды, калганнары көньяк-көнчыгышка, Зыятдин тавы итәгенә таба ашыкты. Фарукҗан исәбенчә, корал төягән кәрван, җан иясе сирәк яши торган чүлдән халык тыгыз утырган үзәнлек чигенә, әлбәттә, ил йокыга талгач кына килеп җитәргә, шуңа кадәр ул иптәшләре белән Багбан коесы тирәсенә барып өлгерергә һәм дошман абайламаслык итеп яшеренергә тиеш иде.

## 30

Иргәшнең тынычсызланып як-якка карануын күзәткән Фарукҗан, атын тыеп:

— Нәрсә, юлны саташтырдыкмы әллә? — дип сорады.

— Белмим. Адашуын адашмадык үзе, шулай да коеның һаман күренмәве сәеррәк.

Аларны озата килгән Зыятдин гарнизоны гаскәриләре дә эзләнүгә ачыклык кертерлек бер сүз дә эндәшмәгәч, Фарукҗан тукталып калды, иптәшләренә Багбан коесы хакында белгәннәрен тагын бер кат искә төшерергә кушты. Шулчак станция ягыннан якынлашучы бер кара күләгә күренде. Карачкы алардан шактый еракта, төньяктан урап узып барганда, оператив төркем, иярдән төшеп, өнсез калды, пошкырып тынлыкны бозмасын өчен, хәтта атларның авызларын да тотып тордылар. Билгеле, ялгыз җайдак әллә кайдан ачык күренгәндә, ишле төркемнең шәйләнмәвенә исәп итү кыен иде. Әмма ят сәяхәтче, Фарукҗаннарның барлыгын бөтенләй абайламаган шикелле, үз юлыннан уңга-сулга һич тә тайпылмастан, җитез җилдерүен дәвам итте. Төнге мосафирдан шикләнгән Байкучатов иптәшләренә:

— Атланыгыз! — дип боерды.— Җайдакны кулга төшерегез!

Әгәр бу бәндә безне юри башка тарафка ияртеп китеп, юлдан яздырырга җибәрелгән булса, эш харап, дип уйлады Фарукҗан. Эченнән шулай пошынса да, серле күләгә артыннан үзе беренче ыргылды. Кәрванны, корал көтеп яткан басмачыларны хәвеф хакында кисәтергә ашыгуы да мөмкин ич төнге җайдакның. Ул очракта кое янына бармый кая томырылсын соң?

Әмма бик кызуласалар да, кызыл гаскәриләр белән шикле сәяхәтче арасы кыскармады. Зыятдиннан Багбан кышлагына барганда һәм аннан монда килгәндә өшәнергә өлгергән атлар ят толпар белән ярышырлык хәлдә түгел иде. Күләгәнең ерагая баруы исә төнге юлаучының әле арымаган шәп атка атлануын гына күрсәтә иде.

Фарукҗан төркеме шулай да билгесез җайдактан күз язмады, куып баруын дәвам итте. Тирә-якта иксез-чиксез ком сахрасы — шактый тигез чүл җәелеп ятканлыктан, монда тиз генә күздән югалу мөмкин түгел иде. Берзаман алданиндидер корылма калкып чыккандай тоелды. Эзәрлекләнгән җайдак шуның янына барып җитүгә,

анда ыгы-зыгы купты — «корылма» хәрәкәткә килде һәм, дүрт-бишкә аерылып, төрле якка тарала башлады.

— Кәрванны көтеп торучы бәдбәхетләр бу! — диде Иргәш.— Качалар!

— Ә нигә корал алып килүче кәрванның үзе түгел?

— Хәрәкәтләре җиңел, күрмисезмени? Дөяләргә йөк асылмаган.

— Дөя? — дип гаҗәпләнде Фарукҗан.

— Әйе, дөя озын торыклы хайван икәнлекләрен таныймын күз. Без аларны чүлдә куып җитә алмаячакбыз. Ат аяклары комга дөянекеннән күбрәк бата.

Атлы карачкы исә көньяк-көнчыгышка таба элдертүен дәвам итте. Фарукҗан хәлне тәмам чамалап алып:

— Теге кабахәт кәрванны кисәтергә чаба икән. Кайсыгызның аты егәрлерәк, житезрәк — шуның артыннан икегез китегез,— дип боерды.— Атышырлык якынайсагыз, толпарын чүкегез! Юкса ычкыначак.

Гарнизон гаскәриләре командиры белән Иргәш боерыкны үтәргә атылып кузгалгач, Байкучатов калган сугышчыларны күздән кичереп:

— Ә сез дөяләрне әзәрлекләгез! — дип фәрман бирде.— Кулга төшерергә тырышыгыз, әмма мавыгып китеп, чүл эченә артык кермәгез. Бер сәгатьтән кое янында җыелырлык булсын. Төшендегезме?

— Хуп, мәйле.

— Амантай, син монда каласың, калганнарыгыз — дошманны эләктерергә!

Кызыл гаскәриләр, төрлесе төрле якка сибелеп, качып барган дөяләләр артыннан ыргылды.

Фарукҗан белән Амантай исә алда караеп калкып торган корылма янына килеп җитеп, аттан төште. Кое бурасы янәшәсенә бик үк биек, зур түгел тирмә тегелгән, аның әргәсендә дәү-дәү капчыклар өеме — тәртипсез бушатылган йөкләр аунап ята иде. Байкучатов, унатарын кулына алып, тирә-юньне сак кына тикшереп чыкты. Тирмәдәгеләр урыннарыннан кинәт купканлыктан, учаклары әле һаман яна, табыннарында ризык мул гына чәчелеп ята, калай кружкаларга ясалган яшел чәйләре дә суынып өлгермәгән иде.

— Тере җан иясе күренми,— диде Фарукҗан.— Әмма алыш-бирешкә яхшы әзерләнгәннәр, кунакларны сыйларга чәйләре дә пешерелгән күренә.

— Безгә дә сусын кандыру хәрәм булмас.

— Дөрес. Тик әүвәл без дә кәрванны әйбәт каршыларга әзерләнеп куйыйк.

Фарукҗан тирмәдән чыгып кое тирәсен күздән кичерде, якында гына дулкын-дулкын җыерчыкланып яткан бархannар буйлап узды. Пулеметны каракүл тутырылган капчыклар арасына урнаштыру ымсындырса да, хәзер инде республика милкенә әйләнәчәк кыйммәтле хәзинәне пулялардан теткәләтергә теләмәде, йөз адым чамасыераклыкта калкыбрак торган бер үр сыртына яшерде, аннары Амантай белән үзенә дә шунда уңайлы оялар әзерләделәр. Моннан кое тирәсен утка тотуны гарантияләргә мөмкин иде. Дошманны чолгап алыр өчен, башка солдатларны кая яткырасын да хәл иткәч, чәй эчәргә утырдылар.

Дөяләрне куа китүчеләр, уңышка ирешә алмый, берәм-берәм кое янына әйләнеп кайтты. Иң соңыннан атлы җайдакны эзәрлекләгән Иргәш күренде. Ул җитәкләгән ат өстенә — иярга бәйләп аркылы салынган яшь кызыл гаскәри дә, дошман да үле иде.

— Ничек бәлагә очрадыгыз? — дип сорады Фарукҗан.

— Иптәшемнең аты елгыррак булып чыкты, мине бик тиз артта калдырып, алга ыргылды. Байтак җир киткәч, әллә нәчә ату тавышы

яңгырады. Ерактан ук күреп калдым: башта дошман җиргә тәгәрәде, аннары иптәшем сөрлекте. Яннарына барып җиткәч аңладым: пуля әүвәл басмачының атына тигән. Дошман, шуннан соң качып котыла алмаячагын белгәч, куа килүчегә төзәп ата башлаган.

— Син аны ничек кулга төшердең соң?

— Иптәшем аны яраларга өлгергән иде. Юри үлгәнгә сабышып ятмасын, дип мин аңа ерактан ук ут ачтым. Чәнчелде!

Фарукҗан дошманның башын күтәреп йөзенә карады, әмма аны күргән-белгән бер генә кешесенә дә охшатмады.

— Тентедеңме үзен?

— Әйе,— диде Иргәш.— Менә мылтыгы, револьвер белән хәнҗәре.

— Уһу!

Кызыл гаскәриләр иптәшләрен иярдән чишеп алган арада Иргәш Фарукҗанга янә бер трофей тапшырды.

— Монысы дошман чапанының чабуына тегеп куелган иде. Алла ярдәм итте — капшаганда кыштырдавыннан белеп таптым,— диде ул.

Байкучатов, тирмәгә кереп, учакка коры кизәк өстәде һәм, ялкын телләре дөрләп уйный башлаганчы, сүрән генә көйрәгән утка өреп торды. Тирмә эче яктырып киткәч, Иргәш тоттырган язуны укырга кереште.

«Полковник Штеннелгә.

Хөрмәтле сэр, шанлы Бөекбритания мәнфәгатьләрен кайгыртып биргән ике әмерегезне бүген үтәдек:

Иске Бохара вокзалында дары төялгән унике тимер юл вагоны шартлатылды. Сугыш кирәк-яраклары, бернichә дистә сугышчысы юк ителде. Йөздән артык солдаты яраланды, күп кенә ат, дөя, Россиягә җибәрергә әзерләнгән кибән-кибән мамык, өем-өем каракүлнең күле күккә очырылды, хәтсез корылмалары сафтан чыгарылды.

Бохара базарларының берсендә Әфганстан сәүдәгәре Габделшөкерхан милкенә ут төртелде.

Станциядәге шартлау һәм базардагы янгын Бохара революциясе җитәкчеләре арасындагы каршылыкларны көчәйтте. Сулларның басымын киметү өчен, премьер-министр Фәйзулла Хуҗаев аларның кайберләрен, дипломатик вәкиллеккә билгеләп, Ташкентка, Хивага һәм Мәскәүгә җибәрергә тотынган иде. Хуҗаев хәйләсен яхшы төшенгән Совет Россиясе вәкиле Валериан Куйбышев, уңнар артык көчәеп китүдән куркып, каршы чаралар күрә башлады: Коминтерн исеменнән Бохара компартиясенең яңа Үзәк Комитетын корды, анда урта юлдан баручы җитәкчеләрне күбрәк кертергә тырышты. Бер үк вакытта, уңнарның көчле ризасызлык күрсәтүенә дә карамастан, Үзәк Россия тәртипләрен артта калган шәрыктә — Бохарада да тайпылышсыз урнаштырырга омтылган барлык сулларны җитәкчелектән куарга юл куймады, үз тарафдарларын тизрәк ишәйтү, халыкның надан түбән катлауларын ашыгыч үз якларына аудару максаты белән, Аксолтанов-Тураевлар активын кышлакларга таратты.

Югарыдан саналган сәбәпләр аркасында, безнең эшчәнлек көткән нәтиҗәне биреп бетермәгәнлектән, мин Мәшһәдкә юлга чыгуымны кичектерергә мәҗбүрмен.

Әфганстаннан Багбан коесына юл тоткан кәрванның исән-имин Зәрәфшән үзәнлегенә якынлашуы хакында хәбәр алдым. Корал җибәрүне моннан соң тагын да арттыруыгызны үтенәм.

Яңа күрсәтмәләрегезне көтеп, капитан Блеккер.
Бохара, егерме өченче октябрь».

Язуны авыр көрсенеп, чигәсен уа-уа укып чыккач, Фарукҗан «кабахәт!» дип пышылдады. Аннары командирын сәерсендереп күзәткән Иргәшкә:

— Коймакның табадан гына төшкәне, булдыргансың, дустым! — диде.— Бик кирәкле язу бу. Дошманнарыбыз үтә көчле, дәһшәтле. Алар бөтен Бохараны зир-зәбәр китерергә дә күп сорамаячак..

Хатта нилэр хәбәр ителүен белмәгән Иргәш:

— Әллә анда хәрби комиссар фаҗигасе турында да берәр сүз бармы? — дип сорады.

— Юк. Әмма күп нәрсәгә ачыклык кертә бу хат. Безнең дөрес юлда икәнлегебезне дә раслый.— Фарукҗан бераз уйланып торды да,

кинәт кабынып, янә иптәшенә эндәште: — Кара әле, Иргәш,ниндирәк кеше булды икән ул хат та́шучы? Җан биргәнче сорау алырга өлгермәдеңме? — диде.

— Өлгермәдем шул. Караңгыда алданудан курыктым. Атыштык.

Амантай кайнаткан чәй, юлга алган коры-сары ризык белән тамак ялгагач, кызыл гаскәриләр бераз кырын ятып ял иттеләр. Инде сугарылган атлары кәрваннан калган карбыз кабыкларын кетердәтә иде. Кабыгын гына түгел, башламаган бөтен карбызларны да бахбайларга бирергә туры килде. Алдагы бәрелешнең ничек тәмамланасын берәү дә анык кына әйтә алмый, дошманны эзәрлекләү бер якта торсын, хәл мөшкелләнсә, койрыкны борыр өчен дә ат кирәк булачагы ачык иде. Шуңа күрә, Фарукҗан аларны ашатырга гына түгел, үзе биләячәк үр артына, аулаккарак илтеп тышауларга да кушты, аннары гына кызыл гаскәриләрне алдан билгеләнгән нокталарга урнаштырып чыкты. Амантай белән бер солдатны исә кәрван киләчәк юл өстенә, коедан бер чакрым чамасы читтәге казанлыкта яшеренергә боерды. Кәрванны үткәреп җибәрергә, ләкин...

Чигенергә омтылсалар, юлларын бикләгез. Без ясаган камалыштан берәү дә тере килеш качып котылмасын!

Байтак көттеләр. Бик үк калын киенмәгән сугышчылар, салкынга бирешмәс өчен, әледән-әле хәрәкәтләнеп алырга мәҗбүр булды. Хәер, йокыга китеп, уяулыкны җуймас өчен, яхшы да иде бу.

Кәрван төн уртасы узгач, ай инде яңадан офыкка тәгәри башлаганда гына күренде. Ун дөянең бишесенә кеше атланган, калганнарына авыр агач тартмалар асылган иде. Фарукҗан отряды аны сабыр гына көтеп алды. Ләкин кәрван кое янына килеп җиткәнче үк туктап калды, аннары төньякка, Зыятдин тавына таба борыла башлады. Шартлы хәбәрләшү билгесе күренмәгәнлектән бу, дип уйлап, Фарукҗан шунда ук пулеметтан тырылдатырга кереште. Кәрван өстендә төрле яктан атылган мылтык пулялары да безелди башлагач, Байкучатов сахраны ярып:

— Сез чолганышта, коралларыгызны ташлагыз! — дип оран салды.

Кәрванчылар аптырап калды. Әмма дөяләләрнең берсе бик тиз аңына килеп, хәвефсезрәк тоелган арт якка борылды, әче итеп сүгенә-сүгенә Фарукҗан тавышы килгән якка ут ачты һәм ничек тә хәвефле боҗрадан чыгып ычкынырга омтылды.

— Атыгыз хәшәрәтләргә!

Дошман кәрваны янә ике мылтык белән җавап бирә башлады, ләкин кызыл гаскәриләр җиргә сеңеп алдан ук казып куелган оялларга кереп яшеренгәнлектән, аларның атуы җитди зыян китерә алмады. Башта кисәтер өчен генә мылтык гөрселдәткән кызыл гаскәриләр, эшләр болайга киткәч, Фарукҗанның алдан ук әмер бирүенчә, кәрванчыларны ауларга керешеләр. Йөген җиргә олактырып, җитез генә артка чигенгән берсен искә алмаганда, дошманнарның каршылык күрсәтүе тиздән басылды. Артка таба качкан әлеге «сәүдәгәрне» исә Амантайлар авыр җәрәхәтләп, кулга төшерделәр. Бәрелеш барышында ике басмачы үтерелде, бер кызыл гаскәри яраланды. Пулемет тырылдый башлагач ук дөядән җиргә сикергән, тын алырга да куркып, борыннарын комга төртеп яткан ике кәрванчы әсир ителде. Ата да белмәгән коралсыз ул байгышларның сәясәткә дә, канлы көрәшләргә дә катнашы булмавына, теләсә нинди эшкә ялланып көн күрүләренә ышанырга бик мөмкин иде. Ә менә Амантайлар яралаганы...

Атыш кубу мондый дәһшәткә күнекмәгән дөяләрне яман өркеткән, алар йөкләрен зир-зәбәр китереп ары-бире ташланган, икесе яраланган, өчесе казасын да тапкан иде. Фарукҗан иптәшләренә

дөяләрнең исәннәрен бергә тупларга, йөкләрен җыйнап, исәпкә алып, яңадан төяргә кушты да тирмә эченә узды. Учакның сүрән яктысында Амантайлар алып кергән яралы басмачының чалымнары таныш сыман күренгәч, аның янына килеп шырпы сызды.

— Уһу, асыл кош аягыннан эләккән икән ләбаса!

Байкучатов басмачы маңгаеның уң ягында күптән ясалган яра эзен күргә. Газәли чәйханәсен исенә төшерде. Аулак арт бүлмәдә киңәш корып утыручы контрлар арасында шушы озынча йөзле, очлы иякле бәндә дә бар иде ич. Чикмәнен, купшы чалмасын бу юлы зәңгәр чапан, колакчынсыз бүреккә алыштырган — бөтен үзгәреше шунда гына. Хәзерге бәрелештә исә пуля калак сөяге астыннан тишеп узган — аркасы да, күкрәк асты да канга манчылган иде.

— Амантай, өстен чишендереп, ярасын бәйлә әле таныш кунакның.

Туктаров командиры боерыгын үтәргә кузгалган гына иде, кемнәр кулына килеп кабуын шулай ук күргән карт:

— Кирәк имәс, сез мордарлардан ярдәм алганчы, шәһит китүем хәерлерәк! — дип ачулы караш ташлады.

— Басмачы дигәч тә, алай ук тәкәбберләнмә, агай! — диде Фарукҗан.— Шәһит киткәнче әле байтак сорауга җавап бирәсең бар. Җитезрәк кайнаш, Амантай, күлмәген ерт та...

— Мин басмачымы? — диде нәфрәтләнгән карт.— Басмачы сез ул! Без Идел буена имәс, сез Бохараны басып алырга килгән. Урыс көчекләре.

— Йә-йә,— дип бүлде аны Фарукҗан.—Күп нотык сөйләсәң, җан тәслим кылуың да бар. Амантай, булыш әле миңа.

Алар икәүләшеп картның чапанын, күлмәген салдырдылар, аннары җәрәхәтен карап, канын туктатырлык итеп кысып бәйләделәр. Киреләнеп сөйләнсә дә, хәле киткәнгәме, яралы каршылык күрсәтмәде. Шуннан соң Байкучатов канәгать төстә:

— Без урыс көчеге булсак, сез — инглизнеке! — дип белдерде.— Коралны кем озатуын бик яхшы беләсез. Үзегезне әүлия санамагыз, ашханәдән китеп барганда миңа атуыгыз да мөселман канын кою өчен иде.

— Сез дә мөселманмы? — дип күзләрен акайтты карт.— Мөселманлыкның терәге булган Бохараи шәрифне вәйран кылучы дәһри, сатлык җаннар да шулай оялмыйча авыз ачса, кһ-кһ-кһ...

Яралы буылып-буылып йөткерергә тотынды. Фарукҗан аның тынычрак сулыш ала башлавын көтеп торды да:

— Ора алмаганның орысы чыгар,— диде.— Тик хәзер без бүтән нәрсә хакында сөйләшик. Коралны сезгә кем китерде? Сез аны кемгә тапшырырга тиеш? Тагын кайчан...

Карт аны бүлеп:

— Йомычка гынамыни?! — дип сорады.— Сез Бохараны утка тотканда егерме җиде мәдрәсә, әмир китапханәсе яну, меңләгән кыйммәтле кульязмалар харап булу югалту имәс, ә? Милли тиңлек, хөррият, дип лаф ордыгыз да әмир алтынын Мәскәүгә озаттыгыз. Бохара мәмләкәтен әнә шулай милли байлыгыннан мәхрүм итү дә безгә булышу хисапланамы?

Байкучатов, кыяфәте белән гади бер диһкан-игенче генә күренгән нindидер басмачыдан мондый ук хәбәрдарлык, үҗәтлек көтмәгән иде. Тирмәгә Иргәш белән янә берничә кызыл гаскәри дә килеп керүенә һәм дошман коткысына колак салып торуына борчылып:

— Ә сез әмир алтынын Бөекбританиягә җибәрергә җыенган идегезме? — дип һөҗүмгә күчте.— Шуңа корал сатып алып, меңлегән гөнаһсызларның канын коярга план кордыгызмы? Барып чыкмас! Бохара хезмәт ияләре тир түгеп тапкан байлык аларның үзләренә ти-

сен әле. Әмир алтыны монда икмәк, кием-салым булып кайтачак.

— Русиядән күп кайтты инде!

Фарукҗан, аның мыскыллы сүзләрен бөтенләй ишетмәгәндәй, дәвам итте:

— Ул алтын монда завод-фабрикалар, типографияләр, шифаханәләр, мәктәпләр рәвешендә Бохара Совет Республикасы кулына керәчәк. Коминтерн, ягъни, бәйнәлмиләл...

— Әгәр бәйнәлмиләлегез алай бик гадел, игелекле булса, ярдәмне нигә бушлай гына өләшми? — дип гыжылдады карт.— Нигә булышуы өчен генә имәс, вәгъдәсе өчен дә алдан ук мең бәя түләтеп куя? Русия безне әз сыктымыни? Талап алган хәзинәсенең бер тамчысын шул байлыкны җитештерүчеләргә кире кайтарганда янә сафсата да кушып бирү нимәгә?

— Ә сез чын юха елан икән! — диде Байкучатов чыраен сытып.— Беркатлы кешеләрне шушылай сайрап юлдан яздыруыгыз да бик мөмкин. Имеш, без мәдрәсәләрне, китапларны яндырган!

— Дөресен әйткәч, ощамыймыни? — диде карт зәһәр көлемсерәп.

— Ялган бу! — диде Фарукҗан кызып китеп.— Хәле мөшкелләнгәч, әмирнең шәһәргә ут төрттерүе, китапларга гына түгел, иген келәтләренә дә нәкъ менә аның ут салдыруы, мәмләкәт казнасындагы миллионлаган тәңкә акчаны, бүтән байлыкны да аның талап качуы безгә яхшы мәгълүм.

— Бохара алтынын Фәйзулланың Мәскәүгә төятеп җибәрүен генә күрми калуыгыз гаҗәп! Дөрес, Фрунзе, Куйбышевларның шуңа күзе кызуын...

Фарукҗан аны тыңлап тормады, тавышын көчәйтеп, үзе дәвам итте:

— Әмир һәм аның тарафдарлары бар яманлыкны безгә сыларга маташуы да билгеле. Халык арасында коткы таратып, безне афәт чыгаручы итеп танытырга тырышуы да...

— Сездәй икейөзле бушбугазны ничек җир күтәрәде? Ходаем, мондый иблисләрне ничек ормыйсың син?!

— Каргышың кара башыңа! — диде Фарукҗан.— Дөрес әйтәмме мин, иптәшләр?

Ләкин Иргәш тә, бүтән кызыл гаскәриләр дә ләм-мим эндәшмәде. Сорау алу барышын башыннан ук тыңлап тормагангамы, басмачы сүзләрендә дә хаклык бар дип уйлауданмы? Россиядә революция, байлар-ярлылар көрәше кабыну ил хуҗалыгын чыгырыннан чыгаруын, күпләрнең мохтаҗлыкка таруын, Идел буенда, Үзәк Россиядә, бигрәк тә шәһәрләрдә азык-төлек, ягулык җитешмәвен, Кызыл Гаскәрнең корал кытлыгы кичерүен, шуңа күрә генә советларның Бохара алтын хәзинәсен файдалануы ихтималлыгын аңлатып тору кирәк идеме хәзер? Дөресен әйткәндә, ул алтынның барлыгын һәм кая куелуын ачык кына белми дә ич Фарукҗан. Дошман лыгырдавына алданып, ялгыш юлга керсен тагын!

Көтеп-көтеп тә иптәшләреннән ни ризасызлык, ни яклау сүзе ишетмәгәч, Байкучатов әсиргә кырыс кына эндәште:

— Без монда килде-китте бәхәс куертырга җыелмадык, әфәндем. Җаныгыз кадерле булса, җавап бирегез: безгә каршы корал күтәрергә сезне кем мәҗбүр итте?

— Намусым.

— Багбан кышлагында сезнең кебек «намуслыларның» нишләвен күрдек инде. Тәүбә итмәсәгез, бу юл һәммәгезне фәкать үлемгә генә алып барачак. Уйлагыз. Йә әшнәләрегезне, аларның алдагы кара ниятләрен ачасыз, йә...

Байкучатов сорау алуын дәвам итәргә өлгермәде, тышта ату тавышы, аннары Иргәшнең:

— Басмачылар! — дигән авазы яңгырады.

Дөяләләр барып чакырганмы? Кәрван белән килгән яңа коралны да кулга төшерсәләр...

Фарукҗан бәрелеп-сугылып тышка чыкканда дошман әле кое янына килеп җитмәгән. Иргәш, командирының ниятен чамалагандай, корал асылган дөяләрне пулемет урнаштырылган үр артына алып китеп бара, калган сугышчылар, мылтыкларын кулларына тотып, куркыныч янаган тарафка карап, җиргә сузылып яткан иде.

— Таң беленүен көтәләр, ахры,— диде Амантай.— Артык ашыкмыйлар.

— Басмачылар икәнне кайдан беләсез?

— Иргәш чамалады. Зыятдин станциясеннән безнекеләр килсә, юллары бүтән яктан салыныр иде, ди.

— Кем атты? — дип сорады Фарукҗан.

— Зыятдинныкылар,— диде Амантай.

— Пешмәгәннәр. Пулеметны монда алып килеп, шыпырт кына көтеп алсак, коендыра идек утка мәлгуньнәрне, их!

Фарукҗан дошман якынлашкан тарафка тагын бер караш ташлады да иптәшләренә:

— Барыгыз да пулеметлы үр артына! — дип әмер бирде.— Күтәрә алган кадәр каракүл капчыкларын да алыгыз.

Басмачылар күп булырга тиеш,— диде уйлады Фарукҗан.— Без — унике, беребез — яралы. Корал җитәрлек, кәрван да пулемет алып килгән булса, бәлки, бирешмәбез. Әмма үзебез һөҗүм итәрлек түгел. Сакланып кына җиңү исә икеле. Берәрсен Зыятдинга җибәреп, ярдәм сорарагмы икән әллә? Караңгыда сиздерми генә дошман янынннан узып китә алса... Хәер, гарнизонда безнең кая юнәлүебезне болай да беләләр, озак әйләнеп кайтмасак, үзләре дә эзләп юлга чыгарга тиеш. Димәк, дәвамлы сугышка әзерләнергә кирәк, тиздән таң беленә башлаячак.

Фарукҗан пулемет тирәсендәге үрдә һәр сугышчысына урын күрсәтеп, яшеренер өчен оя казырга кушты. Дөяләргә төялгән коралны саклану боҗрасы уртасына бушаттылар, караңгыда капшанып, өр-яңа пулеметны да эзләп таптылар. Зыятдин гарнизоны кызыл гаскәриләренең икесе аңардан ата белә икән — бу һәммәсенә җан кертте. Патрон, мылтык дигәннәре тулы бер ротага җитәрлек — ник өч көн, өч төн атышмыйсың!

Дошманның таң беленгәнне көтүе ярап та куйды — һөҗүмне ничек кире кагасын ныклап киңәшеп, уңайлы алгы сызык әзерләделәр. Иң авыры — атлар, дөяләрне коткарып калу иде. Моның өчен аларны ике үр арасындагы казанлыкка кертеп, тышаулап яткырырга, хәтәр көтелгән якка каракүлле капчыкларны тезеп куярга, малларны күзәтер өчен бер кызыл гаскәрине билгеләргә туры килде.

Таң сызылганда дошман хәрәкәткә килде. Фарукҗан йөздән артык җайдакны санап чыгарга өлгерде. Иптәшләренә басмачыларны пулемет уты өтәрлек якынлыкка китерергә, алдан өркетмәскә боерды.

Фарукҗан кылычларын айкый-айкый һай-һулап һөҗүмгә ташланган җайдакларны кое янына килеп җиткәнче салкын кан белән күзәтеп ятты. Юкка гына фронтта өч ел тоташ михнәт чикмәгән, психик атакалардан каушамаска, курыкмаска күнеккән иде ул. Әмма хәрби бәрелешләрдә әле һаман чыныгып җитмәгән сугышчылардан кайсыдыр чыдамады, алдан ыргылып килүчегә атып җибәрде. Тидермәде, бары кызылларның кайда яшеренеп ятуын гына фаш итте бу егет. Фарукҗан теш арасыннан:

— Тинтәк мәнди! — дип сүгенеп куйды.

Бәхеткә, кызышкан җайдаклар, ялгыз мылтык атылуын куркынычка санамый, кое янына ташкын булып килеп җиттеләр дә, монда каршылык очратмагач, Фарукҗаннар яткан үргә таба борылдылар.

Шулчак пулемет телгә килеп, дошманнар өстенә ут яңгыры яудыра башлады. Аның «та-та-та»сына мылтыкларның бах-бахлары кушылды. Дошманның алгы сафы, киселгән агачтай, җиргә ауды, арттан тыгызланып-кысрыкланып килгән атлар шул мәетләргә абынып, корбаннарның санын арттырды. Фарукҗан, тешен кысып, пулеметын уңнан сулга, сулдан уңга боргалап, дошманны кыруын дәвам итте. Ниһаять, җайдаклар айныды, як-якка сибелеп, чигенә башладылар. Үкерү, сүгенү, пошкыру авазларына күмелгән кое тирәсе шундук бушап калды.

— Егетләр, күрәсезме, бу хәсрәтләрнең мылтыклары санаулы гына! — дип кычкырды Фарукҗан.

— Кәрванга исәп иткәннәр икән, тотсыннар!

Ул арада дошман яңа һөҗүмгә әзерләнә башлады. Бу юлы алар, әллә ничә төркемгә бүленеп, арт яктан ташланды. Анда басмачыларны икенче пулемет каршы алды. Һөҗүм бу юлы да өзелде, тагын шактый мәет, яралы калдырып, гаярьләнгән җайдаклар чигенергә мәҗбүр булдылар.

Егермеләп кешесен югалткан басмачылар төркеме кызыл гаскәриләрнең азлыгын белгәнгәме, әле һаман үзен бәрелештә җиңелгәнгә исәпләми иде. Шулай да, кылыч болгап кына эш уңмасын чамаладылар, ахры, аттан төшкән мылтыклылары алгы сафка чыкты. Атлылары исә сибелеп, Фарукҗаннар тезелешеп яткан боҗрага берьюлы бөтен яктан һөҗүм итәргә кучтеләр. Адымнары болай тиз үзгәрү араларында тәҗрибәле хәрби дә булуын күрсәтә иде.

Сибелеп һөҗүм иткән басмачыларны туктату кыенрак иде. Бу юлы ике пулемет берьюлы телгә килде, мылтыклы кызыл гаскәриләр дә кыюланып, ышанычлырак, төзрәк ата башлады. Болай куе ут ачуны көтмәгән дошман, сафлары торган саен сирәгәя баруын күреп, алга ыргылуын сүрелдерде.

Байкучатов, иптәшләренең күңелен күтәрергә теләп:

— Бездә икән көч! — дип кычкырды.— Якынрак килеп кенә карасыннар, иманнарын бик тиз укытырбыз!!!

— Ми урынына кибәк, ахры, боларның,— диде Амантай.— Кылыч болгап өркетмәкчеләр имеш.

Дошман бүтән һөҗүм ясарга талпынмады. Соңгы атакалары сакланучыларга да шактый зыян салуын белмәделәр, күрәсең. Укчы кызыл гаскәриләрнең икесе авыр яраланган, берсе, маңгаена пуля тиеп һәлак булган иде. Әмма пулеметчылар исән-сау, басмачылар гайрәтен нәкъ менә шулар сүндергән иде.

Хәвеф-хәтәр кимегәч, Фарукҗан җиңел сулап ерак офыкка күз салды. Яктырып, нурланып көн туган, сахра күз күреме арада сары матурлыгы белән тыныч кына җәелеп ята, әле генә колакны тондырган атышу, ярсыган сугышчыларның кыргыйларча акыруы-бакыруы, тоякларыннан очкын чәчрәтеп, җир селкетеп чапкан атларның кешнәве — шәфкатьсез бәрелеш, гүя, бер дә булмаган шикелле иде. Ләкин күзне якынгарак салсаң...

Сугыш кырында чәчелеп яткан дошман мәетләрен хәзер инде санап чыгарга да мөмкин иде. Әмма басмачылар аларны җыйнап алып китәргә батырчылык итмәделәр, хуҗасыз калган атларын тотып шактый ерак арада бергә укмаштылар да, ниндидер яңа планнар корып, Каратау ягына таба юртып китеп бардылар. Аларның күздән югалуын кызыл гаскәриләр бик озак игътибар белән күзәтеп торды. Аннары араларыннан берсе:

— Кәрван китергән коралны без алданрак эләктерергә өлгермәсәк, күрәчәгебез шушында буласы икән,— диде.— Корал коткарды.

— Алла кушты дисәңче,— диде янә берсе.— Монда кабер казучы да табылмас, сөякләребезне шакаллар гына кимерер иде, югыйсә.

һәрберебезгә унар дошман ябырылган — дәһшәт каттә иде кү!
Дусты янына килеп баскан Амантай:
— Тукта әле, ботың юешләнгән түгелме соң синең, Иргәш?— дип эндәште.
Отряд бердәм шаркылдап көлеп җибәрде. Тик көлүдән туктап, шунда ук сугыш кызуында яралануын тоймаган Иргәшкә беренче ярдәм күрсәтергә туры килде.
Фарукҗан исә шул арада әсир аунап калган тирмәгә күз салды — басмачы карт ишек төбенә шуышып килеп җан биргән иде.

## 31

Зөһрәгөл Чекадан туп-туры өенә кайтты. Тирә-юненә, атлаган юлына игътибар итмәде, чөнки колаклары берни ишетми, күзләре һичнәрсә күрми иде. Берзаман үз капкалары төбенә килеп баскач кына айнып һәм саташмый, адашмый аяклары нәкъ менә шушында алып кайтып җиткерүенә гаҗәпсенеп, күпмедер вакыт караңгы коридорда ишек яңагына сөялеп торды. Аны, бәлки, күршеләре күреп калгандыр, каршы очраганнары исәнләшкәндер — бу тирәдә, кайсы киемен кисә дә, йөрешеннән үк таныйлар иң Зөһрәгөлне. Ә ул аларны бар дип тә белми, сукыр-чукрак кебек, дәшми-тынмый яннарыннан узып киткәндер. Менә сүз кубар инде хәзер урамда, Нәзиренә дә ишеттерерләр әле!
Әмма бу уй Зөһрәгөлне озак борчымады. Пәрәнҗәсен салып атты да, балаханәгә менеп, кызларына күз салды. Уенга мавыккан балалары, аны күргәч, шундук янына йөгереп килеп, бер-берсен әләкләшергә тотынды, тик эни кешенең үзләренә күңел бирмәвенә үпкәләп, бик тиз кире борылдылар. Зөһрәгөл исә, уку өенә килүчеләрдән сакланып, капканы бикләп куйды да кунак бүлмәсенә кереп утырды. Кулына яраткан китабын — «Төрек ханымнары»н алды, ләкин укырга тотынмады, күкрәген тутырган тынычсызлык әле һаман таралып бетмәгән иде. Хәер, ул аны болай да яттан диярлек белә, андагы тарихка кергән каһарманнарның теләсә кайсы хакында, җиде төн уртасында уятып сорасалар да, сөйләп бирергә әзер иде. Тик Зөһрәгөлнең мәшһүр хатыннар турында сөйләүдән бигрәк, үзенең шуларга охшыйсы, хәтта аларны уздырып, шанлы эшләр эшлисе килә иде. Кияүгә киткәнче шул хакта хыялланды, ярдәме тияр, дип төпле белем алырга тырышты. Аннары тормышына Нәзир бәреп керде. Бала тапканнан соң бөтен көне өйдә, ишегалдында бөтерелеп, андагы киң ябалдашлы чинар күләгәсендә, сәкедә табын әзерләп, бер чаттагы җәйге мичтә ипи салып, аш пешереп, төтенле учакка таба мүкәләргә тотынган кызларын багып көн уздыра башлагач, үзеннән-үзе сүрәнләнә, йомыла төште. Ыгы-зыгысы, мәшәкате кимемәде, арта гына барды, ләкин зур максатлар куеп яшәү, биеккә талпынулар табак-савыт, бала чүпрәкләре белән маташуга алышынды. Өч татар кызының докторлыкка укып чыгуын һәм Балкан сугышына китеп, шөһрәт казануын да ул кызыгып, көнләшеп кабул итте. Нәрсәләре белән өстен булды икән соң алар Зөһрәгөлдән? Сәләтлерәкме, әллә йөрәклерәкме? Сәләт дисәң, Казанда, Аитова ханым мәктәбендә берәүдән дә калышмады лабаса ул, башкалардан алдарак та барды сыман. Ата-анасы чакырып кайтарып кына эшне бозмаган булса...
Менә кемнәр ихтыярына буйсындырды бит ул язмышын. Һәр очракта алардан бары зирәклек, Зөһрәгөлгә нәрсә файдалырак, муафыйграк икәнне дөрес чамалауны көтәргә мөмкин идемени? Балага яхшылык теләү ул әле аның өчен, бернинди ялгышусыз, киң вә якты юллар да ача белү дигән сүз түгел иң. Шулай икән, баланың

үзенә дә ирек алу кирәктер. Бигрәк тә ул балигъ булганнан соң. Әллә соң ирек казаныр өчен Зөһрәгөл үзе дә җитәрлек омтылмадымы? Берәүләр, яраланган кардәшләребезгә ярдәм итәбез, дип ерак Балканга хәтле чыгып китте, ә ул, канлы көрәшләр бусагасына килеп терәлеп, җанына якын кешесенә үлем куркынычы янаганда да, өендә посып ята түгелме соң? Ниндидер Юлтай Симиниев дигән басмачылар агентының Чекага кереп оялавын күрде дә җебеп төште. Ихтимал, ул анда тамыр җибәргән бердәнбер дошман түгелдер. Ләкин күпчелек бит яңа тормыш ягында, Чеканы нәкъ менә шул яңалыкны яклар өчен революцион хөкүмәт төзеде. Анда кереп оялаган дошманнарны фаш итү, ашка тоз салу кебек, бигрәк тә фарыз эш. Тик алны-артны карамый ашыгып, каш ясыйм дип күз чыгармаска, бәлагә тарымаска гына кирәк.

Зөһрәгөл ире һәм аның әшнәләре өнәмичә телгә алган кешеләрне исенә төшерергә тырышты. Авызы пешмәсен өчен, аңа нәкъ менә шуларны — Тураев, Аксолтановларны эзләп табу хәерле иде. Нәмәгълүм кешеләр нишләп йөрүен сораша башласа, хәйләсен дә уйлап тапты: уку өенә китаплар эзли!

— Мин хәзер тегүчегә барып кайтам,— диде ул кызларына.— Өйне туздырмагыз, урамга чыкмагыз.

— Мин дә барам.

— Мин дә!

— Кая ул бу эсседә? Ризык өстәлдә, мәдрәсәдән абыегыз кайтырга да күп калмаган инде, аны каршы алырга да кеше кирәк ич өйдә.

Зөһрәгөл, балалары шыңшуын кырыс кына туктатып, өеннән чыгып китте. Хәзер иң мөһиме — таныш кешеләр күзенә мөмкин кадәр чалынмау, эшне чыннан да кызу тоту иде. Тураев, Аксолтановларны кайда очрату мөмкинлеген чамалаганлыктан, ул башта үзләренә якынрак булган Халык Комиссарлары Советына кагылды.

Шаһруд каналы буена урашкан биек, матур бинаның капка төбендә милиция сагы тора иде. Кызыксынып күз салса да, пәрәнҗәле хатын-кызны ул туктатмады. Зөһрәгөл дә сүз кушмады, хәзер кирәк кешесен теләсә кемнән сорашып эзләү хәтәр икәнлеген белә иде инде.

Өйалды җыйнак, буш, уңъяктагы ишеге ачык әйванда ике ир-ат язу язып утыра иде. Яшьрәге телефон трубкасын колагына куйган да әледән-әле, «әйе, әйе, аңладым», дип җавап биргәли, олырагы, дөнья язмышын хәл итә торган хикмәт иясе сыман, сул кулы белән сакалын учлаган да әйванның ишегалды ягындагы тоташ пыяла диварына күзләрен төбәп, каурый каләмен менә-менә ак кәгазь битеннән йөгертергә тора, әмма акыллы бөек фикер һаман башына килмәгәнлектән, купшы ак ефәк чалмасына кагылып алып, тагын сакалын аралый башлый иде. Зөһрәгөлне таң калдырганы — әйванның түшәме иде. Көзге, тоташ көзге! Ул бүлмәгә әллә нинди бер купшы, якты төс биргә, идәнгә җәелгән матур бизәкле келәмне, китаплар шкафын, өстәлләрне, алар артында утырган эшлекле хезмәткәрләрне, хәтта шул түрәләрнең билләрендәге каешка тагылган револьверларын да чагылдырып тора. Соңгысына игътибарны юнәлтеп, әйтерсең, кисәтә: хәтәр заман бу, сак булыгыз, ат аягын дагалаганда бака ботын кыстырмасын!

Ниһаять, кызу-кызу нидер язып утырган яшь егет, Зөһрәгөлне күреп алып, бер генә минутка телефон трубкасыннан аерылды да:

— Сезгә кем кирәк? — дип эндәште. Пәрәнҗә бөркәнгән зат җавап бирергә ашыкмагач, өстәп куйды: — Фәйзулла әкә Ревкомда. Габделхәмит иптәш берәр сәгатьтән генә килеп җитәчәк. Ни йомыш, бәлки безгә генә әйтерсез?

Тураев белән Аксолтановны «Кызыл шәрык» агитпоезды вәкил-

ләре оештырган бер җыелышта күреп калганлыктан. Зөһрәгөл әлеге егеткә ләм-мим эндәшмәстән, коридор буйлап алгарак узып, сулъяктагы икенче ишекне дә ачып карады. Яшькелт чынаяк плитә белән тышланган, шул чынаяк өслегенә чәчәкле ваза уеп ясалган затлы миче белән истә калырлык иркен бүлмәдә бер җан иясе дә юк иде. Диварында — Бохара Совет Республикасының зур картасы, бүлмә уртасында — өстәл һәм урындыклар. Халык Комиссарлары Совет рәисе кабинетын тагын да купшырак, тантаналырак итеп күз алдына китергән иде Зөһрәгөл. Садә икән. Хөкүмәт башлыгына лаек та түгелдер әле мондый гына биләмә.

Баягы егетнең өйалдына чыгып, үзенә кадалып торуын тойгач, Зөһрәгөл кабинет ишеген шапылдатып япты да кире борылды һәм, әлеге түрәгә ышкылып диярлек узып, ишегалдына атлады. Яшә, Шәрык! Европада йөрсә, хәзер үзен танытмас өчен нәрсә эшләргә тиеш булыр иде икән ул? Бохарада ир-атның пәрәнҗәгә кагылуы Европада хатын-кыз итәгенә үрелү бәрабәрендә. Сорауга җавап бирмәвен дә хатын-кыз әдәплелегенә, шәригатькә сылтарга мөмкин. Таныш түгел ир-атка ни дип авыз ачсын әле ул?!

Ревкомда Нәзир әшнәләре күбрәк болгана бугай. Димәк, хәзер серне ачарлык иң хәвефсез җир — РСФСР вәкиллеге. Әмма ул ерак, Шәех Җәлал мәхәлләсенә хәтле бу эсседә тәпиләү үзе бер сират күперен кичүгә тиң. Вәкиллеккә кемнәр килү-китүен күзәтеп торулары да мөмкин ич әле. Партия Үзәк Комитетына бару, мөгаен, яхшырактыр. Анда Бохара халкы күбрәк кайныйдыр, һәммәсен кара дәфтәргә теркәп бетерү мөмкин түгел. Аннары нәкъ менә шунда Тураев, Аксолтановлар тамырны ныграк җибәрүен чәйнәделәр ич бервакыт.

Зөһрәгөл, тәвәккәлләп, шәһәрнең Сәлләханә капкасы ягына юнәлде. Үзәк Комитет урнашкан Хәвез Рәшиткә килеп җиткән арада ул тәмам тирләп чыкты. Пәрәнҗә кояш сугудан сакласа да, тамак кибүен баса алмый иде. Аяк астыннан бөркелеп күтәрелгән тузан, тегермән ташы астыннан очып чыккан җылы он кебек, оекбашларга сылана, кәвешләр эченә кереп тула, бөтен өс-башка куна. Киемнәрне салып атып, тизрәк салкынча суда коенасы килә. Әмма якын кешесенә үлем хәвефе янавын кабат исенә төшерүгә, Зөһрәгөл сүлпәнәя төшкән игътибарын, ихтыяр көчен тагын уятып, йөзе караларны ничек фаш итәсен уйлый башлый.

Үзәк Комитетта тормыш кайнап тора иде. Монда ашыгып килүкитүләренә караганда, эш белән йөрүчеләр дә күп, бина алдында төркем-төркем җыйналышып, иркенләп гәп сатуларына колак салсаң, кызык эзләп вакыт уздыручылар да ишле икәнлеген чамаларга мөмкин иде. Ирләр генә түгел, берәм-сәрәм хатын-кызлар да күзгә чалына. Йөзләре ачык, димәк, Рәсәйдән килүчеләр. Зөһрәгөл шуларның берсен бинаның түрендәге бүлмәдә, эш урынында очратты. Шкафларга шыплап тутырылган папкалар, өстәлдәге бланклар өеме, махсус тартмалардагы картотекалар монда җаваплы хезмәткәр, белдекле кеше эшләвен күрсәтә иде. Зөһрәгөл итагатьле генә исәнләште дә:

— Тураев яки Аксолтанов әфәнделәр монда күренмәдеме? — дип сорады.

— Әфәнделәр?

Зөһрәгөл каушаудан ясалган хатасын төзәтергә ашыкты:

— Тураев, Аксолтанов иптәшләрне әйтәм.

Ярым хәрби киемендәге, кашларын җыерган хезмәткәр пәрәнҗәсен ачмаган кунакка башын күтәреп карады да:

— Сез кайдан соң? — диде.

— Минем аларның үзләренә генә әйтә торган сүзем бар.

— Таштимер иптәш тазарту комиссиясендә. Утырышлары әле

яңа гына башланды, тиз генә бушамас. Шәмгун Аксолтанов шәһәрдән чыгып киткән иде, кичен кайтып җитсә генә инде. Сез аларның танышымы?

— Түгел.

— Берәр хәвеф-хәтәр юктыр ич?

— Ничек әйтергә инде... Юк, мин һәммәсен дә аларга гына сөйли алам.

— Ә сез курыкмагыз, миннән шикләнмәгез,— диде хуҗа кеше кулына чынаяк касә алып.— Таныш булыйк: мин — Глафира. Фира дисәгез дә ярый. Хәзер чәйләп җибәрәбез.

— Юк, юк, кирәкми.

— Бик эссе ич бүген, сусата. Менә эчегез әле, хәл кертер. Әлегә хатын-кызлар безгә бик әз килә, сез — тансык кунак. Утырыгыз.

Зөһрәгөл, авызы кипкәнлектән, бүтән карышып тормады, тәкъдим ителгән урындыкка килеп утырып, пәрәнҗәсен ачты һәм касәне кулына алды.

— Бохара хатын-кызлары бигрәк боек, бигрәк йомыкый инде,— дип дәвам итте Глафира.— Кайда ул тиңлек, тигезлек өчен көрәшү, урамда йөзләрен ачып йөрергә дә котлары оча.

— Ә сезгә җыен ир-ат арасында эшләү кыен түгелме соң? Бөтенесе күзләрен тасрайтып карап торганда?

— Үз ирем дә шушында гына ич. Без аның белән Верный коммунистлары арасында чыныккан халык.

— Бохаралылар да үзгәрә хәзер,— диде Зөһрәгөл.— Әле менә берәүнең икенче хатыны ирennән аерылды да үзе сөйгән кешегә кияүгә китте.

— Булмас!

— Дөрес, аңа элекке ире «талак» дип кычкырган була.

— Монысы инде хәлне бөтенләй үзгәртә.

— Әмма беренче ире соңыннан «талак» кычкырганлыгын яшерә, аны кире кайтарырга маташа, булдыра гына алмый.

— Моннан соң андый азгыннарның нәфесен бик тиз чикләрбез,— диде Глафира.— Кая, тагын чәй ясыйм әле.

Зөһрәгөл аның ирләрчә кискен хәрәкәтләренә, сүзне хәрбиләрчә өзеп сөйләшүенә кызыксынып һәм сәерсенеп карап торды. Кайдан килгән аңа бу кадәр кыюлык, үз көченә ышаныч? Яше олы түгел, ә шулай да үзен дөнья күргән кешедәй тотуы шаккатырлык. Әллә серне ачаргамы соң шуңар гына?

— Киләчәктә азгыннарга тышау табылыр, тик әлегә алар монда котырына бирә,— диде ул тәвәккәлләп.— Әнә шул сөйгәненә чыккан Балҗанга тагын нидер оештырган элекке ире. Хәзергесе хатынына кемнәр нинди этлек ясавын белмидер дә, кызыл гаскәри ул, басмачылар белән сугышып йөридер. Йөзе каралар астыртын эш итә бит. Балҗан хәлен ачыклыйсы, аңа булышасы иде.

— Сез шуны әйтергә килдегезмени монда?

— Әйе,— диде Зөһрәгөл.

— Булдыргансыз, рәхмәт. Бохара мөселман хатын-кызларыннан да шундый кеше табылыр икән! Ә сез ул Балҗанны кайдан беләсез? Аңа янаган хәвефне?

Коридорда аяк тавышлары яңгыравын ишетеп, Зөһрәгөл тиз генә пәрәнҗәсен төшерде. Бүлмәгә бер ир-ат кереп, Глафирадан ниндидер папкалар таптырып алды. Ул чыгып киткәч, Зөһрәгөл:

— Балҗан минем көндәшем иде,— диде.— Аны эшкә Кагандагы хәрби госпитальгә урнаштырганлыкларын ишеттем. Этлекне исә дошманнар кичә оештырган бугай.

— Сез моны бүген генә белдегезме?

Зөһрәгөл бөтен серен Глафирага ачарга теләмәде, үзе дә сорауга сорау белән җавап бирде:

— Сез партия җитәкчелегендә нинди вазифа башкарасыз?

Ниһаять, Глафира да кунакның икеләнүен, чишелмәс өчен сәбәбе дә җитәрлек булырга тиешлеген төшенеп, елдам гына урыныннан сикереп торды.

— Бер генә минут сабыр итегез әле, мин хәзер монда эзләп килгән кешегезне чакырып китерәм.

— Чекада минем бер танышым да эшли үзе,— диде Зөһрәгөл Глафираны туктатып.— Кайбер нәрсәләрне аңа гына да барып сөйли ала идем мин.

— Соң, шулай булгач?

— Тик ул хәрби комиссар һәлакәтен тикшерергә керешеп, шәһәрдән каядыр чыгып киткән.

— Кем соң ул?

— Фарукҗан Байкучатов. Хәзер менә аңа да куркыныч яный — артыннан бер дошманны тагып җибәргәннәр. Җитмәсә, ул барасы ниндидер Багбанда да сагалап торалар икән егетне.

— У-у, мондый хәбәрне, чыннан да, Чекага җиткерү урынлы булыр иде.

— Анда ярамый!

— Нигә?

— Шулай.

Глафира серле кыяфәттә Зөһрәгөлгә күзләрен тутырып тагын бер карады да йөгереп диярлек бүлмәдән чыгып китте.

— Мин хәзер килермен, көтеп торыгыз!

Зөһрәгөл, күбрәк сайрап ташлавын тойса да, үкенмәде. Бары тәне кызыша, башы әйләнә, колаклары шаулый, күзләре әлҗемөлҗе килә иде аның. Миенең һәр күзәнәгендә уй тулган, зиһене кайный иде. Бөтен барлыгын таш кебек басып торган, рухын имгәткән халәттән котыласы, нарат урманындагы шикелле шифалы саф һаваны күкрәк тутырып сулыйсы, очар кош сыман, үз иркендә, хөррияттә яшисе килә иде. Монда рәхәтләнеп эшләп утырган, мохтаҗларга ярдәм кулы сузарга да икеләнмәгән Глафираны күргәч, аның бу теләге бигрәк тә көчәйде. Ихтыярын богаулап, сәләте ачылуын томалап торган кара көч бер генә иде хәзер — Нәзир! Тирә-якка җәбер, бәхетсезлек кенә таратуы тагын да ачыла төшкәч, гаилә дип, уртак балаларыбыз хакына дип тә чыдап тору мөмкин түгел. Ходай тәгалә шаһит: озак түзде Зөһрәгөл. Ләкин бүтән булдыра алмый.

Ике ир-ат ияртеп бүлмәгә Глафира килеп кергәч, Зөһрәгөл урыныннан торып басты. Тик кабинет хуҗасы аларны күзгә-күз калдыруны кирәк табып:

— Менә үзегез генә сөйләшегез, кунагыбызның ачасы сере хәтсез,— диде дә коридорга чыгып китте.

Аны өрлектәй таза, киң җилкәле, иягендә каралып торган миңле пәһлеван шикләндермәде — бу ир-атның Таштимер Тураев икәнлеген бер күз салгач ук таныды. Ә менә икенчесе эченә суык йөгертте — Чекада каршысына чыгып баскан чекистларның өлкән яшьтәгесе иде бу. Зөһрәгөл куырылып, нишләргә белми аптырап торганда, Тураев:

— Я, кардәш, башлагыз,— диде.— Чека рәисе Галимҗан иптәш Әминевкә миңа ышангандай ышаныгыз. Глафира сез ачачак серләрнең күбрәк аңа кагылачагын искәртте.

Зөһрәгөл Балҗан белән Фарукҗанга янаган хәвефне сөйләп биргәч, Таштимер:

— Боларны кайдан белдегез? — дип сорады.

— Иремнең эшнәләре белән сүз берләшүен качып тыңлап тордым.

— Сез сөйләгәннәр расланса, ирегезнең җәзага тартылачагын

төшенәсезме? — дип сорады Әминев.

— Әйе. Шул кирәк аңа!

— Ни өчен аны фаш итәргә булдыгыз?

— Шәфкатьсез, намуссыз бәндә ул. Балҗан, Фарукҗан кебек бер гаепсез кешеләрне дә кыерсытырга, җаннарын алырга ашкынып тора.

— Балҗан, Фарукҗаннар якын танышларыгызмы?

— Беренчесе кордәшем иде. Икенчесен Казанда укыган чагыннан беләм,— диде Зөһрәгөл кызарынып. Пәрәнҗә аркылы комачтай йөзе күренмәве исенә тәшкәч, батыраеп өстәде: — Фарукҗанның Бохарага килүен мин очраклы рәвештә генә ишеттем.

— Нигә бу хәбәрләрегезне Чекага гына барып әйтмәдегез? — дип сорады Тураев.

Зөһрәгөл Әминевкә таба борылып:

— Кичә сезгә бер хатын-кыз килүен онытмадыгызмы? — диде.

— Сез идегезмени ул? Ләм-мим дәшми нигә кире чыгып качтыгыз соң?

— Качарсың да,— диде Зөһрәгөл.— Мин сезгә ярдәм, яклау өмет итеп килсәм, әле кайчан гына бездә ирем белән иң мәкерле җинаятьләр ясау хакында киңәш корып утырган бәндә чекист рәвешендә каршыма чыкты басты. Танымаса гына ярар иде, дип өркеп калдым.

— Кем иде соң ул? — дип җанланды Тураев.

— Юлтай Симиниев...

— Менә күрдегезме, ничә әйттем мин сезгә,— диде Таштимер ачулы кыяфәттә Әминевкә төбәлеп.— Юлтайның кемнәр белән исәнләшүен күптән сизгән идем аны, шулай булып чыкты да. Трибуналга тапшырырга кирәк ул кара еланны! Кая кереп оялаган лабаса, мөртәт. Шиһабетдинов үлемендә дә, башка һәлакәтләрдә дә шуның кулы уйнагандыр әле. Ә сез аңа шул ук җинаятьләрне тикшерергә, ачарга кушасыз. Ачар, көтегез!

Әминев кызып киткән иптәшен тыеп:

— Монда салкын акыл кирәк, Таштимер,— диде.— Бар, утырышка керә тор син, бу хакта соңыннан киңәшербез. Мин сеңелкәш белән сүзебезне генә очлап бетерим инде.

Тураев чыгып китәр алдыннан, Зөһрәгөлне күздән кичереп, янә бер сорау бирде:

— Ирегезнең аты кем инде, сеңлем?

— Нәзир Әбдиев.

Икәү генә калгач, Әминев кунакка ягымлы итеп эндәште:

— Хәбәрегезгә рәхмәт, якташ. Сез татар ич, әйеме?

— Әйе.

— Пәрәнҗәгезне ачыгыз инде хәзер, танып калыйм, ярдәм кулы сузар өчен дә кирәк бу.

Зөһрәгөл йөзен ачкач, Галимҗан Әминев җитди кыяфәттә сораша башлады:

— Киләчәктә нишләргә уйлыйсыз? Безгә ирегезне хәзер үк кулга алу файдалы түгел. Аларның тагын нләр болгатырга җыенуын, өерләрендә янә кемнәр катнашуын ачыклыйсы иде. Бу эштә безгә киләчәктә дә ярдәм итәргә ризамы сез?

— Хәтәр эш шул бу.

— Әйе, хәтәр. Әмма сезнең ярдәм күпләрне бәладән коткарыр иде. Балҗан, Фарукҗан кебекләрне! Сез таҗикча, русча да беләсездер әле?

— Бераз сөйләшәм.

— Бик шәп ич бу! Әгәр безнең үтенечкә риза булсагыз, киләчәктә Чекага яки монда килеп йөрүегез гомумән кирәк булмаячак. Берәр кешебез сүз куешкан җирдә үзе сезне көтеп алыр.

Шуннан соң Эминев, коридорга башын сузып, Глафираны чакырып кертте дә аңа Зөһрәгөл белән ничек багланыш тоту кирәклеген аңлатты, аннары саубуллашып:

— Ярый, якташ, ак юл сезгә,— диде.— Кыюлык, саклыкны онытмагыз. Бик ашыгыч, кичектергесез булса гына, бүтән юл белән хәбәр бирерсез. Анысын Глафира өйрәтер.

Зөһрәгөл, үзенең ни өчен монда килүен бер генә минутка да онытмаганлыктан, Эминевтән:

— Балҗан, Фарукҗаннар исән-саумы икән әле? — дип сорады.— Дошманнар сагалавы хакында кисәтәсе иде аларны.

— Аңладым, һичшиксез, кайгыртырбыз.

Әмма Каган станциясендә яңгыраган коточкыч шартлау, аннары Бохара базарларының берсендә кабынган зур янгын, анда Әфганстан сәүдәгәре Габделшөкерхан мал-мөлкәтенең тулысынча көлгә, күмергә әйләнүе, тәүлекнең калган өлешен тоташ ыгы-зыгыга күмде. Чека рәисе Галимҗан Эминев тә, Таштимер Тураев та, партия сафларын тазарту комиссиясе утырышын туктаттырып һәм шул һәлакәтләрнең сәбәбен ачарга тырышып, Зөһрәгөлгә биргән вәгъдәләрен тиз генә үти алмадылар. Глафира исә, Шиһабетдинов үлемен тикшерергә тотынган чекистка булышуны күңеленә салып куйса да, партия Үзәк Комитетында бүлек секретаре вазифасын гына башкарганлыктан, җитди көчкә ия түгел иде. Шулай да кул кушырып утырмады, әле һаман күңеленнән чыкмаган хатирәләр хакына кайбер нәрсәләрне ачыкларга кереште.

*Ахыры киләсе санда*

# ШИГЪРИЯТ

## Әхмәт Гадел

### Заһидулла Яруллин — сабан туенда

Үсәлидә — сабан туе...
Кайный мәйдан...

Әбүталип моң очыра биек күккә,
иңә ул моң күңелләргә...
Аккордеон дигән гармун
әллә каян алып кайткан,
бармаклары чаба, чаба,
әйтерсең лә чабышчылар
йөгереп менә үрләргә!..

Малай-шалай, җыелдык та, тыңлыйбыз без:
тамаша кыл, дигәндә, һәй, безгә юк тиң!
Әбү абый оста көйче, әмма, мескен,
бер кулсыз ул, ике күзсез...
Өстәвенә әле, бахыр, дөм ятим...
Тик гармуны, аккордеоны —
газиз дусты.
Шуның белән гаиләле,
хисләргә бай...

— Әбүталип, энже җанлым,
алтын куллым, булдырасың,
әйдә уйна, елат, давай!

Сабан туе —
зур җыен ул безнең якта:
менә Сөннәр, Кыерлылар,
Таулы Ташлык...
Сөрән салды бирәү:
— Бездә кунак
Заһидулла көйче-оста, алың каршы!

Тарантаста. Яхшы атлар биеп тора.
Кече Сөннән...
Бу атларга булырмы тиң?!

---

Әхмәт ГАДЕЛ *(1942) — шагыйрь, татар һәм кырым-татар телләрендә дөнья күргән «Чам», «Яшьлек урамы» һәм «Көмеш кылган җырлары» исемле һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Чал Казаннан махсус кайткан
зур җыенга композитор Яруллин!

Какча йөзле, мут күзләре уйнап тора...
— Әбүталип, ни хәлең бар, сайрыймы бу?! —
Аккордеонны Заһидулла кулына ала.
Марш яңгырый,
оча күккә!
Әй тантана!

— Заһидулла!
— Оста абый!
— Әйдә уйна!!!
— Дәрт уяттың күңелләрдә,

(Болай икән — бу халыкны җиңәрлекме?!)
Композитор, дулкынланып,
яшь егетне чакырып алды,
Мирсәетне...
— Үз гармуным, улым, кайда,
бир гармунны!
Әбүталип, әйдә, якташ, уртак моңны!
«Тау астында салкын чишмә
Челтер-челтер агадыр...»

Өчиледә сабан туе...
Болынлыкта...
Уйный оста,
күккә оча татар моңы...
Болытларны туглый бу моң —
күк күкри...
Яруллинның моңына кушыла яшен чыңы!

Үсәлидә —
Өчиледә сабан туе...
Бу җыенның гомердә дә булмас тиңе!

## Кәрим Җаманаклы

Әй-йа, хода, күпме чиркәү
бу кечкенә генә калага!
Биек тавымы, нәрсәсе беләндер,
хәтерләтә аның туган ягын...
Диңгез исе Алабугада!..

Изалана шагыйрь, күк диңгезнең
сагынып моңлы, назлы шаулавын...
Кыен аңа, кышкы бураннарның
симфониясен кыен аңлавы...

Төннәр буе йоклый алмый шагыйрь,
күңеле ялгыз аның,
ул — ятим.
Кәгазь, каләм ала: яза;
яза...
Җан җәзасын куа,
тынычлык эзли

шагыйрь, галим һәм гражданин Кәрим [1].
Әле белми, шушы җирнең куены
тәнен кочып, назлап җылытыр.
«Ай, нәни»не көйләгәндәй, үзен
«Бишек җыры» белән юатыр...—
Җан рәхәте бирер... гади халык
үзенеке итәр һәм санлар...

Күзен йомган саен күз алдына
килер диңгез, җанланыр чамнар [2]...

Җылы сүзләр, бөек мәкам түгәр
бу туфракка аның йөрәге.
Кырым җыры, диңгез шавы килер...

Юк, бу — тик аның изге теләге!
Соңгы җыры аның — диңгез җыры,
соңгы сүзе аның — тау сүзе!
Якты моңын түгеп, китеп барыр
Кырымга дип, бахыр, ул үзе...

Чал чәчләрен кысып кулы белән,
тыныч кына соң кат елмаер,
зәңгәр күккә багар һәм...
                    Ачы сүз,
«Аһ!» дигән сүз иреннәрдән тамар...

Аның өчен шунда көн баер...
Башка бер сүз чыкмас иреннәрдән,
каләме дә туктар кәгазьдә...

Ә еракта дулкын — «Кайтарма»ны
уйнар, биеп, зәңгәр диңгездә...

## Сатучылар җыры

— Иң элек без саттык тарихны,
Аңа кушып язу-хәрефне...
Аннан ары — китте батырлар...
Бер сатканнар түзмәс — сатырлар!
Яңа тарих — яңа тун сыман,
Яңа хәреф — язгы гөл-хыял.
Без йөрибез — яңадан туган
Язмыш белән йөрибез уйнап.
Язмыш исә — халык тәкъдире,
Киләчәге аның — кояшы,
Йә булмаса ачы күз яше:
Туган йорты, Ватаны, җире...
Я мәңгелек сагышы — чире...
Болай тирән уйлый белмәдек,
Безнең өчен түгел тирәнлек!
Уй киңлеге, хис бөеклеге...
Бу хакта һич уйлый белмәдек!

Ләкин төннәр хәзер борчулы,
Язмышыбыз безгә ачулы:
Үлә алмый иза чигәбез!
Бу газапка дучар нигә без?!
Кайтарыр да идек тарихны,
Аңа кушып саткан хәрефне,
Себер киткән алтын башларны,
Эчкән хәмерләрне, ашларны...
Кулдан килми гали батырлык,
Үлем көтеп калды ятырлык...
Халык түгә чүпне, сафлана,
Халык юа нәҗес-тиресне...
Инде күптән онытты безне!

Безнең заман, тумыйча, үтте...
Кол Галиләр заманы җитте!

---

[1] *Сугыштан соң Алабугада яшәп, шунда үлгән кырым-татар шагыйре һәм галим Кәрим Җаманаклы турында сүз бара.*
[2] *Чам — Кырым нараты.*

## Зоопарктагы тюленьнәрнең әйтер сүзе

— Бик озак диңгезгә карадык,
суларга...
Чем-кара, моңсу-саф бу күзләр шуңарга!
Уйчан без, ятимдәй —
күңелдә ут-сагыш:
Диңгезгә якты юл, әй кешем, син табыш!
Бик озак җылындык без диңгез буенда,
(Шуңа да пакь дәрья, саф диңгез уемда!)
Ярдагы ташларга охшаш без шуңа!
Тозлы су булмаса, тән чатный йә туңа!
Бик озак яшәдек диңгездә,
суларда...
Тар безгә бу җирләр, бу сулар шуңарга!
Йә, ничек кечкенә хавызда [1] йөзәргә?!
Коллыкка — хурлыкка зарланмый түзәргә?!

Күңелдә чиксез моң, күңелдә сагышлар:
Төзәлми кемнәрдер ясаган ялгышлар!

## Өметкә тугрылык

Биектән, җәйләүдән ак хыял
Төште дә күңелгә урнашты.
Зәп-зәңгәр күзләрең, саф уйлар...
Бер бактым — күзләрем камашты.
Бар җирдә туй итә алтын көз,
Йолдызлар — шатлыклы күз яше.
Сер сөйли тауга тау — йөрәк, түз.
Җир үзе Кояшның каләше!
Кич. Тынлык. Җыр. Йолдыз. Янында
Сәлбиләр [2] торалар җыр көйләп:
«Иң чибәр, иң сылу, иң түзем
Кешем, син кайт тизрәк бу җиргә!»
Еракта йөргәндә, онытма:
Моң булып йөрәктә калыр көз.
Күңелгә иңмәсен болытлар —
Бер өмет булыйк гел икебез!

---

[1] Хавыз — киң бассейн.

[2] Сәлби — көньяк тирәге.

## Сәгыйть Хафизов

# ГОМЕРЕМ ФАСЫЛЛАРЫ

ПОВЕСТЬ

### I



Улым, кичә без сине солдатка озаттык. Аерылышу сагышы кешеләр белән шау-гөр килеп озатканда түгел, ялгыз калгач басты мине. Өй, кояшсыз көн төсле, ямьнән мәхрүм. Апаларыңның балигъ булып нигездән китеп барулары да күңелне болай ук иләсләндермәгән иде.

Син ил хезмәтенә чыгып киттең, улым. Аннан син тагын да ныгып, матурланып кайтырсың. Сабырсызланып, күрешүебезне көзәллыйм. Бу минутларны барыбер көтеп алырмын мин. Еллар аша, ераклыклар аша гел бер-берсенә тартылган, тартылачак җаннар бит без синең белән, улым.

Еллар, аралар... Без гомер тавының икебез ике ягында, улым. Син аңа менәсең, мин аннан төшәм. Минем ул — ачыш, сөенү, төшү исә сагышлы... Төшкән кешегә вакыт һаман бер нәрсәне тәкърарлый: «Туең узган, туның тузган», ди... Кызарып баткан кояшлар мине хәзер күпвакыт оеткыч уйларга тарта. Соры көзләр моңсуландыра. Аккан сулар, серле пышылдап, күңелемне сагышка батыра. Көндез генә түгел, төннәрдә дә үзем аша вакыт узганын, вакыт агышын бик ачык тоям хәзер.

Юк, юк, зинһар, әтием үлемнән курка икән, дип уйлый күрмә! Миннән дәвам кала, син каласың, улым. Әйе, әйе, төсем, холкым, рухым белән синдә яшәүне дәвам итәм мин. Ә син киләчәктә улыңда яшәрсең. Аннары оныкларыбызга күчәрбез. Тик оныкларыбыз эзсез-тамырсыз түгел, асылыбызны дәвам итүче анык кешеләр булырга тиеш. Шулай булмаса, яшәвебездә нинди мәгънә, нинди ямь бар?! Кеше булып яшәвеңне тояр өчен кан берлеге генә түгел, рух уртаклыгы да кирәк шул. Бармы бездә мондый бердәмлек?

---

Сәгыйть ХАФИЗОВ *(1946) — филология фәннәре кандидаты, проза әсәре белән журналда беренче тапкыр катнаша. Уфада яши.*

Улым, күптән җыелган бер үпкәмне әйтергә телим хәзер. Авылда туып, шәһәр кешесенә әверелүемне белсәң дә, ничек үсүемне, ниләр кичерүемне юньләп белмисең ич син. Әтиеңнең дә малай чагы булуын уйламыйсың шикелле. Кайчандыр егетлек чоры кичерүемне дә күзалламыйсың инде. Нигә, сабыйлыкта шулай бит ул, дөнья һаман бер казык тирәсендә әйләнә сыман. Эти гел эти булып тора, әни — гел әни... Нәкъ шулай корылганга, балачак дөнья сагышыннан азат та бит ул. Тормыш, балигъ булгач кына, бездән сорый башлый: бабаң, әбиең кем? Нәсел-нәсәбең нинди, тамырың кайда? Кайчагында йөзәрләгән сорау белән баш катырсаң да, бу җәһәттән күңел хакы өчен генә дә бер сорамадың бит, улым. Әниең хакында сорашмавың аңлашыла: күңелемне яралыйсың килмәгәндер. Әмма битарафлык үзе үк яра салу бит ул. Сорашкан, кызыксынган булсаң икән!

Билгеле, үземдә дә гаеп зур. Мәшәкатьләр, борчулар белән булышып, сиңа тормышымны ачмаганмын. Тойгыларым, кичерешләрем белән, мөгаен, синең алда бикле калганмын. Бу — зур хатам. Җинаятем, хәтта. Кичер, улым! Минем рухым сиңа күчәргә тиеш. Дөрес, матур яшәвең өчен сиңа атаң рухы кирәк!

Кичләрен мин синең бүлмәңә керәм. Кулларым ирексездән кәгазь-каләмгә үрелә. Сине янәшәмдә тоеп, үземнең тормышымны язам мин. Табигатьнең җәе, кышы, яз-көзе булган кебек, кеше гомеренең дә үз фасыллары — сабыйлыгы, балигълыгы, яшьлеге-картлыгы бар. Дөньяның салкын бураннары, ләйсән яңгырлары, чәчәкгөлләре булса, безнең дә кайгы-моңнарыбыз, сөенечләребез бар. Әйдә, улым, кайчандыр кулларыңнан тотып, җитәкләп тәпи атлаткан кебек, гомер борылышларым, сөенеч-шатлыкларым, яну-көюләрем дөньясына алып керим әле сине.

## 2

Таш юл буенча дөбердәп чапкан арбада ятам. Күзләремне авырттырып чагылдырган җәйге кайнар кояш белән бергә, еллар аша миңа әниемнең хәсрәтле йөзе иелә:

— Улым, бик авыртамы?

Мин байтак вакыт эндәшмим. Сул күз кисеп чәнчи. Аңа кылчык кереп кадалган сыман. Эре-эре кайнар тамчылар борын янәшәсеннән тәгәрәп үтәләр дә, суынып, муенга төшәләр.

— Кояш... чагылдыра...

Әни, йомшак кына кагылып, биттәге чүпрәкне күзгә шудыра, кояшны каплый.

— Күзләреңне йом, балам, әрнүе басыла төшәр...

Хәтердә янә бер күренеш җанлана.

Түбәтәйле, ак ситсы күлмәкле бәләкәй малай, урак тотып, кабалана-кабалана бәрәңге сабаклары кисә. Туфрак, яшь бүлбе исе аңкый.

Күрше малае Заһит, селтәнеп, түбәтәйле малай ягына бәрәңге алмасы ыргыта. Менә тәлгәш һавага чөелә, менә ул дуга ясап өскә килә, «Тот, тот!»,— дигән сыман, баш өстендә бер мизгелгә асылынып кала. Түбәтәйле малай ураклы кулы белән кискен селтәнә. «Ай!» Кәкре уракның очы бар. Зур, үткер кылчык шуның очыннан кадалып калган. Эре-эре кайнар тамчылар шул урак ясаган чокырчыктан бәреп чыгалар сыман.

— Әни, без кай төштә?

— Җитеп киләбез, улым. Бүлнистә әрнүләрең басылыр, улым...

Кечкенә бер палатаның ак түшәменә текәлеп, әчтән сыктап ятканымны яхшы хәтерлим. Кычкырып, тавыш белән еларга курыктым. Чөнки янымда бик юан гәүдәле бер абзый бар иде.

Баштагы мәлдә мин, авыртудан йомылып, гел урын өстендә

яттым. Абзый борын мышкылдатуымны, сыктавымны сизде:

— Шундый матур малайка елыймы?— дип, баш очыма килеп чын-чынлап гаҗәпләнгән булды. Ә аннары бик җитди төстә әйтеп куйды: — Малайка, елама! Еласаң, күзең бозыла. Матур күзләрең харап була. Син, малайка, аша!

Абзый баш очымдагы сары тумбочкага төрле ашамлыклар тезә торган булып китте.

— Синең кемнәр бар, малайка?— дип сорый миннән әлеге абый.

— Әни бар.

— Тагын кем бар?

— Абый бар...

— Атаң үлдемени?

— Үлмәде.

— Үлмәгәч, кайда ул?

— Минем эти түгел инде ул хәзер...

— Алай...— дип сузды абзый.

Күзем сызлавы басыла төшкән саен, сагынуым көчәйде. Иртәләрен ярый әле, түзәсең. Күзгә дару салалар, докторлар килеп карый. Ә менә коридор талгын тынлыкта калып, кояш баегач, йөрәкне туктаусыз нидер кыса, тырный башлый. Абзый гырлап йоклый, мин, эссе бүлмәне тарсынып, ишегалдына чыгам. Моннан рәшә җәйрәп торган озын калкулык күренә. Калкулык итәгеннән сузылып, еракларда зәңгәр күк белән кушылган соры юл чалымлана. Әни шуннан килергә тиеш...

Иртәләрен җиңелрәк: мин әнине көтәм. Ул кояш чыккач, салкынча мәлдә килергә тиеш. Ә кичен тәгаен килми, килә дә алмый инде ул. Кичен ерак юлга чыкмыйлар.

Эх, әни! Йөрәгемдә үпкә, ачу кузгала: ниндидер бер үчләнү белән әнинең үземне кыерсыткан, рәнҗеткән чакларын барлый башлыйм. Аның эштән кайтуын көтеп, караңгыга чаклы баскыч төбендә шыңшып утыруларым искә төшә. Нәрсәнедер ватканым өчен бер мәл караңгы базга ябып торды. Ә бер буранлы салкын көндә, ялгызымны өйдә бикләп калдырып, каядыр китеп барды. Өйгә әкренләп караңгы иңде. Почмаклардан, мич тарафыннан килгән шомнан котылырга теләп, тәрәзәгә капландым. Тыным белән җылытып бозны эретергә ымсындым. Җаным урам белән, үтеп-сүтеп киткән кешеләр белән берләшер кебек иде. Әмма карлы боз эремәде. Мин шунда, сәгать гере белән бәреп, тәрәзәне ваткан идем. Тәрәзә ватылып, алдымда ак, карлы урам калыккач, йөземә, җан иясе кебек, тере җил килеп бәрелгәч, йөрәккә көч кергән иде.

Моннан соң да күп тапкырлар әнигә үпкәләгәнем булды. Андый чакларда иң олы теләгем — үлеп, әнине елату. Хыялда әнинең буылып-буылып елаганына үчегүле сөенеч туа. Рәхәт тә. Әйтерсең лә, йөрәктәге кысылган ташны әнинең шифалы күз яшьләре юа. Менә таш кечерәя, кечерәя. Күңел тәмам бушый. Ә аннары «үлгәнемә» үкенеп, әнине җәлләп, яшькә чумуыңны да сизми каласың...

— Чү, малайка, тукта, ни хәл бу? Күзләреңне бозасың бит, матур күзләреңне харап итәсең. Әй, тукта дим!

Абзый мине күтәреп үк ала. Мин, күз яшьләренә буылып, аның иңнәренә сарылам.

— Әни кил... әни килмәде бит...

— Йә, йә, килер әниең. Бүген килмәсә, иртәгә килер. Тик син елама!

Абзый, гөрелдәп сөйләнә-сөйләнә, мине бүлмәгә алып керә, йомшак итеп урынга яткыра. Салкын, саллы кулын башыма куеп, тынычланганымны көтеп тора.

Ниһаять, минем янга килделәр. Ләкин килүче кеше әни түгел.

абый иде. Үзебезне дәвалаучы апа бу турыда кереп әйткәч, бүлмәдән — коридорга, коридордан урамга атылдым.

— Абый!— дип муенына асылындым.

Абый да башымнан сөйде. Мине, йомшак кына итеп, җиргә төшерде.

— Мәнә сиңа күчтәнәч,— диеп, төенчекне чишеп җибәрде. Иң элек җыйнак каен тырысы, тырыс эчендәге эре, кызыл җиләкләр күземә ташланды. Алардан баш әйләндергеч хуш ис бөркелә иде.

— Күзең инде бернәрсә дә күрмимени?— Абыйның мондый сәер сүзләреннән куркып киттем.

— Юктыр, мин бит күрәм, тик томанлы, күземне пәрдә каплаган кебек,— дидем.

Абый, канәгать чырай күрсәтеп, башымнан сыйпап алды:

— Һәй, энекәй,болай булгач ярый икән. Ату халык әллә нәрсә сөйли. Әни дә синең хәсрәттән урын өстенә ауды. Ничә көн инде башы әйләнә, торалмый. Их, малай актыгы! Соң, эшләгәндә карап кына эшләргә ярамый идемени?

Абыйның әрләвеннән оялып, башымны идем.

— Йә, ярар, үкенеп кенә файда юк,— диде абый.— Ә Заһитның колагын шәп бордым мин. Онытмас шәт.

— Заһитның гаебе юк, абый.

— Нишләп гаебе булмасын? Дуңгыз ул, һич кеше төсле уйный белмәде...

— Абый, әни гел урын өстендә ятамы?

— Әйтәм ич, урыныннан торалмый. Торса, шундук егыла...

Озак кына дәшми тордым. Кинәт өйгә кайтасы килеп китте.

— Абый, алып кайт мине!

— Син, энекәш, юк белән баш катырма, яме?— диде абый, ике сөйләтмәслек итеп.— Ә күзең төзәлгәч, алып кайтырбыз. Булдымы?

Мин ул кичтә бар тынычлыгымны, бөтен сабырлыгымны югалттым. Беркемне тыңлыйсым, берсенә дә җавап бирәсем килмәде. Тыныч, бөркү палата читлеккә әйләнде. Ак, пөхтә больница койкасы минем кан дошманым булды...

Ниһаять, төн инде. Абзый сабый төсле изрәп йоклый, ә мин һаман керфек какмыйм. «Әнинең башы авырта... әни урынга егылган...» Күз алдыма килә: әни караватына утырган. Башына сөлге ураган. Мөлаем көрән күзләренә, кан качкан йөзенә сыкрану шәүләсе иңгән. «Әй, бала, бала,— ди ул зәгыйфь итеп,— синең аркада шулай башым авырта бит минем...»

Әй, мескен әни! Баш зәхмәтеннән еш егыла шул ул. Минем иң тәүге хәтерләүләрем, сабыйлык тетрәнүләрем дә шуңа бәйле түгелме соң?

Мәнә безнең шәрәләнгән, ничектер зураеп калган өй. Анда минем үз әнием һәм яшь әни Нәркисә. Алар икесе дә кызарышканнар, ярсышканнар, әле бер әйбергә, әле икенче әйбергә килеп сөртенәләр, кулларына эләккәнне идәндәге үз өемнәренә китереп ташлыйлар. Мәнә чират өстәлдәге тегү машинасына килеп җитә. Яшь әни Нәркисә аны үзенә тарта, минем әни — үзенә.

— Машинаны бирмим, ул минеке!— ди үземнең әни.

— Бөтен чүп-чарны калдырсам калдырам, әмма машинаны үземә алып чыгам!— ди яшь әни Нәркисә.

— Оят бел, Нәркисә! Бу машинаны мин үз аякларым белән барып, үз кулларым белән сатып алып кайттым,— ди үземнең әни өзгәләнеп.

— Алсаңни, син бит аны Кадыйм акчасына алгансың!— ди яшь әни Нәркисә.

— Балалар хакы бу!— дип гаҗизләнеп кычкыра үземнең әни.

— Балаларың хакына өй кала. Ә мин урамга чыгам. Эт хәлендә!..— дип кычкыра яшь әни Нәркисә һәм, өрлек кебек таза гәүдәсе

белән хәлсез, зәгыйфь әниемне төртеп җибәреп, машинаны үзенә тартып ала.

— Оятсыз икәнсең, Нәркисә!.. Минем бәддогам төшсен сиңа, Нәркисә!..— дип әни әллә ничек өзек-өзек сулый башлый һәм, иелә төшеп, куллары белән башына ябыша.

Икенче бер мизгелдә мин әниемне караватта яткан килеш күрәм. Янында бөкре им-томчы Сәхфи карчык кайнаша.

— Менә, бик күп итеп мәтрүшкә чәйләре эчерегез. Дәвасы тик мәтрүшкәдә,— ди ул.

Әнигә мәтрүшкә чәйләре эчерүче кеше бар микән? Абый карый микән әнине? Тик мин, күпме ымсынсам да, кырку табигатьле абыйны әни тирәсендә им-том иткән кеше итеп күзаллый алмадым. Юк, мөгаен, әти янында тимер-томырлар арасындадыр ул.

Мескен әни бер ялгызы...

Инде таң атып килә. Кинәт миемне бер үткен уй кисеп үтте. Качарга!.. Теге вакытта тәрәзә ваткандагы кебек, тәнемнән кинәт чиксез бер рәхәт елдырым йөгереп узды. Гаҗизлектән котылу хисе бу. Әйе, мин өйгә кайтам, хәзер үк кайтам!

Урыннан атылып тордым. Өстемә больница пижамасын киеп, балакларны, җиңнәрне җәһәт кенә сызгандым да абый калдырган төенчекне кулыма тоттым. Бүлмәдәш абзый бүрәнә тарттыргандай гырлап йоклый иде, ишекләр төртү белән ачыла иде...

Ниһаять, тыгыз, биек арыш басуына килеп кергәч, тәмам сулуыма кабып, адымнарны акрынайттым. Куа башласалар, арыш арасына кереп качармын, дип уйладым. Бу уй мине тәмам тынычландырып җибәрде. Мин иректә!..

Мин туган авылга, туган төбәккә якынлашам! Бу кырлар, бу үзәннәрдән, чишмәләрдән сут алган анам каны аша минем тәүге күзәнәгем барлыкка килгән. Монда минем тойгыларым, авазларым яңгырап калган...

Чү, кайтаваз килә! Кайдан, кайсы чордан бу? Мин ныграк колак салам һәм күз алдымда кояшлы июль көне җәйри. Әйе, әйе, хуш исле яшь иген исен, чәчәк исләрен аңкыткан тургайлы июль кайтавазы бу.

— Әни, әйт әле, җир кап-кара, ә бодайлар ямь-яшел? Каян алалар алар яшел төсне?..

— Бөртектән, орлыктан, улым. Орлыкта яралгы, төс бар.

— Ә үләнне берәү дә чәчми, ә үзе барыбер яшел. Чәчәкләр кайсы — кызыл, кайсы — зәңгәр, сары була. Алар төсне каян ала?

— Алар да үз орлыкларыннан үсә, улым. Орлыксыз, яралгысыз бернәрсә дә булмый.

— Әни, ә орлыкка төсне кем бирә?

— Кояш, улым. Кояштан төсле нурлар җиргә сибелә. Кояш булмаса, җир гел кап-кара, сап-салкын булыр иде.

— Әни, кояш бер дә, бер дә бетмиме?

— Белмим шул, улым. Сөхфи әбиең әйтә, ахырзаман җитсә, кояш сүнә, ди...

— Нәрсә ул ахырзаман?

— Заман ахыры, улым. Кояш сүнә, җирне ут-су каплый, тереклек бетә...

— Сөхфи әби каян белә ахырзаманны?

— Аның китабына язылган, улым. Җиргә бервакыт ахырзаман килер, диелгән...

Кайтаваз белән бергә хуш исле яшь иген исен, чәчәкләрнең хуш исләрен аңкыткан тургайлы июль ерак, бик ерак көннәргә кереп югалды...

Өйгә мин тәмам арып, сусап, әлсерәп кайтып кердем. Йөрәгем дөп-дөп типкән халдә ишекне ачтым, салкынча бүлмәгә уздым. Әни чынлап та караватында ята. Башында калын ак тастымал, янында — чылатып торырга савыт белән су.

— Әни!
— Әү...— Әни башын калкытты.— Кем анда?
— Әни!
— Улым! Синме соң бу? Улым. Таһирым... Каян болай... И ходаем, әллә саташаммы соң? Улым. Таһирым...

3

Анам каршында мине хәзер дә үкенү хисләре әрнетә, улым... Хәтергә шундый вакыйга уелган. Ул чакта мин өченчеме, дүртенчеме класс баласы идем. Мөгаен, дүртенчедәдер. Безнең башлангычтагы укытучыбыз яшь, чибәр Мәрьям апа иде. Уку елы тәмамланып килгәндә ул, армиядән ялга кайткан бер офицерга кияүгә чыгып, Чәтрәннән бөтенләйгә китеп барды. Һәр ике вакыйга минем өчен чиксез сагышка әйләнеп, йөрәгемдә янәшә урнашып калды.

Хәер, төп сәбәп Мәрьям апада да түгел, безнең үзебездә ләбаса! Миндә һәм әтинең өлкән кызы Рәмиләдә. Без бит авылның Элмәлек очындагы иске агач мәктәпкә, башлангычка, Рәмилә белән бер ел бергә йөреп калдык. Ул беренче класста укыды, ә мин — дүртенчедә. Күп укытучылар өчен без абыйлы-сеңелле Гарифуллиннар булып йөрдек.

...Чыршы бәйрәме алдыннан башлангыч мәктәп укучыларын бергә җыеп, уку алдынгыларына бүләк өләштеләр. Бүләкне ап-ак чәчле, күзлекле Ярмиев абый үзе өләште. Директорның фатихасын, сузган бүләген алу, билгеле, зур мәртәбә иде. Әмма мин үзем моңа исәп тотарга җыенмадым. Бүләк ударникларга, отличникларга гына бирелә бит. Мин аларның ашыга-ашыга зал каршына чыгуларын, елмаешып бүләк алуларын һәм, дулкынланып-тотлыгып, алдагы чиректә тагын да яхшырак укырга вәгъдә бирүләрен артык исем китмичә генә карап-күзәтеп тордым. Бүләк алучылар исемлегендә әти кызы Рәмилә исемен ишеткәч, билгеле, бераз тынычлыгым җуелды, күңелне көнчелек хисе сыман бер нәрсә тырнап узды.

Менә Рәмиләне директор янына кат-кат чакыралар. Әмма ул чыкмый. Рәмилә авыру. Рәмилә мәктәпкә бөтенләй килмәде. Мин бик яхшы күреп торам. Ярмиев абый янындагы укытучылар, шул ук Мәрьям апа, үзара пышылдашып алалар. Менә көтмәгәндә Ярмиев абый матур, көчле тавышы белән минем исемне атый:

— Дүртенче класстан Таһир Гарифуллинны чакырам!

Мин кинәт бик нык каушап калам. Олы киез итекләрем белән алпан-тилпән басып, Ярмиев абый янына киләм, ашыгып кулларымны сузам. Ләкин директор миңа Рәмиләнең бүләген тапшырырга ашыкмый. Уң кулымны йомшак, кайнар кулына алып кысып тора.

— Киләчәктә сеңелең кебек ударник булырсың, дип ышанам!— ди. Зәңгәр күзләре риясыз, үз итеп балкый. Аның бу кыяфәте миңа көч-куәт кертә. Мин җавапсыз калмаска тиешлегемне тоям. Укытучыларга күтәрелеп карыйм, стена кебек тыгыз булып басып торган укучыларга күз сирпеп алам. Аннан соң:

— Мин киләчәктә сеңлем кебек ударник булырга тантаналы вәгъдә бирәм!— дип ярып салам.

Рәмиләгә бүләк итеп «Ачкыч һәм баскыч» исемле рәсемле калын бер китап һәм пенал бирелгән иде. Китап мине артык кызыксындырмады. Чөнки мондый китапны күптән түгел китапханәдән алып укыган идем инде. Ә менә пенал... Хуш исле буяу исләрен аңкыткан бизәкле агач тартмада, башка уку әсбаплары белән бергә, минем күптәнге хыялым — төсле карандашлар бар иде.

Мамык карны ерып мәктәптән кайтып килгәндә мине шул пенал тирәсендәге төрле уйлар бимазалады. Башта мин сеңелем Рәмилә

кебек ударник булмавыма көендем. Ударник булсам, миңа да шундый бүләк эләгәсе иде бит! Аннары кисәк, бу минем үземә бирелмәдеме икән, дигән шик уянды. Чөнки китап битенә ачык, матур хәрефләр белән аның Рәмиләгә бирелүе язылган. Ә менә пеналда мондый язу юк бит. Бәлки директорның миңа да бүләктән өлеш чыгарасы килгәндер... Сеңлесе кебек яхшы укысын өчен алдан ук биреп куйыйм әле, дигәндер. Чынлап та, ул бит минем кулымны юкка гына кысмагандыр. Кул кысып, бүләк тапшыргандыр. Нәрсә тора соң директор кешегә бер пенал?

Мин шундый уйлар эчендә чәбәләнә торам, аякларым этиләрнең бизәкле, урыс капкасына якынлаша тора. Монда кереп, мин Рәмиләнең бүләген калдырып чыгарга тиешмен.

Өй ишеген ачуга, борынга аш исе килеп бәрелде. Пешеп ятамы, әллә ашаганнармы инде?.. Пешә генә булыр.

Эти, тире камзулын аркасына элеп, сәгать төзәтеп утыра. Яшь әни Нәркисә, ишек тавышына почмактан башын сузып, ялт итеп миңа карап алды. Токмач-мазар кисә бугай. Рәзинә белән Рәхилә дә каршыма йөгереп чыктылар һәм икесе беравыздан:

— Безгә ник килдең?— диделәр.

Эшлекле кыяфәттә букчадан китапны алып, этигә суздым:

— Менә, эти, Рәмилә ударник булган. Шуның өчен китап бирделәр үзенә,— дидем.

Эти урыныннан кузгалды. «Яхшы хәбәр белән йөрисең икән. Кая әле, кая?»— дип, минем яныма килде. Йөзенә канәгатьлек, кызыксыну, сөенү галәмәтләре чыгарып, китапны кулына алды, баскан көенә генә аның язуын укыды.

— Кызым Рәмилә, ишетәсеңме? Менә мәктәптән бүләк биргәннәр сиңа!

Эти чаршау эченә кереп югалды. Рәзинә белән Рәхилә дә, инде миннән кызык тапмыйча, этиләре янына йөгерделәр.

Мин ишек төбендә тагын бераз таптанып тордым. Инде китәргә дә мөмкин иде. Ләкин сизәм, букчадагы пенал, каршыма баскан усал эт кебек, мине тотып тора. Болай уртада калдырып китәргә ярамый, аны ничектер хәл итәргә кирәк.

— Эти!— дидем мин әллә ничек төшенке дә, ясалма көр дә бер тавыш белән.— Миңа да бүләк бирделәр бит. Пенал!..

Букчадан чыгарып, пеналны кулыма тоттым. Эти пеналны алыр, мине дә мактар кебек тоелды. Ләкин ул болай эшләргә ашыкмады шикелле. Дөрес, ул чаршау эченнән чыкты, беркавым еракта күз кысып, җентекләп карап торды.

— Син дә ударник булдыңмыни?— дип сорады. Аннары, яныма килеп, миннән җавап көтә башлады. Этинең соравыннанмы, әллә карашыннанмы кисәк коелып төштем.

— Юк... Тик директор абый аны болай бирде. Киләсе чиректә син дә ударник булырсың, дип бирде...

Тәнемә кайнар тир бәреп чыкты, пеналны калдырып чыгып китәргә дә риза идем.

— Ярар соң,— диде эти тавышына рәхимлек, йомшаклык билгесе чыгарып.— Ударник булырга җыенганыңны белеп биргәннәр икән, бик яхшы...

— Мин ударник булам, эти, булачакмын!— дидем мин кисәк эчтән бәргән сөенечтән балкып.

— Ярар, бар...

Ләкин эти сүзен әйтеп бетермәде, мин ишеккә борылырга өлгермәдем, почмактан бәргәләнеп яшь әни Нәркисә килеп чыкты.

— Бармый торсын әле!— дип, кайнарланып, каршыма ук килеп басты. Ул сугышырга әзерләнгән этәчне хәтерләтә иде.— Йә, дөресен әйт, малай актыгы, пенал да Рәмиләнең бүләге бит. Китап белән

пеналның икесен бергә аңа дип бирделәр бит. Шулаймы?

— Пеналны директор абый миңа бирде,— дидем мин, яшь әни Нәркисәнең кызулыгыннан эчтән курыксам да, тыныч итеп. Әти дә яклар кебек иде.

— Юк, пенал — Рәмиләнеке!— дип аяк тибеп кычкырды яшь әни кыза барып.— Авыру баланы рәнҗетәсеңме, әйберен урлыйсыңмы? Менә хәзер үк мәктәпкә барам, караклыгыңны ачам, малай актыгы!

— Югалыгыз күземнән!— дип ярсып кычкырды әти.

Яшь әни Нәркисә зәһәрләнеп кычкырыша калды, әти аңа үз чиратында тагын нәрсәдер әйтте — мин чыгып киттем.

Миңа ияреп, өйгә шом кайтты. Пеналны чыгарып күрсәтергә курыктым. Әни белән абый түр якта өстәл артында чәй эчәләр иде.

— Аш мич алдында,— диде әни.

Мин, ялгыз калуыма куанып, почмакка кереп утырдым. Вакыт уза торды. Күңел нәрсәдер сизенә, пошынып нидер көтә... Тик озак көтәргә туры килмәде. Урамда сызланып капка шыгырдады, каерылып өй ишеге ачылды һәм, салкын буга уралып, башта — яшь әни Нәркисә, аннары укытучым Мәрьям апа килеп керде. Мин тагын эчкә, почмакка кереп сыендым.

— Исәнмесез, керергә ярыймы?— диде Мәрьям апа көмеш яңгыравыклы тавышы белән.

— Әйдәгез, әйдә... узыгыз, утырыгыз!— диде әни кунак каршылагандагы сыман күтәренке бер гаҗәпләнү белән.

— Ярар, без озак утырмабыз, Гадилә апа... Таһир өйдәдер бит?— Мәрьям апаның тавышында гаҗизлек сизелеп китте.— Таһир, чык әле монда.

Аяк буыннарымда хәлсезлек, калтырау тоеп, түр ягына атладым. Башымны иеп, Мәрьям апа каршысына килеп бастым.

— Таһир, пенал Рәмиләнеке иде бит. Иясенә кайтарырга кирәк,— диде ул әкрен генә.

Менә пенал Мәрьям апа кулында. Ул аны, бер дә күрмәгән сыман, әйләндереп-тулгандырып карый. Бәлки карамыйдыр да, әйтәсе сүзен генә исәплидер ул.

— Сез Таһирны гафу итегез, Гадилә апа. Монда минем генә гаеп. Мин бит аңа бернәрсә дә аңлатмадым...

Мәрьям апа белән яшь әни Нәркисә, кергәндәге кебек, кисәк чыгып та киттеләр. Өйдә алар калдырган шыксыз салкынлык оеп тора. Мин шуннан җыерылып, куырылып төштем. Тик әни һаман җыенып сүз әйтә алмый, эчтән нәрсәдер исәпләп тора сыман. Аның каравы абый ярсыган. Менә ул каяндыр каеш та табып алган һәм шуны чыбыркы кебек селки-селки өскә килә.

— Сал ыштаныңны!

Мин аны-моны абайлап та өлгерә алмадым, арканы яндырып берничә тапкыр каеш чажылдап төште. «Мә, карак! Мә, бур!»

— Тукта, кыйнама баланы!— дип кычкырды әни һәм абыйның каешлы кулына килеп ябышты. Ләкин ярсыган абыйны кисәк кенә туктату мөмкин түгел иде. Ул әнинең кулларын җиңеп, миңа тагын бер селтәнде һәм чуалган каеш тимерле башы белән маңгай тирәмне ярып узды. «Ай!»— дип кычкырып җибәрдем мин һәм, кискен әрнүдән күзалларым караңгыланып китеп, идәнгә чүктем.

— Баланы гариплəндерәсең бит, явыз!— дип кычкырды әни йөрәк ачысы белән. Абыйның кулыннан каешны йолкып идәнгә атты.

— Әй, улым, улым,— диде әни бераздан, тәмам ачыргаланып.— Бүләк бүленәмени ул?.. Бүләк бүленми бит ул, улым! Кем кеше бүләгенә нәфесен суза инде!

Әни, әйтерсең, бөтен эчке ярсуын әнә шул ачыргаланулы сүзләре белән тышка чыгарып ташлады. Ул тагын мөлаем, мәрхәмәтле,

нурлы әниемә әйләнде. Менә ул, юеш чүпрәк алып, минем маңгайга саркып чыккан канны сөртергә кереште. Ничектер кызганып, җәлләп күзләремә бакты. Тик кинәт, тиктомалдан аның йөзе үзгәреп, әллә ничек, көзән җыерган кешенеке кебек, чалышланып китте.

— Улым, нәрсә ул синең күзеңдә? Ай, улым, нарасыйкаем, күзең харап булган бит синең...— Әни хәлсезләнеп почмак ягына атлады, чайкалып-чайкалып китте, бер — стенага, бер мичкә килеп кагылды.— Әй, ходаем, нинди гөнаһлар өчен син мине җәзалыйсың?! Әнинең башы кузгалдымы?.. Алайса, ни өчен күземә карап хәле китте аның?

Күземә нәрсә булганын һич аңышмыйча, аптырап, тут баскан зур көзгебез каршына килеп бастым. Сул күздә, нәкъ уртада, урак яралаган төштә, яшь аша бриллиант төсле булып, әллә зәңгәрсу, әллә ак төймә ялтырый иде...

Хәтердә тагын шундый бер вакыйга яңара. Кышкы иртәдә дөрләп янган мич каршында китап укып утырам. Тышта ялыктыргыч озын төн үтеп бара, тынны куырырлык салкын, яисә күз ачмаслык буран. Ә янәшәдә, бер-берсенә уралып, дулкын-дулкын кызгылт зифа ялкыннар биешә. Яну — сөенеч. Сөенеч сиңа җылы, нур, ямь бөрки.

— Улым, шулай бик кызык язганнармыни?— Әнием, камыр баскан җиреннән туктап, бераз хәл җыя. Мин дә китаптан башымны күтәрәм. Әниемнең алсу нур белән балкыган йөзенә яратып багам. Минем укыган һәрбер китабым белән кызыксыну, ачышларым белән уртаклашу әмәлен таба ул. Әниемнең бу гадәте мине һәрчак сөендерә.

— Кигәвен кушаматлы революционер булган, әни. Галәмәт көчле ихтыярлы кеше ул, әни. Тәне сырхау аның, бик еш зәхмәт тота аны, ә ул түзә, ыңгырашмый да... Әллә ничә кат аталар аңа. Аталар, аталар, ә ул үлми. Бик яшисе килә Кигәвеннең. Әни, ул революция эшенә шул кадәр бирелгән була, яралангач, хәтта үз-үзен әтисеннән яшереп йөри.

— Ничек алай инде ул? Бәрәч, әтисе дә үз малаен танымыйча йөриме? Алайса очрашмаганнардыр алар...

— Юк шул, әни. Ата белән малай очрашалар. Тик аларның берсе — революционер, икенчесе динче була. Шунлыктан Кигәвен дә үз әтисен әти итеп танымый.

— Бәрәч!— дип суза әни, чын-чынлап аптырауга төшеп.— Ә атасы? Атасы сукыр булганмыни соң, үз баласын танымаска?!

— Ә... Мин әйтмичә торам бит,— дим мин, әниемнең зирәк соравына кинәнеп.— Бөтен сер дә шунда шул. Кигәвенне суга батып үлгән дип саныйлар. Ә ул батмый да, үлми дә. Аннары ерак җирләргә чыгып китә. Күп вакыт үткәч, бик нык үзгәргәч кенә кайта ул үз җирләренә. Ата шунда инде малайны танып бетерә алмый, шикләнә. Ул да кебек, ул да түгел сыман... Ә ахырда барыбер таный. Таныгач, йөрәге ярылып үлә, әни...

— Ай-һай, гыйбрәтле хәл икән шул,— ди әни уйга чумып.— Шулай да, улым, ата кеше — ата кеше инде ул. Ничек аны шулай санга сукмаска мөмкин?

— Китапка язганнар икән, дөрес инде. Бөтен кеше дә ата дип өзгәләнеп тормый булай булгач,— дидем мин кинаяле бер үҗәтлек белән.— Әни, син миңа әйт әле. Әти ник безне яратмый?..

Маңгайга бәрелгән кебек кисәк бирелгән сораудан әни, шиксез, эчтән каушап, җыерылып төшкәндер. Ләкин тыштан моны сиздермәскә тырыша. Хәтта миңа күз дә салмый. Битараф рәвештә пычак алып, бармакларын камырдан чистарта-чистарта гына сорый:

— Ник алай дисең, улым?

— Соң яратса, бездә торыр иде. Ә ул яшь әни, Рәмиләләр белән генә тора...

— Нәрсә аптырыйсың аңа, улым. Яшь әниең чибәр, матур, шуңа аларныкы булган этиең.

— Ә башта безнеке булганмы? Аннары ничек аларга күчкән соң ул?

— Бигрәк әллә нәрсәләр сорыйсың син, улым...

— Әйт инде, әни, минем бик, бик беләсем килә бит.

— Соң ни... Нәркисә апаң кыз килеш хатын булган. Әтиеңнән алданган ул...

— Нишләп яшь әни Нәркисә алдансын, әти алданган була ич болай булгач.

— Бәрәч, нәрсә инде бу? Ничек әтиең алдансын ди?

— Ничек алданмасын? Хатынын, ике баласын калдыртып, яшь әни Нәркисә аны үзенә алган бит. Бу әтинең алдануы булмыйммы?

Әни, беренче күргән кебек, бер мәл миңа карап торды, ә аннары кисәк кенә үз алдына кытыкланып көләргә керешге. Ничектер рәхәтләнеп, күзләренә яшьләре атылып чыкканчы көлде.

— Синең сүзең рас бит, балам. Алданган кеше Нәркисә түгел, атаң икән бит... Ай, күземне ачтың син, балам. Әтиең үзе кыргый кан капкынына эләккән бәндә икән бит,— дип такмаклый-такмаклый көлде әни шул чакта.

## 4

Шуннан соң күпме гомер акты, улым! Әмма әнинең кыргый кан капкыны турындагы сәер сүзләре хәтергә нык уелган икән. Ни өчен ул яшь әни Нәркисәне кыргый кан дип атады? Ничек этигә капкын булган соң ул?

Нәркисәнең атасы Куян Гатаның яргы гомере читтә, гидайлыкта үткән. Чордашларының гына түгел, хәтта туган-тумачасының да хәтерендә җуела башлагач, утызынчы еллар уртасында авылга кайтып төшә ул. Гата яшь, мәһабәт, озын, сыгылмалы буйлы. Күперенке кара мыек. Өстендә зимагурларча ала-кола кием. Үз артыннан нечкә сыйраклы, шомырт күзле кәләш тә иярткән. Кайда йөргән, ниләр кылган Куян Гата — Чәтрән халкы ачык кына белми моны. Шулай да, кибет янында ирләр белән җыелышып бер утыргач, азрак чишелгән ул.

— Мин, земляклар,— дигән,— Рәчәйне вечь урадым. Себердә гектар-гектар урман кистем. Уралда шалун-шалун күмер чаптым. Диңгез дигәненә дә барып чыктым, мичкә-мичкә балык тозладым. Мин күрмәгән җир, кылмаган кәсеп калмады бу дөньяда, земляклар...

Чәтрән ирләре каршында шулай борчак шыттырып, гармун тартып, ярты төнгәчә урам киеп җырлап йөри Куян Гата.

Кыр тавыгы күкәй сала,
Әрем араларына.
Дошман булсам булам инде,
Керәм араларына.
  Эх-ма, Сәрви яр,
  Ай булмаса, йолдыз бар...

Тузга язмаслык кыланышлары белән бер көн эчендә үзен танытып, Чәтрәнне тәмам гаҗәпкә сала Куян Гата. Әмма тагын да ис китерә торган эшләре алда булган әле аның.

Гатаның хатыны Бибиҗамал төскә бик чибәр булып, буйга да нәфис, килбәтле. Мут күзле ирләр аңа үткәндә-сүткәндә күз салгалап, чегән дияр идең, безнеңчә белә, һәйбәт соң чукынган, дип, авыз суын кортырга өлгермиләр, бердәнбер көнне Чәтрәннең олы урамында матурлыкта Бибиҗамалдан әз генә дә калышмаган икенче

бер ят хатын пәйда була. Тик монысы үз артыннан бер кыз бала ияртеп икән. Шул хатын, кибет янында туктагач, бик нәзакәтле төстә:

— Миңа иптәшем Шәһморзаев Гата йортын күрсәтә алмассызмы?— дип сорый.

Шулай, ишетмәсәң ишет! Бер Куян Гата Чәтрән ирләренең төшләренә дә кермәслек ике хатынга ия булып чыга. Әллә бик сөйкемле сөяк, әллә хатыннары да иш янына куш, һич Гатадан йөз чөермиләр үзләре. Соңыннан кыз бала ияртеп килгәне, Сәрви, Гатаның инде башка хатын белән бер түшәккә баш куйганын белгәч, чәпчеп, тузынып тәртә борыр төсле була. Һәрхәлдә, кибет янында Сәрвигә юл күрсәткән ирләр моны шулай юрап куйганнар. Ләкин, гаҗәпкә каршы, әш һич тә тәртә бору белән тәмамланмый. Сәрви Куян Гатаның үзен бер читтә калдырып, башта көндәше Бибиҗамал белән каты-каты кычкырыша, ә аннары кызган кан белән шул көнне үк мәрхүмә кендекче Мәһрүзә әби өенең томаланган ишек-тәрәзәләрен ача.

Нигезне законлаштырырга килгәч, сельсовет Мөлис сораган моңардан:

— Сәрви сеңел, безнең Чәтрән нәрсәсе белән тартты соң сине?

Сәрви, алдан әзерләнгән сыман, чатнатып җавап биргән:

— Чәтрәнегез ят булса, Гата минем үз ирем, хәләл ирем. Без аның белән чөкердәшеп гомер сөрдек. Бер хыянәте булмады. Кунакка гына кайтып килә́м, диде. Аздырганнар!..— Шунда Сәрви сельсовет Мөлис каршында балавыз да сыгып алган.— Соң персидәтелкәем, үзең уйла, хәләл иремне ничек читләр кулына калдырыйм инде? Калам, бер кайтмаса, бер кайтыр Гатам.

Дөрестән дә, хатыннары белән бер кавышып, бер аерылышып, гомере буе шулар белән әвәрә килеп яшәде Куян Гата.

Әмма бәхеттә озак яшәмәде. Мәгънәсез үлеп китте, мәрхүм.

...Куян Гатаның кызы Нәркисә әнисе Сәрвидән дә чибәррәк булып үсә. Гөләп чәчәге кебек чәнечкеле, чегән кызы кебек әрсез була ул.

Әнинең бер хаты хәтергә төшә. Хәер, мин аны һаман да саклыйм. Менә ул. Саргаеп беткән дәфтәр битендәге шәмәхә карандаш белән тезелгән сүзләр еллар аша әниемнең ягымлы авазларын яңгырата кебек. Исәнлек-саулык сорашу. Шәһәргә китеп, студент булган малайга тәүге олы нәсихәтләр, үгетләр... һәм менә: «Улым, син бик кечкенә чагыңнан ук әтиең хакында сорашып килдең. Чынлап торып сөйләргә әллә ничек күңелем тартмады. Зурлар эшенә төшенеп җитмәссең шикелле иде. Инде менә хәзер бу турыда язып үтәргә булдым. Әтиең сугышның өченче елында яралы булып кайтты. Аның комбайнер булганын да беләсең. Кайткач та шул эшкә куйдылар. МТС кешесе булды. МТС аларны йә бер авылга, йә икенчесенә җибәрде. Икенче елында әтиең үзебезнең Чәтрән кырында эшләде. Смазчикмы дип, саламщикмы дип шунда, әтиең янына Нәркисәне дә куйганнар. Берзаман бик озак яңгырлар явып торды. Шулай да әтиең, тора да, комбайнны төзәтәм дип, кырга китә. Төенчеген тотып, Нәркисә дә аңа иярә. Әтиең, ярар, машинасын төзәтә, ә Нәркисәгә ни калган? Шул шик башымда йөргәләде йөрүен, тик япь-яшь кыз хакында ямьсез уйларга күңелем бармады.

Әмма берзаман авылда Нәркисәнең әтиеңнән авыры бар дигән хәбәр таралмасынмы! Персидәтел булып Камал тора иде ул чакта. Камалның уты да, суты да үзе белән булды. Җитмәсә, Нәркисә Камалларның чыбык очы кардәше дә икән. Әйбер-мазарын тарантасына төяп, Нәркисәне үзе безгә китереп ташлады. Тырнак белән чиртеп карагыз, тормадә черетермен дип янады. Камалга карап тормаган булыр идем дә, кәнтәйне куып чыгарырга үземнең хәл-кодрәт җитмәде шул. Әтиең исә, ике ут арасында калган кеше, үз эченә йомылды.

Шулай ярты еллап өчәү бер түбә астында гомер кыскарттык. Аннары алар үзләренә башка чыктылар. Менә, улым, аз сөйләсәң дә, күп сөйләсәң дә, әтиеңнең безне ташлавы шулай булды инде. Син хәзер үзең житкән кеше. Күп нәрсәләрне аңышып үзең дә тутырырсың. Тик шуны әйтәм, улым, егет булып киләсең, юлыңда әллә нинди асыл затлар очрый торыр, әмма горурлыгын җуйган кыз-хатыннан саклана күр син, яме?!»

## 5

Әти хакында еш уйлыйм мин, улым. Әти күңел күгендә яңгырсыз, кысыр болыт кебек. Андый болытның җисеме, рәвеше бар, әмма дымы юк. Җил өрдеме, югала, юкка чыга.

Мин, зиһенемне көчәндереп, әтине гәүдәләндерергә тырышам. Ул озын, какча гәүдәле шикелле. Бәлки озын да булмагандыр ул. Үзем кечкенә булганга гына шулай тоелгандыр. Ә йөзе? Күпме ымсынсам да, йөзен җанландыра алмыйм менә. Көлсәң көл, еласаң ела. Үз атаңның чыраен, төсен җуй, имеш!

Әллә әнием гаепләме моңа? Кояштай балкып, нурлары белән күңелне тәмам биләгәндер дә, башкаларга урын да калдырмагандыр.

Әйе, әйе, әнием кояш булып, кояшның да яздагысы, таңдагысы булып балкый.

Иртә, бик иртә әле. Иркә, тере май кояшының тәүге нурлары мине җылыта-капшый башлаганнар. Мин йоклыйм да, йокламыйм да. Әни, шыпырт булырга тырышып, кем беләндер сөйләшә. Таң белән безгә кем кергән?.. Һәй, бу яшь әни Нәркисә бит? Аның безгә күптән инде аяк басканы да юк иде. Ни галәмәт? Гаҗәпсенү тәмам зиһенне ачып җибәрә, ирексездән сүзләренә колак салам.

— Инде, Нәркисә, алырдаен да алдың, алмастаен да алдың, бәгыремә төшеп тагын нәрсә сорыйсың инде син миннән?

— Әйтәм бит, Гадилә астакай, Үзи карчык кат-кат әйтте. Малаеңа кондәшеңнең каргышы төшкән, игә китерсә, шуның име генә игә китерер, диде.

— Мин беркемне дә каргамадым, Нәркисә!

— Һи, Гадилә астакай, үз алдымда әйттең бит. Колакларым сатмый, бәддогам төшсен, димәдеңме?..

— Әйткәнмен исә — кайтканмын. Билләһи, хөсетлек кылмадым сиңа, Нәркисә.

— Үзи карчык белгәндер инде, Гадилә астакай...

— Һай алла, Нәркисә, булсаң да булырсың икән кеше! Үз эчемдәгесен мин үзем беләм бит, ник һаман Үзи карчык белән авыз чайкыйсың? Бар әле, Нәркисә, мине тынычлыкта калдыр әле. Үзеңне дә, балаларыңны да һич күрәсем килеп тормый минем...

Әнием шул сүзләрне әйткәч, яшь әни Нәркисә бер мәл тынлыкта калып торды. Болай булгач, ул инде чыгып китәр дип уйлаган идем. Ләкин кузгалу галәмәте сизелмәде, ишек тә шыгырдамады. Кинәт тәнем сискәнеп, куырылып куйды. Яшь әни Нәркисә әллә нинди кыргый, иләмсез җанвар илерүе белән үкереп җибәрде. Башымны күтәреп, әниләр ягына күз салсам, тагын да гаҗәбрәк хәл күрдем. Яшь әни Нәркисә әнә шул җанга тигән авазлары белән елый-елый минем әнинең аякларын кочарга итә, бар гәүдәсе белән идәндә шуыша иде.

— Гадилә астакаем, табаннарыңны үбәрмен, зинһар, ир балам, бердәнберем хакына!.. Кыз бала булса, җаным болай әрнемәс тә иде... Гадилә астакай, алла хакына, нәрсә сорасаң, шул булыр...

Әни тәмам гаҗиз булган. Ул идәндә шуышкан яшь әни Нәркисәдән аякларын арындырырга, бөгелеп, яшь әни Нәркисәне күтәреп

торгызырга итә, ләкин тегесен дә, монысын да булдыра алмый аптырый.

— Йә, Нәркисә!— диде әни, ниһаять эчке бер ныклык, тәвәккәллек белән.— Тор, әнә бала карый, шуышма, яхшы түгел... Тор дидәр бит!— Һәм әни бөтенләй икенче, җиңелгән кеше тавышы белән әйтеп куйды.— Йә, әйт, Нәркисә, нишлим мин? Нәрсә көтәсең син миннән?

Яшь әни Нәркисә идәннән күтәрелде, калтыранган, кабаланган куллары белән сырмасының кесәсендә казынды. Ниһаять, каяндыр төрелгән кәгазь табып алды:

— Менә, Гадилә астакай, догасы язылган. Им-томы күрсәтелгән,— диде ул, балаларча сулкылдый барып.

Әни, ишек төбен караңгысынышмы, әллә миннән сер яшерергә теләпме, почмак якка кереп китте. Аңа яшь әни Нәркисә дә иярде. Шунда, мыдыр-мыдыр килеп, байтак сөйләшеп тордылар. Әмма серләре барыбер миңа килеп ирешге. Минем әни көтмәгәндә карчыклар кебек им-томчы булып куйды!

Әтиләрнең соңгы баласы Шамил, туганнан бирле, ниндидер зәхмәтле чи кутыр белән интегә иде. Әллә нинди карасу нәрсә аның бөтен гәүдәсен, башын, битен басып алган. Бала тәннәреннән кан саркып чыкканчы кашына, баккан-сукканга карамый, көне-төне ярсып акыра. Юньләп имә дә алмый, бичара. Күрәзәче Үзи карчыгы шул баланы имләүне минем әнигә юраган.

Таң атмас борын чүлмәк, кашык алып, Килмәк урманы авызындагы Сөлчә чишмәсенә китеп барабыз. Кояшның нәкъ тәүге нурлары чишмәгә төшкән бер мәлдә әнием аннан чүлмәккә кырык кашык су санап салырга тиеш. Менә шул көтелгән мизгел килеп җитә. Кояшның кызгылт нурлары чәчәкләр, яфраклар арасында күмелеп яткан чишмәнең суларына төшеп чагыла. Әнием чишмәгә иелә. Кашыгы белән суга кагылганчы бераз вакыт чишмәгә багып тора, аның иреннәре селкенеп-селкенеп китә — дога укыйдырмы? Ниһаять, көмеш алкалар ясап, чишмә тирбәлә башлый. Ирексездән мин ул алкаларны саныйм. Бер, ике, өч... Менә утыз тугыз, менә кырык... Ә әни һаман чишмәгә иелә.

— Әни, кырык булды бит!

— Чынмы, улым? Мин утыз сигезне генә санадым ла. Ходаем, чынлап ялгыштым микәнни?

— Чын инде, әни, кырыктан артты ласа!

Әни күп бәхәсләшми, чүлмәкне чишмәгә тотып бушата һәм су өстендә яңадан көмеш алкалар йөгерешә башлый. Бер, ике, өч...

Ниһаять, чүлмәккә төгәл кырык кашык чишмә суы салына. Мин чүлмәкне иңбашыма күтәрәм һәм без кайтыр сукмакка төшәбез.

— Әни, кырыктан артса, ни була ди?

— Шартын үтәмәсәк, Шамил терелмәс бит, улым.

— Шамилны терелтсәк, эти белән яшь әни әй шатланырлар инде, әни!

— Терелсә, без дә шатланырбыз, улым. Сиңа да исән-сау бер ир туган булыр. Берең-береңә таяныч, терәк булганда гына дөнья көтүләре ансат ул, улым.

— Әһе... әни, әни, эшләр уңса, яшь әнидән нәрсә сорарсың? Нәрсә сорасаң, шул булыр, диде бит.

— Миңа аларның бернәрсәсе дә кирәкми, улым. Тик изгелек барыбер җирдә ятмас әле. Яхшылыгы да, начарлыгы да кешенең үзенә кайта ул, улым...

Чишмәгә барганда табигать әле йокылы-уяулы булса, без кайтканда ул тәмам тернәкләнеп җитә. Урманның өч-дүрт төшендә өздереп сандугачлар чутылдый, тавыш бирә. Басу өсте исә җиз чыңлы бердәм тургайлар җыры белән тулган. Кай тарафка бакма, караш-

ларны иркәләп, каз бәпкәсе түшәдәй яңа, сыек яшеллек җәйри. Без шул ямь, хозурлык эченнән Шамил энекәшкә дәва, тереклек суы алып кайтып киләбез. Үзенә чәчәкләр сутын, кошлар моңын, яшәү сөенечен сеңдергән шифалы су Шамил энекәшне терелтер, шиксез терелтер...

Өйгә кайткач, әни чишмә суын әллә ниләр кыйландыра: җылыта, үлән-тамыр төнәтә, суда чыжлый торган ниндидер күк таш салып куя.

Менә юрганга төрелгән бәбәй, кычкырып тавыш бирә-бирә, үзе дә килеп җитә. Әни аны яшь әни Нәркисәдән үз кулына ала. Сөйләнә-сөйләнә чишендерә:

— Вәйт, Шамил дигән егет безгә кунакка кергән икән. Чәпчәп итеп чыгам, дип әйтә. Һай, әниең төргән дә инде үзеңне. Болай ничек тәнең тын алсын ди?.. Һай, Нәркисә, нарасыйны шулай кадерсез итәләрме? Менә бу җирләре тәмам пешегеп беткән бит...

Шамил энекәш үзен суда рәхәт сизә. Әни аның култык асларын, аяк, битләрен юып, сыпырып алганда ул хәтта ирennәрен дә ерып җибәрә — көләргә итәме, наный?

— Вәйт шулай, вәйт шулай. Ыгы, ыгы!— ди әни һәм кызык итеп иреннәрен чөйдереп ала. Сабый тагын җанланып китә. Кул-аякларын дәртле селтәп, тирә-юньгә су чәчрәтә. Мин яшертен генә әниләргә күз салам. Яшь әни Нәркисә күзгә күренеп тернәкләнеп килгән малаена өмет-сөенеч белән баккан. Матур йөзендә, зәңгәр күзләрендә мин әле беркайчан да шәйләмәгән ниндидер илаһи чалымнар барлыкка килгән... Үземнең әнинең җылы су парыннан бите алсуланган. Әллә ничек яшәргән дә кебек, әллә ничек күзләре дә тереләнә төшкән кебек.

Коендырып бетергәч тә, әни Шамилне биреп чыгарырга ашыкмый. Бәбәй белән сөйләшә-сөйләшә аны пөхтәләп төрә, мендәр өстенә китереп сала:

— Азрак суыныйм әле мин. Бәү-бәү итим бераз. Урамда җил дә, салкын бәрмәсен үземә.

Әлли-бәлли, бәләкәч,
Мичләр тулы пәрәмәч.
Пәрәмәчләр пешсеннәр,
Балга, майга төшсеннәр.
Аны Шамил ашар,
Күзен йокы басар...
Әллү-бәү, бәлли-бәү!..

Минем әни нинди кызык такмаклар белә икән! Көен дә ишеткән юк иде. Үземнең дә, баллы, майлы пәрәмәчләрне гарык булганчы ашап, йокыга чумасы килеп китте. Ә Шамил энекәш күптән инде изрәгән. Яшь әни Нәркисә әнигә кыюсыз гына сүз ката:

— Гадилә астакай, алайса, мин бераз эшләремне карап керим.

— Бар, бар, Нәркисә, эшләреңне карап кер,— ди әни йомшак итеп.

Кайгының да берәр шатлыгы була, ди торган иде әни. Чынлап та, Шамил энекәш шулай эштән чыгып чирләмәсә, этле-мәчеле торган әниләр дуслашып китә алырлар иде микән? Хәер, дуслаштылар микән алар? Бәлки, балачакның алдануы гына булгандыр бу. Нарасый акыл тормыштан гел яхшыны, әйбәтне генә көтә бит ул.

Мин һаман, таң атмас борын, әнием белән Килмәк урманы авызындагы Сөлчә чишмәсенә юнәләм. Икәүләп, тын калып, яз кояшының чыгуын көтәбез. Менә көтелгән изге мизгел җитә. Ерак, күгелҗем тау өстеннән зур, кызгылт кояш күтәрелә, тирә-юньгә нур бөрки, ямь сибә. Исәнме, кояш, мәрхәмәтле кояш! Әллә кояш, әллә әнием бу...

Ә эти?... Кем булды соң минем эти?

...Вакыты җитәр, зур фанер чемоданыбызны күтәреп, мин дә авылыбыздан олы дөньяга чыгар юлга атлармын. Авыл юлы кыйгач сөзәклеккә күтәрелер дә, чокыр, ипсезлекләрдән саклана-саклана, бормаланып, зират ихатасына кагылып үтәр. Телисеңме-теләмисеңме, күзеңә эреле-ваклы мүкле ташлар, яшел буяулы рәшәткәләр, төрле кабер бизәкләре кереп калыр. Эти өстенә утырткан каен инде, куп-шыланып, бөдрәләнеп, буй үстереп ята. Аның яфраклары, иркен кыр җилләрендә талпынып, сабырсыз шыбырдашалар. Юк, яфраклар түгел, гүя каен аша әтием сызланып, ялварып миңа эндәшә:

— Улым, үзең белән мине дә ал сана!..

— Юк, рәнҗемә, гаепләмә, эти... Мин сине үзем белән алалмыйм. Тудырган кешем булсаң да, күңел күгендә яңгырсыз, кысыр болыт кебек син. Җисемең, рәвешең бар, әмма рухың юк синең миндә, эти...

6

Кешеләр нишләп үләләр икән? Ник алар үлем-китем күрмичә генә мәңге-мәңге яшәмиләр? Ә бер дә, бер дә үлмәсәләр, гомер бакый яшәсәләр?.. Ул чагында дөнья тәмам эчпошыргыч булып әверелмәсме соң? Кешеләрне бернәрсә дә куркытмас, бернәрсә шатландырмас иде. Ташлар кебек җансыз, рухсыз булырлар иде алар. Мөгаен, ярату да булмас. Болай исә яшәлгән һәр гомер җиргә бер мәгънә китерә. Җирдә күпме мәгънә булса, яшәлгән гомерләр дә шулчаклы. Гомерләр — мәгънәләрдә. Яхшысы — өлге, яманы гыйбрәт аларның. Тик мәгънәләр катлаулы. Шул сыйфатлары белән исәннәрне гел уйландыра алар.

Әнә минем Сәбилә җиңгәм! Аның гомере җиргә нинди хакыйкать ачып киткән соң?.. Хәер, аның хакыйкате үзенеке генә түгел шул. Анда Сарыйм абыемның да зур катнашы бар.

Абый, солдат хезмәтен үтәп кайткач та, тиз генә өйләнеп куйды. Авыл зур, кызлар күп, абыйга башы-күзе әйләнгәнче сайланып йөрергә дә мөмкин булгандыр. Тик ул ерак китеп, озак эзләнеп тормады, үзебезнең урам башындагы Ядкарь картның кече кызы Сәбиләгә өйләнде.

Сәбилә җиңги безнең бер эздән ялкау гына агучы тормышыбызга үзгәреш, яңа ачышлар кертеп җибәрде. Икенче төрле итеп әйтсәк, мине Сәбилә җиңги һәрчак гаҗәпләндереп яшәде. Ничек гаҗәпләнмисең инде, Сәбилә җиңги — Ядкарь бабай белән Зөлхиҗә әбинең иркә канатлары астында үскән төпчек. Бер гөл сыман, шуларның өйләрен ямьләп, бизәп торган ул. Хәер, гөлне өйдән-өйгә күчерсәң, сулып шиңә... Ә Сәбилә җиңги сагышның ни икәнен дә белми, ахры, чит бер нигездә дә канатланып, дәртләнеп дөнья көтә.

Килен булып төшүенең тәүге айларында ук Сәбилә җиңги чәй янында әнигә карап мондый сүз кузгата:

— Безгә, әни,— ди ул,— өй салырга кирәк.

Көтмәгәндә, кисәк килеп ирешкән бу ният әнине эчтән балкытып җибәрә. Әмма шиге дә бик көчле аның:

— Ай-һай, оланнар, кулдан килерме ызба салу? Әле бит кулда бер дә мая юк...

— Нәрсәгә безгә мая?— ди Сәбилә җиңги, әнинең үз планына каршы килмәвенә сөенеп.— Безнең бит имән багана кебек ике ир затыбыз бар, булышка без дә килеп кушылсак, яңа өйнең маясы шул булыр. Менә, әни, күрерсең дә торырсың, быел бүрәнә, тактасын юнәтербез, киләсе елга бурасын бурап, өен торгызып куярбыз. Бүлмәнең иң яктысы, җылысы сиңа булыр, әни...

Әни оялчан төс белән кул селти:

— И, килен, миңа өлкән кешегә кайда да бер... Аерым бүлмә дип

тагы... Әйбәте үзегезгә булыр анысы...

Аларның сүзләренә абый да килеп кушыла:

— Сез теге ни, тумаган тайга атланып сыртын сындырмагыз тагын.

Өй өлгертү хыялы һәрберебезнең күңеленә чынлап кереп урнашты. Бу татлы уй безнең гаиләнең алдагы тормышына мәгънә бирде, киләчәк эш планнарыбызны билгеләде. Әни күп еллар инде фермада сыер сава; гариза язып, колхоз идарәсеннән бүрәнә сорарбыз. Абый оста Гомәргә ярдәмче булып комбайнга чыга. Укып язу алса, икенче җәйгә үзенә дә комбайн биреп куймасलармы? Сәбилә җиңги бер гектар урынына гектар ярым чөгендер җире алыр. Мин... Хәзер миңа да каникулымны үземчә үткәрергә ирек бирмиләр. Тракторчы Шәһит абыйга прицепщик булып чыгармын дип торсам, көт сиңа... «Шәһит бер көн эшләсә, биш көн ремонтта ята, монда ичмаса акчасы күренеп тора»,— дип, этеп-төртеп дигәндәй, мине Сәбилә җиңги янына чөгендергә чыгаралар.

Уф, бигрәк канга тиде ул чөгендер бимазасы! Иртәнчәк салкынча, җиләс һавада ярый әле; әни әйткәнчә, һиммәт барда, бер буй авырсынмыйча эшләп аласың. Ә менә кояш рәхимсез кыздыра башлап, тәнеңнән куәт киткәч, бу шөгыль тәмам тәкатьне корыта башлый. Кулдагы китмән бүрәнәгә әйләнә, бил таш сын булып ката.

Ә Сәбилә җиңгигә эсселек әллә бар, әллә юк — хет таш ясын аңа, бер көйгә эшли дә эшли генә. Күзләренә үк төшереп бәйләгән ак яулыгы, саргылт күлмәге, иелгән-торган хәрәкәтләре белән күбәләкне хәтерләтә ул. Куна күбәләк, оча күбәләк... Каян килә соң Сәбилә җиңгигә шундый чыдамлылык?

Сәбилә җиңги, яңа рәт башлап, миңа таба якынлаша.

— Каенем, карале, күрәсеңме моны?— ди ул һәм минем күз алдымда тычкан койрыгы кебек тамыры белән чүт-чүт җиргә эләгеп торган зәгыйфь үсентене ансат кына чүптән арындырып китмәнләп куя.— Шул чөгендер үскәч, беләсеңме ни чаклы була, каенем?

— Үлчәп карамадым...

— Үлчәмәсәң, колагыңа киртлә, бер мыскал ап-ак, тәп-тәмле шикәр чыга бу чөгендердән. Ә шуның белән кем чәй эчә?

— Белмим...

— Ә мин беләм. Бу шикәр белән, тирләп-пешеп, иреннәрен ялыййолый, Таһир атлы егет кисәге чәй эчә...— Шулай ди дә Сәбилә җиңги, китмәненә таянып, миңа карап рәхәтләнеп көлеп тора. Җиңгинең тапкырлыгына, шаянлыгына сокланып, мин дә көлеп куям. Көлгәч, үзеннән-үзе ачу җуела, эш дәрте кузгала.

Мин тагын дәртләнеп, каударланып бер буй эшләп алам. Әмма тагын кулдагы китмән бүрәнәгә әйләнә, янә бил таш сын булып ката. Ә саргылт күбәләк армый-талмый, һаман чөгендер басуында очып кунып йөри.

— Каенем,— ди Сәбилә җиңги, минем янәшәмә якынлаша төшкәч,— әнә теге кадап куйган таякны күрәсеңме?

— Йә, күрсәм ни була?

— Шуңа җиткәч, безнең бүгенге норма тула.

— Чынмы?— дим мин кайнарланып.

— Билләһи! Мин санап та чыгардым. Сиңа — биш, миңа сигез рәт кенә калган. Бар, бик арысаң, чишмәдә юынып кил дә, тиз-тиз бетереп ташлыйк шуларны.

— Юк, чишмәгә барып тормыйм,— дим мин һәм тагын китмәнемә ябышам. Әллә каян дәрт керә, бил дә язылып китә, артымнан чистартылган, ипкә китерелгән чөгендер рәтләре тезелеп кала.

Чөгендер җирен эшкәртеп бетергән генә идек, бригадир Гарифҗан, сагалап торган диярсең, икенче көнне иртүк килеп хәбәр салды:

— Сәбилә киленнең аш-суга кулы ятып тора, диләр, урак өстен-

дәгеләргә пешекче ясап куйыйк әле үзен. Гадилә астакай.— ди.— Таһирга да эш чыгып тора: тегесен-монысын ташыр, бер буйдан җиңгәсен дә яман күздән саклап йөрер. Атның да, арбаның да менә дигәнен бирәм үзенә.

Әни бик икеләнеп калса да, Сәбилә җиңги бригадир әйткән эшкә чатлап ябышты. Мин исә яңа вазифамны тагын өнәмичә каршыладым. Ачумы шунда, гарьлекме — үзем дә аңлый алмаган бер хис кузгалды. Соң мин Сәбилә җиңгигә иярчен түгелдер бит?

Әмма кырга чыгуыбызның беренче көннәрендә ук мине канәгатьлек хисе, хәтта мавыгу сыман бер нәрсә биләп алды. Гаҗәп кызык шөгыль икән бу кырда казан асып аш пешерү! Азык-төлеген, утынын-суын, дигәндәй, мин ташыйм. «Тәме бар микән, каенем?..»— дип, шөбһәләнеп, кайнар казан тирәсендә Сәбилә җиңги өтәләнеп тиргә чума. Шунысы кызык, миннән башка Сәбилә җиңги юньләп бер ни дә эшли алмас кебек... Ярый әле, рәхмәт төшкере, бригадир Гарифҗан ярдәмчегә мине билгеләгән. Шулай булмаса, канатсыз кош хәлендә каласы иде бит Сәбилә җиңги.

Күпме әйләнгәләсәк-тулгангаласак та, сынатмыйбыз үзе. Нәкъ кояш төшлеккә менеп җиткәндә ашыбыз пешеп чыга, чәебез кайный. Нигъмәтләрне савытларга тутырабыз да, ут кызуында алланган яңакларны талгын кыр җилләренә куеп, механизаторлар янына кузгалабыз. Нәкъ шул минутларда күңелләрдә тантаналы бер тойгы уяна. Сәбилә җиңги, арбаның бер почмагына кунаклап, яшертен генә кечкенә көзгесенә карап, сөртенеп-төзәтенеп ала. Мин, Җирән Кашканы юлга салам да, кесәмнән бригадир Гарифҗан биргән кәгазьне алып, эшлекле бер төстә юлны билгелим:

— Иң әлек Рудник елгасы буена барып Оста Гомәрләрне ашатабыз, шуннан Чирмешән ягына китеп, Әмир абзый комбайнын табабыз. Ә Гыйрфаннар Туймәт ягындагы бодай җиренә төшкәннәр икән. Барып җиткәнче байтак вакыт кирәк, тизрәк кыймылдыйсы булыр бүген, җиңги...

Сәбилә җиңги артык сүз әйтми, ризалык белдереп башын гына селки.

Менә без игене урдырыла башлаган кишәрлек башына килеп туктыйбыз. Борынга камыл, әллә нинди үлән исләре килеп бәрелә. Камыл өстенә ашъяулык җәеп куябыз. Кашык-тәлинкәләрне, ипинетозны алып, шунда тезәбез. Инде табын әзер шикелле.

— Йә, каенем, чакыр!— ди Сәбилә җиңги.

Мин комбайндагыларга кул болгыйм, моның белән генә канәгатьләнмичә, Җирән кашканы да өркетерлек итеп сызгырып җибәрәм. Моторлар берәм-берәм сүндерелә, комбайнның әллә кай җирләреннән тузанга баткан кешеләр сикерешеп төшә башлый. Алар сүзгә, сөйләшүгә сусаганнар.

— Ну, бу Таһир хитрый да икән!— Минем янга эшкә чыгам дип вәгъдә биреп йөрде дә, хәзер казан тирәсенә елышкан.

— Ай-һай, җиңгәсе янында тәмам тазарган бу... Карале, кара, яңаклары да әрләнneкe кебек бүртә башлаган малайның...

— Казан тирәсендә, акмаса да, тама инде ул!

Кесәсеннән ак чүпрәк чыгарып, битен сөртә-сөртә, Оста Гомәр дә сүзгә кушыла:

— Нәрсә, Таһир дус, үртәшәләрме? Көнчелектән шулай алар. Синеке кебек җиңгәләре булсамы, болар...

Оста Гомәрнең әмере белән кашыклар кулга алына, ипиләр тотыла һәм бер мәлгә изге тынлык урнаша. Арыган, ачыккан кешеләр аш ләззәтенә чума.

— Ашың тәмле булган, Сәбилә килен, мең рәхмәт үзеңә,— ди Оста Гомәр. Аның мактавына ихластан башкалар да кушыла:

— Телне йотарлык!

Тик озак сөйләнеп торырга вакыт тар. Оста Гомәр әле кояшка, әле кишәрлеккә карый, иренен яндырып бер стакан чәй эчә дә урыныннан кузгала:

— Ягез, булдык, егетләр, эшкә!

...Галәмәт зур җиһанга әкренләп кич иңә. Җәйге кояш, үз эссесеннән үзе әлсерәп, ялкау гына, талгын гына шәфәкъка чумып бара.

Җирән кашка, арбаны шалтыратып, җай гына авыл ягына юырта. Сәбилә җиңги саламга чүмәшкән, башын бидонга терәп күзләрен йомган. Арыгандыр, талчыккандыр инде, мескен...

— Каенем,— ди Сәбилә җиңги кисәк мине сискәндереп,— син шагыйрь бул әле. Шигырьләр яза торган бер кеше бул әле син!

— Син, җиңги, бигрәк! Шагыйрьлекне теләп кенә алып буламыни? Аның өчен тагын башка кеше булып туарга кирәк.

— Әй, каенем, ир заты, телим дисә, әллә кем була ала бит ул. Мена, малай булсам, укыган булсам, әллә кемнәр булып куяр идем...

— Син, Сәбилә җиңги, каян уйлап таптың соң юкны?! Хәзер ир заты ни, хатын-кыз заты ни — барысы да бер бит, тигез!..

— Әй, ул тигезлек тормышка килеп ирешкәнче әле, каенем... Җиденчедән соң эти шул хәтле укытмакчы иде, әни кырт кисте. Янәсе, хатын-кызның маңгаена язылган, ир карарга да бала тәрбияләргә тиеш ул. Әй, качып кына китәргә кирәк булган шунда миңа өйдән!

Сәбилә җиңгинең гаме мине кисәк сагышландырып куйды. Һәрвакыт тере, шаян җиңгәмнән мондый уфтануларны көтмәгән идем. Әллә соң абый белән араларында берәр күңелсез нәрсә булганмы? Комбайн янында да әллә ничек чит-ят кешеләр кебек кыландылар. Бер-берсенә ачык чырай күрсәтергә җай булгандыр бит? Күпме генә эш өсте булмасын, ир кеше үз хатыны янына килеп сөйләшер сүз тапкан булыр иде инде. Әллә ничек кырку, каты бәгырьле шул минем Сарыйм абый.

Шул кичтә Сәбилә җиңгәм белән Сарыйм абыем арасындагы мөнәсәбәтләрнең ихласлыгына әллә ничек шигем кузгалып калды. Вакытлар үтү белән ул шик җуелмады, киресенчә, йөрәгемне өшетеп, чәнчеп көчәя, үсә генә барды. Кызлары да туды аларның, яңа өй дә өлгертеп киләбез. Ләкин абый Сәбилә җиңги каршында һаман хиссез, тойгысыз, аңа ниндидер кинаяле, чәнечкеле мөнәсәбәт тота. Аннары абыйның әллә нинди шыксыз бер гадәте бар. Берәр нәрсә булды исә, кешегә күзенең агы белән кадала. Миңа, малай кешегә, ярар, ямьсез баксын шулай. Мин төрлесенә күнәм, укам да коелмас. Әмма Сәбилә җиңги аның хатыны, күгәрченнәр кебек гөрләшер кешесе бит! Ни йөзең белән иң якын кешеңнең бәгырен өшетеп тормак кирәк?

Бу өй дә...

Шул өй дип тырышып-тырмашып йөри торгач, мөгаен, Сәбилә җиңгигә берәр зыян килгән, ул кисәк авырып китте. Авыруы да әллә нинди күрелмәгән зәхмәт — операция ясап дәваларга дип, Казан больницасына ук озаттылар үзен.

Дөньяның шау чәчәккә күмелгән бер мәле иде. Дәресләргә чаклы багып калыйм дип, Гөлназ бәләкәчне урамга алып чыгам да, йөрәгем «жу» итеп куя. Син дип еракта анаң өзгәләнә бит, нарасый... Җитмәсә, аралар да җәһәннәм ераклыгында. Барыр идек, хәлен белер, кызын күрсәтер идек.

Ә абый, хатынын больницага салып кайтты да, тынычланды. Уракка кадәр өйнең түбәсен ябасы иде, дип бөтенләй икенче дәрт белән йөри, осталар чакырырга ниятли. Әни исә абыйны юлга димли. Өйдә низаг. Әни:

— Бар, улым, киленнең хәлен бел, кирәксә, баш очында утырырсың,— дисә, абый күтәрелеп-бәрелә. Янәсе, врач-мазармы ул, аңардан чирлегә ни ярдәм? Аннары шундый зур эш кузгатып торганда, акчаны, вакытны ничек юкка әрәм итмәк кирәк? Чуртым булсын-

мы хатын-кызга, терелер!

Абыйның кирелеге, кеше хәленә керә белмәве мине эчтән ярсыта. Әни, дим мин, әллә соң җиңги янына үзем барыйммы?.. Укуың калса калыр иде, тик син ир бала булгач, баруыңнан ни файда? Хатын-кыз җенесе янына кертмәсләр дә үзеңне, дип, әни шиккә бата.

Без тартышып, икеләнеп торганда Казан больницасыннан авыл советына хәбәр килеп ирешә: «Авыруны карарга кеше җибәрегез!» Каһәр генә суксын инде абыйның кирелеген! Шул мәлдә дә, тегесен-монысын сәбәп итеп, җиңги янына барудан баш тартты. Аптырагач, Ядкарь бабай үзенең өлкән кызы Сәлияне тыңлатты. Сәлия апа китеп өч-дүрт көн үтте микән, тагын Казаннан хәбәр: «Мәрхүмәне алып кайтырга машина җибәрегез...»

Шулай кисәктән Сәбилә җиңгәмнең гомеркәе өзелде. Ничек үлгән?— берсен бер тыңламадым, кайтаргач, йөзенә бакмадым, каберенә карамадым. Болай итсәм, чыннан да аның үлеменә ышанырмын кебек иде... Яланга чыктым да җиргә капландым. Йодрыкларым белән туктаусыз туфракны төйдем. «Юк, юк, юк! Әй дөнья, кайда соң синең мәгънәң, гаделлегең синең кайда?..»

Сәбилә җиңгәмнең рухын мин һаман да кырдан, чөгендер эшкәрткән киленнәр, кызлар арасыннан, йә пешекче хатыннар тирәсеннән эзләдем. Киң, иркен сулышлы иген басуларына чыксам, ул үзе үк сары күбәләк булып минем каршыма очып килә.

— Саумы, каенем, шагыйрь булдыңмы әле?— дип сорый.

— Ник мин шагыйрь булырга тиеш соң, җиңги?

— Бәрәч, ник дип, шагыйрьләр кеше җанын аңлый беләләр. Сөенсәң дә, көенсәң дә сизенәләр алар, күңелеңә керәләр. Абыеңда шул сыйфат булмады, каенем. Мин шуңа үлдем. Тик минем тәнем түгел, җаным гына үлде, каенем.

— Синең бит кызың, нарасыең бар иде, җиңги.

— Әйтмә... Тик ул миңа сагыш кына өстәде шул, каенем. Сагынып-сагынып сагышландым да, йөрәктә бер мыскал көч калмады... Йә, китим, каенем, кояш өтә. Гөлназ кызыма сәлам әйт! Син аңа ярдәм ит. Минем ялгышларымны кабатламасын ул...

Сары күбәләк сүзләремә инде колак салмый, үсемлекләр, бөҗәкләр дөньясына кереп югала...

Сәбилә җиңгидән соң Сарыйм абый дүрт кат өйләнде. Соңгысы кибетче иде. Әллә йортына малны күпләп кайтарды, әллә ирнең үзен ныклап боргычлап алды, шуның белән яшәп китте. Бернәрсә хәтерләми, бернәрсәгә көенми абый. Әйтерсең лә Сәбилә җиңги, Ядкарь бабай белән Зөлхиҗә әбинең иркә канатлары астында үскән төпчек, матур бер гөл, безнең нигезгә күчкәч шиңмәгән, һәлак булмаган. Әйтерсең, рухи хатасы, хыянәте юк аның Сәбилә җиңги каршысында. Әй, әни, әни! Нишләп Сарыйм абыйның җанын йөрәк хисләрең белән сугармадың син?! Әллә Сарыйм абыйның бәгырьсезлеге дә кырыс заман хакыйкате булып, шуның каршында тәмам көчсез, гаҗиз булып калдыңмы син?

7

Менә инде яз килде. Язларда яшәү яме, язларда тормыш гаме. Язлар сине, баласын җитәкләгән ана кебек, гел алга, матурлыкка ашкындыра. Аларны син дә мин яраткан кебек үк яратасың микән, улым? Авылдагы язларым хәзер дә йөрәгемне сулкылдата.

Табигать язлары йөрәгемдә бөтен төсләре, шавы белән балкыса да, үз язым шактый гына күләгәле булды шул минем, улым. Бер яктан мин матурлыкка, ямьгә тартылдым. Кояш кара болыт арасына кереп аз гына җуелып торса да, җан тынычлыгым югалды. Ә икенче

яклап, үз омтылышым үз асылыма туры килмәде минем. Хәтта кешеләргә күтәрелеп карарга кыймадым. Шулай баксам, сул күздәге ак, чекерәеп, үзе үк аларның бәбәкләренә кадалыр кебек иде. Менә шуннан оялдым мин.

Иптәшләремнән иң элек аны Миңнури шәйләгән иде. Партасыннан борылып ручкамы, карандашмы сорап алганда, ул бер кавем сихерләнеп миңа төбәлеп торды да кычкырып җибәрде:

— Әникәй генәм, Таһирның күзендә сәдәф бар!

Гариплектән тартыну балигъльлык белән бергә килде. Тел укытучысы Нәзифә апа класска җөмләләр әйтеп яздыра: «Чирен яшергән үлгән...» Шуны дәфтәремә язарга кулым бармады. Их, терсәкне тешләп булса икән! Атналар, айлар буена больницада ятар идем, елларына түзеп күземне дәвалатыр идем... Кайчандыр качып кайткан юлымнан үз теләгем белән ике рәт барып, врачларга күрендем. Сул күземә әллә нинди лупалар белән текәлеп-текәлеп карыйлар да башларын гына чайкыйлар.

Менә шундый өметсез бер хәлдә мин тугызынчыны тәмамлап килəм. Беркөнне директор Ярмиев абый мине үз кабинетына чакырып ала. Ярмиев абый укучылар белән дустанә исәнләшеп, гәпләшеп йөрсә дә, аларны үз кабинетына бик сирәк чакыра иде. Мин, ниндидер аерым сөйләшү көтеп, ишекне ачам.

— Әйдә, Гарифуллин, әйдә!— ди Ярмиев абый. Аңа минем бусагада таптанып торуым ошамый булса кирәк.— Йә, кыюрак бул әле син. Менә монда урындыкка килеп утыр. Шулай... Гарифуллин, син каникулда нишләргә җыенасың? План-мазар бармы синең?

— Бар, абый,— дим мин.— Шәһит абыйга прицепщик булырмын дигән идем.

— Алаймы, вәгъдә дә бирдеңме?

— Юк әле.

— Алайса тыңла әле, зур үтенечем бар сиңа. Районнан безнең авылда сарык кыркучылар бригадасы төзергә кушканнар. Закиров абыең тегендә бәреләө, монда сугыла, тик кеше җыеп бетерә алмый. Син, Гарифуллин, тыңла әле, язып әле шулар бригадасына, ә?

Директор абыйның шулай олы башын кече итеп гозерләп соравы миндә аз гына икеләнү дә калдырмады. Әше әлегә бөтенләй ят күренсә дә:

— Ярар соң, мин риза...— дидем.

Мәктәптә укулар бетмәс борын ук, РТСка йөреп, йон кырку эшенә өйрәндем. Һәм, озак та үтмәде, артистлар кебек, чемоданнарга кием-салым төяп, булачак хезмәттәшләрем белән районның ерак авылларына чыгып киттек.

Баштагы мәлләрдә мин сарыкларны кызганып йөдәдем. Авыртадыр, ипсездер кебек аларга. Әмма, өстәлгә яткырып күпме генә йомшак мөгамәлә күрсәтмә, аңламый сине сарык. Һаман үрсәләнә, тыпырчына.

Тора-бара мин сарыкларны өстәлгә дә яткырмый башладым. Ике бот арасына кыстырып идәнгә утыртам да, башыннан тотып кыркыпмы кыркам.

Янәшәмдә эшләгән Каимә исемле бер кыз, өстәлдә тыпырчынып яткан сарыгы тирәсендә кайный-кайный, һаман миңа сүз ката. Сүзләре әллә ихлас, әллә юри:

— И-и, ирләр эш рәтен беләләр шул алар... И-и, ирләр кулын хайван да тоеп тора шул ул...

Каимәне әле мин бик аз беләм. Ул — күршедәге Тукмак авылыннан. Ишле гаиләнең олы баласы булса кирәк бу кыз. Җиденчене миннән бер елга алдан бетереп, хәзер колхозда эшли. Сәнәк, көрәк тоткан куллары минекеннән дә шәбрәк көчәйгәндер аның. Ир дип көнләшәсе түгел аңа. Хикмәт сарык белән эш итә белмәүдә генә...

— Син сарыкны өстәлгә яткырып азапланма, Каимә. Менә шулай ит тә, идәнгә генә утыртып кыркы син аны.

— И-и, синең сарыгың да тыңлаучан шул. Менә минекен кыркып кара әле син.

Мин Каимәнең сарыгын кыркыйм, кайчысын карап, көйләп бирәм. Ул күңелле гөжләп эшли, сыйфатлы итеп кисә башлый. Каимә чын күңеленнән сөенә, миңа рәхмәтләр яудыра:

— И-и, ир кешенең кулын машина да сизеп тора шул. Кара, җаный, үзе эшли бит бу хәзер!

— Нишләп мин ир булыйм, ди, Каимә?

— Кем соң син?

— Соң, ир түгел бит әле.

— И-и, булмасаң, җаным, булырсың. Эчмисең, тартмыйсың, буйсының төз, кулларың эшкә ятып тора. Ирнең дә менә дигәне булырсың. Әле ферма хатыннары да мактап туялмыйлар үзеңне. Бигрәк бер чибәр егетегез бар, диләр...

— Йә инде, бигрәк син, Каимә...— дим мин, колак очларыма кадәр кызара башлавымны тоеп. Каимә хушланып текәлеп карап тора:

— И-и, оялды да...

Без һәр авылда диярлек фатирга кызлар, егетләр аерым-аерым керәбез. Кичке ашны ашап, кайсы кая таралыша башлагач, Каимә мине урамга чакырып ала. Төзәтенгән, бизәнгән, хушбуй исләре бөркелә үзеннән. Көндез кара, шыксыз халаттан йөргән, сукрана-сукрана сарык кыркыган кыз бу дип һич уйламассың...

— И-и, Таһир, киче бигрәк ямьле, әйдәле, йөреп керик әле!— ди ул ачык елмаеп.

— Каимә, әнә Әхмәтне чакыр син, минем бигрәк йоклыйсым килә. Үлеп арылган...

— Йә, йә, сакал чыкмас борын бабай булып ятма. Бар, ике минут эчендә киенеп чыккан бул, көтәм!

Минем башка чарам калмый. Киенеп, Каимә янына чыгам.

Һәр авылда диярлек, эңгер-меңгер төшкән чакка туры китереп, яшьләр йә су буена, йә әрәмәлеккә җыела. Аннары, ярты төннәргәчә, күңелләрне айкап, гармун моңнары, җыр тавышлары тынмый. Каимәнең юанычы да шул урында. Әйлән-бәйлән уйнаучы яшьләр уртасында иң күбе Каимә бөтерелә. Таган атынучылар арасында иң көчле көмеш тавыш — Каимәнеке. Яшьләр биеп, йөгерек уеннар уйнап арыгач, ял иткәндә әйтешкән иң үткен, иң җор сүзләр — Каимәнеке...

Мин Каимәне көтә-көтә ялыгып бетәм. Ә ул сулышына кабып, әсәрләнеп йөгереп килә дә:

— И-и, Таһир, әнә шул озын буйлы егет белән тагын бер генә биеп алыйм инде?— дип, очынып, тагын уен эченә кереп китә. Булса да була икән кешедә дәрт!

Кайтырга чыкканда, озатырга дип, һәр кичтә Каимә артыннан ике-өч егет иярә. Кыз мине култыклап ала, тән кайнарлыгын сиздереп, миңа сарыла. Ә тегеләргә, чебен куганадагы кебек, кулларын гына селеккәли:

— Йә, йә, йөрмәгез юкка, егетем бар!

Ялгызыбыз калгач, Каимә һаман да кайнар, ихлас бер халәт белән мине сөйләшүгә тарта:

— Йә, кайсы күбрәк ошады? Егетләрнең!

— Ә... гармунчылары әйбәт.

— И-и, Таһир җаным, үземнең дә күзем шуңа төште. Чәчләре бөдрә, ә күзләре зәңгәр... Ну матур! И-и, бер үбешәсе иде шул чукынчык белән!..

— Аннары шуңа кияүгә дә чыгып куярсың...

— Кит, сөйләмә! Матур кешегә кияүгә чыгаммы соң, аллам сакласын!

— Матур дип өзгәләп дә, кияүгә чыкма, имеш. Дөрес сөйләмисең бит, Каимә?

— Ипидер! Матур кешегә кияүгә чыкмыйм, Таһир. Матурлар һавалы, сансыз булалар алар. Беләм бит мин, тормыш итеп булмый алар белән...

— Кызык син, Каимә! Күңелең тартмаган кеше белән ничек тормыш итәргә җыенасың соң син?

— И-и, Таһир җаным, иремне мин гел шулчаклы кадерләрмен, аягы астында тузан булырмын. Назлы сүзләр генә әйтермен. Чит иргә артык бер кәлимә сүз катмамын, күземнең ялгыш та нурын сирпемәм. Ирем шуны ярату дип белер. Ә чын ярату белән балаларымны яратырмын мин. Минем өч ир балам, бер кыз балам булачак...

Федотовка — керәшеннәр авылы, безнең бригаданың соңгы эш пункты булды. Машиналарыбыз көйләнеп, үзебез остарып җиткәнбез, кыркасы сарыклары хәтсез күп булса да, атна-ун көн эчендә эшне төгәлләп кайту насыйп булыр, дип, җилкенеп керештек. Мине авыл, бигрәк тә әни сагындырган иде... Күчеп килүебезнең икенче көнендә, төш узгач, кояш баешы ягыннан бик ямьсез кара болыт чыкты. Ишелеп-ишелеп килгән шул куркыныч болытлар, төпкелдәге су кебек бөтерелешеп, бер-берсе белән чәкәште, күзләрне камаштырып, җиргә яшен утлары сузылды. Эре-эре салкын тамчылар тама башлады. Без, эшебезне туктатып, лапаска чүмәштек.

— Бу, мөгаен, берәр җиргә чәпи инде. Бу чәпәми калмый инде,— ди Каимә хафаланып.

— Яшен тоткычлары бардыр лабаса.

— Һәй, тоткычыңа карый ди синең...— Каимә сүзен әйтеп бетермәде, кинәт күзгә яктылык сукты, секундның күпмедер бер өлешендә авылның кырый йорты өстендә утлы елан сузылып, асылынып торды, артыннан колак тондыргыч шартлау яңгырады. Чынчынлап котым алынып, искә-аңга да килергә өлгермәдем, Каимә кычкырып җибәрде:

— Яна бит, и-и, яна!..

Кешеләр, кулларына корал-мазар табарга теләп, тегендә-монда буталыша калдылар, мин исә түбәсендә кызгылт ялкын телләре сузылып-җыерылып яткан агач йортка карап, бар куәтемә шунда йөгердем. Кызган тәнгә ара-тирә эре, салкын яңгыр тамчылары тамгалый. Ләкин ямый. Аның каравы җил, тегендә-монда авышып, ялкынны котырта, узындыра бара.

Мәхшәргә карап йөгерә-йөгерә, күрмим дә икән: каршыма чатанлый-чатанлый керәшен карты килеп чыккан. Таягын хәтәр болгыйболгый, миңа кычкыра:

— Тукта! Утка кагыласы булма! Тагын кодайдан безне аттырасың киләме? Тукта, дим! Я кода, кара сыер сөте китерегез, кая, кара сыер сөте!..

Мин картның таяк белән үземә кизәнгәнен, сул яңакны шуның очы тырнап үткәнен тойсам да, берни аңышмыйм, атылып ихатага йөгереп керәм. Ишектә йозак күземә чалына. Төтен пыскыган тәрәзәләргә баксам, аһ иттем. Бөтен буйлары белән тәрәзәгә ябырылып ике бала елый... Мин кулыма эләккән түмәрне тәрәзә төбенә бәрәм. Тәрәзәне тибеп ватам, өйгә төшәм. Менә төтенгә тончыга-тончыга елашкан балалар кулымда. Берәм-берәм мин аларны артымнан калмый йөгереп килгән Каимәгә сузам. Шуннан соң, анда бәргәләнеп, монда сугылып, кулыма эләккән өй җиһазларын тәрәзәдән атам. Күздән яшь ага, сулыш буыла, мин йөткерә башлыйм. Әмма Каимәнең илерүле тавышы сискәндерә:

— Чык, Таһир, өстеңә ишелә!

Җиргә сикергәч тә, минем өстемә су койдылар, әмма кызулыкны, тончыгуны бу гына җиңәлмәде, мин инешкә чаптым...

Кичен хуҗабикә Анна минем сыдырылган яңакка күз ташлаштыргалап сөйләнеп тора иде: «Үләт Гөргери, ничә еллар эчеп, сазда аунап первай хулиган булып йөрде дә, хәзер изге ата булмакчы... Оятсыз, кара сыер сөте белән җенләнеп, балаларны карап торып яндырып үтермәкче...

— Анна апа,— дим мин.— Кара сыер сөте нигә кирәк булган соң?

— Безнең калыкта ул шундый ышану бар инде. Яшен утына кара сыер сөте сипсәң, янгын басыла була... Кодай каныкмый була...

Шулчак ишек кактылар. Әллә ничек уңайсыз бер халәттә калдым. Җитмәсә, авызга зур итеп ипи дә капкан идем.

— Такир, ничек кенә рәхмәтләр әйтим икән сиңа, улыкаем... Балаларымны исән-имин уттан алып калгансың, ничекләр генә үзеңә яхшылык кылыйм, Такир энекәем!

Каршымда басып торган хатын-кызларның бер-берсенә гаҗәп охшаш булуына игътибар иттем. Икесе дә озын, зифа буйлы, дымсу күрән күзле, туткыл чырайлы иде. Тик берсе бик өлкән булса, икенчесе бик яшь иде аларның. Өлкәненең чәче бик пөхтәләп кызгылт косынка эченә җыештырылган, ә яшенең саргылт бөдрәләре күбектәй кабарып җилкәләрен каплап тора.

— Без сезгә, Таһир, балаларны коткарган өчен рәхмәт әйтергә килдек,— диде яше көмештәй яңгыравыклы, җырчан бер тавыш белән һәм кыю гына миңа кулын сузды.

— Алисә... Ә бу минем әни, Анфиса Григорьевна!..

Алисәнең кулы бик йомшак, гадәттән тыш ак иде. Кыз, карашын читкә төбәсә дә, кулларын алырга ашыкмады:

— Сез чын-чынлап герой, Таһир!

— Йә инде, нинди герой ди...

Әмма аны әнисе хуплый:

— Юк, юк, Такир улым, син бик батыр егет...

— Әни, Такир түгел бит, Таһир дип әйт!

Ана белән кыз Анна апа янына барып тагын нидәрдер сөйләшеп тордылар да китеп бардылар. Күрешәсең кеше белән, танышасың, ә аннары бер-берең өчен мәңгегә җуеласың... Аз буламы кеше гомерендә андый узгынчы танышлык!? Алисәнең кыяфәте, килеш-килбәте мине дулкынландырып, эчтән ничектер өтеп алса да, кыз белән кабат очрашырбыз дип һич уйламаган идем.

Бу — өч көннән соң булды.

Федотовка авылы каршында текә тау бар. Тау итәгеннән ургылып чишмә чыгып ята, зирекле куе әрәмәлек башлана. Берничә көн яңгырлар явып, салкын җилләр исеп торгач, көн биниһая ямьләнеп китеп, яшьләр шунда уенга чыктылар. Мин агачка сөялеп, гадәтемчә, Каимәнең биеп-уйнап туйганын көтеп, тамаша кылып тора идем, тавышка сискәнеп киттем.

— Хәерле кич, Таһир!

Әллә караңгыдан, әллә агач ышыгында булганга, мин үземә сәлам бирүче кызны тиз генә танып ала алмадым.

— Һәй, Алисә бит мин, онытгыңдамы әллә, Таһир?

Әйе шул, көмештәй яңгыравыклы, җырчан тавыш иясе Алисә бит... Ничек шундук аермадым соң!

— Миндә тавык күзе, ахры!

Алисә ихластан көлеп җибәрде. Мин дә елмайдым. Ләкин сул күз галәмәте искә төшеп, кинәт күңел сызлап китте. Ярый әле караңгы, теләсәң күпме текәлергә була...

...Без ул кичтә бер-беребез хакында ачышлар ясап һәм шул ачышлар сөенечена бирелеп, вакытның үтүен, уендагы яшьләрнең таралышуын да сизми калганбыз. Алисәне озата барып, икенче көнне тагын очрашырга сүз куеп хушлашкач, кинәт бәреп чыккан сөенечемә чик-чама булмады.

Мин кыз озаттым!..

Иртән эшкә килгәч, Каимә миңа ят, сәер бер караш ташлап-ташлап ала.

— Син кичә кая югалдың, Таһир?

Мин дәшмәдем, әмма минем чыраем тыелгысыз мутлык белән балкып, үз-үземне сата иде.

— И-и, Каимә апаңнан яшерә алмассың, Таһир. Асыл кошны эләктердем диген инде. Күз өстендә каш... Бөтен Федотовка егетләренең авыз суын корыткан кыз! Тик берсен дә янына якын китерми, ди... Исеме ничек әле? Алисәме... Тик, Таһир энем, бик иртә кинәнәсең. Бер егет сөйләде инде миңа. И-и сантый, и-и хыялый ди ул синең Алисәң. Патшага чыгам дип йөргән кызларның берсе икән ул...

Каимәнең тел төбен һич аңлый алмыйм мин. Әллә юри, әллә чынлап сөйли. Шулай да сүзләре зиһенгә каккан кадак кебек кереп кала.

Юк, юк, сантый түгел Алисә! Ул мин белгән кызлар арасында иң акыллысы, иң әйбәте...

Мин әле дә, Алисә белән җитәкләшеп, бер-беребезгә ярдәм итешеп, Федотовка авылы каршындагы текә тауга күтәреләм. Тыннарыбызга капланып, көлешә-көлешә, ниһаять, тауга менеп җитәбез.

— Сезнең яклар матур, Алисә!

— Мин бу җирне бик яратам, Таһир! Моннан кош кебек талпынсаң, очып китәрсең кебек.

Ни гаҗәп, Алисәне хәтерләсәм, мин гел тауга менгән кебек булам. Алдымда киң, иркен җиһан җәйри башлый. Карашларым ачыла, яктыра төшә. Ерак матурлыкларга караган кебек, күңелдә изге, олы уйлар кабына, тормышка ышаныч, дәрт туа... Ә инде чынлап биеклеккә менсәм, мин тагын көмеш яңгыравыклы, җырчан тавышны, шул тавышка төренгән татлы сүзләрне ишеткән кебек булам.

— Алисә, иртәгә без китәбез бит.

— Беләм, Таһир.

— Алисә!..

— Әү, Таһир!..

— Киткәч тә мине онытырсың, Алисә...

— Син үзең онытып куярсың әле. Минем гел сине уйлыйсым килеп тора, Таһир. Зиһенемне чуалттың инде син...

— Алисә!

— Таһир!

Иртән, китәсе көнне мине коточкыч сагыш басты. Федотовканы ташлап чыккач та, үземне үзәк өзгеч бер халәт басачагын сизенә идем. Ләкин әлеге эч пошу аерылышуны сизенүдән генә булмаган икән...

Төш тирәләрендә соңгы сарыкларны кыркып бетереп, юлга җыена башладык. Миннән башка барысының да кәефләре күтәренке, шат. Шул халәтне тагын да дөртләтеп, бригадирыбыз хәбәр сала:

— Колхоз алдынгыларны бүләкләргә җыена. Унбиш-егерме минутка җыелып алабыз.

Озак та үтмәде ачык һавада кечкенә генә җыен сыман бер нәрсә оешты. Озын буйлы, бик чибәр ир уртасы кеше, колхоз рәисе, бик мәгънәле генә итеп урак-чүкеч дуслыгы турында сөйләде, колхозга искиткеч зур ярдәм күрсәтүебезне әйтеп үтте, кат-кат рәхмәт белдерде.

Бүләкләрне, диде ул, уку алдынгысы Алисә Макушева тапшыра. Һәм янәшәдә торган җиңел машина ягына борылып әйтеп алды:

— Алисә, син әзерме, кызым?

Машина кабинасында мин кемнәрнеңдер эвәрә килгәнен шәйлә-

сәм дә. Алисә шунда булыр дип башыма да китермәгән идем, билгеле. Һәм менә сиңа!.. Озын, зифа буена искиткеч килешеп торган укучы кызлар формасында, оялчан елмая төшеп, Алисә килеп чыга.

Мин, сихерләнгән кебек, Алисәдән күземне ала алмадым. Бөтен хәрәкәтләре килешле, матур аның!

— Таһир, чукрак, ишетмисеңме әллә?! — янәшәмдәге Каимә шулай дип кабыргага төрткәч, сискәнеп киттем.

— Нәрсә?..

— Бар, бүләгеңне ал, сине чакыралар бит! И-и, бу кадәр дә сихерләр икән үзеңне...

Менә мин, кирәкмәгәнчә бер кызулык белән, Алисә ягына атлыйм. Йөрәгемнең дөп-дөп тибүен, авызымның кинәт кибеп куюын тоям. Йә, нигә шул чаклы дулкынланам соң? Минем шул тынгысыз халәтемне тойган сыман, Алисә дустанә, тыныч елмая, ярдан тартып алырга җыенган кеше сыман, алдан ук ак, нәфис кулын суза.

— Чын күңелемнән котлыйм сине, Таһир!.. Сәгатең гел-гел мине искә төшереп торсын!

Алисәнең дымсу күрән күзләрендә чын сөенү, ямь... Әмма алар кисәк электр тогы бәргән шикелле тартышып куя.

— Таһир, нәрсә ул күзеңдә?..

Мин, кинәт сискәнеп, башымны аска иям, тәнемне гөлт итеп ут баса. Бетте... Алисә дип төн белән көнне аермый башлаганмын. Күренми, ничек текәлсәң дә була, имеш... Бөтен тәнем ялкынланган хәлдә артка каерылам...

Мин әле дә гаҗәпләнәм. Аякларымны Алисә яныннан сөйрәп алып иптәшләрем янына барып басарга ничек көчем җитте икән? Ничек шуннан соң да мин кеше күзенә күренеп йөри алдым икән? Хәер, халәтнең хәтәрргә афәт минутында түгел, соңарып, соңлап килә, диләр...

...Менә мин ялгызым үзебезнең Килмәк урманына кереп киләм. Серкә очырып килгән бодайлар арасыннан сузылган тар юл, сөзәкләп булса да, үргә күтәрелә. Атлаган саен каршымда киңрәк, мәһабәтрәк дөнья ачыла. Әмма миңа биеккә күтәрелү дә авыр икән. Монда Алисә сагышы көчәя. Түзалмаслык, бәгырьне көйдерә торган утлы сагыш... Оят та, әрнү дә шунда.

Тик мин һаман атлыйм. Мин кая таба, нәрсәгә атлаганымны бик яхшы беләм...

Хуш инде, Алисә! Таһир дигән бер бәхетсез Мәҗнүн йөрмәсен әле сиңа күз көеге булып. Син үзеңә тиңне, әйбәтне табарсың, Алисә. Ә миңа, җирдә йөргәнче, үлү артык... Тик син бераз чак каберемә кил, чәчәкләр утырт, Алисә?! Мине искә төшереп бер җырла син, зинһар, яме? Әй, хуш, Алисә!

Мин, базга сикергән сыман, имән кәүсәсеннән җиргә ыргытылам... Тик өнме бу, төшме? Таныш, бик таныш үзәкне өзгеч тавыш яңгырап китә: «Улым! Таһирым! Әй-и!..» Әни бу! Миемне үкенечле уй яндыра... яндыра... Әни, мин сине уйларга онытканмын бит, әни-и!..

Тулысынча һушка килүем больница койкасында булды. Әллә нинди тере, әрсез бер истән җыерылып, күземне ачтым. Тирәмдә ак халатлы берничә кеше кайнаша иде. Олысы, калпагы астыннан чаларган чәчләре күренеп торганы, эшеннән туктап, бер мәлгә миңа багып торды.

— Әй, энем, энем, туып җитмәгәнсең, инде гомереңне өзәргә җыендыңмы?

Шелтә, ихлас әрнү сүзләре кинәт айнытып, зиһенне язып җибәрде. Мине әлмәктән төшергәннәр!..

Яшәүнең кадерен исән, нык чакта түгел, һәр күзәнәгең белән чиргә каршы баскач бик ачык тоясың икән ул. Исән калу сөенечен-

нән минем үкереп елыйсым килә. Ләкин янәшәмдәге сестрадан тартынам. Ул мине саклый. Бу егет тагын үзе белән берәр хәл кылмасын, диләрдер.

Улым, гомеремдә иң авыр вакыйга булып торган хәлне — үз-үземә кул салуны мин синнән яшереп калырга җыенган идем. Бу үткәнем өчен миңа әле дә оят. Үз-үзеңә кул салудан да зуррак хурлык, түбәнлек бармы соң? Бу бит дөньядагы иң изге нәрсәгә — яшәүгә хыянәт итү. Бу — мәхәббәтне аяк астына салып таптау. Бу, ниһаять, кеше асылын пычрату.

Сизәсеңдер, миңа иң газаплысы әни каршында калу иде. Мин аны елар, тиргәр, әллә нинди сүзләр табып оялтыр, дип көткән идем. Әмма мин әнине бик начар белəм икән шул. Дөрес, мин аның йөзенә, күзләренә күтәрелеп карарга кыймадым. Анда бәлки әллә нәрсәләр укырга мөмкин булгандыр. Сүзләрендә исә әни тормыш кебек сабыр, төпле һәм гади булды:

— Болай ук каты бәгырьле булырсың дип уйламаган идем, улым. Сәбилә җиңгәң ярты дөньямны алып китте. Инде син... Бер йорттан бер-бер артлы ике җеназа чыгартырга җыендыңмы? Үлүчегә генә ансат, бөтен авырлыгы җыештыручыга төшә аның...

Әни битемә, муеныма йомшак кына кагылып уза:

— Әле ярый бау алганыңны күреп калдым, улым. Төсең качкан, сөйләшүеңдә мән юк иде. Бау өзеп алуыңны күргәч, йөрәгем «жу» итте. Ходайның рәхмәтләре, шуны күрмәсәм, артыңнан урманга менәргә башыма килер идемени?!

Әнидән соң яныма Каимә килде. Ләкин ул мине сүгә дә, юата да алмый.

— И-и, Таһир! — ди дә, нәрсәдер әйтмәкче була. Әмма әйтә алмый, күз яшьләренә каплана. Тәки күңелендәгесен җиткерә алмыйча китте. Болай ук йомшак күңелледер дип һич уйламаган идем үзен.

Тегесе-монысы килеп хәлемне белсә, үгетләсә дә, яныма Ярмиев абый килер дип башыма да китермәгән идем.

— Исәнме! — диде ул минем аптыраулы карашымны игътибарсыз калдырып. — Син безгә бик зур мажара ясый яздың бит, Гарифуллин. Шулай ук зур трагедиягә юлыктыңмыни? ...Йә, ярар, буласы булган, берәр атнадан чыгарырлар үзеңне, әйдә, юлга җыен!

— Кая, абый?

— Мәскәүнең үзенә үк юнәлергә туры килер. Күзеңнең авыруы бик җитди ди бит... Ярар, борчылма, атом заманында күз төзәтер кеше табылыр әле. Тәвәккәллик, Гарифуллин!

Ярмиев абый күңелемдә сөенеч кабызып китте. Мин газаплы кичерешләремнән кинәт арындым, өметле, якты киләчәк белән яшим.

Үземә операция ясап күземне ачар кешене күптән инде ак сакаллы җыйнак кына бер карт кыяфәтендә күрә идем. Борынына зур күзлек тә атландырган ул. Мондый хирургны киноларда, рәсемнәрдә күреп, язмышымның шундый кеше белән бәйләнүен тели идем. Ул башта мине күземне карап итүем өчен әрләр, ә аннан соң, хисапсыз күп шәкертләрен җыеп, тәвәккәлләп, операциягә керешер... Әмма чынбарлык бөтенләй башка кеше — яшь, чибәр бер апа белән очраштырды. Ярмиев абый белән без аны Мәскәүнең күз өлкәсендәге үзәк фәнни-тикшерену институтында эзләп таптык. Регина Николаевна, ихластырмы-юкмы, мине очратуына үзе дә чиксез шат:

— Без уйлап табып, гамәлгә кертергә җыенган ясалма хрусталик нәкъ шундый күз патологиясе өчен. Сынауга гаҗәп уңышлы очрак!

Ниһаять, минем тормышымда иң бәхетле көн туды. Еллар буе бәгырь катырып, кимлек-хурлыкларга төшергән ак сәдәфне күземнән алып ташладылар. Тагын бер операция ясап ясалма хрусталик куйдылар.

— Регина Николаевна, күрәм! Мин бөтенләй яхшы күрәм!

— Братишка, синең өчен мин дә чиксез шат! — ди Регина Николаевна, шулай ук дулкынланып.

Авылга кайткач, рәхмәт әйтим дип, иң элек Ярмиев абый янына чаптым!

8

Әни!.. Әни мине исәр һәлакәткә алып барган Килмәк урманы юлыннан гына түгел, бөтен гомере буена артымнан саклап, озатып барган икән... Моңа мин, билгеле, хәзер генә төшенәм. Вакытында исә, үземне җитлеккән кешегә санап, аңардан тиешле ерагаям дип ерагайдым. Дөрес, хисләнеп, аңа сыенган чакларым да булды. Әмма күбрәге — мин әнидән еракләша барганмын шул.

Замана да, холкым да туры килеп торган моңа. Безнең буын артык канатлы булды. Сәбәпле дә, сәбәпсез дә туган нигезләрен ташлады. Ара еракклыклары — әле ярты бәла. Күңелләрең береккән булса, поезды, самолеты бар. Җаннар бәйләнешен җую куркынычрак иде.

Әни чарасыз калган чакларында гел уфтанып әйтә торган иде: «Нишлисең, күрәчәк маңгайга язылган инде, улым...»

Чынлап та, тормыш нәрсәдән, ничек ясала соң? Шул уйлануларымнан соң мин үз тормышыма икеләтә-өчләтә игътибарлы була башладым. Кызык бит! Мин үзем адым ясыйм һәм, читтән карап торган бер кеше кебек, үзем үк үз адымымны тикшерә, бәяли торам. Әмма көтмәгәндә минем күзәтүләр авыр, катлаулы уйлар кузгатып җибәрде. Әле хәзер дә колагымда өн яңгырый:

— Таһир, миңа стипендия бармы?

Бу — Асыл тавышы. Асыл да, мин дә университетның тел-әдәбият бүлеге студентлары. Икенче курсның кышкы сессиясен йомгаклаган чак. Мин, группаның старостасы буларак, тулай торакка стипендия хакында хәбәр алып кайтып килә́м. Асыл шуңа үз бүлмәсеннән миңа каршы йөгереп чыккан:

— Йә, Таһир, әйт инде, бармы миңа стипендия?

Асылның самими зәңгәр күзләре, чибәр чырае, юк болар гына түгел, хәтта чаңдыр, төз гәүдәсе дә сорау белән тулган. Асыл университетка детдом баласы булып килгән, бөтен өмете стипендиядә генә.

— Таһир, әйт инде, нигә газаплыйсың соң?

— Бар, Асыл!

Асыл кинәт бәреп чыккан сөенеченнән сикереп, балаларча кулларын чәбәкли һәм, муенымнан кайнар кочаклап, биттән үбеп ала.

— Ай, рәхмәт, Таһиркай!

«Нәрсә булды соң бу, ялгышумы? — дип үз-үземнән сорыйм мин. — Ник Асылны алдадым мин?..» Юк, нигә алдыйм ди? Стипендиямне биреп барырмын. Миңа нәрсә, армиядән кайткан егеткә, өчдүрт рәт барып вагон бушатсам — үзе бер стипендия. Ник дип әле шул бичаракайны кара кайгыга батырып хисаплашып торырга? Сөенсен әйдә!..

— Таһир, әйдәле, бу кадәр шатлыкны билгелик әле. Киного чакырам мин сине!

Чибәр группадашы белән киного барып кайтудан кайсы егет баш тартсын? Мин рәхәтләнеп риза булам. Үзара юк-барны сөйләшеп, көлешеп «Анна Каренина» фильмын барып карыйбыз. Асыл Лев Толстойның бу мәшһүр романын укымаган булган икән, берьюлы ике куян аттым, дип сөенә. Кино да каралган, программа таләп иткән әсәр дә үзләштерелгән... Мин исә кызга үгет биреп маташкан булам. Әдәби әсәрне иң яхшысы — үзең тотып уку. Асыл. Шулай иткәндә

зачет, имтиханда җавабың да тәпле, тулы булачак.

— Мин бу әсәрдән куркам,— ди Асыл.

— Чынлапмы, ә нишләп?

— Аннаның кыланышлары мине куркыта. Ә ирен чынлап кызганам. Һич кешечә генә түгел, әллә нинди бит ул Анна...

Сәер фикерләү дип уйлыйм мин. Ләкин башка сүзләр янәшәсендә ул җуела. Асылның уйларына мин юньләп төшенми калам.

Айның уникесендә кассадан алып, студентларга стипендия таратам. Миңа һәр айда ике ведомость тутырырга туры килә. Берсе — бухгалтериягә, икенчесе Асыл өчен. Шуңа кул куеп, тиярен алганда кыз һәрчак шикләнә:

— Минем «өчле»ләрем күп, ничек бирделәр икән, Таһир?

— Соң бирмичәни, синең гаиләә хәлеңне, Асыл, берсенеке белән дә тиңләп булмый!..

Бер ай стипендия алды Асыл, ике ай, өч ай, әмма дүртенчесендә мин тотылдым. Соңыннан үзем дә аңладым: яхшы эш булмады бу. Кызга хәер бирү кебек бер кимсетү, хурлау булып чыккан.

Ә «капчыктагы без»нең тишеп чыгуы болай булган. Асыл дәрестә чакта, бүлмәләренә бик ярсынып, тузынып, комендант килеп керә.

— Шәрипова общежитие хакын түләүдән качып ята, мин аны куам!— дип кычкырына һәм Асылның мендәр, түшәкләрен күтәреп чыгып та китә.

Асыл кайткач, билгеле, бик куркынып, комендантка төшә:

— Мин бит стипендия алам, апа, торак хакын шуннан тотып калалар,— ди ул.

— Син әле намуссыз булу өстенә, аферистка да икәнсең!— дип зәһәрләнә хатын.— Стипендия алсаң, түләргә кушмаслар иде, менә бит документ! Дүрт ай инде син бурычлылар исемлегендә!

Асыл комендантка ышанмый, бухгалтериягә йөгерә. Анда аңа стипендия бирелмәвен әйтәләр... Ярый әле, комендант хәлгә керә белә торган хатын икән, яхшылап аңлаткач, бурычны түләгәч, Асылны тиз гафу итте.

Әйберләрен коменданттан алып, бүлмәсенә илтеп куйгач, кызарынган, ялкынсынган Асыл, сөйләшергә дип, мине урамга алып чыкты.

— Ник болай иттең, Таһир?

— Беләсеңме, Асыл...

— Дөресен әйт инде, кызгандым, диген... Үксез бала, мохтаҗ бала, дидең...— Асыл, кесәсеннән яулык алып, күз төпләрен сөртте, ләкин тавышы әүвәлгечә тигез, тыныч калды.— Мине бит гел шулай җәлләп килделәр... Бәгыремә төштеләр инде шул җәлләүләре белән. Мин теләмим, теләмим үземне кызгануларын. Минем кеше төсле тигез буласым килә, аңлыйсыңмы шуны?

— Аңлыйм, бик аңлыйм, Асыл...

— Аңлыйсың... бернәрсә дә аңламыйсың шул син, Таһир!

— Ну, кирәген аңлыйм инде.

— Кирәге нәрсә соң аның?— Асыл артык гаҗәпләнә төшеп минем күзләремә караш ташлады.— Нәрсә аңлыйсың син, Таһир?

— Ә син нәрсә аңлавымны теләр идең соң?

— Бар, янымнан ун метрга читкә кит, аннары әйтәм...

— Шаяртасыңмы?

— Юк! Алайса үзем китәм.

Чынлап та, Асыл сәер атлап янымнан китеп барды, бераздан борылды һәм беркавым миңа текәлеп торды. Нәрсә эшли соң бу Асыл, нинди шаярту кора?

— Бел, йөрәгемдә йөрткән егет син буласың!

Һәм Асыл йөгереп китеп тә барды...

Асыл артыннан ташланырга кирәк булгандыр бәлки... Ләкин аякларым тыңламады, кызның хәбәре мине әллә ничек тораташтай итте.

Асыл мине ярата... Өнме соң бу? Мин үзем, яр сөеп карасам да, кызлар гыйшкын татыганым юк иде. Бигрәк сәер икән бу халәт. Үзеңне ничек тотарга да белми аптырап каласың икән бу вакытта. Мин Алисәгә гашыйк булган чагымны сагындым. Яну, көю йөрәккә якынрак икән ләбаса! Яратылган түгел, яраткан бәхетле инде болай булгач...

Юк, көтелмәгән сер булганга гына каушап калганмын. Асыл миңа ошый. Бу чибәр кыз мине дөрләп торган утка салмагае әле. Хәер, нигә ут, нәрсәгә ялкын? Миңа Асыл янәшәсендә искиткеч рәхәт, мин гел аңа тартылам. Без лекцияләрдә гел бергә. Киносына, театрына бергә җитәкләшеп йөрибез. Кичләребез дә аулакта бергә үтә. Ялгыз калсам да Асыл минем уйларымны, хыялымны били. Юк, Асыл — бөтен барлыгы белән мин хыялланган кыз, ул минеке, мин аныкы кебек. Нәкъ менә шундый парлар тигез, бәхетле, тыныч тормыш корып җибәрәләр дә ул...

Май азагы иде. Университетта лекцияләр тәмамланыр чак. Семинарлар оештырылмый диярлек, ә имтиханнарга кадәр вакыт бар әле, студент халкы бераз ял-хәл ала, язгы кояш, ямь белән хозурлана.

Дәрестә чакта ук миңа бер язу сузалар. «Таһир, бик мөһим сүзем бар, мине көт әле! Альмира». Карашым белән арткы парталарның берсендәге Альмираны табып, баш селким. Кабыргага ручка белән Асыл төртеп куя: «Нинди сер? Миңа да әйт!» «Ярамый, дәүләт сере». Альмира бу араларда бик боек йөри. Балтасы суга төшкән кеше кебек рәк. Ә элек ут белән бер иде бит. Группаның беренче активисты, һәр эштә төп таяныч иде. Нәрсә булды икән соң, дип пошынып уйлыйм мин. Һәм, ярдәм-фәлән сораса, һичшиксез, кызга ярдәм итәрмен, дип фикерлим.

Асыл белән хушлашып, иң арттан төшеп килүче Альмираны каршыладым.

— Йә, профорг иптәш, мин сезнең карамакта!

— Бик хуш...— дип елмайды Альмира.— Әйдә, урамга чыгыйк әле, көне бик матур.

Альмира бик нәзакәтле, рәтен белеп киенә. Студент кына булса да, дәрәҗәле ханым сыман. Сүзендә дә кешегә йога торган ниндидер бер көч сизелә.

— Альмира, синең миңа сүзең бар иде шикелле.

— Туктале, Таһир, кафега кереп капкалыйк булмаса.

Альмира кафеда иң затлы ризыкларны сайлап ала. Тик күреп торам, гамендә ризык тәме түгел, әчтән нәрсәдер исәпли.

— Яз җитеп, паркны да күргән юк. Әйдәле, парк ягына барыйк әле, Таһир,— дип, әйтәсе сүзен тагын көттерә төшә Альмира.

Паркта ямь. Туктаусыз кошлар сайрый, агачлар яфрак ярып маташа.

— Таһир,— диде Альмира, ниһаять.— Син миндә берәр нәрсә сизәсеңме?

— Сизәм,— дидем мин.— Синең кәефең юк, боексың.

— Юк, эчемдә түгел, тышымда.— Альмира җәйге пәлтәсен җилбәгәй җибәреп, каршымда бөтерелеп алды.— Минем гәүдәмдә берәр үзгәреш сизәсеңме син?

— Сизәм, чәкчә атып киләсез, Альмира иптәш!

Альмираның йөзендә кинаяле елмаю балкып алды.

— Чәчәк коеп килә дисәң, дөресрәк булыр...

— Һи, койганчы, атып бетәсе бар бит...

— Атасы аткан инде, Таһир. Минем җимешем өлгереп килә...

Һай, бу хатын-кыз затын! Гомергә юньләп аңлап булмады шуларны. Нәрсә әйтергә теле соң Альмира бу кинаяләре белән? Әллә? Мин кинәт уңайсызланып, кызарып киттем. Кызга карамас өчен, якындагы зур карама агачында казынган тукранны күзәткән булдым. Хәер, Альмира үзе дә читкә төбәлгән, бите әллә ничек кызарып, тим-

гелләнеп чыккан икән.

— Менә шулай, Таһир. Мин инде нишләргә дә белмим хәзер. Пожалуйста, ачыктан-ачык сөйләшик әле. Булдыра алсаң, ярдәм ит!

— Кем соң?..

— Нәрсә кем, Таһир?

— Соң гаепле кеше. Әтисе дияргәме?

— Ә? Зинһар, сорама, хайван ул бер... Ничек булды дип тә сорама.— Альмира кинәт үксеп-сулыгып елап җибәрде, сыгылып төште. Тик мин аны тотып калдым.— Таһир, хәлемә кер ничек тә, мин дөньяга рисвай булырга торам. Врачлар табарга кушалар. Ә җилдән мин ничек бала табыйм соң? Мине бит укуымнан куарлар, әти-әнигә ничек күренермен?.. Хурлык, шул кадәр хурлык! Таһир, ярдәм ит әле, җаным! Бөтен өметем бары синдә минем!

— Ничек ярдәм итә алам мин?!

— Син, Таһир, бары тик катлауландырып кына уйлама. Хәлгә бары тик формаль кара. Шулай итсәң, мөгаен, ризалашырсың. Таһир, бу эшне бары син булдырасың. Бары син мәрхәмәт күрсәтә аласың...

— Әйт инде, нишлим соң?

— Таһир җаным, әйдә язылышыйк!.. Юк, уйлама, син миңа өйләнмәссең. Бары формаль рәвештә, язылышыйк кына... Коткарып кына кал син мине бу бәладән. Юк, юк, Таһир, алай авыр уйлама син!..

Соңгы сүзләрен Альмира минем йөземә карап, куркынып әйтте бугай. Чынлап та, минем чыраем качкан булырга кирәк. Уйлар өереннән зиһенем, электр бушануы кебек, чытырдап киткәнен беләм. Нәрсә соң бу?.. Нинди күрелмәгән ирексезләү, көчләү бу? Ни әйтергә моңа?

— Кызык син, Альмира,— дидем мин, ниһаять, эчке ярсуымны сиздермәскә тырышып.— Сиңа бит мин бүген киеп, иртәгә атып бәрергә бер күлмәк түгел. Мин бит кеше. Аңлыйсыңмы шуны?

— Кеше булганга сиңа килдем дә, Таһир. Кеше кешегә дус, иптәш, туган дип әйтәләр бит.

— Бу бит ярдәм түгел, үзеңдәге кешелекне бетерү!

— Кешелек үзе шул рәвеш белән яшәп килә түгелме соң? Мин бит синнән кешелек, кеше хакында ярдәм сорыйм, Таһир?..

Альмираның соңгы сүзе минем чуалган зиһенемне кинәт айнытып җибәрде. Чынлап та, сүз бит бала хакында, аны саклап калу, яшәтү хакында бара. Киләчәк буын, кешелек хакында сүз... һәр очракта аңа шулай һөҗүм ясалса, дөньяга кем туар? Кем тормышны дәвам итәр?.. Һәртөрле намус, кешелеклелек турында сөйләүләр шуның янәшәсендә сафсата гына булып чыга түгелме соң?

Тулай торакка ялгызым кайтып барганда мин Альмирага биреп ташлаган вәгъдәм өчен әллә ни кайгырмадым. Миңа гел шулай, тәшвишләнү соңлап килә. Ә хәзергә минем миемне бер сорау бораулый. Чын-чынлап бөтен вөҗүдемне билгәгән ул. Альмираның тавышы кемнедер хәтерләтә. Кемнекенә охшаган соң аның ялварулы, еламсыраган тавышы?.. Тагын кайда очраттым мин шундый тавыш иясен? Студентлар арасындамы? Юк. Армиядәме? Юк. Бәлки РТСта эшләгәндәдер?.. Яшьлектәме? Балачактамы? Әһә, балачакта! Мин бөтен барлыгы белән май иртәсен хәтерләдем. Әнә яшь әни Нәркисә безгә кергән дә ялварулы, еламсыраган тавышка сыктап ята... Альмираның тавышы яшь әни Нәркисәнеке ләбаса! Кара син аны, килеш-килбәтләре бөтенләй аерым, аз гына уртаклыклары да юк бит. Яшь әни Нәркисә — кинәле, әдәп-холыктан мәхрүм кеше. Альмира исә мәдәниятле, нәзакәтле гадәтләр җыелмасы. Ә шулай да тавышлары, шулардагы төсмерләр ничек охшаш! Ничек әлек сизмәгәнмен соң бу уртаклыкны? Яшь әни Нәркисә дә үземнең әни каршына бала хакын китереп куя. Альмираның да гозерендә дә төп сәбәп — бала, нарасый

хакы. Иң нечкә җирне тапканнар лабаса алар. Тукта. Альмира баланың үз атасына, чын атасына шундый таләп, шундый хак куярга тиеш иде бит.

— Әй, әни. Альмирага вәгъдә биреп дөрес эшләмәдем бит. Бик тирән ялгыштым бугай мин?

Хыялымдагы әни, күзләрен кыса төшеп, нәрсәдер исәпләгән сыман, бер мәл уйланып тора.

— Юк, улым, хаталанмыйсың сыман. Кешегә булдыра алган кадәр игелек кылырга кирәк.

— Кем, нәрсә хакына соң, әни?

— Соң, нәрсә хакына, дип, изгелек барыбер җирдә тапталып калмас әле, улым.

— Кеше хакын көйләп, үземә көйсезлек килсә? Мин Асыл турында әйтәм. Ул бит аңламас, моны үзенә хыянәт дияр.

— Аңлар, шәт... Аңламаса, күрәчәгең шул була инде, улым... Вәгъдәң дә бар...

Әйе шул, әни дөрес кисәтә, вәгъдә дә бар. Бер атнадан загска язылышырга барырга тиешбез.

Берничә көннән Асыл миңа, бик дулкынланып, тәфсилләп, төшен сөйли:

«Беләсеңме, Таһир, йөзлекләр чыгарып син миңа балдак сатып алдың. Балдак сырлы, бизәкле. Киеп карасам — таман. Әй шатланам. Минем бит гомергә дә алтын балдак кигәнем юк. Менә мин дә хәзер кеше рәтеннән йөри алам инде дип сөенәм. Урамга чыктык. Каршыга дүрт-биш чегән хатыны килә. Чегәннәрдән мин гел куркам. Әйдә, җаным, китик моннан, дим. Син коләсең генә. Мин сине тартам, син китмисең, әйдә язмышыбызны юратыйк, дисең. Чегән хатыннары сине уратып ала, имеш. Ә берсе миңа туры итеп карап тора, хәлемне ала. Мин куркам, сине тартам. Кулыма карасам, балдак юк... «Таһир, балдак юк бит!» — дип кычкырам. Теге хатын балдакны әләктергән дә, качып бара... Менә шул чак уянып китәм, Таһир. Әйт инде, нинди төш соң бу?..

Асылга мин һич нәрсә әйтә алмадым. Әйтмәүнең дә егетлек түгел икәнен яхшы аңладым мин. Нәрсәгәдер өметләндем, ләкин шул ук вакытта авыр бер афәт киләсен дә тоеп тордым. Шундый авыр, саташулы төш хәлендә бер атна үтеп китте...

Язылышуны мин үзем өчен шулай авыр булыр дип һич көтмәгән идем. Альмира белән икәүләп загска кердең, өйләнешү турында таныклык алдың, паспортларга билге суктырдың да, шуның белән йола бетәр кебек иде. Әйдә, кияү белән кәләш, үз кыйблаларыгызны карагыз аннары... Бу хәлне бит хәтта берәү дә сизмәскә мөмкин иде. Азмыни дөньяда шундый кысыр серләр...

Юк-юк, мин Альмирага кинә тотмыйм...

Әй, минем беркатлы, хәйләсез акылым! Мин загс йортыннан Альмира белән култыклашып чыгып, машинага утырам, яңа керә башлаган йолага буйсынып, мәйданчыктагы һәйкәлгә чәчәкләр куям, зиннәтле, бай бер квартирада оештырылган мәҗлестә кияү сыйфатын алам. Әллә мин, әллә мин түгел бу! Ә хәлләр нәкъ туйдагыча: биюләр, җырлыйлар. Ниһаять, барысы да тына, кунаклар таралыша...

Альмираның тумачасы урын-җир белән кайнаша башлый...

— Йә, Альмира, минем формаль вазифаларым бетте шикелле, китим...

Альмира чиксез арыган, күзләре сулган. Шулай да йөзендә зәгыйфь елмаю чаткылары бар:

— Рәхмәт, Таһир җаным, мәңгегә онытмам!

— Хуш, Альмира!..

— Хуш, Таһир!..

Минем чыгып китүемне күреп, фатир хуҗасы — исерек ир — та-

выш чыгарырга маташа. «Тукта, шаулама,— дип каршы төшә аңа җиңгәчәй,— хәзерге яшьләрнең законы үзләре белән, кысылма син яшьләргә!..» Күрәмсең, ул барысын да белә иде.

Урамда, ниһаять, үз асылыма кайттым. Тик мин кыйнап ташланган кеше хәлендә идем. Җәберләнүдән, кимсенүдән, сызланудан үкереп елыйсым килде. Мин язмыш каршында мондый алдануны көтмәгән идем.

Әй, тормыш, нәрсәдән, ничек ясаласың син? Көтмәгәндә, уйламаганда каян шулай борылып, үзгәреп китәсең соң син?..

Каршымда Сарыйм абый пәйда була, күзләрен чекерәйтеп байтак вакыт миңа карап тора, әллә нинди мыскыллы, кимсетүле елмаю белән көлеп җибәрә:

— Сиңа, Таһир, сөйләргә тел әрәм. Валлаһи, тел әрәм сиңа!

— Үземә дә хурлык, абый. Тик аңла, мин кешегә изгелек эшләргә тырыштым бит.

— Изгелек... Нинди изгелек? Пычагым да изгелек түгел бу. Кемдер себерелеп йөри, ә син шуның баласына ата, үзенә ир булырга ризалашасың. Дураклыктан да дураклык бу. Ике бозауга кибәк аерып бирә белмәү!

— Ярар, абый, шулай да булсын. Тик ничек мин бу хурлыкка төштем соң?

— Син шуны белмисеңме?

— Юк, чын, абый!

— Әйтсәм, абый тупас дип зарланмассыңмы тагын?

— Юк, юк...

— Тол хатын малае син, Таһир! Бөтен булмышың шунда синең.

— Тол хатын малае... Ничек инде?

— Ничекме? Ике бозауга кибәк аерып бирә белмәгән аңгыра була. Тиешле урында сүзен, кирәк җирдә эшен эшли алмый, җебегән була. Белдеңме инде?— Абый киная белән тагын бер сынап карап тора да, кисәк кенә күздән җуела.

Әйе, әйе, тормышта миңа атам рухы, атам үлчәме җитми. Әй, бу әтисезлек! Әтисезлек аркасында рухым да гарип булып киткәнме әллә минем. Тән кимчелегем төзәлде, мәрхәмәтле кешеләр төзәттеләр аны. Ә рух гариплеге һаман саен үзәгемә үтеп торыр. Бу, мөгаен язмыш шомыдыр, әни әйткәнчә, күрәчәгемдер ул минем. Әй, әни, әни! Тол хатын булып гомер сөреп, үзеңә генә түгел, балаңа да кимлек-хурлык китергәнсең түгелме син?!

Тулай торакта мендәрем өстендә мине Асылның хаты каршылады. Соңгы өмет тә өзелде. Үзе белән сөйләшкәндә бәлки аңлашырга урын калыр иде. Ничек, каян шулай тиз белгән соң ул? Хат та түгел икән, дымланып беткән записка гына: «Тахир, дөньяда синеке кебек хыянәт булганы юк. Мең, мең... юк, йөз мең ләгънәт сиңа!!!»

Шулай Асылны җуйдым мин. Хәтта кыз каршында саф күңелле булуым ачылгач та җуйдым. «Элеккечә яратсам да, мин синнән чынлап куркам, Таһир»,— диде Асыл.— Син кешечә түгел, әллә нинди икән. Синең белән тагын әллә ниләргә очрап бетәрсең. Ә мин кешечә яшәргә кызыгам. Хәзер синең паспортың да пычранган. Син инде кеше ире. Мин сиңа икенче хатын булырга теләмим. Бала чагында кимсенүләрем дә бик җиткән. Һәрберсе кебек тигез, тулы кеше буласым килә. Саф калганнар да табылыр әле миңа, Таһир!»

## 9

Кеше күңелендә һәр нәрсә сурәтле, җисемле була. Мәхәббәт хисе миндә, йә тилерткеч шатлык, йә үзәк өзгеч моң уятучы чалымнар

хәлендә калды. Мөлдерәп торган шомырт кара, серле-шаян карый торган күзләр, йөрәктә эрегән елмаю... Улым, түзмәссең, миннән сорап куярсың кебек:

— Әти, бу — әниме?

— Әйе, улым, әниең...

— Әти, минем әни бик-бик матур идеме?

— Улым, әниең минем өчен төс матурлыгыннан бигрәк, мәгънә матурлыгы — мәхәббәт ул...

— Әти, ә син әнине мәхәббәт дип ихлас әйтәсеңме соң? Син бит кайчандыр Алисәгә гашыйк булдың, Асылны сөйдең...

— Аңлыйм... Тойгыларың таркалгач, чын мәхәббәткә урын каламы, дип сорыйсың килә синең. Урынлы шик. Тик мәхәббәт — эзләнү шул ул. Гомер юлында төрле ярлар очрарга мөмкин. Узгынчы ярлар килә дә китә. Ә мәхәббәт синең тәнең һәм җаныңның яртысы икән. Ул инде синдә кала...

Университетны тәмамлагач та, кече командир сыйфатында практика узу өчен, мин кыска сроклы хезмәткә чакырылдым. Яз мәле. Таулардан төшкән ташу суларыннан Ашказар елгасы ташый. Ә төнлә чиләкләп койган яңгыр суларыннан ул тәмам ишәеп, кисәк күтәрелеп, шәһәргә дә бәреп керә. Су ташкыны, күбекләр чәчеп, көчле гаскәр ташкыны кебек, урамнар буенча тәгәри.

Халык куркып уяна. Өлгерә алганы, бала-чагасын күтәреп, калкулыкка, яңа шәһәр бистәсенә йөгерә. Ә су эчендә калганнары чормаларга, өй башларына, түбәләргә үрмәли.

Тревога белән кузгатылган хәрби часть бөтен техникасы белән шәһәргә килеп җитте.

Минем взвод хәрәкәт иткән урында башта ук кыен хәл килеп туды. Җимерелеп, бер катлы таш өйнең ишеге капланган, гаилә бикләнеп эчтә калган иде. Мин ишекне тәртипсез өелгән бүрәнәләрдән аралап, өйдәгеләрне коткарырга команда бирдем. Үзем, беренчеләрдән булып, боздай салкын суга ташландым. Шунда каударланып эшләгәндә минем сул ботымны нәрсәдер җәрәхәтләде. Салкын су әрнүне тиз басты. Шулай да җәрәхәтне әйбәтләп бәйләп кую кирәк иде. Әмма, суда канның туктамаячагын чамалап, мин ярам белән булышып ятуны килештермәдем. Солдатларым белән беррәттән, җилкәмә бала-чага, карт-корыны атландырып йорт белән бронетранспортер арасын урый башладым.

Әмма каным туктаусыз агып, хәлем китә баруын тоеп тордым. Су әсирлегендә калган тагын өч-дүрт йорт халкын коткаргач, кинәт минем күз алларым караңгылана башлады.

Менә мин операция өстәлендә ятам. Минем ярам пүчтәк иде, билгеле. Аны инде тегеп бәйләп куйдылар, ул хәзер рәхәт сулкылдап тора. Ләкин мине өстәлдән төшерергә ашыкмыйлар әле. Сизенүемчә, миңа кан бирергә җыеналар, тик эшләре ансат кына барып чыкмый булса кирәк.

— Доктор, дүртенче группа резус положительный юк бит...

— Ничек юк инде, Маша, ничек юк?!

— Соң, беткән. Бу группа канны ике банка гына алып кайтканнар. Ә бүген, үч иткән кебек, дүртенче кеше... барысына да шул кан кирәк.

— Табыгыз! Әгәр тапмасагыз, пациент янына ятыгыз да, үз каныгызны бирегез!

Озын, таза гәүдәле хирург теш арасыннан сыгып кына сүгенеп куйды.

— Доктор!.. Сез бит беләсез... Миндә икенче группа.

— Мин бернәрсә дә белмим... Әмма шушы минутта дүртенче группа резус положительный кан әзер булсын. Аңлаштыкмы?

Чынлап та, бер кавым вакыт узмады, минем чиксез гаҗәпләнүе-

мә каршы, шуышма өстәл янына донорны китереп тә куйдылар. Хирургның һәм операция сестраларының аның белән шаяра-көлеп сүз алышуларыннан мин донорның биредә үз кеше икәнен чамаладым. Хирург бик кызык сүз әйтте. Ничек диде соң? Ә... «Кыз каны егет затын котырта инде ул. Каның белән бирәттән адресыңны да калдырырга онытма син»,— диде. Тегесе дә җавапсыз калмады бит: «Әй, доктор, ничә тапкыр кан бирдем, тик берсе дә эзләп килми әле. Хәзерге егет халкын беләсез бит. Үзебезгә эзләргә калыр ахры...» Тавышына караганда бу, мөгаен, яшь кенә кыз иде. Шат күңелледер, сөенече бар кеше сыман гел елмаеп йөридер... Әйе, әйе, шулай булырга тиеш! Кан күчерүне тәгәлләп, ике арадагы пәрдәне җыештырганда мин аның йөзен... юк, күзләрен күреп калдым. Мөлдерәп торган кара сусыл күзләрдә йөрәкне сулкылдатып куйган ямьле чаткылар, якынлык күрдем. Нишләптер, таныш кебек миңа бу караш? Нинди сихерле күзләр соң бу?

Икенче көнне мине хәрби госпитальгә күчерделәр.

Хәрби хезмәтне тәгәлләп, яшь укытучы сыйфатында яңа эш урыныма килдем.

Ничек ямьле минем беренче тапкыр зур хезмәт юлына аяк баскан чакларым! Әй, ул Чыршылы авылының ак томанлы сентябрь иртәләре! Дулкынланып, ашкынулы ниятләр белән мәктәп юлыннан атлаулар! Ул кырмыскалар кебек эшчән, тере авыл балалары белән мәҗ килешеп бәрәңге алулар... Ул авыл яшьләре арасына кереп бергәләп концерт куюлар, театр уйнаулар... Кайчак шундый минутлар була, мин Чыршылыны калдырып китүемне җәллим. Эшләргә иде, яшәргә иде шунда гөр килеп. Шәһәр олы мәгънәләре белән кызыктырды шул.

Чыршылы, Чыршылы... Чыршылының кызлары чибәр иде. Әллә нинди сылу, зифа токым иде, сөрмәле кызлар иде Чыршылыда. Тик минем төшләремә мөлдерәп торган кара сусыл күзләр керде. Баштарак мин моны Алисәнең күзләре дип йөрдем. Әмма Алисәнең күзләре көрәнсу, дымсу иде, болар исә кара... шомырт кара күзләр. Мин Стәрлетамак шәһәрен хәтерләдем. Мине янә аңлатып булмаслык сагыш басты. Бу күзләр дә кире кайтарып алып булмаслык үткәннән карыйлар кебек иде. Көннәр үткән саен, алар миннән ерагая-ерагая...

Кышкы суык мәлдә мин Челтерле елгасы буена төштем. Тирә-юньзыкы салкыннан туңа, калтырый. Ә Челтерле, суыкка һич исе китмичә, җырлый-җырлый ага бирә. Җитмәсә, өстеннән шатлык, сөенеч булып бу күтәрелә... Нигә мин дә шул Челтерле кебек хәрәкәттә түгел соң? Ник мин урынсызга күңел нечкәртеп хәл-хәрәкәтсез ятам әле? Барыйм да, күрим шул кызны!.. Челтерле буеннан мин исәр ният белән кайттым. Озак икеләнеп тормадым, кышкы каникул башлангач та, төшләремә кереп тинтерәткән серле күзләр иясен эзләп юлга да чыктым. Белеп торам, сәер сәфәр бу. Кызның җисемен түгел, исемен дә белмим бит хәтта... Әмма мин аны табуыма аз гына да шикләнмәдем. Больницасы, кешеләре анык. Тик тапкач, күргәч, нәрсә диярмен соң мин аңа? Җитмәсә, ул кеше яры булып чыкса, мине җиде ятның берсе итеп санаса?..

Бардым, кердем, үземә кан бирер донорны тапкан докторны эзләп таптым. Ул минем хикәямне бик кызыксынып тыңлап торды-торды да, кулларын күкрәгенә кушырып, ихлас көлеп җибәрде:

— Хәтерлим, хәтерлим... Күгәрченкәем, ул сез идегезмени?!

— Доктор, бәлки сез миңа кан биргән донорны да хәтерлисездер?

— Нигә хәтерләп торырга? Үзебезнең Зөһрә ич ул!

— Зөһрә!— дидем мин гаҗәпләнүдән кычкыра язып. Ярый әле тойгылануымны доктор сизмәде.— Мин бит аңа рәхмәт тә әйтми калганмын...

— Нигә үкенәсез, аны бит әле дә әйтергә була.
— Мөмкинмени бу?
— Әлбәттә, кирәк икән, чакырам үзен.
— Чакырыгыз, зинһар!

Доктор җиңел генә баскычтан өскә менеп китте. Баскычлардан атламый, әйтерсең лә минем йөрәктән атлый иде ул.

Уф, нигә шул чаклы дулкынланам соң?.. Төшсен генә иде... Төшсен генә иде! Төшсә, ничек тә кыздан дулкынлануымны яшерергә кирәк миңа. Сизмәсен, очраклы танышлык бу, дип уйласын.

Менә баскычтан, ничектер очынып, яшь чырайлы, зифа шәфкать туташы төшеп килә. Доктор аңа минем хакта әйткән, әлбәттә. Коридорда халык шактый булса да, кыз мөлдерәп торган кара сусыл күзләренең карашын ашыгып миңа сирпеде. Ниндидер сөенечле гаҗәпсенү бар кебек иде ул карашта.

— Ник сакырдыгыз, абый?— диде ул башкортчалап.

Күңел тәрәзәләреннән кояш балкыган өй кебек, кисәк яктырып китте.

— Сез миңа каныгызны биргән идегез...

Шулаймы? Исәнлеккә булсын, кый!

— Миндәге кебек кан башкаларда юктыр дип йөри идем, очрый икән әле...— дидем мин сүзне ялгап китәргә тырышып.— Мин Таһир булам, күршегез Татарстан җиреннән.

— Син Таһир...— дип ихлас текәлеп сорап куйды туташ.— Син Таһирмы, кый?

— Әйе, Таһир,— дидем мин үз чиратымда аның шулай гаҗәпсенүенә аптырап.— Мин Таһир булам...

— Ә мин — Зөһрә,— диде ул, ничектер кызарып китеп.— Мин Зөһрә бит!

Менә шуннан соң йөрәкләр арасында бәйләнеш, тартылыш юк дип әйтеп кара инде син! Бар ул, бар күңелләрне бер-берсенә бәйләүче рухи җепләр. Бар алар зиһенгә һаман да сер булып калган хикмәтле аңлашулар. Дөнья нәкъ шулар белән кызыклы да, ямьле дә, өметле дә бит ул.

Кәләшем булгач, мин Зөһрәдән сорыйм: «Теге чакта, танышканда, ник миңа «Мин Зөһрә бит!»— дип әйттең син?» Ул, минем соравымнан хушланып, иркәләнеп тайпылырга маташа:

— Таһирга Зөһрә пар, кый!
— Анысын беләм лә мин.
— Белсәң, сүзгә каныгып торма.

Чыршылыда Зөһрәм белән бик аз яшәп калдык. Юк, яшәмәдек. Чыршылы безнең бәйрәмебез булды. Челтерле буйларындагы куп-шы шомырт, баланлы әрәмәлекләр, кыйгач Бирәмәт таулары үзләрендә һаман да безнең сөенечләрне яшәтәләрдер кебек. Вакыт табып кайтам әле бер Чыршылыга, табам әле мин шул эзләрне... Аннары безнең тормышыбызда кискен борылыш килеп чыкты.

Зөһрә кер чайкарга Челтерлегә төшеп киткән иде. Кулыма яңа гына килеп ирешкән хат мине шатлыктан сикертә, мин дә Челтерлегә чабам.

— Зөһрә, Зөһрә!.. Сөенеч!
— Сөенеч? Нәрсә бар соң, әйт, Таһир!
— Мине аспирантурага чакырганнар.
— Аспирантурага!.. Кит лә, алдалама шулай.
— Менә хат, ышанмасаң, укы!
— Дөрес лә, кый. Абау, җаным, булдырырсыңмы соң? Бик зур уку ла ул!
— Булдырырмын, Зөһрә. Синең белән барысын да булдырам мин.

Шулай итеп, без авылдан шәһәргә китеп бардык. Авыл белән

аерылышуны мин хәзер генә сагышланып искә алам ул. Үз вакытында исә яңа мәгънәләр ачып, рухи камилләшүгә сусаган яшь күңел бу сагышны бар дип тә белмәде. Хәер, укуга, гыйльми эшкә тартылуым шәһәрдә яшәүгә кызыгу түгел иде бит. Башта мин монда аспирантурада укыйм дип кенә яшәдем. Аны тәгәлләп, гыйльми дәрәҗә алгач, вузда укытам, шуңа шәһәрдә торам, дип тордым. Инде университет минем ике балалы гаиләмә тугыз этажлы йорттан ике бүлмәле әйбәт квартира биргәч, сулышына кабып туктап калган йөгерешче кебек, кисәк калкынып аңышып куйдым. Мин шәһәр кешесе булганмын лабаса...

Фатир сөенеченнән Зөһрәм төннәрен йоклый алмыйча чыга. Юа, ышкый, ялтырата. Монда тегесен, тегендә монысын сатып алып куярбыз, дип, исәр кеше кебек һаман исәпли, чутлый. Мин исә шул көннән катлаулы тойгылар каршында калдым. Бер яктан, мин шундый дәрәҗәгә ирешүемә чамасыз сөенәм. Уен түгел бит. Авыл малае, тол хатын малае башың белән ак мәрмәр колонналы университетта, зур аудитория каршына басып, илебезнең төрле почмакларыннан сайланып җыелган иң укымышлы егет, кызларга лекция укы әле син!

Әмма икенче яктан вөҗданым тынгысыз минем. Бигрәк тә кыр эшләренә дип, студентларны җитәкләп яртылаш буш авылларга чыксам, күңел газабы көчәя. Олылар күзенә туры карый алмыйм хәтта. Алар мине шелтәлидер кебек.

Фатир алгач, мин әнине шәһәргә, үзебезгә алып килә башладым. Үзем дә гаҗәпсенеп, аптырап калдым. Соңгы елларда әни бик тә бирешеп, картаеп киткән икән. Чын карчыклар төсе кергән үзенә. Чәчләре тәмам агарган, битендә аркылы-торкылы җыерчыклар буразнасы. Бил дә бөгелгән, тамырлар да каралып бүрткән... Тик күзләре генә, шактый төссезләнсәләр дә, элеккечә ямь, җылылык белән балкыйлар.

Ә бәйрәм кичләре җитсә, әни Зөһрә белән мине теләгән җиребезгә җибәрә. Юк алай түгел, димли иде.

— Барыгыз, мин барында йөрегез, ял итеп калыгыз,— ди.

Безнең гаиләдәге бу хөррият никадәр генә озын, дәвамлы булмасын, барыбер аның ахыры җитә шул. Кояш турырак, мәрхәмәтлерәк карый башлап түбәләрдән тамчылар сикерешә башлагач, әни озаклап-озаклап тәрәзә янында утыра. Аннары бишмәтен киеп, шәленә уранып, оныгы Алия белән урамга да чыгып китә. Үзе кебек картлорыны очратып, сәгатьләр буена сөйләшеп утыра ул. Ниһаять, күмәкләшеп чәй эчкән мәлдә әни янә бер сүзен безгә җиткерә:

— Инде бик, бик озак кунак булдым, балалар. Бик рәхмәт үзегезгә. Шулкадәр кадер-хөрмәт күрсәттегез, рәхмәт яусын! Инде, улым, юллар өзелгәнче кайтарып куй син мине!

— Әни, бездә генә торсаң ни була соң? Кал бездә, рәхәтләнеп бергә торыйк, әни, ә?— ди Зөһрә.

— Әби, китмә!— дип, Алия ялына башлый.

— Әй, оланнар,— ди әни, итәгенә сарылган Алиянең башыннан сыйпап.— Бик калыр идем дә, Килмәк урманы миннән башка яфрак яра алмас шул...

Мин әнине кошлар кайткан вакытларда авылга кайтарып куям.

Нигез йортта — Сарыйм абый зары. Сарыйм абыйга да вакыт үз рәвешен мулдан салган. Килешсез юанайган, корсак үстергән. Йөзе дә итләчләнеп, бүртенеп киткән. Кысык күзләре кешегә тагын да чекерәебрәк карый сыман. Абыйның зары балалары хакында.

— Галимҗаннықылар, Барыйныкылар елына әллә ничәшәр йөз акча салып яталар. Минекеләрдән бер файда юк. Киттеләр дә баттылар. Сәлам хат та җибәрмиләр. Әллә эзләтеп судка бирергә инде үзләрен. Син дә, Таһир, шундый зур урында эшләп, минем берәр

малайны укытып, кеше ясап чыгармадың шунда.

— Абый, тормышың менә дигән итеп корылган бит. Тагын ни җитми инде сиңа?

Сарыйм абый, яшь бала беркатлылыгыннан кызык тапкан кебек, башын чайкап, үзалдына елмаеп тора:

— Әй, Таһир, син һаман тормышның бер рәтен дә белмисең икән әле...

Абый өчен минем алда әни уңайсызлана бугай. Ялгызым калгач, әйтеп куя:

— Абыең сүзләренә әллә ни исең китмәсен инде, улым. Зарланудан башы чыкмады инде аның. Менә таш йорт салдылар. Бүлмәләрендә буталып адашып йөрим. Җиһаз, киемнең дә чуты юк... Эшен дә эшли абыең. Җәен комбайнда бит, кышын фермада мич яга. Мактала да, акчасын да төргәкләп бирәләр. Тик нәрсәдер җитми үзенә? Зарлана да, каргана шул. Үзенә дә, кешегә дә бер җан тынычлыгы юк аннан. Әллә нинди генә бала булды инде абыең...

Әйе, Сарыйм абый әллә нинди шул. Әмма ул да бит шул мохиттә үскән. Үзебезнең җир-судан матдәләр алып, болын, урман, кырлар һавасын иснәп үскән ул... Әй, чыгасы иде дә иң биек урынга менеп сөрән саласы иде:

— Кайтарыгыз, минем абыйны! Кайтарыгыз минем җиләкне, сөйкемле көрән абыемны!..— диясе иде.

Әнине дүрт-биш рәт кара көздә авылдан алып китеп, язлар җиткәч, кайтарып куйган идем. Әнинең яшәү рәвеше очар кошларныкына охшап калган иде... Аннары әнидән көтмәгәндә бер-ике җөмләлек кенә хат килеп төште: «Улым, исәнлегем тәмам китте. Кайтып ал, зинһар!»

Әни чынлап бетерешкән иде. Шәһәргә алып килүгә, аны төрле больницаларга йөрттем, мәшһүр врачларга күрсәттем. Әмма әнинең өмете өзелгән иде. Әни бөтенләй урынга ятты. Көзге чәчәк кебек күзгә күренеп сула, кибә әни...

Көннәрнең берендә, эштән кайткач, әни мине үз янына дәшеп алды:

— Улым, сезгә сүзем бар иде...

— Нәрсә соң, әйт, әни!

— Улым, әйтеп калдырасы сүзләрем ул, икегез дә килегез.

Йөрәк сулкылдап, авырттырып кысылып куйды. Шулмы инде ул кешенең соңгы минутлары җиткәнче әйтеп калдырасы хушлашу сүзләре? Шул була микәнни васыять?

Кояш батып бара. Кызгылт нурлары тәрәзә аша үтеп, урын өстенә төшкән. Әнинең сулган йөзенә дә шул илаһи, мәгърур нурлар сирпелгән.

— Балалар, җитәрлек яшәдем инде. Рәнҗеш калмады,— дип башлады әни сүзен тыныч кына. Күрәсең, ул әйтәсен алдан ук уйлаган, исәпләгән иде.— Әйтергә генә ансат бит. Яриңгә хәтле тартсам, 70 яшь булыр иде. Һәркайсының ничә фасылы, ае, көне бар дигәндәй. Булды, яшәсемне яшәдем, күрәселәремне күрдем инде... Тик менә сездән аерыласы бар...

Әнигә нindидер юату сүзе әйтәсе килә. Яшәрсең әле, күрерсең әле, диюләр урынсыз. Тик сүз әйтмәү дә килешми.

— Әни, кадер-хөрмәт тә җитеп бетмәгәндер, бәлки. Әйт син, тартынма, нәрсә теләсәң, шуны эшләрбез...

— Кадер-хөрмәт юк дигәнне авызыңнан җил алсын, улым. Гел дә канәгать булдым мин сездән. Киленнән дә, синнән дә... Гел хәлемне аңлап тордыгыз. Әле каршыңда үземә кыен булып китә, улым. Кеше баласы кебек үсмәдең, әллә нинди кыенлыклар кичердең инде син... Төрлесе эләкте инде сиңа, балам...

— Йә инде, әни!

— Улым, яшерен-батырын түгел, янмагыз да, әллә ни көймәгез дә, бездән генә калмаган бит бу эш... Туган туфракка кайтарып күм син мине... Тиешле йолаларны да кулдан килгәнчә үтә. Рухым да рәнҗемәслек итә күр инде, улым...

— Әни, әйтмә әле боларны!?

Әни бераз әл-хәл алып торды.

— Инде, килен, сиңа гозерем үтә дә зур минем. Әйтергә тартынып йөредем, хәзер әйтәм инде. Кызларың бар... Асыллар, матурлар. Тик син кыенсынмыйча гына тагын бирәр бәбәй тап инде. Анысы, шаять, малай булыр, ходай кушса. Таһир улымның үз рәвешен җирдә калдыр инде син. Тегесе-монысы җитми дип тормагыз. Бар нәрсәгез дә җиткән. Үстердек бит әле, әллә нинди шартларда да үстердек... Яме, килен?

— Ярар, әни...

Гаилә коргач та, мин малай турында хыяллана башлаган идем. Юк, бу ниндидер кәперәюле нәфес түгел, мәгънә белән тулган хыял иде. Малай ул минем өчен нәсел тамыры, рухи буын иде. Үзем ирешә алмаган теләкләрнең мин малаемда гамәлгә ашуын көтә идем.

Әмма икенчесе дә малай булмады...

Мин сүз әйтмим, һич чытык чырай күрсәтмим. Алия дә, Гөлия дә минем балалар. Әмма Зөһрәм сизенеп тора: мин малай көтәм.

Ләкин табигатьнең үз исәпләре бар икән шул, өченче баланы аңа врачлар табарга кушмадылар.

Мин инде малай турындагы татлы хыялларым белән хушлашкан идем. Зөһрә дә әни каршында кисәк кенә вәгъдә сүзе әйткәндә хәлне җитди бәяләп өлгермәде бугай. Хәер, боларны нечкәләп уйлап торыр чак идемени соң?

Әнине үзебезнең авыл зиратына барлык шартын китереп җирләдек...

Сарыйм абый белән өйгә бергә кайттык. Кызарына-бүртенә итеген салып атты да, өс киемнәре белән лыркылдап өстәл артына килеп утырды ул:

— Менә шулай, Таһир! Яши-яши дә кеше, беркөнне юк була. Бар иде кеше — юк кеше! Балчык түмгәге генә торып кала аннан. Йә, син шуңа нәрсә дисең?

— Нәрсә диим? Әнинең тере җисеме юк, әмма аның рухы, җаны калды. Ул күңелләрдә безнең...

— Юкны сөйлисең!— дип кисәк сүземне өзде абый һәм, күзләрен елтыратып, миңа текәлеп торды.— Мондый сүзне мин әйтсәм дә ярар. Син бит укыган кеше. Студентлар тәрбиялисең. Нинди рух, нинди җан ул? Мулла сүзен сөйлисең бит син... Үлдең — беттең, димәк, вәссәлам! Яшәү — мин исән чагында гына. Мин үлдем икән, барысы да бетә. Бернәрсә дә калмый. Белдеңме... Валлаһи, җыен сафсата белән баш катырудан ерак китмәгәнсең син, Таһир!

Гаҗәпләнеп, абыйның күзләренә күтәрелеп карадым. Аның кечкенә коңгырт күзләре әллә нинди хәтәр ут, миңа карата өнәмәү хисе белән яна. Нәрсә бу? Исерүеме! Үлемнән куркуымы?

— Йөреп керим әле!— дидем дә чыгып киттем.

Соры, томанлы кыр юлына чыктым. Аннан, кире борылып, чишмәгә сугылдым. Суы шундый тонык, саф, төбе ялтырый... Яфраклар кыштырдатып урман юлларыннан атладым. Мин әллә ни кайгырмыйм да сыман. Әни бит үзе янмаска-көймәскә кушып китте. Җирнең кеше булып йөргән бер заты, яңадан да гомерен үләннәр, чәчәкләр, бөҗәкләр булып дәвам итәр өчен, тыныч кына күз йомып җиргә кереп ятты...

Мин олы юлга килеп чыктым. Ул томан аша җәйрәп боргалана-сыргалана еракларга сузыла. Кисәк кенә аңга, маңгайга нидер бәргән кебек булды: мин бит китәм... Бу җирләрне ташлап китәм. Мин бит туган төбәгемнән бөтенләйгә аерылган кеше.

Иртәгә чемодан тотып шул олы юлга чыгып баскач, томан аша, урманнан килгән агачлар шавы булып, кырлар, болыннардан искән җилләр булып, әни, мөгаен, сагышланып әйтер, әйтми калмас.

— Китмә, улым, Таһирым! Зинһар, мине ташлама, таш-лама!— дияр.

Әмма мин барыбер әнием рухыннан — туган җирдән китәм. Бөтенләйгә, мәңгегә аерылып китәм. Йә хода! Мин бит үз туфрагымны, җиремне җуйганмын ласа!.. Бу һичнинди акыл, зиһен белән дә тынычландырып булмаслык, төптәге, тирәндәге тойгы иде. Гаҗизлектән күзләремә кайнар яшьләр атылып чыкты:

— Гафу ит мине, Туган җир! Кичер!..

Гомеремнең иң авыр, иң сагышлы көннәре иде болар минем, улым. Тагын бер елдан мин Зөһрәм, әниең белән дә хушлаштым. Төннәр буе керфек какмаган чакларым булды. Акылдан шашаммы, дип үз-үземнән курыктым, хәтта.

Мин малай да, малай дидем бит... Әмма гомеремдә шундый мизгел булды. Ак биләүдәге бәбәйне кулыма алу түгел, аңа күтәрелеп карыйсым да килмәде. Ана гомерен өзеп дөньяга килгән малай булды бит ул...

Әй, дөнья, ниләр генә кылмыйсың да, нәрсәләр генә күрсәтмисең син кешегә! Мөлдерәп торган серле-шаян күзләре белән елмайган Зөһрәм урынына, больницада шул ак биләүсәне тоттырдылар. Зөһрәмнең соңгы йөрәк тибешенең җанлы шаһиты иде ул... Бу — син идең бит, улым!

Әнинең гозерен үтим дип, күрә торып үз һәлакәтенә барды бит Зөһрәм. Һәм сиңа, миңа булган мәхәббәт хакына эшләде ул моны...

Миңа кан бирүдән башлап, ул гел минем өчен янды. Әйтсәм, әйтим: кызганды ул мине хәтта. Авырсам, эштә күңелсезлеккә очрасам, хәтта ачыксам да кызганды. Сәер дә инде бу. Мин өрлек кебек таза, дәү ир. Ә ул чандыр, җыйнак... Әмма мин хатынымның олы, миһербанлы җанын тоеп, рәхәтләнеп шуңа сыена идем. Зөһрәм исә миндә шундый сыену тапкандыр. Мәхәббәт бер-береңнең җанына сыену бит ул. Шунда тынычлык, шунда ямь, шунда сөенеч табу...

Гомер юлымны мин һаман аның белән үтәм. Онытa алмау, тугрылык саклау — шулай ук мәхәббәт бит ул.

Улым, мәхәббәт хакында юкка гына сөйләмим. Минем иң олы рухым сиңа мәхәббәтне олылау, шуңа тугрылык булып күчсен иде!

Улым, син тагын миннән бөтен сөенечләремне, шатлыкларымны ал! Бел, бөтен тойгыларым белән син үзеңә мине генә алмыйсың. Миндә үземнең яраткан кешеләрем, әнием, Зөһрәм, Сәбилә җиңгәм, Алисә, Ядкарь бабай, Каимә, Ярмиев абый... тагын әллә кемнәр бар. Яратмаган кешеләрем дә бардыр анда. Син, минем белән бергә, заман төсмерләрен һәм авылдашларыңны да аласың, улым.

Һәй, сиңа соңгы вакытта йөрәгемне дулкынландырган бер яңалык турында әйтми торам бит әле. Син Альмира апаңны хәтерлисеңме? Минем сабакташны?.. Шул, күпме еллар үткәч, әллә кайдан, ерактан миңа хат язган. «Улымның сине бик күрәсе килә. Килсәк, рөхсәтме?»— дигән... Рөхсәт булмыймы соң? Сабакташымны, аның малаен үземнең дә бик күрәсем килә минем. Нинди икән, кем булды икән минем язгы фасылыма кагылышлы ул бала?..

Янә бер кат әни хакыйкатен ачам, улым. Гамәлне кылдым да, котылдым, дип яшәп булмый икән дөньяда. Яхшылыгы да, начарлыгы да барыбер кешенең үзенә урап кайта шул ул. Аларның барысы да безнең үз асылыбызга төбәлгәннәр... Бу хакыйкать сиңа гомерлек юлдаш булсын, улым!

*1986*

# ХӘЕРЛЕ ЮЛ!

*1951 елда Казанда туган яшь шагыйрь Илдар Хөсни унбиш-егерме еллар инде шигырьләр яза. Узган елның июнь аенда Әлмәт язучылары яшь шагыйрьнең беренче китабын (кульъязмасын) укып тикшерделәр һәм аңа югары бәһа бирделәр. Кульъязманы нәшриятка тәкъдим итәргә кирәк, дигән фикерләр әйтелде. Илдар Хөсни иптәшнең дәртле аһәң белән язылган бик заманча шигырьләре «Казан утлары» укучылары күңеленә дә хуш килер, дип өметләник, яшь шагыйрьгә хәерле юл телик.*

**Гамил АФЗАЛ.**

## Илдар Хөсни

### Җырлар иле

Сандугачым «тамак шештергән»
«Әллүки»ле тугайларымда...
Хисләремә юлдаш, дус эзләп
Йөрүләрем туган ягымда.

Аккошларым боек утыра
«Ак чишмәле» болыннарымда.
Моңым чәчеп, кабат моң урып,
Яшәүләрем туган ягымда.

Тиеннәрем җилгә йон коя
«Карурман»лы урманнарымда.
Талларымнан җанга моң-сиртмә
Үрүләрем туган ягымда.

Дәвам итә нәсел шәҗәрәм
«Олы юлның тузаннары»нда...
Сандугачым,
Меним янына,
Җырлап үлим туган ягымда!

### Авыр-та-а-а!

Җанны моңга төреп,
Чорлар буйлап килдек.
Көрәш мәйданында
Сыкрап торды ирек.

Елъязмалар яздык
Йөрәк каны белән.
Киләчәкне сөйдек
Килер шаны белән.

Юдык,
кырдык,
сөрттек
Күңел караларын,
Ирек яраларын
Тәңгә ала барып.

Эх!..
Ахрысы, тормыш
Аз иләгән безне!
Гаҗәп үзгәрешне
Әллә күрмибезме:

Җанда, сипкел сыман,
Вәгъдәсезлек арта.
Битарафлык арта,
Мәгънәсезлек арта.

Көнгә янау булып
Шеш-чуаннар арта.
Җырга йодрык төйгән
«Пәһлеваннар» арта.

Алабута, сарут,
Чебен гөмбәләре
Арта...
Арта...
Арта...

Әллә кайдан,
Чорлар күкрәгеннән
Ишетелә аваз:
«...Авырта-а-а-а!»

## Томырылып очам

Очам гына хыял тулпарында,
Тыны бетеп артта җил кала.
Әллә инде хәл алырга теләп,
Кагыла ул минем аркага.

Кая инде туктап артка карау,
Җил хәлләрен белү бу чакта!
Яшәү сорап, башланмаган еллар —
Гомер тыпырчына кочакта!

Түгелергә торган моңнарым бар,
Алар белән бергә ачынам.
Бишегендә яткан Киләчәкне
Уятырга диеп ашыгам.

Тик өлгерим генә, алдан килим,
Егылып калсын артта кайгылар.
Савыктыргыч көчле аваз булып,
Яшәү җыры күктә яңгырар.

Бу бакчага нигә кердең әле,
Сытып гөлләр өнен?
Чәчәкләрне ни дип économie изден әле,
Хистән мәхрүм энем?

Сизмәдең дә: бүген харап иттең
Табигатьнең кемен?
Яшәү агачына кул күтәрдең,
Миһербансыз энем!

Килер көнгә — уртак Киләчәккә
Балта чапкан көнең,
Киләчәксез гомер иткәннәрнең
Кыйбласы юк, энем!

Сәбәпчесе булырсыңдыр минем
Йөрәктәге җөйнең:
Сәләтле син... кеше үтерергә,
Мәрхәмәтсез энем!

Бишегеңә кабат кайтарасы
Килә сине минем,
Акылга сай,
Тик бер күзәнәкле
Уйсыз, гамьсез энем!

## Буш кул

Әй, алдык та инде җир байлыгын!
«Җиңү яулап», күңел исерде.
Ә җир безгә
Кызганмады берни,
Киң күңелле ана шикелле.

Соңгы чиккә җитеп йончыган ул,
Үзәгенә үткән хәлсезлек.
Ә без тагын килдек, азга гына...
Уебызда һаман әрсезлек.

Ә куллар — буш,
Килдек без, искечә,
Берни алмый гына, бүләксез...
Йөзләр кырыс, усал, уйламыйбыз
Каласылар барын тәрәксез.

...«Җиңү арты җиңү яулап» яшәп,
Әй, сикерде күңел, исерде...
Ята җирем — ярык тагаракта
Керен юган ана шикелле.

# Таһир Шәмсуаров

## Дөнья

Син булмасаң да бара,
Мин булмасам да бара...
Берәү — соңгы юлга бара,
Ә берәү — тәпи бара.

Берәүләр ташлар җыя,
Берәүләр алтын җыя.
Берәүгә сарай да кысан,
Бишәү — бер өйгә сыя.

Берәүләр — исән килеш тә
Яшәүдән туктап кала.
Берәүләр — үзе үлсә дә
Алгы сафларда бара.

## Әтиләр нигезе

Яшь чагында без мең төрле
Уйлар уйлаган идек.
Әтиләр салган өйләргә
Никтер сыймаган идек.

Бу җиһанны тәпи-тәпи
Бергә урыйсы идек;
Айга менеп хыяллардан
Бура бурыйсы идек.

Безнең балта йөзләре дә
Бары көмештән иде;
Эчкән су гади су түгел —
Сихри инештән иде.

Чәчрәгән йомычкалар да
Алтын йолдызлар иде.
Уйда ай-кояштай гүзәл,
Тиңдәшсез кызлар иде.

...Җиһанны иңли ала тик
Сабыйлык күзе генә:
Әйләнеп кайттым әтинең
Гап-гади нигезенә.

---

Таһир ШӘМСУАРОВ — *яшь шагыйрь, укытучы, Лениногорск районында яши. Журналыбызда беренче тапкыр тәкъдим ителә.*

## Сагыну

Килә ява, килә ява, килә ява бер болыт,
Каршыма чыгарсыз төсле ап-ак бураннар булып.
Сагынып үткән көннәрне, җилләр елый сулыгып:
Килә ява, килә ява, килә ява бер болыт...

Килә ява, килә ява, килә ява бер болыт,
Сездән калган ак эзләргә битем куям онытылып.
Очрашулар, күрешүләр калды авыр моң булып:
Килә ява, килә ява, килә ява бер болыт...

Килә ява, килә ява, килә ява бер болыт,
Янарсыз хәтер күгендә мәңге сүнмәс ут булып.
Кышкы кардан ялан тәпи йөгерер идем томрылып,
Килә ява, килә ява, килә ява бер болыт...

## Карт әманәте

Сандугачлы соңгы таңым бүген,
Әманәтне, зинһар, аңлагыз.
Күкеләрне димим... хет күкеле
Сәгатьләрне, улым, саклагыз!..

## Бәйге

Бәйгеләргә бәйле безнең язмыш:
Җилдән җитез җайдак икәнбез.
Байталларның ялларына ябышып...
Балачакны узып киткәнбез.

*

Яңа дөнья күргән китап —
Яңа туган сабый төсле.
Китап та бит, кеше сыман,
Киләчәге белән көчле.

## Тормыш

Ләйлә, Ләйсән, Искәндәр
Тиз чарасын күргәннәр.
Бердәнбер зур алманы
Өч кисәккә бүлгәннәр.

Ләйлә, Ләйсән, Искәндәр
Капканнар да йотканнар.
Төшләрен йотмаганнар —
Бакчага утыртканнар.

Ләйлә, Ләйсән, Искәндәр
Озак сабыр иткәннәр.
Алмагачлар үсүен
Айлар буе көткәннәр.

Ләйлә, Ләйсән, Искәндәр
Үсеп буйга җиткәннәр.
Өчесе өч тарафка
Таралышып беткәннәр.

Йодрыктай җимешләрдән
Алмагачлар сап-сары.
Тырышып алма җыя
Ләйләнең Лилиясе,
Ләйсәннең Ләнисәсе,
Искәндәрнең Инсары...
Алмагачлар сап-сары!

# Хатип Касыймов

## Өлкәннәр

Алай кабаланмыйлар да,
Исләре дә китми артык.
Туйганнардыр, арганнардыр
Бу дөньяның йөген тартып.

Сөйләшәләр салмак кына,
Ургып-кызып та китмиләр.
Әйтерсең, шулай сак кына
Ызгыш-талашны иплиләр.

Моңнары ята тирәндә
Гомерлек бер мирас булып.
Алар үткән үзәннәрдә
Рәшә уйный сулык-сулык.

Бирмәделәр гомерләрен,
Әҗәт итеп, бирәчәккә;
Күпмеләре ятып калды
Күпер булып киләчәккә.

Кечерәеп калган алар:
Дуга итеп бөккәннәрме?
...Гүя тере тарих алда —
Карап торам өлкәннәрне...

❁

Әрем, тигәнәк, тирәк тә —
Чәчәге бит дөньяның;
Күргән юк чәчәкнең җирне
Ямьсезләүче булганын.

Һәрбер бөҗәк,
Һәр күбәләк
Яратылган кирәккә;

Кем — шомыртка...
Мин табынам
Горур, уйчан тирәккә.

Кемгәдер кирәк яшел җәй,
Кемгәдер — кар-бураннар.
Гөл дә үссен,
Тигәнәк тә,
Күпсенмәгез, туганнар!

❁

Кыр казлары китеп бара
Күкләр буйлап тезелеп,
Бәгырьләре генә кала
Туган илдә өзелеп.

Чайкый алар канатларын
Күкнең зәңгәр күлендә...
Ничек түзәр! —
Катлам-катлам
Моң агышы күңелдә.

---

Хатип КАСЫЙМОВ — *Түбән Камада яшәүче яшь шагыйрь. Шигырьләре журналыбызда беренче тапкыр басыла.*

Үзәннәрдә рәшә уйный.
Рәхәт тә күк, монсу да;
Кырдан барам,
Йөрәк елый,
Тургайларны юксына.

Җырлыйлар иде өздереп,
Көнелләр була иде.
Җанга, иркәләп һәм назлап,
Татлы моң тула иде.

Тузган күлмәкләр шикелле
Дәверләр алышына,—
Гербицидлар «һөҗүм итте»
Тургайлар тавышына.

Гамьнәр төяп, яңа чорның
Кырлары аша үтәм.
Тургай тавышларын тыңлап
Булмас микәнни бүтән?!

## Ятим авыл

Кемдер аны утырткан,
Баглагандыр зур өмет.
Ник утырткан, алмасын
Алыр булмагач өзеп?

Алмалары ал гына,
Үзе тәмле — бал гына.
Бала тулы урамнар
Килделәр күз алдыма.

Юк иде шул, юк иде
Элек андый алмалар...
Алмасы бар,
Тик хәзер
Малайлары кайдалар?!

# ПУБЛИЦИСТИКА

Марсель Галиев

# ЯШӘҮ БЕЛӘН ҮЛЕМ АРАСЫНДА

*Сөйли торган, күрә торган ташлар,*
*Җанлы ташлар бар бит дөньяда.*

Нәби Дәүли.

I



Менә ул: ачык китапка охшаган мәһабәт бина — Казанның үзәк урамына аерым бер тантаналык биреп торган нәшрият йорты. Мин аның авыр ишекләрен кыюсыз гына ачып керәм дә каушап кына өскә күтәрелә башлыйм. Саллы култыксага тотына-тотына, Җәлилләрне, Фадеевларны, Луи Арагоннарны хәтерләгән баскыч ташларыннан ниндидер эзләр күрергә теләгән кебек, акрын гына менеп киләм. Төрле катларда яңгырап киткән тавышлар бергә кушыла да, халыкның асыл улларын, акылын, тарихын туплаган бу бина минем аңымда изге сарайга әйләнә һәм шушы олы дөньяга үз кеше булып кушыласы килү хыялыннан биткә оялчан кызыллык бәреп чыга.

Җирдәге күпме яңалык күптән инде искергән икәнен әлегә белмәгән, киләчәктә кабатланмас ачыш ясаячакмын, дип йөргән бөек уйлы җитмешенче еллар студенты өчен шушы мәгърур бинаның икенче кат буфетында, тозлы томат согы белән аркылыга киселгән юка итле бутербродны өстәлгә куеп, туктаусыз керепчыгып йөргән язучыларны тамаша кылу да бәхетнең беренче баскычы булгандыр, мөгаен. Хис дигәннең юшкыны гына да калмаган, салкын, үле карашлы бүгенге шәһәр яшьләреннән аермалы буларак, без — сугыштан соң туган буын — соклану, гаҗәпләнү, табыну кебек табигый тойгылардан мәхрүм түгел идек.

Монда минем өчен һәркем — ачылмаган утрау. Китап тылсымлы сулыш белән языладыр дип, самими хыялланып үскәнгәме, гадәти киемле шушы тере кешеләрнең Сүз хакимиятенә ия булуларына хәзер инде акылым ирешсә дә, күңел түрендә һаман әле ниндидер каршылык ята.

Буфет гөрләп тора. Керәләр-чыгалар. Бер-ике шигырь бастырган, нәшрият коридорларында ышкынырга өлгергән елгыррак курсташларым бер-берсен уздырып, пышылдап кына таныштыралар: бусы фәлән язучы, бусы тегән... Арада исемлеләр, исемсезләр бар. Шаркылдап көлү яңгырап киткән якка ирексездән борылып карыйм. Ак калфак кигән буфетчы ханым каршында — өлкәнрәкләр. Башын артка ташлабрак көлгәне кулына коньяклы рюмка тоткан, алдында — кәгазе каерып ачылган шоколад. Тезелеп киткән алтын тешләренең яктысы калын иреннәрендә чагыла. Муенга төшеп торган көлсу чәчен бармаклары белән яратып сыйпап ала. Канәгать, бәхетле көлү... Кем ул? Менә ул юан бармаклары арасында сытылырга торган ыспай

рюмканы күтәреп куйды, шоколад капты, гөрелдәп нидер сөйли-сөйли ишек ягына кузгалды. «Нәби Дәүли»,— дип пышылдады кемдер. Баштан ук белгән булсам, дигән нәүмиз алгысыну белән аның бер күрүдә хәтердә кала торган кыяфәтен күздән кичерәм. Шунысы гаҗәп: концлагерьларда җәфа чиккән Нәби ага, минем күзаллавымча, мәңге моңсу, бик ябык, хәлсез булырга тиеш иде бит. Ә ул әнә нинди: шактый таза, калын иңсәле, шат күңелле... Үсмерчакның катып калган хыялына каш җыерам да, нәкъ шулай, мин яратып укыган әсәрләр язган Нәби Дәүли шушындый кыяфәтле булырга тиеш, дип, икеләнүсез кабул итәм.

Ул чыгып китүгә, буфет эче бушап, бераз караңгыланып калды кебек. Читтән генә булса да аны тагын бер күреп калу нияте белән мин дә урынымнан кузгалам.

Хәтер артка чигенә. «Яшәү белән үлем арасында» повесте басылып чыккан еллар... Һәр яңа китапны талымсыз «әчеп» кенә барган үсмер малайга, ниһаять, бәйрәм килде. Әти, һәркөнне иртән, лампа куыгын бәллүр кебек җемелдәрлек итеп чистартып куя иде. Униы лампа кичләрен, тәрәзәләргә якты биреп, әллә каян үзенә чакырып тора. Шул яктылыкмы, әти-әнинең күңел җылысымы күрше-тирәне безгә җыйгандыр. Ул кич утыруларның газиз минутлары онытырлыкмыни?! Кабак төше ярып, көнбагыш чиртеп, бер-берсен бүлдермичә, авыр, газаплы чорлардан да кызык табып, чөкердәшеп кенә гәпләшәләр. Өстәлгә көнбагыш, кабак төше кабыгы пирамида булып өелә. Әнә шундый кышкы озын төннәрдә мин күрше-күләнгә «Яшәү белән үлем арасында»ны кычкырып укыйм. Урыны-урыны белән күз төпләрен яулык почмагы белән сөртеп: «И, мескеннәр...»— дигән бәгырь авазы чыгарып, урыны-урыны белән: «Каисыз да булган икән фашист тәресе!»— дип, ачуын тыя алмыйча сүз кыстырып, бердәм тыңлыйлар. Әсирләргә карата таралган яман фикерне әйләндереп каплаган бу китап хәбәре өйдән-өйгә тиз таралып өлгерде. Көн дә шулай җыелып укый торгач, бу повестьны, үзем дә сизмичә, ятлап өлгердем. Стеналар шартлап торган зәмһәрир салкын төннәрдә дә, кайнап дулаган зәһәр буранлы төннәрдә дә кич утыру дәвам итә иде. Мин җан елавы белән язылган бу әсәрне инде китапка карамыйча гына яттан сөйли башлыйм. Әмма мине шыпырт кына бүлдереп туктаталар:

— Үзеңнән чыгарма, карап укы,— диләр. Аларга рәнҗемичә генә китап битләрен ачарга мәҗбүр булам. Коръәннең һәр сүзе куктән иңгәнлеге каннарына сеңгәнгә күрә, гадәти кеше язганын онытa белеп, һәр китапның да сүзе изге икәнлегенә беркатлы ышану кадере бар иде шул елкәннәрдә.

Күпме кешеләрне елаткан да, юаткан да шушы китапны язган әдипне мин бүген менә якыннан күрәм. Шушы ук бинага урнашкан Язучылар союзының үзенә күрә бер «көфер почмагы» бар. Ак мәрмәрдән ясалган Тукай бюсты янында күрешәләр, сөйләшәләр, бәхәсләшәләр. Әнә, бер төркем язучылар арасында — Нәби ага Дәүли. Мин, кыюсызланып, читтәрәк туктап калам. Сыңар шигырь бастырганын үзе генә белгән яшь шагыйрь кисәге әгәр шушы төркемгә кыю гына барып керсә, аңа Гегельдән цитата китергән чебенгә караган кебек карарлар иде. Үзеңнең барлыгыңны раслар өчен, Пегас тоягыннан чәчрәгән утлы туфрактан алтын бөртекләре эзләп, ак кәгазь өстендә күпме елларны йөгәнлисе бар әле...

Читтән генә күзәтәм. Менә Нәби ага, йөзенә мәҗүси кыяфәт чыгарып, кесәсенә тыгылды, «Казбек» кабы чыгарды. Учына куеп сак кына ачты да тезелеп яткан симез папирослар арасыннан иң тересен сайлап алды, тәмәкеле ягын өскә каратып каккалап торды, куллары ашыкмый, ирене инде түземсезләнеп, бөрелеп килгән. Ул арада аңа ут биреп өлгерделәр.

Карасу чыраенда мәгънәле ягымлылык. Яңакларын җыерчыклар кискәләгән. Ләкин ул бер дә картлык җыерчыгы булып тоелмый, син аның барлыгын шундук онытасың. Вакытсыз тирәнәйгән сызыклар аның ирегеп буган чәнечкеле тимер чыбыкларның каһәрле шәүләсеннән уелып калган истәлек-яра кебек.

Мин кызыгып күзәткән бу төркемгә озынча йөзле, ябык гәүдәле, җирән сакал килеп кушылды. Аның белән күрешкәндә Нәби ага:

— Нихәл, «освобожденный советскими войсками»! — дип көлеп алды, аннары җилкәсенә кулын салып: — Менә, егетләр, пленнан азат иткәндә, мин нәкъ шундый кыяфәтле идем,— диде.

— Ялганлыйсыз, Нәби ага, сез ул чакта кырык биш кило гына булган, ә мин, аллага шөкер, илле кило! — дип үзе дә рәхәтләнеп көлгән Җирән сакалның хикәяләр язу остасы Габделхәй Сабитов икәнен мин соңрак белдем.

Сөйләшәләр, көлешәләр... Барып танышырга да: «Нәби ага, мин бит сезнең «Яшәү белән үлем арасында»ны яттан белә идем»,— дип әйтергә иде. Кыюсызлык җитә, кыюлык җитми... Үкенечкә калмас, ашыкма, күңел! Елларга һәм елларга рәхмәт әйтәсең алда әле. Аланкай якларында, Мишә буйларында, Идел кинлекләрендә бергә йөрербез дип башыңа да китермисеңдер?! Аңа кадәр Нәби ага яшь язучылар

семинарында синең язганнарыңны тәнкыйтьләр. Шигырьләрдә «мин» күбрәк, дияр.
Нишлисең бит, әдәбият-сәнгатьне рухи батракка әверелдерүче «халыклар атасы» тудырган чырайсыз күмәклек шаукымы безнең канга сеңеп өлгермәгән, ахрысы. Яңа заман, яңа сулыш... Җан тибрәнешен, уй-хисләрне пышылдап та, кычкырып та: «Мин!» — дип үз исемеңнән әйтергә була. Шигърияттнең табигый ярларына төшеп, гадел хокукларын кире кайтара барган чагы. Тормышта һәм әдәбиятта нинди дер күтәренкелек еллары иде бу. Күнегелгән киртәләрне җимереп, «Такташ үлде» дигән шигырьдән соңгы дәвердә йокымсырап яткан катламнарны кузгатып, шигърияткә дүрт «Р» — Равил, Ренат, Рөстәм, Рәдиф (Фәйзуллин, Харис, Мингалим, Гатауллин) һәм дә Гәрәй Рәхимнәрнең килүе, безнең дә күңел пәрдәләрен ачып җибәргән иде. Алар йогынтысында дәррәү ак шигырьләр яза башладык. Классик шигырьне, график сурәтенә карап, кирпеч дип кенә йөртә идек. Безне «фәгыйләтен, фәгыйләтен, фәгыйләт» көен бозып, сындырылган юллар белән язылган, кетелмәгән әйләнмәләргә бай шигырьләр генә җәлеп итә иде. Әлбәттә, бу — гасырлар буе килгән кол психологиясен җиңеп, бөтен кеше охшаш бер калыпта булырга тиеш, дигән кысаларны бәреп чыгарга тырышкан каршылык авазы булгандыр. Сиксәненче елларда туган рок-музыка да шундый ук шартлау түгелмени!?
Без генәме?!. Тәнкыйть җиле кагылмаган каланчада утырган өлкәннәрне дә яңа шигърият давылы бөтереп алды. Бу шаукым бары тик Хәсән ага Туфанга гына кагылмагандыр, үзе исән чакта ук ул инде чал Тарихка әверелгән иде. «Арттан килгән аяк тавышларын тыңларга яратам»,— дигән Сибгат ага Хәким, беренчеләрдән булып, адымнарын кызулатты. Галстук урынына «күбәләк» тагып, зәвыклы киенергә яратучы, морзаларныкыдай кыяфәтле Нури ага Арслан да күңелендәге арысланын читлектән чыгарды. Тәнкыйть әле исәнгерәп калган якса черек күсәк күтәргән бер мәлдә Нәби ага Дәүлинең «Баскычлардан баскычларга» исемле язмасы дөнья күрде. Аның шагыйрь Ренат Харис иҗатын кабул итүе, аңларга тырышуы — шушы буынның яшь һәм гайрәтле авазын тануы иде.
Боларны әле мин соңрак аңладым. Хәзергә... семинарда Нәби ага миңа карата: «Яшь иптәш бөеклек турында күп яза, тыйнаграк булырга иде!» — ди. Күп нәрсәне инкарь итәргә кызыккан күңелем аның бу фикеренә үпкәләмәде. Әчтән шундый нәтиҗә генә ясадым. Нәби ага Дәүлинең яшьлеге болгавыр елларга туры килгән. Ул инде ныклап, яңадан каләмгә тотынганда утырган акыллы, ир уртасы була. Иҗат яшьлегендә ул, кыланып, бер бөтерелеп алу бәхетеннән мәхрүм калгандыр, шуңа күрә без яшьләрнең кайнарлыгын да аңлап бетерә алмыйдыр...
Кызык бу өлкәннәр. Күндәм кыяфәт чыгарып, «әйе», дип баш кагып кына торганнарны, иҗатыннан бигрәк үзен «әйбәт егет» дип мактыйлар икән. Шактый зур көч-сәләтен әйбәт булып күренергә сарыф иткән андый тәти егетләрнең тыйнаклыгы вакытлыча гына икәнен, ныклы аякка баскач, битлекләрен салып ташлап, бөтенләй икенче рәвешкә керәсен алар әле уйларына да китерә алмыйлар...
Иҗат галәменә килеп кергән яшьлектә җимергеч көч тә, яңаны төзү дәрте дә, бөеклек хыялы да булырга тиеш. Күңел ирекен яуламыйча, Мирсәй ага Әмир әйткәнчә, «мокытлык дәрәҗәсендәге тыйнаклык»та утырып калсаң, эт сикертә торган көйгә такмак язудан ары китә алмавың да бик мөмкин. Инде Гайсә пәйгамбәр яшенә, ягъни, утыз өчкә җитеп тә «бөеклек чире»ннән арынып, үз мөмкинлегеннең чикләрен ачыклый алмыйсың икән, дөньяда бернәрсәне дә кабул итми һәм ярата белми торган кызганыч шәүләгә әйләнүең бар.
«Кәфер почмагы» андыйлардан үтергеч көлә белә...

## II

Хәтер ак кәгазь каршында сәҗдә кылып кына, күк капусыдай ачылмый, аның өчен елларга һәм юлларга чәчелгән вакыт белән кабаттан яшәп алырга кирәк. Үз чорында гадәти генә тоелган ваемсыз көннәр дә, сагыну рәшәсе аша, ерактан яктырып, гомернең мәгънәле бер өлешенә әйләнә икән. Якын иткән Кешенең тере тавышын, күз карашын, әйтелгән фикерләрен яңарта алудан юанып хатирәләргә бирелә сең дә... каләм ярдәмгә килә.
Юл йөрергә җайлы кеше иде Нәби ага. Иөрәгендәге иярле аты тышауланмаган, чын мәгънәсендә егет кеше иде ул. Тумыштан бирелгән шушы сыйфаты аркасында тормышта кыенлыкларны да, уңайлыкларны да күп күрергә туры килгәндер аңа.
...Итәген Мишә елгасы сыйпап аккан Әлбәден авылында безне интернатка урнаштырдылар. Җәйге ялга киткән балалар тавышы тынган. Ялан кадәр ташландык бүлмә. Бер кырыйга өелгән матрац-одеалларны төшереп, тузаннарын кактык та, панцирлы караватлардан урын алдык. Галимҗан ага Латыйп иркәрәк яшәргә күнек-

кән, ахрысы, туктаусыз зарлана, яхшырак фатирга урнаштырмауларына рәнҗеп ул зарланган саен, Нәби ага:

— Шәп бит, Галимҗан! Миңа ошый монда, шәп! — дип, аны үчекләгән сыман көлә.

— Концлагерьдан соң, сиңа кайда да шәп инде,— ди Галимҗан ага. Караваг панцирында сабыйларча атына-атына көлгән Нәби агага мин дә кушылам. Бераздан Галимҗан ага мыжыклануын сыек кына гырлауга күчереп, йокыга талды. Нәби ага белән икәү, шыпырт кына торып, ишегалдына чыктык. Айлы төн. Чирәмгә чык төшкән. Авыл йоклый. Кайдадыр еракта, үтә саф тынлыкка эче пошкандай, юаш этләр өреп куя.

Телнең гаҗәп нечкәлекләрен, моңын саклаган керәшен авылы бу. Шушы тыйнак авыл сукмакларында уйнап үскән Петя исемле малай, утлар-сулар кичә, хәрби академия бетерә, майор дәрәҗәсенә җитә. Брест крепосте герое майор Гавриловны күпләр ишетеп беләдер. Герой, дип әйтү генә аз, легендар шәхес. Брест өчен барган көрәшнең иң соңгы кешесен — яраланган, һуштан язган Гавриловны немецлар носилкада алып чыгып, саф алдыннан почет белән үткәрәләр. Батырлыкны фашист та таный белә икән. Газаплы әсирлек елларының кара шәүләсе, илгә кайткач та, артыннан калмый аның. Хаксызга онытылган күп батырларны күтәреп чыккан кыю язучы Сергей Смирнов, ниһаять, Гавриловны эзләп таба. Әлбәдән авылында туып үскән татар егете Петр Михайлович Гавриловка 1957 елда Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Ул Алтын Йолдыз һәм берьюлы ике Ленин ордены белән бүләкләнә.

Шушы чирәмле мәйданда берничә елдан соң аңа һәйкәл куелыр. Әлегә без хакдөреслекнең соңлап килүе, сындырылган язмышлар турында сөйләшеп йөрибез.

Борын-борыннан җирдә сугышлар барган. Хәтта без варвар дип атаган чорларда да сугыш соңында әсирләрне алмашу булган. Егерменче гасырда, бары тик безнең илдә, әсирлеккә карата коточкыч гаделсез караш ничек туган? Сугыш театрында командирларның хатасы аркасында яисә корал җитмәүдән, яисә башка бер сәбәптән тулы армияләр чолганышта калырга мөмкин ләбаса. Солдатның монда ни гаебе бар? «Дошманга терелэй бирелмәскә!» дигән приказны ничек кабул итәргә? Сугыш өчен дип түгел, тыныч тормыш төзергә яратылган кешегә гомер бер генә бирелә. Ул яшәргә тиеш! Агач мылтык тотып сугышка кергән кешеләрнең сөйләгәннәрен ишеткәнем бар. Агач мылтыклыдан: «Терелэй бирелмәскә!» — дип ничек таләп итәсең?! Вәхшилек түгелмени бу?! Үзе таләп бирелмәгән әсирләргә карата «илне саткан» дигән мөһер сугарга кемнең хакы бар?!

Минем шушылай кызып сөйләвемне Нәби ага сабыр гына тыңлап торды да, серле тавыш белән:

— Тиран кан сорый. Аңа миллион корбаннар кирәк. Шунсыз ул яши алмый,— диде. Минем аптырап, тиран дигән хәтәр сүзне кемгә юрарга белми торуымны сизеп ул:

— Сталинның бик күп явызлыклары ачылачак әле. Без инде ул көннәрне күрмәбез, сиңа насыйп булыр, минем сүзләрне онытма! — дип өстәде.

Аның бу сүзләрен кабул итү шактый кыен иде миңа ул чакта. «Халыклар атасы» алла тәхетеннән төшмәгән иде әле. Аңымда «ике мин» бәрлыкка килде: берсе килешергә тели, икенчесе рәнҗетелгән кешенең хак бәя бирүенә шикләнә. Урталыкта — ышану-табыну кебек тойгыларның нигез ташлары кузгатылган бушлык... Күпне белгән икән шул өлкәннәр.

Мишә буе. Учактан ялкау гына төтен күтәрелә. Балык шулпасы кайнаган чиләктән саркыган хуш ис куаклар күләгәсендә тын гына аккан елга киңлекләренә тарала. Без, Нәби ага белән, чәчәкле алан буйлап атлыйбыз. Минем күптән кыҗрап йөргән бер соравым бар. «Яшәү белән үлем арасында» повесте бәхетле тәмамлана. «Чынлап та шулай булдымы?» — дип сорыйм. Бу сорау гаҗәп тоелмасын, моннан унбиш еллар элек чын дөреслек җиде йозак артында иде, без күп хәлләрне аннан-моннан ишетеп кенә белә идек.

Нәби ага бер ара дәшми торды, кулындагы чыбык белән, сүнгән учак урынын актарган шикелле, үлән төпләрен каезлап алды да:

— Язганча булса икән... Ул минем хыялым иде... Ил чиген узгач, тагын тоткын булырмын, дип башыма да китермәгән идем,— диде.— Себергә үк озатмадылар озатуын... Чәнечкеле киртәләр сузып, шпал ташып үзебезгә үзебез лагерь төзедек. Хәл юк, ач-ялангач. Ике кеше берләшеп, шпалны җилкәгә саласың да, көч биреп, яңак белән терәп барасың. Менә бу шадра эзләре шул шпалдагы май кисеп кергәннән...— дип, ул сакал төкләрен шыкырдатып, яңагын сыйпап алды.— Фиргавеннәр чорындагы коллар кебек, шпал күтәргән колонна чакрымнарга сузыла. Иң кыены шәһәр урамыннан узу иде. Бала-чагалар, карт-корылар, хатын-кызлар карап кала, арада төрлесе бар: ләгънәт укыганы да, безнең хәлне аңларга тырышканы да...

Күрде инде башлар. Дөнья бу!..

Нәби ага Казанга кайткач та эшкә урнаша алмыйча, һичнинди хокуксыз йөри. Язган әсәрләрен беркайда да басмыйлар.

— Кич житсә, жантимер килә, Черек күл буена алып китәләр дә төне буе аяк өсте тотып сорау алалар. Атналар буе шул хәл, йокысызлыктан тәмам исереп, аң бетә башлый. Тегендә... фашистларны күп күрдем, үз илемдә күзеннән иман нуры качкан палачлар барлыгын белү икеләтә авыр иде. Хром итекләрен шыгырдатып йөргән тук чырайлы тикшерүче — тыл күсесе — мәгънәсез сораулар биреп тәмам чыгырдан чыгарды. Өстәленә беркетелгән таш арыслан башын сыйпый-сыйпый, миннән чит ил шпионы ясарга теләүче ул бәндәгә беркөнне әйтмичә калалмадым: «Сез сыйпаган арыслан — җансыз таш, без күргән тере арыслан каршында нишләр идегез икән?» — дигәч, тикшерүче алагаем кизәнеп, яңак төбенә китереп сукты. Ничә төннәр йокы күрмәгән тәнем куырылып килде». «Ничек тә егылмаска, бу палач каршында егылмаска!» — дип кабатлыйм. Күз алдымнан караңгылык таралуга, күрәм, тагын кизәнә бу, ыргылдым да җан ачысы белән беләгеннән кысып алдым.— Нәби ага, шул халәткә кереп, саллы кулын беләгемә салды.— Шуннан ни булды дисеңме? Моны көтмәгән бәндә агарып чыкты, ярсуы бетте, ә мин кулны ычкындырырга телим — булмый гына, үлем исерегә белән кысылган бармаклар торараш каткан, йозак кебек бикләнгән. Бераздан тикшерүче һушына килеп, кнопкага басты, ике жантимер йөгереп кереп, ябышып каткан кулны көчкә каерып ачтылар. Шуннан соң теге бәндә бүтән кизәнмәде.

Минем әүвәлге сорауда канәгатьсез киная сизгән кебек, ул яңадан повестька әйләнеп кайтты:

— Соңгы бүлеген нәкъ тормыштагыча язсам, әле бүген дә дөнья күрмәс иде. Болай да бастыра алмыйча ничә ел йөрдем. Мин үлгәч булса да, чыгар дип, бер данәсен җиргә күмгән идем. Өлкәннәрне гаепләргә ашыкмагыз. Шундый чорлар әйләнеп кайтса, белмим, кемнәр нинди хәлдә калыр иде икән?.. Ходай язмасын!..

Нәби ага, авыр хатереннән арынырга теләгәндәй, тынып калды, аннары, кинәт кенә беләгемнән тотты да:

— Әнә тегендә кара әле! — дип елга борылышындагы текә ярга күрсәтте.— Күрәсеңме, елмаеп торган кеше башы.— Үз табышына үзе үк сокланган сабый халәтендә иде ул. Аның майлы буяулар белән табигать күренешләрен киндергә төшерүен ишетеп белә идем, әмма сүз арасында, төрле катламнар белән чуарланган текә ярдан шундый сурәтне күрә алуы гаҗәпкә калдырды.

Җәелеп, үзе турында күп сөйләргә яратмый иде ул. Әнә шулай, юл йөргәндә, кәефе килгән чакларда, өзек-өзек кенә искә төшерүләреннән, әсәрләренә сыймый калган кайбер вакыйгалар хәтергә сеңеп калган.

— Утыз җиденче елда шундый бер төш күргән идем,— диде Нәби ага.— Каядыр поезд белән барабыз, имеш. Бер тарлавыкта поезд туктады, юл кырыена чыгып тезелдек. Яшел чирәмле үрдә кап-кара киемле кешеләр тезелгән, һәрберсе ыргып торган эт җитәкләгән. Ни өчен мондый төш керде? Аптырап, нәрсәгә юрарга да белмичә йөргән идем. Берничә елдан соң, Германия җиреннән безне Бухенвальд лагерена алып барган чакта поезд тукталды. Безне чыгарып тезделәр. «Ия хода!» — дип үз күзләремә ышанмый торам. Каршымда ничә ел элек төшемә кергән күренеш: шул ук яшел чирәмле үр. Үр өстендә эт җитәкләгән кара киемле солдатлар... Шулай итеп, яман төштәгене өндә күрсәтергә әзерләп куйган икән язмыш...

Бай табынлы бер мәҗелестә ул аннан-моннан гына кимерелгән сөяккә күрсәтеп:

— Немецлар баланда бирәләр иде, шунда зур гына сөяк була, итсез әлбәттә,— дип сөйләп китте.— Шыр сөяк йөзләгән әсир арасында, чиратлап, кулдан-кулга китә, кире әйләнеп кайтмый, кимерелеп беткән була,— дип, ул ипи сыныгын кулына алды да: — Мондый ипине төштә генә күрә идек, пычкы чүбе, чөгендер, тагын әллә нәрсәләр кушып пешерелгәнне бирәләр иде, шуны тип-тигез итеп, йөзләгән кисәккә бүләргә кирәк. Алданмас өчен, һәркем агачтан үзенә үлчәү ясады, шулкадәр төгәл үлчәү — чебен кунганны да сизә. Беркөнне немецлар безне плацка чыгарып тезделәр. Баракларда тентү башланды. Безнең теге үлчәүләрне кочак-кочак күтәреп алып чыктылар да мәйдан уртасына тау итеп өйделәр. «Эх, сез, коммунистлар, бер-берегезгә ышанмыйсыз, шул бетерәчәк сезне!» — дип, бензин сибеп, теге өемгә ут төрттеләр. Безнең ачу килә, «Шундый шартларга куйсаң, нишләр идегез икән, арий токымы?!» — дип, тешне кысып карап торабыз. Дөнья бу! Алтын сарайларда үс, әллә кем бул, әгәр ирегеңне буып, хайван хөкеменә калдырсалар...— дип Нәби ага тел шартлатып куйды.— Муса Җәлилнең шигыре бар бит:

*Чәнечкеле тимер чыбык белән*
*Уратылган безнең йортыбыз.*

*Көне буе шунда казынабыз,*
*Әйтерсең лә тирес корты без...*

Без ул чакта Колыма лагерьларында, коточкыч шартларга дучар ителгән кешеләребезнең адәм ашауга кадәр барып җитүләрен белми идек шул әле...

* * *

Нәби ага белән табында утыру рәхәт. Яше буенча олпатлыгын оныта белеп, кечелекле, уенчак холкын саклаган хәлдә, ара калдырмыйча, иптәш булып, үзен тигез дәрәҗәдә тота. Хәмер белән ул сәбәпсез мавыкмый, Гомәр Хәямчә, шигъри ләззәтен белеп кенә, чама белән генә тота иде, анда да затлысын гына... Бергә юл йөргән соңгы елларда ул, табындагы белән канәгатьләнеп, элек чирканыбрак караган «ак»ны да кире какмый башлаган иде.

Бервакыт ул мине бөтенләй гаҗәпкә калдырды. Эш сәгате бетәр алдыннан кабинетка килеп керде, пошаманга калган, кәефе киткәнрәк сыман. Бераз сөйләшеп утыргач, табадан гына төшкән, өр яңа калын китабын чыгарды. Ул чакта әдәбиятны пропагандалау бюросы авылдагы каравыл өе кебек иде: бер дә язучылар өзелми, тел чарлау, сүз көрәштерү, чыныгу мәйданы иде ул. Яңа китабы белән котлагач, «Юарга кирәк инде моны...» — дигән сүзләр дә ишетелеп куйды. Нәби ага уңайсызланып кына портфеленнән «Агъстафа» шәрабе алып өстәлгә утырткач, бер мәлгә мин өнсез калдым:

— Нишләдегез сез, Нәби ага?

— Нигә? Нигә алай дисең?

— Дәрәҗәгезне төшерәсез бит. Сезгә коньяк кына килешә иде. Шушындый шатлыклы көнегездә, арзанлы кызыл аракы белән...

— Шулай төшәсең икән аны,— диде Нәби ага. Бераздан аңлашылды: йөз мең данә белән русча басылып чыккан китабына, кабат-кабат басылу сәбәпле, бер тиен дә гонорар түләмәгәннәр икән. Ис китәрлек хәл. Акчаның һәм кешенең кадерен белгән илләрдә кабат басылган китап өчен, киресенчә, күбрәк түләнә бит югыйсә. (Ул чакта дәүләт иярләрендә утырган әшлеклеләрнең, үзе язмаган китаплар чыгарып, миллионнар көрәп утыруы аңыбыздан ерак тора иде.)

— Ач күзеңне, дөнья бу! — дип, Нәби ага үзеннән һәм дөньядан көлеп куйды. Шушылай, бөтен тәрәзәләрен ачып, көлә белүе белән ул үзен дә юата, кешеләргә дә канат куя белә иде.

Бөек җиңүнең утыз еллыгы уңаеннан ветеран-язучылар чәй мәҗлесенә җыелганнар иде. Арада күкрәк тулы орден-медальләләр бар: Берлинны алганда яраланган майор Риза ага Ишморат, Тын океанда йөзгән крейсерлар өстеннән очып узганда татарларга сәлам әйтеп радиограммалар җибәрергә яраткан очучы Салих ага Баттал, «Алтын Прага, злато Прага» дип язган, Европаны азат итүдә катнашкан Мөхәммәт ага Садри, Украинаның Тернополь шәһәрен Беренче һәм Икенче бөтендөнья сугышында азат иткән Идрис ага Туктар, орден-медальләре кырыена төрле значоклар да сипкән Мәхмүт ага Хөсәен. «Без дә солдатлар идек» повестен язган Әмирхан ага Еники — барысы өч дистәгә якын өлкәннәр. Сыннары туры, йөзләре яшәреп киткән кебек. Бер-берсенең орден-медальләрен тотып-тотып карыйлар. Күзләрендә — еракта янган төнге учак кебек, үзләре генә белгән моңлы хатирәләр. Арада бердәнбер Нәби аганың гына түшендә берни дә юк. Шул чакта мин аны кызганып куйган идем. Үзе исә берни сиздерми, бәйрәмчә шат йөри, эчендә нинди әрнүле уйлар кайнаганын үзе генә белгәндер. Повестендагы тетрәндергеч юллар аның бәгырь авазы түгелмени?!:

«Минем ярам да юк, орденым да юк. Мин сездән көнләшәм, солдатлар. Мин үз язмышымны каргыйм. Миңа сезнең алда оят кебек. Беләм, сез мине читкә какмассыз. Әгәр мин сезгә үз язмышымны сөйләп бирсәм, сез мине кызганырсыз. Ләкин миңа аңардан җиңел булмас. Бары йөрәк кенә сызланып калыр. Нишлим соң, солдатлар? Ләкин мин беркемнән дә йөземне яшермим. Карагыз, солдатлар, минем күзләремә, сез минем сагышымны аңларсыз. Миңа пуля тимәде, ләкин минем йөрәгем яраланды. Ул яра мәңге төзәлмәс. Фашизм минем яшь гомеремне алып калды. Ләкин туган илемә булган мәхәббәтемнең бер генә тамчысын да, бер генә тамчысын да фашизм минем йөрәгемнән саркыта алмады...»

Шушы юлларны укыгач, шәһәр үзәгендә, койма буенда үскән бер тирәккә шаккатып карап торганым искә төште. Рәшәткә тимере тирәкнең яшь тәненә сөңге кебек батып кергән булган. Тирәк шул салкын тимерне «чәйни-чәйни» кәүсәсе белән бөкрәеп тореп, йомып алган да, ярасын чит күзләрдән эчкәре яшергән. Яралы тирәк рәшәткә белән көрәшкән елларда аның янәшәсендәге тирәкләр инде шак-

тый биеккә үрләп өлгергән... Тимер рәшәткәне каерып алып кара хәзер — тирәкнең бәгыреннән кан тамачак, үзәген җимереп кергән шул сөңге белән бергә яшәргә хөкем ителгән ул...

Соңгы дистә ел дәвамында Нәби ага Дәүлигә дә, башка ветераннар белән бергә, юбилей медальләре бирелә башлады. Шуның берсен пиджак якасына кадерләп тагып йөртә иде ул.

Фронтовик дуслары — шагыйрь Шәраф Мөдәррис, Гали Хуҗи, Әнвәр Давыдовларны сагынып искә ала, аларның туры сүзле, кыю булулары турында сөйли иде Нәби ага. Үзенең дә, җыелышларда битараф калмыйча, кырмыска оясын болгатып ала торган гадәте бар иде. Кайсы чакта, уенчак холкына турылыклы калып, бөтен кеше буйга сөйләгәндә, эч пошканнан гына, аркылы килеп куя сыман иде...

Әдәбиятта да ул медальсез иде. Бәлки, аңа үз укучысының меңләгән рәхмәтен ишетү рәсми бүләкләрдән өстенрәк булгандыр... Шулай уйлыйк. Үз вакытында әдипнең әдәби хезмәтен бәяли белмәү сансызлыгын аклап карарга тырышыйк...

Хәер, ялтыравыкка кызыккан сабыйлык галәмәтен онытыйк та табигатьнең зирәк акылы каршында баш иик... Уян, каләм! Еракта калган хатирәләрне исеңә төшер... Төнге учак... Нәби ага учак каршына тезләнгән дә утлы сулыш бөркеп торган күмерләрне актара. Астан ялкын бәреп чыга, кыргый атларга охшап, уйнаклый-уйнаклый күккә ыргыла. Учак-ут каршында кеше, дөнья мәшәкатьләреннән арынып, кыргый табигыйлегенә кайта. Керләнмәгән ялкын чисталыгыннан үз җанына теләктәшлек эзли. Шушы мизгелне мин күңелемнән генә рәсемгә төшерәм. Эре сызыклар белән каймаланган, ирләргә генә хас чибәр кыяфәт. Сәлҗүкләр токымынныммы, күк төркиләрдәнме, һуннардынмы — кайда башланган аның нәсел агачы? Халыкларның бөек күчеше вакытында ырулар буталган, кан кушылган, шанлы чорларның кайтавазы сыман сүнә барган учакка карап утырган ирнең карасу чыраенда моңлы шәрык борынгылыгы чалына. Шушы язылмаган картинага карап мин яшәү белән үлем арасындагы Кеше гомере турында уйланам. Берәү дә фәрештә түгел. Үз ялгышлары, үз хаталары бардыр. Әмма нәкъ шушындый язмыш җирдә бүтән мәңге кабатлана алмый. Мәрхәмәтле бул, күңел! Иң беренче нәүбәттә кешенең кара ягын күрергә тырышсаң, үзеңә дә корым йогар, иң башта якты ягын күрә бел — үзеңә дә яктысы төшәр. Яктың киңәйгән саен шәфкатьлерәк була барырсың...

Сүнмә әле, учак, сүнмә, җанга төшәр яктыңны җәлләмә...

## III

Нәби ага Дәүли, Рөстәм Мингалим — без өчәү Кулаткы районында чыгышлар ясап йөрибез. Клублар шыгрым тулы. Казан аһәңен сагынганнар. Нәби аганың сәхнәдә торуы бүгенгедәй күз алдында. Шигырьләре дә ятланып калган. Тавышы аның яңгыравыклы түгел. Виолончель кылларыннан чыккан шикелле, күңелне уятып, сагайта торган язмышлы тавыш.

*Бәхетлеме кеше дөньяда?*
*Ят илләрдә рәхәт торса да,*
*Гөмбәзләрен бизәп алтынга,*
*Асылташтан сарай корса да,*
*Туган йортын кабат күрмәсә,*
*Туган җиргә ятып үлмәсә,*
*Яз көнендә чәчәк куярга*
*Каберенә дуслар килмәсә,*
*Ник яшәгән кеше дөньяда?..*

Шигырь соңында ул залда купкан алкышлар яңгыры астында ләззәтле оеп тора белми, кул чабуны өнәп бетермичә, тизрәк икенче шигырьгә күчәргә теләп тынычсызлана. Ә бу юллар: «Поездлар килә дә китә...» Күз күрмәгән ераклыклар җиле белән җанны бөтереп, яннан поездлар үткән чакта, алгысынып карап калу кемнәргә генә хас түгел?! Борылышларга кереп тына барган тәгәрмәчләр җыры билгесез сагыш уяткан мәлдә, шагыйрьнең үзе өчен тирәнрәк тойгылар аңлаткан бу шигырь юллары үзеннән-үзе хәтергә килә:

*Ә йөрәк һаман ышанмый,*
*Ә еллар һаман үтә.*
*Чәчләремә кырау төшә,*
*Поездлар килә, китә...*

Менә сәхнәгә җырчы кыз чыга. Консерватория белеме белән имгәтелмәгән тавышы, җил-су агышы кебек үк, үз табигыйлегендә. Залга моң агыла.

Нәби аганың йөз җыерчыклары арасына кызгылт рәшә бәреп чыккан, күзләре рәхәт кысылган. Эчке бер канәгать елмаюын иреннәре чак тыеп тора. Җырны нәкъ үзе теләгәнчә башкарып чыгуын көтеп дулкынлану да, бераз мактану да — кыскасы, иҗат кешесенә хас бөтен самимилекне йөзенә таратып, җыр дулкынында яшәп тыңлый. Халык йөрәгенә иңгән шушындый җырлары булу шагыйрь өчен олы бәхет түгелмени?!

Очрашу соңында Нәби аганы хатын-кызлар урап ала. Укытучылар, китапханәчеләр. Үткер тоемлы Нәби ага арадан иң чибәренә карабрак сөйли. Аның ташбака кебек авыр кул арасына чибәр ханымның нәфис кулы үзеннән - үзе суырылып керә. Ханым кулын онытa, тартып алырга базмый. Ул әдипнең иҗатына гашыйк. Мут елмаерга кыҗрап торган иреннәренә гашыйк. Йөзендәге кискен җыерчыкларны да оныттырып, бу тормышны, кешеләрне ярату нуры мөлдерәп тулган кабарынкы күзләренә гашыйк. Дөресрәге: гашыйклыкка бәрабәр хөрмәт бу! Нәби ага чибәр ханымның оялчан кулын сыйпый-сыйпый сөйләшә, алтын тешләрен ялтыртып, көлеп тә куя. Күпме еллар шатлыктан мәхрүм яшәгән кеше генә шулай тәмен белеп, йогышлы итеп көлә беләдер.

Кулаткы мишәрләре таза хәлләләр, көр яшиләр. Ерак та түгел Суслов туган җирләр, шунлыктан юллар шәп монда. Берничә көннән соң без күңелгә хуш килгән бу район белән саубуллашып, Ульяновск каласына килеп төштек. Казанга моннан төрлечә кайтып була: суданмы, һаваданмы, тимер юл беләнме — кайсын сайлыйсың, рәхим ит. Бераз киңәшләшеп алганнан соң, без, Идел ярларын тамаша кылып, «Метеор» белән кайтырга булдык. Бер уңай килсә, килә бит ул. Билетка чират та юк, Казан «Метеоры» кузгалырга хәтсез вакыт бар икән. Гәрләшеп сөйләшә-сөйләшә елга порты ресторанына кердек. Сусынны басар өчен генә «Үгез каны» шәрабе алып, байларча ашап утырабыз.

Минем кәеф — югары катта. Ниһаять, үз гомеремдә беренче тапкыр «су җәнлеге»нә утырып кайтам. Сай инештә вак маймычлар гына сөзеп үскән малайга вакыйга түгелме?!

Алданрак кузгалып, билет кассасына юнәләм. Безнең «Метеор» алтмыш өченче причалдан сәгать бердә кузгалачак икән. Карыйм: ун гына минут киткән югыйсә, ә причалдагы «Метеор» янында халык кайнаша. Ресторан ишегеннән аш сеңдереп, гамьсез генә чыгып килүче юлдашларыма: «Тизрәк!» — дип, кул болгыйм да йөгерә башлыйм. Арттан киң итәкле сумкасына ияреп Рөстәм Мингалим теркелди, авыр гәүдәсен саллы гына селкетеп, Нәби ага да йөгергәндәй итә. Сулу кабып килеп җитүгә, зәңгәр киемле, кокардалы ханым:

— Кто еще с билетами?! — дип кычкырды. Өчебез бертавыштан горур аваз салдык. Билетсыз халык көнләшеп, кызыгып, безнең каршыда икегә аерылды. Ул арада мин кокардалы ханымга билетны төрттем, ул аны илтифатсыз гына ертты да, без, сыгылмалы траптан төшеп, «Метеор» авызына чумдык. Эчтә — кеше!.. Энә төшәр урын юк. Трапны шундук алдылар, «Метеор» бөтен гәүдәсен калтыратып, тирбәлә-тирбәлә кузгала да башлады. «Метеор» алгы борынын күтәреп дәрт алгач, Мингалим белән икәү капитан рубкасына менеп киттек. Арабызда иң өлкән язучыбыз, сугыш ветераны дип, Нәби агага ничек тә урын яулап алырга иде. Капитанның әмере бик тиз үтәлде, яшьләрне кузгатып, Нәби агага урын таптылар. Без инде басып барырга да риза. Нәби ага урынын җылытып, тәмам күнеккәннән соң, канәгать елмаеп, безнең янга чыкты. Ульяновск дулкыннар артында күмелде. Биек ярлар зәңгәр рәшә артында чак-чак шәйләнә. Чын диңгез уртасында тирбәләбез. Кичен мәркәзебез Казан безне Сөембикә манарасы белән каршы алачак. Нәби агача итеп: «Ач күзеңне, Казан бу!» — дип әйтергә телне чарлап куйганмын. Йөзләрдә талгын рәхәтлек. Уйлар инде алга йөгереп өйгә кайтып җиткән. Өчебез өч төрле тәмәке чыгарып бер уттан кабызабыз.

— Шәп бит, ә, егетләр! — дип, Нәби ага Идел киңлекләрен кулы белән сыйпап ала.

— Моны кабатлап булмый, кабатлап булмый, Нәби ага,— ди Рөстәм Мингалим.

— Идея кемнеке? Поезд белән кайтмакчы идегез бит әле,— дип, мин үземне мактатырга уңай форсаттан файдаланам.

— Сиңа рәхмәт, сиңа рәхмәт! — ди Рөстәм Мингалим.

Кокардалы баягы ханым кырыйдан тыз-быз үткәли. Мин тәмәке төтенен, бөҗралатып кына чыгарып, болай, күңеле булсын дип кенә, җилкә аша аңа эндәшәм:

— Әйтегез әле, Казанда сәгать ничәдә булабыз?

Кокардалы ханым кинәт туктап кала:

— Нинди Казан? Без бит Куйбышевка барабыз!

— Шаяртмагыз әле,— дим хәлсез тавыш белән.

— Бернинди шаяру юк, без Куйбышевка юл тотабыз!

Иөрәк убылып төште. Бер мәлгә тынсыз калдык. Акылга сыймаслык иде бу хәбәр. Шулвакыт Нәби ага тимер кулы белән иңемнән селкетеп алды:

— Суга төртеп төшерәм бит, кая утырттың син безне!

Сабыр холыклы Нәби аганың болай кызып китүен күргәнем юк иде, шүрләп калдым, бердәнбер чара: үземнең гаепле икәнемне белгән хәлдә, тавышны күтәреп, һөҗүмгә күчү:

— Алтмыш өченче причал, диделәр... «Метеор» тора... Каян белим мин, беренче утыруым!.. Берегез дә Казан димәдегез... билет тикшергәндә дә... Мин каян белим!

Ул арада Рөстәм Мингалим әче тәмәкесен ташлады да, әле уңга, әле сулга чыгып, гадәтенчә, җайлый башлады.

— Туктагыз әле, кызмыйк әле, чынлап та, беребез дә Казан дип әйтмәде бит, гаеп барыбызда да...— дип минем башка төшкән төп хатаны өчкә бүләргә керешге.

Бу хәбәр өске катка да менеп җиткән икән, капитан да яныбызга төште:

— Их, егетләр, чак кына алданрак әйткән булсагыз, күчереп утырта идем бит Казан метеорына, әнә, яңа гына каршы булды,— дип май өстенә ут салды. Әле Ульяновскига барып кына яткан, без утырасы «Метеор»ның ярылып калган дулкын буразналары арасыннан койрыгы гына күренә иде инде.

Иң якын тукталыш туксан чакрым ераклыкта икән, капитан безне тынычландырып, рубкасына менеп китте. Инде хыялы белән өйгә кайтып җиткән кешегә бөтенләй кире якка ыргытылуны белү шактый кыен икән шул. Чырайларга болыт төште. Арада — җил...

Хәтсез барганнан соң, без шыксыз гына бер пристаньдә төшеп калдык. Ульяновскига «Метеор» сәгать дүрттә генә була икән, ике сәгатьтән артык вакыт бар. Кемнәрнеңдер киңәшен тотып, без үр өстендә күренеп торган автовокзалга киттек. Якын гына тоелган иде, бара торгач, чакрымнан артык ара булып чыкты. Автовокзал яны — мәхшәр. Исерекләр, җырлаш, кычкырыш. Якын килмәле түгел, шыплап тулган автобус, ишек-тәрәзәләреннән асылынган кешеләре белән ыңгырашып кузгала. Нәби ага, өметсез кул селтәп, эскәмиягә барып утырды. Аның өчен борчылабыз. Кәефе төште картның.

Күпмедер вакыт үткәннән соң күрәбез: пристаньга таба, аккош шикелле йөзеп, бер «Метеор» килеп ята.

— Ульянга түгел микән, белеп чык әле, белеп чык,— ди Нәби ага. Мин автовокзал начальнигына кереп киттем. Бетте баш! Нәкъ безгә кирәкле «Метеор» икән. Монда, Мәскәү вакытыннан тыш, җирле вакыт та йөргәне бөтенләй хәтердән чыккан. Ульяновск вакыты белән өчтә китәсе «Метеор»га нибарысы биш минут вакыт калган. Пристаньга кадәр очып барсаң да җитешеп булмаячак. Нишләргә? Аякка герләр асылган кебек, әкрен генә чыгам. Рөстәм Мингалим каршыга килә.

— Безнең метеор, Нәби агага әйтә күрмә, бетерә...— дим авыр сулап. Мингалим, пырхылдап, авызын каплады да бөгелеп төште.

— Кая, кая, кая бара? — дип Нәби ага ерактан эндәшә. Бер үк сүзне шулай шомарта-шомарта, кабатлап әйтә торган гадәте бар аның.

— Бүтән якка,— дим читкә карабрак. Куак артына китеп, Мингалим белән эчләрне тотып җүләрләрчә көлешәбез. Кызганыч хәлдә, еламас өчен, шулай мәгънәсез көлеп, үзен юатадыр адәм баласы. Җитмәсә, икебезнең дә кесәләр буш, сукыр бакырлар гына зәгыйфь тавыш бирә. Тиеннәр кәгазь акча янәшәсендә генә күңелле зеңгелдәшә бит ул. Бөтен өмет — Нәби агада. Аның туфли алырга дигән акчасы исән калды шикелле. Ләкин бу халәттә ничек сүз башларга?

Ара-тирә бу тузанлы почмакка таксилар да килеп чыга икән.

— Такси тотарга кирәк, такси! — дип Нәби ага безгә кул изәде. Вакыт-вакыт әлеге көлү өянәге кузгалганга күрә, без аңардан читтәрәк торырга тырышабыз.

— Ни бит, Нәби ага... безнең бит...— дип Рөстәм Мингалим аңа таба бара башлады.

— Таксины ычкындырмагыз, әнә берәү килә бугай!

— Безнең хәлләр...— дип Рөстәм Мингалим тагын уңайсызланып кына башлаган иде, Нәби ага аны бүлдерде:

— Акчамы? Минем кулга каласыгызны сизгән идем инде мин, алыгыз такси! — дип, ниһаять, көлеп җибәрде. Җиңел сулап куйдык та, мәйданга шалтырап, дөбердәп килеп туктаган бер калтырча таксины сугып кына алдык. Калҗайган, ян-яклары корт тишкән кебек челтәрләнеп беткән бу иске «Волга»да безнең өчен шатлык, алга кузгалырга өмет иде. Ачылса ябылмый, ябылса ачылмый торган ишекләрен каерып кереп тә утырдык. Бакыр чәчле рус егете машинаны кузгатуга, әчтә кайнап тузан күтәрелде, газ исе җәелде. Тизлек — хәтәр! Бичаракай машинаның бөтен җире калтырый, сызгыра, чыелдый, дүрт ишек дүрт көйгә күгәнендә биеп бара —

мәхшәр...

— Тарала бу, тарала бу, егетләр! — дип Нәби ага тешләрен елтыратып көлә башлады. Җитдилек үзе көлке булгандыр бу минутта. Аның кәефе күтәрелүгә сөенеп, без дә көлү капчыкларын чишеп җибәрдек.

Нәрсәдер бик каты дөберди башлагач, шофер егет кырыйгарак алып машинаны туктатты. Чыгып карасак, тәтен чыга торган торбасы кубып төшкән дә җирдән сөйрәлеп бара икән. Шофер аны тимер чыбык белән тарттырып азапланды да, булдыра алмагач, асфальт астына тибеп төшерде.

— Әйттем бит, тарала дип...— Нәби ага безгә шыпырт кына тәртеп алды.

Утызынчы еллардагы мактаулы трактор тавышы чыгарып, машина кузгалды. Ваемсыз рус егете, ят телдә сөйләшеп, туктаусыз көлешкән бу пассажирлар турында ни уйлагандыр, әмма ул безне түкми-чәчми Ульяновск каласына кайтарып төшерде. Кичке елга порты бушап калган. Дебаркадерларга бәрелгән дулкыннар гына безне үртәгәндәй шаулый.

Тимер юл вокзалын эзләп табып, төнге поездга билет алганнан соң Нәби ага:

— Теге машинада исән-имин кайтып җитә алсак, сыйлармын дигән идем, чукынып китсен туфлие, әйдәгез ресторанга! — дип, утлар кабынган үзәк урамга алып китте.

Шулай итеп, сәяхәтнең соңы иртә-таңда тәмамланды. Казан әле уянып кына килә. Арып-талган гәүдәләрне, тизрәк өйгә кайтып, таратып ташларга дигән уйны Нәби ага икенчегә борды:

— Нигәдер өйгә кайтасы килми, әйдәгез, бераз йөрик әле...

Казан елгасының дымсу-салкынча һавасын иснәп дамба буйлап киттек. Безгә күренмәгән кояшның беренче нурлары белән Сөембикә манарасы гына коена. Тыптын елга өстендә — көймәләр. Калкавычка төбәлеп, оеп калган балыкчылар үзләре дә ерактан калкавыч сыман күренә.

Нәби ага үзенең ятимлектә, детдомнарда үткән үсмер чагы турында яңа әсәр башлавын сөйли. Берничә елдан соң без аның «Ак ат» дигән күләмле әсәрен уку бәхетенә ирештек. Хәзергә... язучының үткәне һәм бүгенгесе арасында дөнья кайный. Газаплы да, татлы да истәлекләр йөрәк тибешен икеләтә тизләтәдер. Үзе генә белгән тормышны кәгазьгә төшергәндә аңа артта калган еллар янәндә утырган күпме кешеләр белән бергә үлеп тә, терелеп тә алырга туры килгәндер.

— Ничек кенә ярлы үтсә дә, балачак хатирәләре кадерле. Язарга рәхәт. Утызынчы елларга җиткәч, иң авыры булачак. Кая төртелсәң дә, ярамый. Цензура менә монда утыра,— дип ул маңгаена шапылдатып куйды.

Кояш мәһабәт Кремль диварларыннан өскә калыкканчы сөйләшеп йөрдек без ул иртәдә. Саубуллашыр алдыннан, кичәге гаебемне һаман да истә тотып, борчылган хәлдә мин:

— Кичә кайтасы идек бит, бер көнгә тормыштан артта калдык,— дидем.

— Бер көн нәрсә ул,— диде Нәби ага.— Менә минем ун елдан артык гомеремне сызып аттылар. Бүген язасыны күптән язарга тиеш идем инде.

Аның әрнеп әйткән бу фикерен кабат-кабат хәтеремнән чигерәм. Үзе кичереп караган гына мондый язмыш фаҗигасен тулысынча аңлыйдыр. Язучының рухын сындырып, шәхесен таптап килгән шул дистә еллар эчендә ак кәгазьдә бөреләнәсе күпме шытымнарга кырау тигәндер, илһам чишмәләрен ачып, упкын аръягында калган туры юлыңа чыгу өчен тагын күпме еллар сорала. Әдипнең иҗатын әнә шул яссылыкта, язмышы белән бәйләп карау өчен мәрхәмәтле каләм кирәктер.

Галәм туктаусыз хәрәкәттә. Кояшлар сүнә. Яңа йолдызлар кабына. Әдәбият та шундый хәрәкәткә буйсына. Сүнгән йолдызның нуры мең еллар буе килергә мөмкин. Ләкин уты сүнгән әсәрнең ялган нуры озакка бармый. Классика киштәсенә җиңел генә куелган күпме әсәрләрнең заман тетрәп, төшенчәләр үзгәргәндә, комы коелуын күрәбез. Ярлар күчә... Дулкын юлын күрсәтергә тиешле маяклар ком өстендә утырып кала... Көнлекче иҗат, ясин укылмыйча гына, Вакыт каберенә күмелә. Язучы-әдипнең гали зат, халыкның пәйгамбәре икәнен онытып, кара елларда янәшәдәге каләмдәшен сатып, эшафотка озатканнарның да исеме чыга бүген. Шулай кирәк! Үзең исән түгел икән, балаларың, оныкларың каршында каберең җавап тотсын. Берни дә эзсез онытылмый бу җирдә! Иманы каршында тез чүккән мондый каләмцыләренең н а м у с ы өстендә кылга әйләнгән кылыч тора кебек. Намус каршында ак йөзле Нәби ага Дәүли, андыйлар белән чагыштырганда, күпкә бәхетле иде. Тәңре биргән сәләтен түкми-чәчми, үз иҗатын укучысы күңеленә юллый барган бу олы җанлы шәхес әдәбиятка гадел хезмәт итте.

Ул яратып әйткән тостның азагы болайрак бетә иде: иң шәп җыр нинди җыр? Без язмаган җыр! Күтәрик әле бокалны без язган җырлар өчен!

Әйе, ул язган җырларның моңы-аһәңе — йөрәкләрдә. Язасылары күпме иде әле?!

Үзе кичергән кырыс чынбарлыкны кыю рәвештә язарга мөмкинлекләр ачылгач кына... яшәргә иде, теге елларга үч итеп яшәргә дә яшәргә иде бит әле. Нишли сең, тәкъдирнең карары теләкләрдән өстен шул...

Язучының иҗат гомере уңъеллыклардан тора. Кылган хезмәтләреңне барлап, сайлап алу һәркемгә хас. Алтмыш еллык юбилее алдыннан Нәби ага да калын кулъязма алып нәшриятка килә.

— Җитмешкә үк җитәлмам инде, үләрмен. Кулга тотарлык китап чыгарырга иде бит,— дигәч, ул чактагы бүлек редакторы, үзе бер дә елмаймыйча, көтелмәгән юмор әйтә белгән Шәүкәт Галиев:

— Сез, Нәби ага, илледә дә шулай диган идегез... Әйтәсез дә, сүзегездә тормыйсыз бит,— дигән. Бу сүзгә каршы Нәби ага яңгыратып көлеп җибәргәч, үзе дә тыелып кала алмаган. Җитмеше тулган көннәрдә шушы мәзәкне сөйләп, беренче ишеткәндәй көлә иде Нәби ага. Картаймаган иде, кәкре башлы таягын да иптәшкә генә тотып йөри иде бит әле. Тагын сүзегездә тормадыгыз, диярга күп тә түгел, бары бер генә адым калган иде бит, сиксән яшьлеген бәйрәм иткән көннәрдә искә алырга иде шуны, юк инде, кабатлап булмый... Аның мең тапкырлар үлем белән күзгә-күз очрашкан әлдермешле рухына күңелдән генә эндәшеп була:

— Дөньяга синең көлү җитми, Нәби ага!..

* * *

Япониядә Рёандзи дип аталган ташлар бакчасы бар: табигатьнең нәзберек җанын тыңлый-ишетә белгән японнар анда килеп сәгатьләр буе уйланып утыралар икән. Дөньяның бакый серләрен йөрәгенә яшергән ташларның өнсез мәңгелегендә җанны тынычландыра торган тылсым бар, күрәсең. Төрле рәвештә унбиш таш куелган бу фәлсәфи бакчаның гаҗәеп ягы шунда: кайсы ноктага күчеп карасаң да, бары тик ундүрт кенә ташны күрәсең; унбишенчесе бүтән таш артында каплана. Минем уемча, яшәешнең бөек хикмәте салынган бу бакчага. Тормышта синең үз ноктаң, җирлегең бар. Иманлы булсаң, төрле ярга ташлана алмыйсың. Синең ноктадан ундүрт кенә таш күренә. Икенче ноктада торучының күз карашына шулай ук ундүрт кенә таш сыя. Мин син күрмәгән унбишенче ташны күрәм, син мин күрмәгән унбишенче ташны күрәсең. Димәк, икебез бергә генә дөньяны камил кабул итә алабыз.

Бердәмлек, янәшәңдәге Кеше кадере турында сөйләмиме бу бакча?

Рәхимсез үлем унбишенче таш серен шәхес белән бергә алып китә. Әмма каләм иясе, әдипнең олуг бәхете бар, таш серен ул бүтәннәргә язып калдыра ала...

## Вахит Юнысов

# «ӘС-САБРУ МИФТАХ ӘЛ-ФАРАҖ...»

Багдад урамы. Кояш рәхимсез кыздыра. Газ белән сугарылган һава тынга каба. Машина эчендә кондиционер булмаса, алла сакласын, эреп, табадагы сызыкка әйләнүең ихтимал. Нәкъ Тукай язганча:

> *«...Каты эссе. Һава бөркү.*
> *Кыза дөнья, сабыр җитми...»*

Каядыр ашыгучы меңләгән, йөз меңләгән машиналар урамны тәмам буып куйган. Мин машина эчендә шул буаның ачылганын көтеп утырам. Уйландыра. Кеше, теләгенә тизрәк ирешү өчен, ашыга бит һәм нәкъ шул ашыгу тизлекне юкка чыгара. Иң борынгы заманнарда адәм заты җәяү йөргән. Моннан берничә мең ел элек атка, ишәккә атланып йөри башлаганнар. Бүгенге көндә күп кеше машинада йөри. Әгәр шушы безнең машина туктаган Һарун әр-Рәшид урамыннан җәяүлене, җайдакны һәм машиналыны ярышка җибәрсәң, Багдадның үзәге саналган Тәхрир мәйданына алар бер чамада килеп җитәрләр иде...

Чит ил кешеләре, гарәпчә «әҗнәбиләр», эт итеп мондагы тәртипне тиргиләр. Соңга калуның төп сәбәбе — шәрыкның пошмаслыгы, дип уйлый алар. Мин гарәпләрне күзәтәм. Әнә, карагыз, алар үзләрен ничек тоталар: машинаның ачык тәрәзәсеннән башларын тыгып, шатлана-көлә хәбәрләшәләр. Күрше машина эчендәге гарәп, утыргычка ята төшеп, радио тыңлый, аның янындагысы кабинага урнаштырылган магнитофоннан моңлы тавыш белән коръән «укыта». Җирле халык арасында бер генә дә ашыккан, кабаланган, соңга калам, дип борчылган кеше күренми. Урам буйлап тезелеп киткән кәеф-сафа биналарында салмак кына әңгәмә, үзара аңлашу бара. Аларның йөзләрендә тынычлык һәм канәгатьлек.

Гарәпләр кеше җыела торган урыннарга Коръәндәге: «Аллаһы тәгалә түзем кешегә мәрхәмәтле»,— дигән сүзләрне язып элэләр. Ашыгуда мәгънә юк, фани дөнья барыбер үз агышында барачак, аны туктатып та, тизләтеп үзгәртеп тә булмый. Тизме, әкренме — тәкъдиреңә язылса, барасы җиреңә барып җитәсең, ә инде тәкъдиреңә язылмаган икән, нишлисең, язмыштан узмыш юктыр... Бар нәрсә — аллаһы тәгалә карамагында. Яшәүнең алтын кагыйдәсе — борчылма, кабаланма, маңгаең белән бушлыкны сөзмә, ышан А ң а, язмышыңны ихластан А н ы ң кулына тапшыр. Әгәр син гарәп икәнсең — бу сиңа фарыз. Әҗнәби булсаң, шушы бөек түземлекнең мәгънәсенә төшенергә тырыш, төшендең — бу инде Шәрык белән Мәшрикъның бусагасын уздың дигән сүз. Яшәүнең төп кагыйдәсе — ашыкмау, кабаланмау, сабырлык һәм түземлек: «Әс-сабру мифтах әл-фарәҗ»... Бездәге: «Сабыр төбе — сары алтын» дигән мәкальгә туры килә.

Тиз генә борылып чыгарга теләп, безнең эш белән шөгыльләнүче офиска (конторага) кердем. Урамда буылып тору аркасында соңга калыбрак килдем. Бүгенге ниятләрем тулысынча тормышка ашсын өчен, эшне тизрәк бетерү кирәк иде. Клерк Әбү Вәлид әфәнде мине елмаеп каршы алды, йомшак кәнәфидән урын күрсәтте:

— Истерыйх, мистер Юнессоф!

Бу инде «утыр» дигән сүз генә түгел. «Истерыйх»ның эчтәлегенә «ял ит», «хәл җый», хәтта «тынычлан» дигән мәгънәләр сыя. Гарәп офисында утырганда син ашыгырга тиеш түгелсең. Сөйләшүең, хәрәкәтләрең, хәтта күз карашың да салмак сабырлыкка көйләнгән булырга тиеш. Керәшеннәрнең борынгы җырлары искә төшә: «Әкрен кирәк, иплəп кирәк, ишетергә сандугач сайрауларын...» Гарәпләр белән эш иткәндә син үзеңне нәкъ шушы җыр тәкъдим иткән рәвештә тотарга тиешсең. Кинәт кенә уйлап аласың: бәлки бу җыр нәкъ Ибне Фазлан төркеменең Идел буе болгарларын сабырлыкка өндәп йөргән чакларда тугандыр?

— Чәй эчәбезме, кофемы? — дип сорый Әбү Вәлид. Карашында — җылы итәгатьлек, ихтирам һәм тәрбияле кешеләрдә генә очрый торган кайгыртучанлык.

— Юк-юк, эчәсем килми. Әле генә чәй эчеп килдем,— дим. Тизрәк йомышымны башкарырга теләгән идем, тик баш тартуның файдасы тимәде. Клерк ишекне ачып дәште:

— Фарраш!

Бу илнең иң кечкенә оешмасында да йомышка йөрүче малай — фарраш бар.

Идарәнең бер кечкенә бүлмәсендә, бу инде бәхәссез, чәй, кофе әзерләүче бер карт та булмыйча калмый.

— Шикәрсезме, шикәрне әз генә салыпмы, аллә татлырак итепме? Бәлки сезнең бераз тамак ялгап та аласыгыз килә торгандыр? — дип сорый Әбү Вәлид фаррашны көтеп торган арада.

— Әз генә шикәр салып. Чәйне мин кардамон белән эчәргә яратам,— дим, котылу мөмкинлеге юк икәнлеген аңлагач.

Чәй килгәнче, клерк сәламәтлегем, хәл-әхвәл, эшемнең барышы, гаиләм һәм кәеф турында сораша.

Монда килер алдыннан мин атна чамасы авырып яткан идем. Бу турыда сөйләргә ярамый. Бу — табу. Эшеңнең барышы турында да сөйләргә кирәкми, көлкегә калуың, үзеңнең әдәпсез, надан икәнлегеңне ачыклавың бар. Бу — очрашканда бирелә торган гадәти сораулар. Аның җаваплары да әзер. Тәрбияле кеше моны белә һәм ритуалны бозмыйча җавап кайтара:

— Әлхәмделилла, зейн, кулли зейн — Аллага шөкер, әйбәт, бик әйбәт!

Хәтта син, танышыңның берәр якыны вафат икәнен ишеткән булып, аның кайгысын уртаклашсаң да, гарәп кешесе зарланып тормаячак. «Алла кодрәте белән дөньяга килде, вә шул ук кодрәт белән аның янына күчте», дип, коръән сүзе белән генә җавап кайтарачак.

Фарраш чәй китерде. Без Әбү Вәлид белән тәмләп чәй эчәбез. Хәл-әхвәл сорашу тәмамланды. Клерк минем эшне офиста Ибне Хаддам исемле кеше алып баруы турында белешмә бирде һәм йомышчы малайны шуны чакырырга җибәрде.

Берничә минуттан йомышчы әйләнеп кайтты:

— Ибне Хаддам абыйсының җеназасына, Нәҗәф шәһәренә киткән. Бәлки иртәгә кайтыр,— диде.

Мин шундук абайлап алдым: Ибне Хаддам, дине ягыннан — шигый (шәһид). Хәллерәк шигыйлар якын кешеләрен хәзрәте Галинең кабере урнашкан Нәҗәф шәһәре тирәсендәге зиратларга җирләргә тырышалар. Әбү Вәлид мине озата чыкты:

— Иртәгә Ибне Хаддам офиста булыр, иртәгә килегез, алла боерса, иртәгә барын да эшләрбез,— диде.

Иртәгесен тагын киләм. Ибне Хаддам әле кайтмаган. Кем инде Нәҗәф дәрәҗәсендәге изге шәһәргә барып, тәүлек эчендә әйләнеп кайтсын!? Шигыйларның иң зур, искиткеч бай һәм матур мәчетенә кереп, хәзрәте Галинең көмеш челтәрле каберенә зиярат кылмыйча, коръән укытып, садака өләшмичә, гарип-горабаны сыйламыйча, мөмкин булганда, мәрхүмнең җидесен дә үткәрмичә кайтсын!?

— Ибне Хаддам кайчан Багдадка кайта? — дип сорыйм.

— Бачыр.

Тагын — «бачыр»... Бу «бачыр» инде ун көн кабатланып килә. Ибне Хаддамның эш телефонын язып алам да һәр көн офиска чылтыратырга тотынам. Ниһаять, Ибне Хаддам Нәҗәфтән кайткан, урынында утыра.

— Иртәгә килегез, сезнең мәсьәләне хәл итәрбез,— диде ул. Димәк, тагын — «бачыр».

Иртәгәсе көнне Ибне Хаддам мине елмаеп каршы ала. Йомышчыны чәй алырга җибәрә һәм аны көткән арада рәсми документның караламасын әйбәтләп яза да йомышчы аша машинкада суктырырга җибәрә. Чәй янында Ибне Хаддам Кэмбриджда укыган вакытындагы кызыклы вакыйгаларны, балаларының мавыгуларын, халык-ара хәлләрне, Багдад тарихы турында сөйли.

Ниһаять, документны әзерләп китерәләр. Ибне Хаддам аны Вавилон патшасы Хаммурапи кыяфәтендә, башын артка ташлый төшеп, зур горурлык белән укып чыга. Чыннан да, эш кәгазе әйбәт язылган.

— Зейн, кулли зейн,— ди ул.— Хәзер мөдир кул куя да — эш бетә. Зинһар бер генә минут көтегез. Дәкыйка!

«Дәкыйка» — бер генә минут — гарәпләрнең иң яраткан сүзе. Әйтик, кибеткә чалбар карарга кердең. Син теләгән чалбар юк.

— Дәкыйка,— ди дә кибет хуҗасы юкка чыга. Син берүзең каласың. Синең карамакта миллион динарлык товар. Чыгып китәргә җыенганда хуҗа пәйда була. Кулында син сораган чалбар. Дөресен әйткәндә, син ул чалбарны, хакын белер өчен, кызыксынып кына сораган идең. Котылу өчен син башка төстә, башка фасонда һәм башка зурлыктагы чалбар кирәк икәнлеген белгертәсең.

— Дәкыйка,— сәүдәгәр юкка чыга да тагын бер ун-унбиш минуттан нәкъ син сораган чалбар белән әйләнеп керә. Җиңә бу сине, валлаһи! Тукай аның җиңәсен белгән:

*Шулай булгач, ничек алмый түзәрмен?*
*Алам мин: бәлки рәхәттә йөзәрмен...*

«Дәкыйка» сүзенең семантик мәгънәсен белгәнгә күрә, Ибне Хаддамның ярты сәгать югалып торуына аптырамыйм мин. «Бер генә минут»ның сәгатькә, көнгә, атнага сузылуы мөмкин. «Хак тәгалә ни кылса да ирке бар...»

— Мистер Юнессоф, гафу итегез, мөдир ял алып, Равандуз курортына киткән, имза куйдырта алмадым.

— Ә ул кайчан кайта? Аның урынбасары гына кул куя алмыймыни?

— Мөдир, алла боерса, бер айдан кайта. Аның урынбасары кичә өч көнгә Дивания каласына командировкага киткән.

Эчемнән генә монда үзләштергән доганы укыйм: «Тыныч бул, кабаланма, борчылма. Сабырлык — бәхет ачкычы...»

— Борчылмагыз, мистер Юнессоф, урынбасар командировкадан кайткач, кул куйдыртып документны сезгә йомышчы белән җибәрермен,— ди Ибне Хаддам.

Бу инде «бачыр» түгел, «бәгыд бачыр» — ышанмаска хакым юк.

Шушы тәҗрибәләрдән чыгып, бер ачыш ясыйм: бюрократизм — интернациональ көч, ул кайда да очрый. Бездәге бюрократизм белән чагыштырганда, шәрык бюрократизмы кешелеклерәк, ул көләч йөзле, хәтта, үзенчә, сине кызгана да белә. Бездә булса, Ибне Хаддамның женазага китүен: «Аны өлкәгә киңәшмәгә чакырдылар»,— дип белгертерләр иде һәм синең белән, бу инде кемгә дә билгеле, тәкәббер, тупас сөйләшерләр иде.

Мин инде икенче тапкыр Гыйрак илендә яшим. Иртән торып эшкә китәм, кайтып ял итәм. Күзәтәм, чагыштырам. Гарәпләрнең яшәү ысулларын, шәрык кешесенә генә хас психологияне аңларга тырышам. Коры кызыксыну түгел бу. Гарәпләр аша мин үземнең ата-бабаларымны аңларга, Иван Грозный чорында колгә әйләндерелгән тарихи чынбарлыкны ачыкларга тырышам.

Алтмышынчы еллар башында мин бу илдә дүрт ел яшәп кайткан идем инде. Шул чакта мин Гыйракның тарихын өйрәндем, гарәп авторларын укыдым, этнографик белешмәләрне үзләштердем. Туган илемә әйләнеп кайткач, гарәпләрне беләм, аларның үзенчәлекләренә төшендем, дип бик озак ышанып йөрдем мин. Хәзер аңлыйм, ул чакта мин бу илгә Европа кешесе күзлегеннән караганмын, шунлыктан бөтенләй башкача күргәнмен. Тагын күзәтәм, тагын аңларга тырышам — күз алдымда бөтенләй башка ил, бөтенләй башка төрле халык һәм гаҗәеп үзенчәлекле, сәер чынбарлык.

Дөрес, Гыйрак белән Иран арасында тугыз ел канлы сугыш барды. Сугыш ил өзендә ямьсез җыерчыклар, кешеләрнең язмышларында канлы җәрәхәтләр калдыра. Мондагы үзгәрешләрдә сугышның да өлеше зур, ләкин үзгәлекнең иң зурысы минем бу юлы культ һәм торгынлык доньясыннан түгел, яңартып кору, хәбәрдарлык иленнән килүем аркасында, тоела.

«Россию умом не понять, ее аршином не измерить, у нее особая стать, в Россию можно только верить»,— дигән күренекле рус шагыйре. Һәм без, рус арасында яшәүче татарлар, русча белем алып, шушы фикерне аксиомага санап йөрдек. Уйлап карасаң, бер генә илне дә һәм шул илләрдә яшәүче халыкларны да үз аршының белән үлчәп булмый. Бигрәк тә Шәрыкта яшәүче халыкларны, аларның гореф-гадәтләрен.

Гарәпләр бары тик шәрыкка гына хас салмак, әкертен ритмда яшиләр. Ничек бәяләргә бу тоташ пошмаслыкны? Безгә, социалистик ярыш ритмында, план куу шартларында тәрбияләнгән совет кешеләренә, гарәпләрнең ашыкмавы гафу ителмәслек кимчелек тоела. Әмма... аллага шөкер, гарәпләрдә егерменче гасырның куркыныч хастасы — стресс күренми. Бәлки безнең ерак бабаларыбыз ашыгыч эшнең нинди нәтиҗә тудыруын яхшы белгәннәрдер? Бәлки алар ашыгып, абаланып яшәүнең стресска дучар итүен дә аңлаганнардыр? «Әкрен кирәк, иплән кирәк...» шикелле үгетләр керәшеннәр җырында гына түгел бит, халкымның мәкаль һәм әйтемнәрендә андый үгетләр — меңләгән.

Культ һәм торгынлык елларында «давай-давай» камчысы белән куылып, күзләребезне акайтып йөгергәндә нихәтле күркәм гореф-гадәтләребезне аяк астына ыргытып, таптап киттек. Шулар арасында иң аянычлысы — халкыбызның милли педагогикасы, күп гасырлар буе камилләштерелгән гаилә кануннары һәм дин тәрбияләгән әхлак кагыйдәләре. Телебез турында фикер йөртергә дә куркам мин. Бу афәт, аңлаган кешегә, милләт өчен — үлем хөкеменә тигез.

Минем эш урыныма яшь гарәп клеркы Хөсәен әфәнде килеп йөри. Англиядә укып кайткан. Кесәсендә — Оксфорд дипломы. Инглизчә, французча акцентсыз сөйләшә, төрекчә дә шактый шома сукалый. Аның белән татарча сөйләшеп җанга рәхәтлек табабыз. Хөсәен әфәнде европача киенгән. Мәдәниятле. Аз сүзле. Өздереп эшли. Биш-алты елдан киң колачлы бизнесмен булачак. Шул ук Хөсәенне мин искечә яшәүче кадимчеләр арасында күрәм. Монда ул алардан бер генә сыйфаты белән дә аерылмый диярлек. Ул нәкъ картлар шикелле озак итеп амин тота, ва-

карь белән генә сөйләшә һәм шәригать кануннарын үти. Без, татарлар, әгәр башкаланың берәр дәрәҗәле югары уку йортын тәмамлый алсак, алла сакласын, татарча сөйләшәбезме соң инде яки ата-бабадан калган гореф-гадәткә тугрылык күрсәтәбезме — мәңге күрмәссең!

Белмим, каян барлыкка килгән икән: чит ил кешесе алдында без түбәнчелек белән баш иябез. Хәтта руслар янында да без, ихтыярый рәвештә, үзебезне икенче сортка куеп эш итәбез. Гарәпләрнең «әҗнәби»ләргә карашлары үзгә. Гарәпләр чит ил кешеләренә нәкъ бала-чагага караган шикелле карыйлар. Нишлисең, ул бит «әҗнәби», аны аллаһы тәгалә башка төрле итеп яраткан... Һәм мин шуны күрәм: шәхесара мөнәсәбәткә гарәпләр изге карыйлар. Бәлки шунлыктандыр, гарәп белән элемтәгә кереп, уртак тел таба алмасаң, аның белән эш итүе, белеп тор, җиңел булмаячак.

Галәмнең сурәте, безнең күңелгә төшерелеп куелган. Без, шул күңелдәге сурәтне чынбарлык белән чагыштырып, бәхет кыйбласына таба барабыз. Әгәр чынбарлык шул эчке сурәткә тәңгәл килсә, яшәү рәхәт, дөнья тигез тоела. Инде чынбарлык белән эчке сурәт бер-берсеннән үзгә икән, яшәү михнәткә әйләнә. Күңелдәге галәм сурәте белән чынбарлык арасында берниндн дә уртак нокта калмаган очракта адәм баласы акылыннан язарга мөмкин.

Гарәпләрнең күңелендәге галәм сурәте безнекеннән үзгә. Алардагы сурәт киңрәк тә, баерак та. Без бит бары тик бу дөньяны гына истә тотабыз. Фани дөнья гарәпләр өчен галәмнең бары тик бер өлеше генә, калганы — Газраил белән очрашып, сөаль алудан узганнан соң башланачак «теге дөнья». Бу дөньяга без әзгә генә килгәнбез, нигә соң ыгы-зыгыга бирелеп, нәфесне тыймыйча, ашыгып, кабаланып михнәт чигәргә? Киләчәктә, урыным җәннәттә булган очракта, әле күпме рәхәтлекләр күрәсем бар!.. Яшәү — мәңгелек. Аллаһы тәгалә боерган булса, барысына да өлгерербез. Бу тормыш бары тик бакый дөньяга әзерләнү генә... Гарәпләрнең күпчелеге шушы фәлсәфә нигезендә яши.

Алар арасында атеистны очратканым юк минем. Эшнең иң кызган чагында гарәп, туктап, тәһарәт ала башлый. Битен, терсәкләреннән башлап кулын, бармак очларына кадәр аякларын юа. Пакьләнә. Тирә-юньдә миңа кагылырлык пычраклык юкмы? Аллага шөкер, тирә-юнь саф, тыныч. Гарәп кыйблага каратып намазлык җәя, аяк киемен сала, намазлыкка баса. Шушы мизгел белән намазның эчтәлеге арасында коръән телендә «ния» аталган бер мәл бар. Ния вакытында намазчы күңелен, дикъкатен тирә-юньнән, гомумән, чынбарлыктан аерып, бөеклеккә, безнеңчә әйткәндә, гомуми абстракциягә юнәлтергә тиеш. «Ния», башкача аңлатсак — күңел түрендәге тынычлыкка ирешү дигән сүз. Кайгы-хәсрәтләреңне сызып ташладың, борчылуларың юкка чыкты, хәзер синә дөнья ыгы-зыгысы тәэсир итә алмый. Шушы мөмкинлеккә ирешкәч намаз укучы:

— Йа алла, ният кылдым өйлә намазының дүрт рәкәгать сөннәтенә, юнәлдем кыйбла тарафына, колу сән аллаһы тәгалә!— дип башлап китә.

Намаз укучының куллары колакларына кадәр күтәрелә:

— Аллаһы әкбәр...

Сул кул уң кул белән тоташты. Намаз укучы учлары белән тезләренә таянды, тагын торып басты, кулларын күтәреп, тантаналы төстә, коръән сүзләрен кабатларга керешге:

— Аллаһы тәгалә үзен олылаганны ишетә...

Тагын тәкъбир әйтү. Тагын тезләнү, ниһаять, намаз укучы учлары белән намазлыкка таянып, маңгаен җиргә тигезде һәм сәҗдәгә китте.

Намаз укып утыручыларны мин көн саен күреп йөрим. Әйтерсең, мин чит илгә килмәгәнмен, үземнең ерак бабаларым арасында яши башлаганмын. Кайвакыт балачак хатирәләре җанланып китә. Культ заманы, торгынлык чоры искә төшә. Ул чорларда безнең күңелләргә күпме рәнҗеш, күпме җәбер җыелды. Шул сүзләрне җыелышта әйтсәң, «козгын»га утыртып туры сөргенгә озатачаклар. Сер сыйган кешегә дә әйтеп булмый, аның үз эченә җыелганы да җитәрлек. Бердәнбер юл — кибет артындагы ташландык әрҗә өстенә «ак чалмалы»ны утыртып, эчкә җыелганнарны шул агу белән яндыру. Мәскәүдәге квартирым янында кибет артына җыелучы «алкашлар» исемә төшә. Җөмлә саен кабахәт сүз. Тешләр шыгырдый, аларның ыңгырашулары: «Ты меня уважаешь?..»

Урта Азиягә командировкага баргач, мин үзбәкләрдән сорашгырып йөрдем:

— Бу төбәкләрдә аракыны кемнәр ярата?

— Руслар һәм татарлар,— булды җавап.

Шәрыкта безнең татар үзен бүтәнчә тота башлый. Бу кыланыш — үзенә күрә, мин сездән алдынгырак, күрәсезме, минем «олы туган»нардан бер җирем дә ким түгел, дип масаю галәмәте.

Бер газаплы сорауга җавап таба алмый интегәм мин. Халкымның исламны кабул итүенә бер мең бер йөз ел тулып узды. Революциядән соңгы җитмеш ике елны алып ташласак, безнең ата-бабаларыбыз мәдрәсәләрдә бер мең егерме сигез ел гарәпчә укып йөргәннәр. Шушы озын вакыт эчендә алар ни сәбәпле туган телне онытып, гарәпчәгә күчмәгәннәр? Русча уку бары тик сугыштан соңгы елларда гына башланды бит. Илле ел да юк. Нилектән шушы кыска гына вакыт эчендә туган телебезне харап иттек? Тел югалту — сөйләшү коралын югалту гына түгел бит ул. Телдә милләтнең тарихи язмышы, мең еллар дәвамында тупланган яшәү рәвеше һәм рухи җаны. Әйтегез, тел катастрофасының сәбәбе нәрсәдә?

Тукаебызның:

*Куп яттык без мәдрәсәдә,*
*Аңламадык бер нәрсәдә,*
*Селкенмәдек таш төсле без,*
*Җилбер-җилбер җил бәрсә дә...—*

дигән сатирик юлларын аксиома урынына кулланып, дини мәдрәсәдә уку бернинди гыйлем бирмәгән, дип ышанып йөрдек. Европаның иң күренекле ориенталистлары Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗанигә баш игән. Казан университетының Шәрык разряды Мәрҗанинең белемен фәнни китапханә урынына кулланган. Каюм Насыйри, Риза Фәхертдинев, Хөсәен Фәезханов, Исмәгыйль Гаспринский кайда укыган? Гаҗәп, дипломлылар күбәйгән саен белемлеләр, мөстәкыйль фикер йөртә алучылар азая бара икән. Бу серне безгә КПСС Үзәк Комитеты чыгарган карар чиште. Культ һәм торгынлык елларында белем алу урынына диплом алуга күчтеләр. Культ чынбарлыгы, торгынлык өчен иң кыйммәтле кеше — робот рәвешендә боерык үтәүче манкорт иде, шунлыктан, белемсезләрнең, фикер йөртә белмәүчеләрнең базарлары күтәрелде. Артта калган чорның укыту методикасы сәләтсез укучыны кеше итүгә көйләнгән иде. Торгынлык елларында күпме талант, күпме сәләтле кеше исраф ителде. Халыкның рухи байлыгы тапталу, юкка чыгарылуы турында сөйләп тә торасы юк. Ул елларда безнең әдәбият, сәнгать һәм рухи мәдәният тәхеттәге ваграк татар брежневлары кулында иде. Алар талант иләрен, бүре куган шикелле, облавалар ясап әзәрлекләделәр.

Гыйрак чынбарлыгына кайтыйк. Бу илдә педагогика фәненең соңгы казанышларына таянып эшләүче колледжлар бар. Алардан тыш урта гасырлардан соң бер тамчы диярлек үзгәрмәгән кадими мәдрәсәләр дә әле һаман яши бирә. Бу мәдрәсәләрдә белем алу нәкъ Әбүгалисинә, Кол Галиләр чорындагыча алып барыла. Укыту программасы юк. Хәлфәдән план һәм методика таләп итеп, аның канына тоз салмыйлар. Хәтта билге кую, өлгерешне тикшерү дә юк мондый мәдрәсәләрдә. Мөдәррис класска керә, исәнләшә, бисмилласын әйтеп, тема игълан итә. Дәрес баштан азакка кадәр бәхәсләшү, ярышу, фикер алышу ысулында бара. Талантлы шәкертләр — дискуссиянең үзәгендә. Наданлыкны алга куйган сәләтсезләр — читтә. Талантлы шәкертләрнең иң тырышлары мөдәррисне җиңә башлый. Ул алардан котылу юлын эзли — талантлы шәкертне югарырак сыйныфка күчерә. Шул «селкенмәс таш төсле» яткан шәкертләр арасында җиде-сигез ел эчендә югары белемгә ирешкән шәкертләр очрый. Искәреп үтик: кадими шартларда энциклопедик белемгә ирешү өчен Шиһабетдин Мәрҗанигә — унбер ел, Ибне Синага аннан да кыскарак вакыт җиткән.

Гыйракта архаик мәдрәсәләрдән тыш халык педагогикасы да көчле роль уйный. Яшь буынга тәрбия бирү, аны әдәпкә утырту — җәмгыять карамагында. Тәрбия эше белән җәмгыять махсус шөгыльләнми. Җәмгыять, күз карасы шикелле итеп, гореф-гадәтне саклый. Гореф-гадәт — адәм баласына туган мизгеленнән алып гүргә кергәнче иң кирәкле, иң ышанычлы таяныч.

Без, фәнни атеизмны өйрәнгәндә, наданлык бетү белән дин юкка чыгачак, дип, бер-беребезне ышандыра идек. Бу турыда күпме диссертация язылды, күпме китап басылды. Европа, Америка һәм Япония университетларында укып белем алган гарәпләрне күзәтәм. Алар — биш вакыт намазларын калдырмаучы фанатиклар түгел. Алар арасында ураза тотучылар, хаҗ кылучылар да сирәк очрый. Әмма шундый европача әзерлекле интеллигент алдында ислам диненә тел тигереп кара әле! Алар ислам динен әхлак күзлегеннән чыгып яклыйлар. Аларның фикеренчә, әхлак кагыйдәләре — бүлгәләнми торган берәмлек. Иманлы кеше дин өлкәсендә генә түгел, үз-үзен тотышында да, гомумән, иманлы. Андый кеше игелекне, мин — сиңа, син — миңа, дип түгел, җаны теләгәнгә, күңеле хушлансын өчен эшли. Дини әхлак кагыйдәләре, кешелек дөньясы мең еллар буе туплаган тәҗрибәдән алынып, шәригатькә теркәлгән. Шәригать кануннары исә кешенең бөтен яшәешен урап алган. Дини әхлак кагыйдәләре урлашу, җәбер, ялган сөйләү, гайбәт, зина кылу, икейөзлелек, ял-

каулык һәм, гомумән, җәмгыятькә, кешеләргә авырлык китерә торган күп сыйфатларны гөнаһ саный. «Җавап бирегез әле, мистер Юнессоф, сездәге коммунизм төзүчеләрнең әхлак кодексында бу сыйфатлар ничек бәяләнә? Кешегә игелек эшләү, ярдәмчеллек, кешелеклелек, миһербанлык, хакыйкать сөю, намус, пакъ яшәү, тыйнаклык кебек сыйфатлар безгә савап санала. Сездә бу сыйфатларга нинди бәя бирәләр?...»

Кайчакта безнең бәхәсләр тирәнгәрәк тә кереп китә. Оппонентларым Европа һәм Америка галимнәренә мөрәҗәгать итә. Гарәп мөселманнарының иң яраткан галимнәре — инглиз тарихчысы һәм социологы Арнольд Джозеф Тойнби. Дөнья күләмендә күренекле бу галим бүгенге капиталистик системаның эчке каршылыкларын, Көнбатыш белән «өченче дөнья илләре» арасындагы конфликтны бары тик рухи яңару, меркантиль фәлсәфәдән ваз кичү һәм байлыкка табынудан туктау юлы белән генә хәл итеп була, дип раслый. Киләчәкне куркынычта тотучы кризис — кешенең комсызлыгы нәтиҗәсе,— ди ул «Тарихны тикшерү» исемле хезмәтендә.— Ислам азга канәгать булырга, аскетлыкка өнди, кирәгеннән артыкны алмаска өйрәтә. Әгәр дә дөньяда яшәүче барлык халыклар ислам динен тоткан булса, кешелек дөньясы экологик кризиста калмас иде. Гарәп зыялылары бу галимнең фәнни эшләрен яттан диярлек белә. «Безнең Коръәнгә таянып язган»,— дип куаналар. Бездәге яңартып кору, хәбәрдарлык хәрәкәтен Гыйрак гарәпләре кызыксынып күзәтә. Мин монда безнең илдә укыган белгечләрне дә еш очратам. Алары бездәге үзгәрешләргә бигрәк тә куана.

Туган илдән килгән газета-журналларны түземсезлек белән көтеп алабыз. Көндәлек матбугат битләрендә плюрализм сүзе еш кулланыла башлады.

Яңартып кору, хәбәрдарлык татар халкының тарихын гадел иттереп язу мөмкинлеген ачты. Шул тарихны язар өчен гарәп илләрендә сакланган борынгы кулъязмаларны барлау, халкымның язмышына кагылган чыганакларны өйрәнү вакыты житте. Без гарәпләр белән аралашырга, турыдан-туры элемтәгә керергә тиешбез дип уйлыйм. Андый аралашу ике якка да файдалы һәм отышлы булыр иде.

Патша хөкүмәте чорында да, революциядән соң канлы утызынчы елларга кадәр дә шәрык белән элемтә тотуда татарлар зур һәм файдалы эш алып бардылар. Яңартып кору чорында шул тәҗрибәгә кире әйләнеп кайтырлар, дип уйлыйм мин. Казан университетында татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты ачылу бу мәсьәләне хәл итүдә зур роль уйнаячак.

Кыскасы, автономияле республикаларның хокуклары һәм мөмкинлекләре киңәюенә шигем юк минем. Шул уңайдан әйтәм: туган республикамның гарәп илләре белән элемтәсе дә, һичшиксез, киңәячәк һәм бик күп уртак предприятиеләр барлыкка киләчәк. Уртак предприятие ачу мөмкинлекләре тугач, ни сәбәптер, безнең эш кешеләре Европа һәм Америка бизнесменнары белән элемтәгә керә башладылар. Бу омтылышлар күп очракта уңышсызлыкка китерә. Гарәп илләрендә Европа белән уртак предприятиеләр кору буенча гаҗәп бай тәҗрибә тупланган. Ул тәҗрибә белән танышу безгә хисапсыз зур файда китерер иде. Һәм мин бу эшне безнең Татарстан экономистлары, инженерлары, яңа формалашып килгән менеджерлары хәл итәр дип ышанам.

*1989 елның июле, Насирия шәһәре.*
*Гыйрак.*

# ТУКАЙЛАР РУХЫ

## НУРИХАН ФӘТТАХ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ



— *Нурихан ага, бүгенге заман турында кайбер фикерләрегез белән уртаклашмассыз микән? Сезне бүген niләр борчый, niләр куандыра?*

— Иң борчыганы — тел, милләт, культура. Күңелен мүк басмаган татар өчен бүген шулардан да зуррак кайгы-борчу булырга мөмкин дә түгел. Тормышта бүген куанычлар да бар, әлбәттә. Бөтен илдә кузгалыш, хәрәкәт бара. Дөнья кайный, дөнья гөж килә. Элеккечә һәр үзгәрешкә куркып, шикләнеп карау юк. Күңел сизенә — бу үзгәрешләр, барыбер, безнең файдага — җәберләнгәннәр файдасына булыр!

— *Тукай сүзләрен бүгенге көнгә карата куллансак, нинди җавап алырбыз икән: татар халкы үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?*

— Үлмәгән дә, йокламаган да — мәсхәрә ителгән, имгәтелгән, миңгерәүләтелгән. Аның күзен ачасы, рухын канатландырасы бар.

— *Безнең тормышның, яшәвебезнең күп яктан рәте киткән. Аны каян, нәрсәдән башлап рәткә китерергә? Бу хакта сез ничегрәк уйлыйсыз?*

— «Безнең» дигәнне бөтен ил турында әйтелгән дип уйласак, «кемнәр дөньяның астын өскә китергән булса, шулар төзәтсен бозылганны» дип әйтер идем, тик менә аларның төзәтәселәре килми. Бит алар, «марксизм-ленинизм теорияләренә нигезләнеп», бәхетле тормыш төзеделәр. Безнең өчен түгел, үзләре өчен... «Без»не татар дип, Татарстан дип уйласак, «бөтен илне рәткә китермичә торып, татар тормышын гына рәткә китереп булмаячак» дип әйтергә туры килә. Бит безнең бар яктан да аяк-кулларыбыз богауда, рухыбыз читлектә. Богауларны өзәргә, читлекне ватарга кирәк. Бөтен ил белән, барлык демократик, прогрессив көчләр белән бергәләп.

— *Соңгы елларда язучы белән власть вәкилләре арасындагы мөнәсәбәттә берәр төрле үзгәреш сизәсезме? Сезнеңчә ул мөнәсәбәт ничек булырга тиеш?*

— Татарстандагы власть вәкилләре тарафыннан миңа карата беркайчан якты йөз, ягымлы сүз булмады. Мине алар язучы дип тә, гомумән кеше дип тә исәпләмәделәр. Кырык яшькә кадәр мин яшь язучылар рәтендә йөрдем, кырык яшьтән соң «һ. б.»ләр рәтенә кердем. Рәсми мәкаләләрдә минем исем дә, минем әсәрләр дә телгә алынмады. Шул ук вакытта минем кем белән очрашуым, кайда нәрсә сөйләвем, кайчан ашавым-эчүем, кайчан тышка чыгуым — барысы да «Черек күл»гә билгеле булып торды. Үз өемдә, үз илемдә мин ирекле тоткындай яшәдем. Бүген инде заманалар башка. «Ләкин» дип әйтергә туры килә, зур ишекле, зур өстәлле кабинетларда, йомшак креслоларда һаман шул ук кичәге кешеләр утыра. Милләткә кабер казыган, безнең телне, динне, культураны юкка чыгаручыларга, безнең җанны, милли хисне, вөҗданны-намусны талаучыларга тырышып-тырышып хезмәт күрсәткән, Иблиснең канлы итеген ялаган кешеләр утыра. Тиешле урында алар инде башкача, заманча сөйлиләр. Ләкин — күзләре бездә, колаклары — Мәскәү ягында. Кылган гамәлләре искечә. Мондый власть вәкилләренә карата мөнәсәбәт нинди булырга мөмкин? Әлбәттә, искечә, ягъни — кабереңякын булмасын!

— *Бүгенге тормышта, әдәбиятта Тукайны күз алдына китерә аласызмы? Тукай исән булса, бүген ничек яшәр иде, нәрсәләр өчен көрәшер иде дип уйлыйсыз?*

— Тукай берничек тә бүгенге көнгә кадәр яши алмаган булыр иде. Тукай 1913 елда үлмичә, «коммунизм кырына» аяк баскан булса, аны инде күптән «Черек күл»нең сасы базларында черетеп юкка чыгарган булырлар иде. Бүген, яңарыш чорында без бу хакта аннан-моннан ишетеп белер идек тә, балаларча куанып: «Исхакыйлар заманында бездә Тукай дигән шагыйрь дә булган!» дип сөйләнер идек. Уфадагы берәр патриот киресенчә: «Тукай фашистлар агенты булган ул» дип исбатларга тырышыр иде.

— *Кайбер язучыларның ил һәм дөнья мәйданына чыгарга ашкынуларына ничек карыйсыз?*

— Минем моңа бер дә исем китми. Теләгән кеше теләсә нинди мәйданга ашкынсын. Без болай да йомылып беткән, түбәләнгән халык. Ил күләмендә, дөнья күләмендә безнең милләттәшләрнең исеме яңгырый икән, безгә аннан зыян юк. Тик менә нәрсә белән чыгасың да, ни өчен чыгасың — бөтен хикмәт шунда. Әгәр үз өеңдә прозаик, тәнкыйтьче буларак танылмый торып, төрле юл белән Мәскәү басмаларында ялтырарга ашкынасың икән, яисә татарча укып булмаслык дәрәҗәдәге бөек әсәреңне Мәскәүдә түгел, хәтта Чехословакиядә тәрҗемә иттерә аласың икән, мондый данның, мондый «мәйдан»ның милләт өчен сукыр бер тиенгә дә кирәге юк.

— *Соңгы елларда татар әдәбиятына килгән яшьләр арасыннан кемнәрне игътибарга лаек дип әйтер идегез?*

— Бик авырлык белән булса да, татар матбугаты да үзгәрә, төрләнә башлады. Һәр басмада диярлек яңа исемнәр күренеп кала. Һәр әсәрдә яңа фикер, яңа рух сизелә. Шулай да бу күбрәк шигърияткә кагыла. Прозада әлегә күзгә ташланырлык үзгәрешләр юк. Шигъриятта, минемчә, яшь шагыйрь Зөлфәт Хәкимне «әнә ул!» дип әйтергә була. Дөрес, исемнәре яңа түгел — бездә инде Зөлфәт бар, Хәким булды. Шигырьләре исә — яңа, саф. Зөлфәт Хәким композитор да икән. Композиторлыгы ничегрәктер, әйтә алмыйм. Ләкин «Казан утлары»ның быелгы беренче санында басылган шигырьләренең һәркайсы — үзе бер җыр, үзе бер симфония. Мин яшь Зөлфәтнең килмәктә генә түгел, хәзердән үк олы Зөлфәтне дә, карт Хәкимне дә узып китүен теләр идем. Адашына фатиха биргән Зөлфәтнең моңа эче пошмас дип уйлыйм. Мин әле яшьләр белән ярыша алам дип, бәлки, тагын да усалрак, тагын да активрак яза башлар. Карт Хәким моңа бары сөенер генә дип фараз кылыйк.

— *Иң яраткан язучыгыз кем һәм ни өчен ул?*

— Яраткан, якын иткән язучым бер генә түгел. Аларның барысының да исемен атауның кирәге юк. Шулай да арадан берничәсен төртеп күрсәтсәм, башкаларның хәтере калмас дип уйлыйм. Өлкән буыннан — Әмирхан Еники, кордашлардан — Миргазиян Юныс, энекәшләрдән — Батулла белән Тәүфикъ Әйди. Боларның һәркайсының үзенә хас холкы-фигыле, уңай һәм кире яклары бар. Иҗатлары да төрлечә. Ләкин аларның барысын да берләштерә торган уртак сыйфатлар бар. Ул да булса, батырлык, иман, талант. Болар белән киңәшергә дә, серләшергә дә була, боларга шулай ук ышанырга да була. Болар сине сатмаячак, башыңа басып, аяк чалып, югары да үрләмәячәк. «Мин — утыз өч пьеса авторы! Мин — бөек язучы!» дип, теләсә кайда шапырынып та йөрмәячәк.

— *Бүгенге көндә кайбер язучыларның төрле юллар белән җитәкче булырга омтылуларына сез ничек карыйсыз?*

— Язучы өчен иң зур бәхет, иң зур мәртәбә — язучы булу. Әгәр дә мәгәр язучы дигән кеше, үзенең язучылыгыннан гына канәгать булмыйча, ниндидер җитәкчелеккә омтыла икән, димәк ул безнең арага ялгыш кына килеп кергән. Җитәкче буласы килә икән, булсын әйдә. Татар түрәләре арасында да татарча укый-яза белүчеләр булырга тиештер лабаса!

— *Иҗат юлыгызның башында сезнең остазыгыз кем булды?*

— Иҗат юлының башын хәтерләмим. Мин, ахрысы, ана карынында ук телгә, сүзгә, милләтемә гашыйк булганмындыр. Дөньяга тугач Тормыш дигән бөек остаз матурлыкны күрергә — шигырь, хикәя язарга өйрәткән. Бит дөнья шундый матур — монда беркем сугышырга, бер-берсенең канын коярга түгел, киресенчә, бары шигырь-хикәяләр генә язарга, бер-берсенә мәдхия генә җырларга тиеш иде кебек.

— *Кырым татарлары белән кардәшлек мәсьәләсенә ничек карыйсыз? Аларга карата мөнәсәбәтегез ничек?*

— Кырым татарлары — безнең туганнар, кан-кардәшләр. Авырлык килгәндә туганнар бер-берсенә ярдәм итә. Моңарчы без кырым татарларына ярдәм итә алмадык. Ничек ярдәм итәсең — безне бит сарык көтүләре кебек аерым-аерым бүлеп алып тукмадылар. Бүлгәләү, буташтыру, ахыр чиктә юкка чыгару — төп максат шул булды. Хәзер инде болай булмас кебек. Һич югы сүздә шулай. Сүздән файдалана белергә һәм үзебездән дә ныграк кыерсытылган туганнарыбызга кулдан килгән кадәр ярдәм итәргә

кирәк дип исәплим.

*— Татар халкы тарихын гыйльми өйрәнү торышыннан сез канәгатьме? Бу өлкәдә нинди мөһим бурычлар тора?*

— Татар тарихын өйрәнү күптән башланган. Татар тарихы хакында күп бәхәсләр булган, күп хезмәтләр язылган. Ләкин аларның барысы да диярлек берьяклы һәм өтек-көтек. Безнең тарих җиңүче халык күзлегеннән, хаким халык мәнфәгатьләреннән чыгып, аның максатларын күз алдында тотып аңлатылган. Әле дә ул шулай булып кала бирә. Татар тарихын өйрәнүче бурычлар — тау кадәр. Бүгенге көндә безнең тарихның бары Болгар чоры гына әзме-күпме өйрәнелә. Бу эштә үз галимнәребез алда баралар. Болгар чорыннан соң бөтенләй диярлек кузгатылмаган Казан ханлыгы чоры, колониаль чор, тагын әллә нинди чорлар бар. Болгарга кадәрге заманнарда йөз еллар белән түгел, меңәр еллар белән исәпләнә торган борынгы чорлар тезелеп китә. Бүгенге көндә безнең татар тарихы белән шөгыльләнә торган бер-ике кафедрабыз, бер-ике бүлегебез, унлап докторларыбыз-кандидатларыбыз бар. Безнең тарихның таудай өелгән, таштай каткан катламнарын актарып тикшерү һәм аңлату өчен бер-ике кафедра, бер-ике бүлек һәм унлап галим түгел, бәлки унлап институт һәм меңләгән, ун меңләгән галимнәр кирәк булыр иде.

*— Хәзерге әсәрләрнең сәнгать ягы сезне канәгатьләндерәме? Канәгатьләндермәсә, ни өчен?*

— Бүгенге татар прозасының сыйфат дәрәҗәсе бик түбән. Күпчелек прозаиклар әдәбиятта сөйләү методы белән күрсәтү методының нидән гыйбарәт икәнлеген дә аера алмыйлар. Безнең күп авторлар озын итеп, күңелсез итеп берәр актуаль темага мәкалә язалар да, шуны хикәя, повесть, роман дип атыйлар. Мин яшь чакта шундый мәкалә язучылар кинәт кенә үсеп киттеләр, данга, шөһрәткә ирештеләр, җитәкче булдылар һәм турыдан-туры әдәбиятның үсешенә йогынты ясый башладылар. Андыйлар хәзер күп. Алар бер-берсен мактыйлар, бер-берсен яклыйлар һәм берсе икенчесе турында: Пастернак та Дудинцев дип кенә җибәрәләр. Драматургиядә алар — Островский да Чехов. Хәтта Шекспир, Толстой, Достоевский булудан да баш тартмаячаклар — шулай дип атаучылар гына булсын. Яшьләр күбрәк менә шундый атаклылардан өйрәнде һәм өйрәнә, шулар тирәсенә елыша. Шулай итеп, әдәбияттә кәсепчелек, кода-кодагыйлык, заманча әйткәндә, мафия тамыр җәя. Җәйгән инде. Үз кешеләрен мафия җитәкчелеккә күтәрә, үз кешеләренә премияләр бирдерә, тоткарлыксыз китапларын чыгарта. Мондый юл белән чын әдәбиятне үстереп булмады һәм булмаячак. Милләт алдында, аның бүгенгесе, киләчәге алдында шәхси җаваплылык тойган һәм намуслы язучы моны аңларга тиеш дип уйлыйм.

*— Хәзерге әдәби телебезнең культурасын күтәрү өчен нәрсәләр эшләргә кирәк дип уйлыйсыз?*

— Әдәби тел культурасын күтәрү өчен «урам теле» культурасын күтәрергә кирәк, «урам теле» культурасын күтәрү өчен бакчаларда, мәктәпләрдә... Барысы да билгеле — әйтеп тормасаң да була. Әдәби тел культурасын күтәрү иң әлек безгә — язучыларга, журналистларга, фән һәм культура әһелләренә кагыла. Әлегә без телнең кирәклеге турында гына сүз алып барабыз кебек. Безгә хәзер телдәге бозулар, ялгышлар, хаталар турында сөйләшә башларга вакыт. Бүгенге хәлендәге сөйләм теле һәм язма тел шул көенчә ныгып, нормага әйләнеп калса, татар телен дәүләт теле дип игълан иткән очракта да, ул үзеннән-үзе юкка чыгарга мөмкин. Бүгенге сөйләм телендә, язма телдә — радио-телевидениедә, вакытлы матбугатта, матур әдәбиятта җитмеш ел буена даими өстенлек итеп килгән урыс теленең көчле йогынтысы сизелә. Без хәзер тәрҗемә телендә сөйләшергә, тәрҗемә телендә уйларга күнегеп киттек. Бездә хәзер татар сүзләреннән русча җөмләләр белән мәкалә, хикәя-роман язу гадәти нәрсәгә әйләнеп бара. Газета-журналлардагы тәрҗемә әсәрләрне мин, гомумән, укый алмыйм. «Әллүки»дә бер өлкән язучыбызның «Менә сиңа, мә!» («Вот тебе, на!») дип исемләнгән хикәясен күреп, артыма авып китә яздым. Тел остасы шулай язгач, башкаларга ни кала? «Чаян» журналының узган елгы 24 санында бер рәсем басылган. Ике төпсә янында ямь-яшел чыршы үсеп утыра. Зур төпсә кечерәк төпсәгә: «Киемнең энәдән генә төшкәнен кидертәм балакаема» ди. Моның русчасы «одеваю с иголочки» булгандыр инде. «С иголочки» тәгъбиренең татарчасын тәрҗемәче белмәгән, шуңа күрә үзенчә тәрҗемә иткән. Нәтиҗәдә көлке мәгънәсезлек килеп чыккан. Мондый көлкедән җылыйсы килә. Татарча дөрес сүз, дөрес тәгъбирләр өчен иң әлек «Чаян» көрәшергә тиеш иде кебек. Ләкин көрәшче «Чаян», татарча «Чаян» күптән инде үлде. Сүз уйнатуга нигезләнгән юмор-сатира әсәрләрен тәрҗемә итеп булмый. Кайчандыр татарча гына чыккан «Чаян»ны башта русчага тәрҗемә иттеләр, хәзер татарчага да тәрҗемә итә башладылар. Татар матбугаты өчен моннан да зур хурлыкның булуы мөмкин түгел. Революциягә кадәр үк безнең саф татарча юмор-сатира журналларыбыз булган. Бүгенге «Чаян»га теләсә каян теләсә кем теләсә нәрсә яза. Тик анда татар тормышы, татар культурасы,

татар теле мәсьәләләре генә чагылмый. Журналның тиражы сигез йөз меңнән артык. Татарча тираж күпмедер, билгесез. Күп булса, ун-унбиш мең булыр. Татар матбугаты өчен җибәрелә торган тонналаган кәгазь фонды юмор төйгысын онытып бетергән бер үк авторларның тамагын туйдыру өчен хезмәт итә. Минемчә, мондый «Чаян»нан милләткә бернинди дә файда юк. Безгә өр-яңа сатирик журнал кирәк. Татар теленә, татар милләтенә хезмәт итә торган саф татарча журнал кирәк. Башка басмаларда да туган телгә, татар сүзенә игътибарны көчәйтә төшкәндә нур өстенә нур булыр иде.

— *Байтак еллар элек тә, соңгы елларда да сез кайбер яшь иҗатчылар колагына усал гына тәнкыйть сүзләре әйткән идегез. Хәзер бу мәсьәләдә фикерегез ничек?*

— Әйе, булды андый хәлләр. Алтмышынчы елларда мин берьюлы берничә яшь шагыйрьне тәнкыйтьләп чыктым. Үземчә әлләни усал да язмадым кебек. Моңарчы мактаудан башка берни ишетмәгән кайбер яшьләргә бу тәнкыйть аяз көнне яшен суккан кебек тәэсир иткән ахрысы. Ул чакта кайберәүләр мине хәтта тотып кыйнамакчы да булып йөргәннәр имеш. Күрәсез, ул замандагы яшьләр шигърияткә чын күңелдән бирелгән булганнар. Минем үземне дә яшь чагымда тәнкыйтьчеләр уңнан да, сулдан да тәпәләделәр. Тәнкыйть сүзе ишетү күңелле түгел, әлбәттә. Ләкин әдәбият — көрәш мәйданы. Көрәшергә чыккансың икән, әзме-күпме авыз-борын канатып алудан куркып торасы юк. Бүгенге әдәбиятта мин шул көрәш рухы сизелми. Чын мәгънәсендәге тәнкыйть юк. Булганы тешсез. Бүгенге тәнкыйть күбрәк мактау, сылау-сыйпау һәм кимчелекләрне йомып калдыру белән мәшгуль. Чын әдәбиятны, конкрет әсәрләрне белмичә, күз йомып кына тәнкыйтьләргә азапланулар да күренгәли. Тәнкыйть турында сүз чыккан икән, шунысын да әйтим: иң үтемле тәнкыйть — үз-үзеңне тәнкыйть итү. Ягъни үз кимчелекләреңне үзең аңлау һәм нинди генә әсәр язсаң да, гамьсезлеккә, битарафлыкка, сыйфатсызлыкка юл куймау һәм туктаусыз камиллеккә омтылу. Язучы белән тәнкыйтьче арасында дуслык бары шул җирлектә генә туа ала.

— *Гамәлдәге орфографияне үзгәртүгә ничек карыйсыз? Әлифбага өч хәреф өстәү безнең хәлне җиңеләйтер микән?*

— Хәзерге чорда, хәзерге шартларда милләт өчен моннан да зарарлырак нәрсәне, күрәсең, беркем дә уйлап таба алмас иде. Без менә уйлап таптык. Без бит талантлы халык! «Болгармы-татармы?» бәхәсеннән котылып өлгермәдек, безгә әлеге «орфографияне камилләштерү»не китереп чәпәделәр. Сумгаитта, Фиргана өлкәсендә аңлы рәвештә милли конфликтлар барлыкка китергән кебек, безнең игътибарны читкә юнәлтү өчен эшләнелгән хәйләкәр провокация булмады микән бу дигән шик бар. Татарстан Автономияле Социалистик Республикасының статусы сугышка кадәрге Африкадагы колонияләр статусыннан да түбәнрәк. Безнең җиребез, суыбыз, сулый торган һавабыз үзебезнеке булмаган кебек, телебез, әлифбабыз да үзебезнеке түгел. Шунысын да онытмыйк, урыс патшалары безне күп нәрсәдән мәхрүм иткәннәр, ләкин динебезне, телебезне, хәрефебезне тартып алырга аларның кыюлыгы җитмәгән. Төрки халыкларның гарәп хәрефен үзгәртү мәсьәләсе Ленин исән чакта — егерменче елларда ук кузгатыла. Шул хакта дәүләт комиссияләре төзелә. Ләкин 1923 елда Гордлевскийның татар язуын урыс графикасына күчерү проекты ныклы каршылыкка очрый. Ул вакытта бу план тормышка ашырылмый кала. Ләкин «новаторлар» чигенергә теләмиләр. Чын укымышлыларны берәм-берәм чүпләп бетергәч, татар язуын урыс хәрефенә түгел, латинга күчермәкче булалар. Галимҗан Ибраһимов, күрәсең, бу хәйләне дә яхшы аңлаган — латинга ул каршы булган. Без инде беләбез: гарәп хәрефләрен башта латинга алыштырдылар, ун-унбиш елдан соң ук латинны урыска әйләндерделәр. Барысы да «гыйльми» нигездә эшләнде. Татар хәрефен үзгәртүне, әйтик, Ильминскийлар, Гордлевскийлар түгел — Ильминскийлар, Гордлевскийларның шәкертләре Мөхәммәт Фазлуллиннар күтәреп чыкты. Мөхәммәт Фазлуллиннар үлгәч, аларның эшен дәвам иттерү өчен яңа буын Мөхәммәт Ильминскийлар кирәк булды. Монысын инде минем кордашлар, сабакташлар башкарды. 1965 елны Мирфатих Зәкиевнең татар теленә күпләп урыс сүзләре алырга кирәк, яңа терминнар ясаганда рус сүзләрен шул көенчә кулланырга кирәк, рус теленә күчү — иң прогрессив күренеш дип шау-шу кузгатуын әле дә кайберәүләр онытып бетермәгәннәрдер... 1989 елда җан исәбе алуда бер миллион 130 мең чамасы татарның үз туган телен ана теле дип танымавы шуның бер нәтиҗәсе булып тора. Күпләр, ихтимал, уйлап та карамыйлардыр — татар хәрефләре генә түгел, татар язу кагыйдәләре дә тулысынча урыс теле нормаларына яраклаштырылган. Мин, мәсәлән, илле еллап инде язу-сызу белән шөгыльләнәм, ләкин кайбер сүзләрнең язылышын, кайбер өтерләрнең куелышын әле дә үзләштерә алмыйм. Бүгенге татар теле дәүләтендә үз законнары, үз кагыйдәләре белән, урыс, гарәп-фарсы сүзләре аерым «дәүләт» булып яши бирәләр. Татар әлифбасында, татар грамматикасында, синтаксисында татар теленең хокукы юк дәрәҗәсендә. Татарстан АССРда татарның хәле нинди булса, монда да шулай. Барысы да уйлап эшләнелгән.

Гамәлдәге алфавитка өч хәреф өстәү ул череп беткән һәм тору өчен куралэтә

яраксыз өйне сипләү белән бер. Сипләргә түгел, ут төртеп яндырырга кирәк ул өйне. Аның урынына заманча иркен, яңа, нык йорт салып куярга кирәк. Тәкъдимнәр күп булды безнең яңа әлифбабыз латинча булырга тиеш.

*— Әйтә алмассызмы — хәзер нинди әсәр язу белән мәшгульсез?*

— Язылып беткән әсәрем булмаса, фәлән әсәр язам дип, басылып чыккан китабым булмаса, фәлән китап бастырам дип сөйләнергә күнекмәгәнмен. Тәҗрибә шуңа өйрәтте. Фәлән нәрсә язам әле дип танышыңа сер чишәргә өлгермисең, икенче көнне үк имеш-мимеш тарала. Күп тә үтми, Тукай клубында орган вәкиле шомлы итеп: кайберәүләр, хатыннарына да сиздермичә, яшереп роман язалар икән дигән яңалык әйтә һәм татар язучыларын уяулыкка, дошман пропагандасына бирелмәскә өнди. Кемнең яшереп роман язуын әйтмәсәң дә аңлашыла. Андый кеше бездә бер генә. Яисә фәлән елга фәлән китабың нәшрият планына кертелә. Китап чыга инде дип көтеп кенә торганда, я сине бөтенләй планнан төшереп калдыралар, яисә бер-ике елга арткарак чигереп куялар. Хәзер инде әллә ни сер дә юк, сер чишелер дип курыккан да юк. Бу арада мин үземнең яшьлек еллары турында яңа китап язам. Дөрес, ул инде бернichә мәртәбә язылган, тик аны яңа баштан карап чыгып, тагын берничә мәртәбә язасы гына бар. Аннан соң — Тарихны өйрәнәм. Тагын берәр тарихи роман язып булмас микән дигән хыял белән яшим.

*— Каләмдәшләрегезгә әйтәсе килгән иң зур теләкләрегез нинди?*

— Иң зур теләгем шул — язарга кирәк. Ходай тарафыннан бирелгән аңлы, кадерле, сәламәт гомерherең минутын да юкка-барга әрәм итмичә язарга кирәк. Тылсымлы сүз белән милләтнең исемен-дәрәҗәсен күтәрергә, башкаларны кабатламыйча, үз акылың, үз көчең, үз ихтыярың белән яңа һәм сыйфатлы әсәрләр иҗат итәргә кирәк!

Әңгәмәне журналның әдәби тәнкыйть бүлеге редакторы
**Мансур ВӘЛИЕВ** алып барды.

# Кыям Миңлебаев

## Хәзинә алмашканда...

Татар әдипләренең китапларын башка телләргә тәрҗемә итү мәсьәләсе уйландыра... Элегрәк безнең Разия ханым Фәизовабыз бар иде. Ул чын мәгънәсендә билингвист булды, ике телне дә тиң белеп, оригиналның бөтен нечкәлекләренә хәтле аңлап эш итте. Бер дә мөгез чыгармыйча гына, татарча әсәргә тәңгәл килердәй тәрҗемә ясап куя торган иде. Шул ханымның фидакарь хезмәте аркасында Г. Ибраһимов, Г. Бәширов романнары бөтен илгә таралды, хәтта әле чит илләрдә соклану уятты.

Әмирхан ага Еникинең дә төрле әсәрен төрле кеше төрлечә тәрҗемә итеп карады. Аларның кайсысына «баш ияргә» икәнен һич белгән юк. А. Бадюгина, әйтик, оригиналдан тәрҗемә итә. Әмма ләкин үз теленә «беләм!» дип әйтү генә җитми бит әле, ул «беләм»не һәрчак ныгыту һәм тирәнәйтү кирәк. Моның өчен, иң әүвәл, татар әдәбиятын тоташтан, бервәзлексез уку мәҗбүри. А. Бадюгинаның русчага ясаган тәрҗемәләрендәге бер урында таптану туган теленә илтифаты җитмәүдән килеп чыгадыр, ахрысы... Ә инде Р. Кутуй оригиналны кулына да тотып карамый: файдасы юк, чөнки ул ана теленнән мәхрүм калган. Оригиналның бөтен нечкәлекләрен белмәгәч, подстрочниктан, ягъни эштер-өштер генә ясалган сүзгә-сүз тәрҗемәдән, өр-яңа әдәби әсәр корыштырырга мәҗбүр ул. Андый әсәр, Еники темасына язылган яңа әсәр буларак, саф рус телендә матур яңгыраса да, ул инде безнең Әмирхан абзыйдан шактый ук ераклашкан була...

Мәгәр иң аянычлы язмыш Фатих ага Хөснине сагалап торган, ахрысы. Аның көйләп укырлык гүзәл әсәрен — «Йөзек кашы» повестен русчага Н. Мальшакова тәрҗемә итте. Әмма ул татар теленә дә, авторның үзенә дә әллә ни хөрмәт саклап тормыйча, «төзәтү», «шомарту»лар кертүне үзенең бурычы санады булса кирәк: сабан туенда ат чабышында катнашучы авыл малайларын... ияргә атландырды. Мондый «шомартулар» халыкның тормыш-көнкүрешен рәтләп белмәүдән, өйрәнмәүдән килеп чыга.

Фатих аганың зур-зур романнарын тәрҗемә итүче Н. Богданов турында исә татарчаны да, халык тормышын да белми дип әйтү генә аз булыр: ул әле шуның өстенә безнең олы язучыбызны адым саен малайсыта, китапларның эчтәлегенә тыкшына, әллә нинди «мөгезләр» чыгарып азаплана. Сабан туенда көрәшеп кенә калмыйлар, уйныйлар-биилләр, танцевать итәләр, яңа туган баланы... чукындыралар, ә бер геройны хәтта «церковноприходская школа»га укырга илтәләр... Милли колоритны мондый юл белән «көчәйтү» бернинди киртәгә дә сыймый, билгеле.

Фатих аганың лирик повестьлары үзенә бер нәфислек һәм гүзәллек белән өртелгән. Әмма Е. Манько дигән иптәш аны-моны уйлап тормаган, артык баш ватмаган: грамматика җәһәтеннән дөрес җөмләләр корыштырса да, Хөсни хәтле Хөснинең телендәге лирик аһәңне, илаһи бизәкләрне, әлбәттә, саклый алмаган. Тик анысы аның бер бәла. Е. Манькога андый зыян гына аз тоелган һәм ул «Без яшь идек» повестенда болай хәрәмләшә: оригиналда Фуат сугыштан соң Одессада төпләнеп кала, молдаван кызына өйләнә, бер малайлары туа. Озак еллардан соң Миңнегөл сөйгәненнән хат ала — бу инде фәкать безнең лирик моңга бай сөекле авторыбызда гына булырдай хәл, аның иҗатына, язу стиленә гомумән хас бизәк. Тәрҗемәче аны азсына, үзенчә «үзгәрешләр» кора башлый. Башта ул Фуат белән Миңнегөлне вокзалда очраштырмакчы булып азаплана, тик очраштыра алмыйча гына кала — үзеннән ике-өч бит мәгънәсез штамп өсти. Аннары ул молдаван кызын Одессада очратуны бик үк өнәп бетермичә, текстка мондыйрак экзекуция ясый: Фуат япон милитаристларына каршы да сугышкан икән, Ерак Көнчыгышта үзенең мәхәббәтен очрата, исеме София икән, «милләте белән молдаван икән», шул ук часть та фельдшер булган икән, Фуатка ул ике бала (!) табып биргән икән... Шул ук тәрҗемәче җырлап торган шигъри проза белән язучы Фатих Хөснинең тел байлыгын, стиль үзенчәлекләрен бирә алмавына, имештер, компенсация ясый һәм: «Где-то читала я»,— дигән булып, әсәрнең эчтәлегенә дә, гомуми настроениега да һичбер мөнәсәбәте булмаган, җиде ел кайнаса да шулпасы катнашмастай уникe юллык шигырь белән тәмамлый. Гаять урта кул бу шигырь җитмәсә әле: «Ногу крепче держите в стремени...» — дип башлана. Фатих аганың тәрҗемәчеләре әллә сүз беркетеп куйганнар инде: әледән әлеияр-өзәңге белән авторның теңкәсенә тия торалар...

Драматургиядән Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»ен генә алыйк. Ю. Мочалов бу әсәрне болай намус белән эшләгән, бер дә күрәләтә хыянәт итмичә, нәкъ русча матур яңгырардай, адекват тәрҗемә биргән. Тик миңа әлеге тәрҗемәдә геройларның холкына аз-маз зыян килердәй урыннар очрый, монысы инде милли колоритны тулаем аңлап җиткермәү бәласе.

«Әй, кем бар өйдә, чәй чыгарыгыз!» — дигән мәгъруР таләп урынына, гайрәте бөтенләй сүрелгән, мескен бер бабайның сүзләре ишетелә:

«Эй, кто там есть, в доме? Чай вскипел? Чаю хочется, слышите?»

Ата-бабадан озын гомерле булган мәгъруР картны рәнҗетү булып яңгырый бу урыны. Чөнки оригиналда ул искиткеч гайрәтле, тормышчан, һәм аның өендә самавыр көннең-көн буена җырлап торырга тиеш.

Оригиналдагы: «Сарыклар абзарын ремонтларгамы?» исә «Пионерский лагерь» булып киткән бит, әй!

Хәмдебануның бикле капка янында әйткән сүзләре һич тә картая белмәгән егет-картка кинә булып яңгырамый инде югыйсә: «Әстәгъфирулла... тфү, кешедән оят! (...) чакырып кертеп, рисвай итеп чыгармасаң... (...) Кая, нәрсә соң бу?» Ә менә тәрҗемәдә ул әдәпфәләп саклап тормый, татар карчыклары гомерендә әйтә алмаслык сүзләрне яудырыпмы-яудыра:

«Девяносто лет прожил — ума не набрался»;

«Шутом был, шутом остался!»

«Открой, дурень, а то всю деревню созову!»

«Отопри!»

«Открой, говорят!»

Боларның бер ишесе элекке заманда татар хатыннарының нинди тәрбия алганнарын белмәүдән килсә, милли колоритны гәүдәләндерүдә каза булса, икенчеләре инде бичара тәрҗемәченең үзеннән «бизәк» өстәргә маташу бәласе... Ә бит инде татар халкының үткәнен-бүгенгесен дә, гореф-гадәтләрен дә, телен-фигылен дә гаҗәеп әйбәт белгән һәм укучының да, тамашачының да олуг мәхәббәтен яулаган Туфан Миңнуллинны рус укучысына түкми-чәчми илтеп җиткерү вазифасын гына үтәргә тиеш иде тәрҗемәче!

Әсәрен тәрҗемә итәргә алынган авторыңа тулаем ышану кирәк. Бик күп еллар элек мин үзем дә Л. Н. Толстойның автобиографик өч повестен тәрҗемә иткән идем. Әйтик, «Балачак» дигәнендә Гриша исемле дивана дәрвиш бар. Аның образы, башкалар шикелле үк, җиренә җиткереп эшләнгән, чынбарлыктан алынган булуына һичбер төрле шикшөбһәгә урын калдырмый. Сәер хәл, әмма шушы образга тулысынча ышанганлыктан, авторның истәлекләрендә, ул образны уйлап кына чыгардым, дип әйткәненә һич ышана алмыйм гына бит...

Кайчагында безнең замандашларыбыз чынбарлыктагы хәлләрне китапларына әштер-өштер генә күчереп куялар да — художество дәрәслегенә ирешә алмыйлар, образлары ясалма чыга, ышандырмый...

Тәрҗемәче үзенең авторын олылап, хөрмәт белән карамаса, әллә нинди хәлләр, үзгәртү-төзәтүләр килеп чыгуы ихтимал. Рус поэзиясендә А. Ахматованың тоткан урыны гаять зур. Ә менә Тукайны русчага тәрҗемә итүе бер дә инде сөендерми. Г. Тукайның «Мәктәптә» исемле шигыре, исегездә булса, болайрак башланып китә:

*«Игеннәр тулган ындырга, халыкның эшләре беткән,*
*Вә көньякның вакытча безгә килгән кошлары киткән».*

Тәрҗемәдә ул болай укыла:

*«Хлеб убрали, стало тихо и пустынно на полях,*
*Птицы южные вернулись зимовать в родных краях».*

(Малая серия «Библиотека поэта», 1963, 300 б.).

Тәрҗемәче биредә шигырьнең эчтәлеген үзгәртә, авторның фикеренә хыянәт итә. Г. Тукай «Пар ат» шигырендә Уральск белән саубуллашкан чагында болайрак ди:

*«Сау бул инде, хуш, бәхил бул, и минем торган җирем.*
*.................................................................*
*Хуш, гомер иткән шәһәр! Инде еракта калдыгыз...»*

Тәрҗемәдә исә әлеге юллар мондыйрак килеп чыккан:

*«Край родной, не будь в обиде, край любимый, о, прости,*
*.................................................................*
*О, прощай, родимый город, город детства моего!»*

(Шунда ук, 118 б.)

Габдулла Тукай үзенең Кушлавыч авылында тууын гомерендә дә исеннән чыгармый, хәтта әле күңеленә бик якын булган Кырлайга карата да: «Гәрчә анда тумасам да,

мин бераз торган идем».— ди. Уральскины ул Кырлайдан соң, тугыз яшендә генә күрә һәм беркайчан да «туган ягым» яки «туган шәһәрем» дип әйтми. Димәк ки «родной» һәм «родимый» дип мөрәҗәгать итүе — ялган, фальшь. Бу шигырьнең стилена дә зур зыян килгән: оригиналы яңгыраш ягыннан ат тоягының каты юлга бәрелүен хәтерләтә, сәфәр настроениесен тудыра; ә тәрҗемәдә исә андый яңгыраш бөтенләй юкка чыккан, бары тик «Пара лошадей» дигән исеме генә торып калган, укучыга эмоциональ тәэсир итү көче югалган.

Ә бит тәрҗемәче бер дә масаймыйча, «Ярамаган тагын аңа» дип уйламыйча, оригиналны үзе укып сокланган һәм авторның даһилыгын тулысынча аңлаган очраклар да — катлаулырак тезмә юлларны да матур гына башкарып чыгарга мөмкин.

Менә бер мисал — А. С. Пушкинның «Эхо» шигыре.

*Ревет ли зверь в лесу глухом,*
*Трубит ли рог, звенит ли гром,*
*Поет ли дева за холмом —*
*На всякий звук*
*Свой отклик в воздухе пустом*
*Родишь ты вдруг...*

*Тын урманда ерткыч куйса улап,*
*кук кукрэсэ, быргы куйса уйнап,*
*Тау артында бер кыз куйса җырлап —*
*Барсына да*
*Син шуларның кайтарасың җавап*
*Тын һавада...*

А. С. Пушкин — һәммәбез өчен бөек шагыйрь, даһи шагыйрь. Әхмәт ага Исхак та аңа шулай олылап карый һәм аның шигырьләрен тәрҗемә итәргә керешкәч, бер дә көчен җәлләми, бөтен шигъри талантын эшкә җигә, шигырь үлчәвен 8 иҗектән 10 иҗеккә үзгәртүдән гайре һичбер төрле каза китерми, эчтәлек-мәгънә ягыннан тулаем тәңгәл килердәй адекват шигырь иҗат итә. Нәтиҗәдә — безнең укучыга әсәрнең илаһи бер гүзәл яңгырашын китереп җиткерә. Тәрҗемәчегә шуннан да зур куаныч юк.

Икенче бер аксакалыбыз Нури ага Арсланның фарсы шагыйре Гомәр Хәйям даһилыгына мөкиббән китеп, гомере буена аның робагыйларын — дүрт юллы шигырьләрен оригиналдан тәрҗемә кылуы, оригиналның бөтен нечкәлекләренә үтеп керүе, яхшыдан-яхшы вариантлар ясый торгач, сокланргыч шигъри юллардан төзелгән нәни генә бер китап китереп чыгаруы — олуг егетлек, иҗат иясенең халыкка зур бүләге.

Укучыга илтифатлы булу дигән сүз ул — үзеңнең туган телеңне белүеңә, дәрәҗәгә, ни дәрәҗәдә белүеңә бәйләнгән. Бүгенге көндә бик күп яшьләрнең русча белән артыграк мавыгып китеп, татар телен акрынлап онытa башлавы барча халыкка мәгълүм.

Мондый чир, кызганычка каршы, мине дә читләтеп үтмәде. Мәктәптә укуны туган авылым Кече Чынлыда башлап җибәргәннән соң гаиләбез белән Казанга, хәзерге Дәрвиш поселогына күчеп килдек. Тора-бара минем уку татарча-русча аралашып китте. Әмма сугыш беткән бер заманда телемнең ярыйсы ук чуарланып китүен абайлап алдым, һәм йөрәгем җуу итте, үземнән үзем оялып куйдым. Шуннан инде шәһәргә татар мәктәбе эзләп киттем, 12 нче мәктәпне табып, унынчыны шунда тәмамладым. Шәһәрнең үзендә дә татар телен һәм әдәбиятын укытучы юньле педагог очратмадым очратуын, мәгәр әлеге мәктәпнең директоры Кәрим абый Хәмитов, завучыбыз Әхәт абый Богданов, биология укытучысы Мәрзия апа, химия укытучысы Хәлимә апалар үзләренең фәннәрен саф ана телендә өйрәтү белән генә дә чикләнмичә, сугыштан соңгы гаять авыр елларда укучыларга миһербанлылык күрсәтеп, аларның хәл-әхвәлләре белән кызыксынып, булышлык итеп яшәделәр.

Бары тик үзең яраткан, таланты алдында баш игән язучыларның гына иҗатын ныгытып өйрәнергә, анда да әле күңелеңә бик тә хуш килгән әсәрләрен генә татар укучысына тәкъдим итәргә кирәктер, дип уйлыйм. Хәер, безнең телгә тәрҗемә итү өчен китап сайлаган чагында минем коллегалар мондый таләпне күздән ычкындырмыйлар. Әдәби тәрҗемәнең бүгенге әйбәт сыйфаты да күктән килеп төшмәде, дистәләрчә еллар буена армый-талмый эзләнүләр-өйрәнүләр нәтиҗәсендә фидакарь хезмәт белән яуланды.

Университетта укыган чакны шулай В. Шишковның «Угрюм-река» дигән романы кулыма килеп керде. Бер генә әдәби әсәрдән дә шулчаклы нык тәэсирләнгәнем булмагандыр: авторның гуманистлыгы да, теленең гаҗәеп дәрәҗәдә халыкчан булуы да, геройның язмышы-кыяфәте дә, холык-фигыльләре дә, үз-үзләрен тотышы да мине тәмам сихерләде. Үзем укып кына калу җиңаять сыман тоелды, шуннан дусларыма да укыттым. Аның белән генә дә чикләнеп каласым килмичә, үзебезнең Кече Чынлы малайларына да, русча белмәүче башка авыллардагы малайларга да укытасым бик-бик килде. Ләкин ул чагында әле тәрҗемә эшенең ни дәрәҗәдә читен эш — энә белән кое казу икәнен белеп җиткерми идем. Китапның исемен безнеңчә ничегрәк итеп әйтергә икән, дип баш вата башладым. В. Шишковның башка китапларын да укый торгач, бөтен иҗатын өйрәнеп чыкканымны сизми дә калганмын.

Шунысын әйтергә кирәк, ул чагында Г. Гобәй, М. Максуд, А. Гомәрләрнең тәрҗемәләре миндә канәгатьсезлек тойгысы калдырды. Алар шикелле сүзне сүзгә әйләндереп бару белән, калька ясау белән чикләнергә ярамаганын аңладым. Иң зур сабакны шу-

лардан алдым. Тик әле башка юлны сайларга да, бүтәнчәрәк эшләп карарга да көч таймадым — шушы авыр хезмәткә үземне әзерли башладым. Беренче тәрҗемәләрем студент чакны ук дөнья күрде, шул арада җиде ел гомер үтеп тә китте...

Ул елларда тәрҗемә өлкәсендә иң дөрес юлдан баручы Сәрвәр Әдһәмова, Ибраһим Гази, Афзал Шамов һәм Сәгыйт Фәйзуллиннар безнең ише «бала-чага»га искиткеч дустанә карыйлар, теләктәшлек күрсәтәләр, киңәш бирәләр иде. Укытучыларым дип әнә шул игелекле затларны саныйм. Шулардан фатиха алып, китапның исемен «Хәсрәт дәрьясы» дип халык рухында язып куйдым да, тәвәккәлләп эшкә керештем. Көн саен эшли торгач, бер мәртәбә язып чыктым. Аннары кабат эшләргә-шомартырга тотындым. Җиде кат телемне чарлаган арада, янә җиде ел үткәнен сизми дә калганмын. Бу авыр хезмәт минем өчен бер үк вакытта газаплы да, ләззәтле дә булды. Нәтиҗәдә киләчәгемне дә әнә шул хезмәт билгеләде: әдәби тәрҗемә — иҗатыма әверелде һәм мин шигырь язуны да, хикәя-повестьларны да читкә ташладым. Татар мәдәниятын урта кул әсәрләр белән чүпләгәнче — дөнья әдәбияты гүзәлләре исәбенә баетырга карар кылдым.

Рус әдәбиятында гаҗәеп күренекле урын алып торган, А. Толстой иҗатында иң күркәм саналырга лаек «Хождение по мукам» эпопеясын тәрҗемә итү — үзе бер тарих. Тиңе булмаган остаһы, стилистны ничек итеп икенче телдә сөйләтмәк кирәк?! Уйлана торгач, авторның стилен кечерәк күләмле әсәрләреннән үзләштерергә ниятләдем: әүвәл «Аэлита» белән «Инженер Гаринның гиперболоиды» дигән маҗаралы һәм фантастик романнарын эшләдем. Фәкать шуннан соң гына «Михнәтле заман» трилогиясенә ныклап тотындым. Биш-алты ел буе яраткан геройларым дөньясында яшәдем.

Ара-тирә авторның текстын чак кына үзгәртеп җибәрү кирәк булуын да аңладым. «Хождение по мукам» трилогиясенең өченче китабында, мәсәлән, Алексей Толстой болай дип яза: «Единственная память — изумрудное колечко, зелененький огонек, подарок Вадима, затерялось еще в селе Владимирском». Бәй, монда баш ватып торасы юк, тотасы да тәрҗемә итәсе! Мәгәр кешедә хәтер дигән нәрсә бар бит әле. Ничәмә-ничә елдан бирле шушы геройлар белән аралашып яшәгәч, сиңа бит инде һәркайсының холкы-фигыле, кайчан ниләр эшләгәне мәгълүм. Шуңа күрә син әлеге җөмләгә шикләнеп карыйсың, алдагы ике романны актарырга тотынасың. Күпмедер эзләгәннән соң, алдагы томның 432—433 битләреннән икенче төрлерәк хәбәр табып аласың: Катя үзенең сеңелесе Даша һәм беренче ире Николай Иванович белән бергәләп, Нева проспектына чыккан икән дә, шунда аңа туган көненә дип зөбәрҗәт кашлы йөзек бүләк иткәннәр икән. Сугышка чаклы булган шушы вакыйга һәммә нәрсәгә ачыклык кертә. Инде син тәрҗемәңдә бер тапкыр шушы вакыйганы язып куйгансың икән, ничек итеп онытмак кирәк тә, ничек итеп икенче җирдә бүтән төрле итеп язмак кирәк? «Автор үзе ни сәбәпле болай бутады икән?» дип уйланасың. Ихтимал, Катя беренче ирен искә төшерергә теләмидер, һәммә күркәм нәрсәне дә Вадимнан күрәдер; бәлкем, автор үзе героинясының язмышын тулаем сөекле кешесенә бәйлидер; ә бәлкем, йөзек вакыйгасын автор онытып җибәргәндер?..

Рус теленең үзенә генә хас төсмерләре еш кына очракта әдәбият кешеләрен дә аптырашта калдыра. Әйтик, әлеге трилогиядә: «...под муки — пара штанов без заплаток»,— дигәнне «...ямаусыз чалбарга бер пот он бирәләр»,— дип тәрҗемә иткән идем. Рецензентка бу арзандыр сыман тоелган һәм ул: «ике чалбарга»,— дип үзгәрткән. Редактор да тәрҗемәчесенең русча белүенә бик үк ышанып җитмәгән һәм карандаш белән «төзәтелгән» сүзне хуплаган, кара белән язып чыккан. Ә бит ныклабрак уйлап карасаң, монда хикмәт һәр ике телнең үзенә генә хас булган үзенчәлегендә: бездә берлектә йөргән әйбер рус телендә парлы булып исәпләнә (пара перчаток, пара ботинок, пара штанов) һәм аны, русчасында булган өчен генә, безнең телгә дә күчереп утырту хата булыр иде.

Берзаман Колумбиянең хөр фикерле әдибе Г. Гарсиа Маркесның рус теленә тәрҗемә ителгән «Сто лет одиночества» исемле романы кулыма килеп керде. Кеше язмышын бу чаклы да тирән ачуны, бер гаиләнең гасырдан артык вакыт эчендә кичергәннәрен — бәхет вә шатлыкларын, фаҗига вә аянычлы хәлләрен, ахыр чиктә һәлакәткә дучар ителгәнен — һәммәсен дә искиткеч зур осталык белән тасвирлауны күреп, тәмам хәйран калдым. Бу авторга кагылышлы мәкалә вә аңгәмәләр минем өчен аерым бер планета сыман кызыксыну уятты. Әнә шул гадәттән тыш кызыксыну ул авторны шәхес буларак олыларга, хөрмәт итәргә, аның гуманистлыгы алдында баш ияргә, художник буларак аны бүгенге көн әдипләреннән иң олысы, иң зур талант иясе дип танырга мәҗбүр итте.

«Хәсрәт дәрьясы», «Михнәтле заман», «Ялгызлык»... Миңа калса, бу әсәрләр арасында күзгә күренмәгән ниндидер серле җепләр сузылган. Бу әсәрләрне иҗат итүче авторлар — В. Шишков, А. Толстой, Г. Гарсиа Маркес үзләре дә — бөек художниклар. Алар заман рухын тоеп, иң кирәкле теманы күтәргәннәр һәм үз геройларының сикәлтәле чуар язмышлары аркылы барча халыкның, алай гына да түгел, бөтен дөньяның, һәммә кешелекнең язмышын гәүдәләндергәннәр. Янә килеп, әлеге әсәрләрнең һәркайсы гуманист идея белән сугарылган. Аларның һәркайсында тормышчанлык, илаһи бер ышандыру көче ята...

# ГАМИЛ АФЗАЛ КӨЛҮЕ

Гамил Афзал исемен ишеткәч тә күз алдына җор телле, үткен фикерле, көчле һәм көр рухлы кеше килеп баса. Халык аны чәнечкеле шигыреннән, җор сүзеннән яхшы белә. Чөнки дистәләгән еллар буенча Гамил Афзал шигыреннән башка эстрада сәхнәсендә пәрдә ачылмый. Профессиональ артистлар да, үзешчәннәр дә кинәнә аның иҗаты белән. «Тәвәккәл әби», «Әсмабикә җаным, ахирәт», «Өф-өф итеп» һ. б. әсәрләре менә 30 елдан артык телдән төшми, һаман тәкатьсез көлдерә, алардагы шифаны тоеп бүген дә шатланасың. Боларга яңалары да өстәлә тора...

Моңа кадәр әдәбиятчыларны Гамил Афзал күбрәк лирик буларак кызыксындырды. Бу өлкәдә Т. Галиуллин, Н. Юзиев, Р. Мостафин кебек галимнәрнең эзләнүләре мәгълүм. Шулай да, шагыйрь иҗатын гомуми бәяләгәндә, аның көлү осталыгын, сатирик талантын бәһаләүче фикерләр дә очрап тора. Газета-журналларда дөнья күргән С. Хәким, Ф. Шафигуллин, Н. Хисамов, Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин мәкаләләрендә Гамил Афзал сатирасы турында җитди уйланулар бар. Шагыйрьнең лирикасын югары бәяләгән хәлдә, без аны бүген талантының кабатланмас дәрәҗәсен көлү өлкәсендә ачуын һәм заманыбызның Тукай рухлы иң көчле сатиригы булуын таныйбыз. «Шагыйрь иң элек үзен шушы авыр, четерекле, җаваплы жанрда танытты». (Ф. Шафигуллин).

Лирика һәм сатира агымы Г. Афзал иҗатында берчә тынып, берчә шаулап яши. Әле лирик агым көчәеп, сатира саегып кала, әле көлү өстенлек итә. Алтмышынчы елларда көлке агымы тараебрак, саегыбрак калса, соңгы елларда ул шагыйрь иҗатында тагын да тернәкләнә, җанлана төшә.

Илебездә кискен үзгәрешләр бара. Бюрократларга, эшнәлеккә, әхлаксызлыкка каршы көрәш дәвам иткән чорда әдәбият мәйданында сугышчан жанрлар алга чыга. Югары Советта да тәнкыйть үзәк юнәлеш булып китте. «Җәмгыятебезнең бердәнбер яшәү принцибы — тәнкыйть һәм үзара тәнкыйть. Алардан башка үсеш юк,» — диде М. С. Горбачев КПССның XXVII съездында. Шулай ук XIX нчы Бөтенсоюз партконференциясендә: «Тискәре күренешләр белән көрәштә сатира кебек жанрның көчен тулырак файдаланырга кирәк,» — диелде.

Димәк, сатирага һәм шушы дилбегәне кулында тоткан сатирикларга игътибарны арттыру — әдәбият белемендә һәм тәнкыйтьтә төп юнәлеш булырга тиеш. «Көлү көлкеле эш булса да, уен эш түгел. Ул халыкның рухи дөньясы, җәмгыятьнең үсеше белән бәйле күренеш» (Нил Юзиев).

Беренче рус революциясе һәм реакция елларында Тукай сатирасы... Егерменче еллар ахырында Такташның кешелекле юморы... «Аннары Ә. Фәйзи, Ә. Давыдов, З. Мансур, Ә. Исхак... Һәм бу агымга куәтле дулкыннар өстәп, безнең революциягә килеп җитүчеләр Гамил Афзал, Шәүкәт Галиев, Гәрәй Рәхим... Болар арасында Г. Афзал язмышы белән дә, бормалы-бормалы иҗат сукмагы белән дә, сатирик куәтле, әрем ачылы теле белән дә аерылып тора. «Гамил Афзал башта ук, беренче шигырьләреннән үк җиргә ябышты. Икенче ныклап ябышкан объекты — Тукай... Тукайчылык Гамил Афзал иҗатының рухында,» — дип язды С. Хәким. Менә шушы сыйфат шагыйрьгә милли сатираның дилбегәсен ышанып тоттырган да инде. Аның шигырьләре — тормышыбызның, әхлагыбызның, кешелекнең йөзен таплаучы һәртөрле күренешләр белән җанын аямыйча көрәшкән иҗат үрнәкләре. Яшәешнең һәр күзәнәге өчен борчылу, һәр бюрократ, һәр формалист, һәр куркак белән көрәшү тармаклы проблемаларга, темалар төрлелегенә алып килгән. Образларына, үзе тудырган сатирик типларга шагыйрь кат-кат әйләнеп кайта, туктаусыз көрәшә, һәр очракта аларны яңача фашлый, тынычланып калырга һич тә уйламый...

Ә мондый көрәшче рухлы, үткен сатира нигезендә нәрсә ята соң? Аның әйдәүче йолдызы, остазлары кем? «Шагыйрь нечкә тоемлы күңелгә, чичәннәрнекедәй телгә ия. Ул бу байлыгы белән табигатькә һәм гасырлар буена мирас-хәзинә булып килгән, уй-фикерләрне садә итеп, ягымлы, тапкыр һәм төзек итеп әйтеп бирергә сәләтле халык теленә бурычлы» (Р. Фәйзуллин). Гамил Афзал бәләкәй чагыннан ук халыкның җыр-бәетләрен тыңлап, хикмәтле һәм мәзәк сүзләр ишетеп үскән, халыкның көй-моңнарына гашыйк шагыйрь. Шигырьләрдә халык җырларына хас җиңеллек, гадилек бар «табигый агышны дастаннарга хас салмаклык алыштыра» (Р. Гатауллин). Җиңеллеккә, гадилеккә алып килгән нәрсә — халык авыз иҗатын киң файдалану. Халыктагы җор фразеологик бөтеннәр, хикмәтле сүз, мәкаль-әйтемнәр — болар барысы да шагыйрьнең кул астында. Шигырьләрдә халык җырлары стилен, борынгы ядкаребез «Кыйссаи Йосыф» ритмын сиземләргә була. Г. Афзал сатира-

сының төп сыйфаты — «милли традицияләрне үткән буын шагыйрьләре китереп җиткергән бер үзәннән әләктереп алып, чор алып килгән яңалыклар белән синтезлап, үзенчә дәвам иттерә белүдә. Ул татар теленең тапкырлыгына, тел-сурәт байлыгына тирән үтеп кереп, аны үзенчә яңгырата белә, халыктан алган тапкыр әйләнмәне үзгәртә, шигъри тукыма эчендә эретеп җибәрә»,— дип язды Т. Галиуллин.

Сатирада халык тел байлыгын файдалану, шушы нигездә фикер тыгызлыгына һәм сүз үткенлегенә ирешү — Гамил Афзалның Тукайдан өйрәнгән иң гүзәл сыйфаты, дисәк, ялгышмабыз. Шагыйрь әледән-әле Тукайга мөрәҗәгать итә. Аның сюжетын да, образларын да (мисал өчен «Кәҗә белән Сарык хикәясе» һ. б.), шигъри үлчәмен дә («Дошманнар», «Мөдир төше», «Тукай белән киңәшеп утырганнан соң»), фашлау алымнарын, сатирик ысулларын да оста файдаланып, Тукай рухын, аның сатирик акцентын көнүзәк проблемага җигә. Г. Афзалның «Донжуан Ногман маҗаралары», «Сайладым, их сайладым», «Үз туксаным туксан» һәм башка бик күп шигырьләрендәге көлкеле типлар сатирик монолог аша фашлана. Мондый фашлау ысулын Тукайның «Мулла зары», «Ысул кадимче» кебек шигырьләрендә дә күрергә мөмкин. Авторның рифма-ритм белән оста эш итүен, теге яки бу шигъри үлчәмне имгәтми-нитми күчереп, үз мәнфәгатендә оста файдалануын «Аракыга каршы» шигыре ачык дәлилли:

*Аракы юктан гына җирдә халыклар үлми ич,*
*Пусть мәләкләрең берлән кунак чакыр да, үзең эч,—*

ди автор. Шул рәвешчә, Г. Афзал заманча проблемалар, көнүзәк мәсьәләләрне күтәрә. Шигъри форма өлкәсендә дә, тема, проблема төрлелегендә дә туктаусыз эзләнә. Аның геройлары — тормышның әчесен-төчесен татыган, дөньяга әзме-күпме җайлашкан, үзләренең сәер гадәтләре аркасында көлкегә калучы яки нинди дә булса «фәлсәфәгә» ия булган, урта һәм өлкән буын кешеләре. Бригадир Ахун, мактанмый булдыралмый торган Сәләхеттин абзый, йомшак креслога кунаклаган председатель яки үзенең черек мещан фәлсәфәсенә табынып яшәүче «урынбасар» дисеңме — болар барысы да тормышчан һәм тере типлар. Мондыйлар бүген дә һәр авылда, һәр төбәктә очрый. Шуның өчен дә укучыга алар таныш һәм үз. Гамил Афзал, үз геройлары арасында гомер буе кайнаган кешедәй, аларның психикасындагы һәр нечкәлекне тоеп, тормышларындагы һәр күзәнәкне танып, төсмерләп яза. Кешеләрне мыскыллау түгел, аларны кызгану, тәрбияви мәгънәдәге ярату хас бу сатирага. Телендә әрем әчелеге булса да, тупаслы, дорфалыктан ерак тора шагыйрь. Ул һәр авыруга дозаны төгәл билгели, еш кына йомшак түшәп катыга утырта. «Г. Афзал шигырьләрендә гуманист җанлы тәрбияче кулы сизелә»,— ди Н. Хисамов. Геройларның бер ишеләре, минем эшне сизмиләр, белмиләр, дип йөри, үзенең көлкегә каласын чамаламый. Мәсәлән, анда-санда эшләгән булып, тормышка һич игелек күрсәтә алмаган җилкуар («Анда-санда»)... Улына-кызына «асыл» киңәшләр яудыручы Флүрәттәй («Флүрәттәй акыллы»...). Бүрәнә өстендә юкны-барны сөйләшеп гомер үткәрүче колхозчылар («Лавка алдында күләгәдә»). Мондый шигырьләр тыныч тондагы гади хикәяләүне хәтерләтә, сатирик монологлар аша образлар үзләрен үзләре фашлый. Тискәре образларның икенче берләренә исә — карьеристларга, мин-минлекләре чиктән ашкан эгоистларга, үз шәүләсеннән үзе куркып яшәүче «тун асты кыюларына»— усал камчысын кызганмый автор. Шигырьләрендә аларга кабат-кабат кайта, яңа ысул һәм яңа чаралар ярдәмендә сатирик типларны яңача пешерә.

Менә безнең түрә кәеф-сафа сөреп, секретарь кыз Дания белән гыйшык-мыйшык уйнап, кабинетта гомер сөрә... Менә ул шабашниклар белән чыш-пыш килеп, колхоз малын анда-санда өләшеп, үз кесәсен калынайта... Һәр җинаятьнең барышы — сатирикның уч төбендә. «Үрләттек» шигырендәге түрә, шәп докладлар сөйләргә оста булса да, «Маяк»ны таякка калдыра. Өйрәнсен, күрсен дөньяны, дип, аны «Алга» ук күчерәләр. Бу колхоз да белә, артка китә. Булмаса, котылыйк моннан, дип, аны тагын да югарырак күтәрәләр.

*Ул хәзер еракта, биектә,*
*Безләрне кубызга биетә,*
*Ел буе шелтәләр яудыра,*
*Сүгәргә чакыртып алдыра,*
*Хрусталь графиннан су эчә,*
*Үзенең кемлеген белмичә.*

Күрүебезчә, сатира угы типик язмыш, типик биографиягә юнәлтелгән. Шагыйрь көндәлек тормыш, гадәти кешеләр прозасын курыкмыйча поэзиягә алып керә. Гоголь

фикеренә кушылсак, шагыйрьнең осталыгы иң вак һәм гадәти көнкүрешне үзенең таланты ярдәмендә сәнгать әсәре дәрәҗәсенә күтәрә белүендә.

Һәр сатирик үзенчә нәфрәтләнә, үзенчә елмая, көлә. Шәүкәт Галиев дөньясын онытып, рәхәтләнеп елмая, шуңа күрә дә аның көлүе юморга тартымрак. Гәрәй Рәхим исә хәйләкәр, мыек астыннан елмаючан. Ә инде Зәки Нури кайчакта нәфрәтләнеп китеп, тупас сүзләр дә ычкындыргалый, көлүен онытып, коры фашлау сүзенә күчә. Гамил Афзал сатирасы исә традицион канунарны да саклый, үзенчә, яңача да яза. Автор шигырьнең образның эчендә, ягъни ул — үзе бер персонаж. Тормыш драмасында ул читтән елмаеп-көлеп торучы гына түгел, ә анда актив катнашучы. Тәнкыйтьләнәсе мохитнең эченә үтеп керә ул, әйләнеп-әйләнеп аның көлкеле якларын фаш итә.

Гамил Афзалның образлар хәзинәсендә икенче бер төркем — «Мыек борам», «Тун астында кыюлык», «Сак кеше», «Курку хисе» кебек шигырьләрнең геройлары. Болар — алны-артны кат-кат уйлап та, үз фикерләрен әйтергә куркып ишәүче типлар. ...Менә ул үз кыюлыгыннан үзе куркып, тун астында ята («Тун астында кыюлык»). Югыйсә, власте булса, ул да дөньяны дер селкетер иде. Ләкин әле бит фатир аласы бар, телеңне тыймасаң, премиядән коры калуыңны көт тә тор. Алла сакласын, «ялгыш фикер әйтеп януың бар», эштән дә куып чыгарулары ихтимал.

*Ә хәзергә тун астында ятып,*
*Суккалә дә, брат, типкалә...*
*Үзе алдында*
*Якты чырай катып*
*Җизни диеп эндәш эткә дә.*

Мондый типларның икенче берләре исә «оптимистрак», алар җайлы гына урнашып өлгергән, хәтта үз мәнфәгатьләрен хуп күреп, аны башкаларга да тәкъдим итәләр. «Урынбасар булу яхшырак», «Файдалы киңәшләр», «Исәп-хисап», «Киңәш» шигырьләренең геройлары «бай» тормыш тәҗрибәсе туплаган акыл сатучы кыяфәтендә:

*Тыныч карап яхшылыкка, яманлыкка,*
*Әз генә дә хәтәр эшкә кулын тыкма.*
*Биләп алып тыныч урын, җайлы урын*
*Өстәл сугып патшалык ит, җепшек борын.*

*(«Киңәш»)*

Сатирикның игътибар үзәгендә — черек мещан фәлсәфәсе. Бу турыда «Тормыштан — поэзиягә» исемле мәкаләсендә Р. Мостафин да сүз ачкан иде (Советская Татария, 1981, 24 май). Җинаятьне күрмәмешкә салышу, җаваплылыктан качу, ничек тә уртадангарак, җил-яңгыр тими торган кулайрак урын сайлап, шунда оялау... — менә кайсы дөньяны тузгыта автор! Кешенең күңелен, җанын кечерәйтүче мещан психологиясен тамырыннан йолкып алырга омтылу, мондый куркыныч социаль эпидемиягә каршы ут ачу кебек сыйфатлар Гамил Афзал сатирасын бүгенге көрәшнең иң алгы сафына куя.

Шагыйрь кешенең кешелеклелеге, зурлыгы, аның мөмкинлекләре турында уйлана, фикри әҗәлдән, ваемсызлык чиреннән сагая. Аның герое — күпкырлы, катлаулы, кабатланмас социаль берәмлек. Шагыйрь үзенең геройларын Туган иленә, гаиләсенә, дус-ишләренә һәм, гомумән, тормышка булган мөнәсәбәтендә күзәтә.

Патриотик рухта язылган «Икенче Ватан», «Вохмяков мистер булып карады» шигырьләрендә эштән өркеп, «уен да үбеш»кә, малга ашкынып туган телен, илен саткан хаиннар мәсхәрәле хөкемгә дучар ителә:

*Каксалар да, суксалар да, суксәләр дә инде түз,*
*Тупсалар типсәләр дә елмаясың бетле күз,—*

дип, шагыйрь Тукайча ачы көлү, нәфрәтле мыскыллау белән коендыра сатлыкҗанны.

Тематик офыгының иркенлеге турында сөйләгәндә, халык тарафыннан аеруча җылы кабул ителүче мәхәббәт, гаилә кору, бала тәрбияләү өлкәсенә кагылган әсәрләргә тукталып китәсе килә.

Халык стиленә нигезләнгән гади һәм йөгерек тел, предметлылык, комик детальләр белән туендырылган реаль ситуация шигырьләрдә көчле ироник тон ала. Дөньяны онытып көләсең, гыйбрәт аласың, дәваланасың аларны ишеткәч. Гомер буе ныклы оя коралмыйча, матур хатыннан матур хатынга йөрүче «шомакай» ахырда үзенең язмышын менә ничек сурәтли:

*Урам ташларына абына-абына,*
*Майлы бәлешләрне сагына-сагына,*
*Киттем*
*Хатын номер два янына.*
*Малай үскән.*
*Минем хәлне хатын ишеткән.*
*— Пшол! — диде миңа ишектән.*

*(«Донжуан Ногман маҗаралары»)*

Ирдән-иргә йөрүне гадәткә керткән Әсмабикәне дә, гомер буе кызлар сайлый-сайлый 42 яшькә җитеп тә өйләнә алмаган егетне дә, чиктән тыш иркәләп, уларын тәмам эштән чыгарган ата-аналарны («Өф-өф итеп») иртәгәсе көндә тормыш фаҗигасе көтә.

Кешенең әхлакый йөзе, шәхси тормышы — мәңгелек проблема. Заманалар үзгәрә, яшьләр, яңа гаилә коручылар алдында да хәзер яңа таләпләр куела. Ләкин, кызганычка каршы, йолалардан, традицияләрдән читенү, Көнбатышка сукыр рәвештә иярү шатлыклы нәтиҗә китерми. Кайсыбер яшьләр хәтта нәрсә яхшы, нәрсә начар дигән төшенчәләрдә дә буталып кала. Бу өлкәдә сатирикларыбызга да эш җитәрлек. Чөнки үткен скальпель дә, көчле дару да алар кулында!

Г. Афзалның сатирик поэзиясе шигырь, мәсәл, пародия, фельетон, әкият, комедия кебек жанрларны иңли. Болар арасында халык җырларын хәтерләткән «Айныткыч турында җыр», бәет детальләрен файдаланып язылган «Шабашчылык бәете», доклад стилендәге «Чүбек чәйнәп май чыкмый», эш кәгазе рамкаларын кулланган «Характеристика» кебек әсәрләр игътибарга лаек. Автор фашлау ниятендә төш, монолог, диалог ысулларын да эшкә оста җигә. «Шомакойрык белән Сарытырнак диалогы»нда завмаг эте белән судья этен сөйләштереп, гаять үткен нәтиҗә ясаган ул. Кибет мөдиренең этенә сөяк-санак кына түгел, майлы калҗалар да еш эләгә икән, чөнки җинаятьчел хуҗасының өендә көн дә кунак, көн дә туй.

Төрле темаларны эченә алган «Дошманнар», «Кара песинең әтлеге», «Йомшак басып» кебек шигырьләрендә дә автор этләр, песиләр тормышын үтә зирәклек, кызыксыну, ярату хисе белән яза. Аларның кәефен, психологик халәтен бөтен нюансларда сурәтләргә сәләтле ул. Мәсәлән, «Йомшак басып» шигырендәге:

*Утынлыкта әни чыпчык, әти чыпчык.*
*Сөеналәр: «Җәйгә чыктык, җәйгә чыктык!»*
*Тикшерәләр кем оясын кем корасын,*
*Күкәй салу, ашау-эчү проблемасын,—*

кебек юлларда нинди уңышлы авазлар гармониясенә, нинди төгәл яңгырашлы рифма-ритмга ирешкән шагыйрь. Чыпчыкларның дөнья мәшәкатьләре, песинең планы, йомшак атлап килүләре, уңышсызлыктан соң ни рәвешле китеп барулары ышандырырлык итеп, реаль детальләр аша чагылдырылган.

Халык авыз иҗатына, классик сатира традицияләренә тугры булу белән бергә, Г. Афзал жанр, форма, тел-стиль өлкәсендә туктаусыз эзләнә. Тукайлар калдырган кыюлыкны бүгенге көннең четерекле мәсьәләләренә алып керә, үзенчә ерып чыга, нәтиҗәләр ясый...

Торгынлык чоры тәнкыйтькә озак еллар буе аяк чалды. Күпләр сатира өлкәсеннән читтәрәк булуны хәерле күрде. Ләкин бу жанр сүнмәде. Адаштыргыч бураннарда да, җил-давылда да Гамил Афзаллар көлү юлын дәвам итте. Чөнки Тукай йолдызы аларга сүнмәс маяк һәм ышанычлы әйдәүче булды.

**Ләйсән КӘШФИЕВА,**
Казан дәүләт университеты аспиранты.

# ТӨЗӘТМИКЧЕ ТУКАЙНЫ!

КҮПТӘН ЯЗЫЛЫП ТА, МАТБУГАТТА ЧЫКМАГАН МӘКАЛӘ

...Рухи ихтыяҗ тоеп та, көндәлек эшем буенча да миңа еш кына сөекле шагыйребез Габдулла Тукай иҗатына мөрәҗәгать итәргә туры килә. Ләкин күңелдә һәрвакыт аның гаҗәеп шигърият дөньясына кереп җитмәү, поэтик җимешләрен тулысынча татымау тойгысына охшаш бер хис кала иде. Ни хикмәттер, бу канәгатьсезлек хисе миндә елдан-ел арта бара. Мин үземне ирекле-ирексез бөек Тукаебыз мирасына күләгә төшерүдә катнашы булган гаепле бер кеше итеп сизәм. Һәм бу тойгыдан берничек тә арынып җитә алмыйм. Әлеге халәтемнең сәбәпләрен эзли башлыйм. Ниһаять, бер нәтиҗәгә киләм. Эш Тукаебызны бөтен тирәнлеге белән аңлый-аңламаудан гына тормый булырга кирәк...

Без дистәләрчә еллар әдип иҗатын, мәрхәмәт белмәс сугым пычагы белән эш иткәндәй, бугазлап, тунап, тураклап һәм, гафу итегез, печеп, укучыларның «томаналыгына», «әдәби зәвыгы чамалы» булуына исәп тоттык, аны шигърият табынындагы иң татлы ризыклардан мәхрүм итеп килдек. Юк, минем Тукай әсәрләре җыентыкларын төзеп, зур көч куйган мөхәррирләребезгә тел-теш тидерәсем килми. Алар заманы өчен булдыра алган кадәресен эшләгәннәрдер. Тик шулай да... 1955-1956, 1975-1976 елларда дөнья күргән дүрттомлыкларда гына түгел, инде хәбәрдарлык, үзгәртеп кору куәт алган чорда, 1985-1986 елларда басылып чыккан биштомлыкта да Тукай җәүһәрләренең бик күбесе гарипләндерелгән, имгәтелгән, яисә басмага бөтенләй кертелмәгән. Патша самодержавиесенең «кыл иләк» белән эш итүче цензорлары керфек тә какмый үткәргән әсәрләрне тунап, без бөек шагыйребез иҗатына гына түгел, бөтен татар әдәбиятына җәрәхәт салып килдек.

Мисалсыз сөйләшмик. Менә Тукайның «Әлгасрел-җәдид» журналының 1906 ел 11 нче, «Фикер» газетасының 1906 ел 26 ноябрь саннарында басылган «Кичке азан» шигыре. Ул совет чорында күп еллар буена, гомумән, дөнья күрмәде. Шөкер, биштомлыкның 1985 елда чыккан беренче томында без аны инде очратабыз. Ләкин ни аяныч! Анда сугым пычагы мондый юлларны тунап аткан:

*Китте Касыйм!*
*Китте Казан,*
*Бетте татар,*
*Кырылды хан,*
*Бохар, Хоканд*
*һәм Әстерхан!*

Әйтерең бармы, «кот очарлык» юллар! Тукай татарның шәүкәтле дәверен сагына! Бу юлларны кыркып, без шагыйрьне төзәтәбезме,әллә үзебезне тел-теш тиюдән саклыйбызмы? Патша цензурасы бернинди җинаять күрмәгән, ә без эзлибез, ә эзләгәч, билгеле ки, табабыз...

Ары киттек. Инде «Әлгасрел-җәдид»нең шул ук 11 нче санында «Үз-үземә» дигән шигыренә күз салыйк.

*Телим булырга мин инсане гали бөек кеше,*
*Тели күңлем тәгали биттәвәли туктаусыз күтәрелүне.*

*Күңел берлән сөям бәхетен татарның,*
*Күрергә шаһлыгын, тәхтен татарның.*

Юк шул, соңгы ике юл, «4 нче дәфтәр»гә сылтап, «Күрергә җанлылык вактын татарның» дип «төзәтелгән». Чөнки, алла сакласын, Тукай татар халкының мөстә-

кыйльлеге мәсьәләсен күтәрә бит! Ә беренчел чыганакка мөрәҗәгать итмәскә без күптән өйрәнгән инде!

Хуш. Инде килеп Тукайның «Мөридләр каберстаныннан бер аваз» шигыренә (1906) тукталыйк. Андагы ике юлны шагыйрь әллә язган, әллә юк: бернинди тәкәллефсез умыра килдек. 1985 елгы басмада да юк алар, әмма анда инде сынык җәяләр пәйда булып, эченә мул итеп күп нокта сибелгән. Монысы да «казаныш». Ә ул ике, урысча әйтсәк, «многострадальный» юл татар әдәбияты классигы, олуг әдибебез Гаяз Исхакый һәм аның «Ике йөз елдан соң инкыйраз [бетү]» дигән мәшһүр әсәрен телгә алган иде.

*Дөрест гыйбрәт вирде безгә «Инкыйраз»нам [исемле] бер әсәр,*
*Аh, буны язган кеше инсан [чын кеше] икәндер белмәдем.*

Менә тагын бер мисал. Тукайның 1907 елда язылган «Бер татар шагыйренең сүзләре» дигән әсәре бар. Андагы бер строфада шагыйрь тәвәккәллекләре өчен беркадәр симпатия белдергән эсерлар (социалист-революционерлар) телгә алына:

*Куркъмаслыкта күңлем мисле [төсле] «эс-эр» минем,*
*Күңлем дүзәх [тәмуг], аузымнан ут чәчрәр минем.*
*Дошман бозмый фикерем, уем җәмгыятен,*
*Аңар каршы керпекләрем гаскәр минем.*

Бусы тагын ни дигән сүз, Тукай эсерлар ягына «каера» түгелме соң? Әлбәттә, бу юлларга да урын бирелмәде. Хәер, 1985 елгы басмада алар беренче мәртәбә искәрмәдә генә булса да торгызылган, шөкерана кылыйк.

Күбрәк урын алса да, бөек шагыйребезнең тагын бер әсәренә тукталыйк. Ул «Тәмсил», ягъни «Мәсәл», «Чагыштыру» дип атала һәм «Г. Т.» имзасы белән «Вакыт» газетасының 1912 ел, 7 ноябрь санында басылган.

ТӘМСИЛ

I

Әһле Балкан кечкенә бер эт иде,
Төркия күктә очар бөркет иде.
Һәр заман торды бу көнче эт өреп,
Күктә очкан солтанәт [мәһабәт] кошны күреп.
Өрде, өрде, кошны иткән күк харап,
Торды пычрак аузы күкләргә карап.
Хөр вә шат, якты фәзада [күктә] кош оча,
Койрыгын болгап җылый эт: эч поша.
Эт улый мәшьүм [шомлы] вә тырный үз битен,
Бәдбәхет, чәйнәргә хәзер үз итен.
Ошбу күренеш башкаланмый күп заман,
Төркия хәле, гүзәл, этнең яман.
Очты бөркет киң һавада хөр вә шат.
Кәгъбә [тоткан юл] шат, милләт вә шат, солтан рәшад [туры юлда].

II

Әллә кем аткан тирән бер ярадан,
Билгеле бер саеде [ау] мәльгунәдан
Кош төшә җиргә (бу мәгълүм язмый ук),
Кәрлә этнең, көнче этнең аузынук.
Шунда да курка һөҗүмгә эт сәфил [түбән, хур],
Читтән әйткәнне көтә: «Өсс!» яки «пиль!»
Чөнки шанлы кош чокып алса күзен,

III

«Пыль» диде, кемнәр җибәрде өстерәп,
Сугыша маэмай койрыгын селкеп, өреп...

Ошбуны «изге, кирәк бер кан» диләр,
Сугыша Инҗил белән Коръән диләр.
Алдый алмаслар халыкны юк белән,
Монда хәзрәтләр сугышмый поп белән!

Бу мәсәлне укучы бер генә совет чоры басмасында да тапмас. Аны Тукай бөтенләй «язмаган». «Тәмсил» Төркияне зурлый, аңа мәдхия җырлый, ә Балкан илләрен (Болгария, Сербия, Греция һәм Черногория) кимсетеп сурәтли. Тукайның Төркия дәүләтенә булган симпатиясен укучыларга җиткерүдән дә зур җинаять бар идеме соң? Әйтерсең, күптән түгел генә безнең сәясәттә шул ук Югославияне (Сербия белән Черногория шуңа керә) эт итеп сүгү булмады да. Кытай, АКШ, Израиль һ. б. мәмләкәтләргә «затлы» эпитетлар тагылмады. Кем әйтмешли, әйтсәң сүз, төртсәң күз... Ә без андый шигырь барлыгын белмибез дә икән!

Тукайның балаларга атап язган дистәләгән берсеннән-берсе гүзәл шигырьләре турында әйткән дә юк. «Ходай», «рәсүл», «дога» һ. б. ш. дини сүзләр еш очраганлыктан, алар балалар әдәбиятына гына түгел, 70 еллар дәвамында академик басмаларга да кертелмәде. Чөнки ярамый, Тукай дингә мөкиббән киткән зат була. Шагыйрьне шомарттык, яңа җиз самавыр кебек ялтыраттык, төзәттек, ыспайладык, бүгенге заман каланчасыннан гына торып бәя бирү өлкәсендә тәмам каешланып җиттек. Ул аны атеист итү дисеңме, социал-демократ ясау дисеңме... берсе дә калмады. Без әдипнең иҗтимагый карашларын шик-шөбһәсез беренче планга куярга, шигърият диңгезендә гаувәслар (су төбенә төшеп әйберләр чыгаручы.— Р. Э.) булуны арткы планга этәрергә өйрәндек. Кызганыч, бу мәсьәләләргә киңрәк тукталырга мәкаләнең кысалары мөмкинлек бирми. Бу урында шуны гына әйтеп китәм: әгәр без шагыйрь иҗаты турында камил төшенчә аласыбыз, тулы мәгълүмат хасил итәсебез килә икән, кичекмәстән беренчел чыганакларга кайтырга тиешбез. Сүз Тукай әсәрләренең биш томы турында гына түгел, Г. Ибраһимов әсәрләренең сигезтомлыгы һ. б. турында да бара. Күп нокталарга, сынык җәяләргә иялəнгән күзләргә яңа, сыйфатлы азык кирәк.

Соңгы мисал. «Аң» журналының 1912 ел 1 (15 декабрь) санында Г. Тукайның «Аң» исемле шигыре басыла. Ул «Без Бишенче елны бер көнне уяндык таң белән» дип башлана. Шушы журнал варианты бүгенгә кадәр безнең барлык басмаларда да үзгәрешсез урын ала килде. Ник? Сәбәбе миңа караңгы. Шулай да «Аң» журналының 1917 ел 3—4 (20 апрель) санына игътибар итү зыян булмас. Чөнки гыйбрәт алырлык хәлләр бар. Анда әлеге шигырь тулысынча торгызылган килеш кенә түгел, редакциянең мөһим искәрмәсе белән дә басылган.

«Бу шигырь мәрхүм шагыйремез Габдулла Тукаев тарафыннан «Аң»га багышланып, журналымызның беренче елгы беренче санында дәрҗ ителгән [урнаштырылган] иде. Ләкин ул шигырьнең икенче мисрагыннан [шигырь юлыннан] дүрт юлы шул вакытларда матбугатымызны борындыклап алып, үзләренең каты хөкемнәрен йөрткән мәрхәмәтсез цензорлар тарафыннан журналымызда басарга манигъ ителеп [тыелып], төшереп калдырылган иде. Инде без мәзкүр [әйтелеп үтелгән] шигырьне *хәзерге көннәрнең рухына бик якын тапканымыздан* (курсив безнеке — Р. Э.), тулы бер мәгънәне аңлатсын өчен бөтенләен бер юлы шагыйрьнең идарәмездә сакланган мөсәүвәдәсеннән [караламасыннан] гайнән [үзгәртмичә] күчереп, «Аң»га тәкрар [кабат] дәрҗ итәмез. Цензор төшереп калдырган дүрт юл калын хәрефләр белән басылды. Идарә».

Менә ул юллар:

*Кем бу гафләттән [гамьсезлектән] итә файда шуны күрдек торып,*
*Шундый төнге аучыларның өстенә йөрдек торып,*
*Галибанә [җиңүчеләргә] качырдык, барчасыны сөрдек торып,*
*Чөн [чөнки] дә Чыңгызча сугышка башладык дошман белән.*

Белмим, бәлки безнең мөхәррирләрне «Чыңгызча сугышка башлау» гыйбарәсе өркеткәндер...

Кыскасы, «Аң» идарәсенең 1917 елгы Февраль революциясеннән соң кылган бу мактауга лаек гамәленнән безгә бүген үрнәк алырга кирәк. Үзгәртеп кору, яңару, ак тапларны бетерү заманында Тукаебыз иҗатын тулысынча торгызып, халыкка кайтарырга вакыт шаять бик җиткәндер.

**Равил ЭМИРХАНОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

Китап күзәтү

# СӘХИФӘЛӘР КАЛКА ТАРИХТАН

**Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романының икенче китабы чыгу уңаеннан**

Тарихи әсәрләр иҗат итүче язучылар әдәбиятыбызда күп түгел. Нурихан Фәттах — алар арасында иң танылганы.

Уклар төз һәм ерак очсын өчен җәя кирәк. Укны җәя корал итә. Җәяң ышанычлы булсын дисәң, ашыкма, аны озак сайла, ныклап сына. Н. Фәттахның «җәя»се исә ышанычлы булып чыкты. Әдип кабаланмаган, үзенә кирәкне сабыр гына эзләгән, җыйган, өйрәнгән. Тарихи әсәр язуның икеләтә җаваплы эш икәнен яхшы аңлаган. Ул, каләм остасы булу белән бергә, билгеле бер дәрәҗәдә галим һәм тарихчы буларак та иҗат итә. Шушы караштан чыгып, барлык шартларга һәм таләпләргә аерым-аерым тукталганда, әсәргә бирелгән исемнең мәгънәсе икеләтә мөһим икәнлегенә дә ышанасың.

Теләсә нинди ук сызгырмый. Сызгырса — әсәр башкачарак аталыр иде. Авторның әсәренә әлеге исемне бирүенең фәнни нигезе бар. Кыскача әйткәндә, сызгыручы уклар — борынгы сөннәрнең (яки һуннарның) сугыш сәнгатендәге тарихи казанышы, археологиядәге визит карточкасы ул. Авторның бу хакыйкатьне ярты юлда ук ярып салмавы, билгеле бер дәрәҗәдә, әсәрнең кызыксындыру көчен арттыра. Укучылар тарихи сергә 380 нче биттә генә килеп җитәләр һәм менә шул чакта инде тагын да бер кат әсәрнең укылган өлешен искә төшерү, казанышка ирешүнең катлаулы озын юлын тирәнтен фикерләү мөмкинлеге туа. Нурихан ага Фәттахның тарихи чыганакларны яхшы белүе, археологик характердагы хезмәтләр белән таныш булуы, гыйльми эзләнүләре зур ихтирамга лаек.

Безнең эрага кадәрге I меңъеллыкның соңгы чиреге — Төньяк Себердә һәм Үзәк Азиядә этно-социаль процессларның кискен җанлану чоры. Әсәрдә сурәтләнгән заман (III гасырның ахыры — II гасырның башы) политик вакыйгаларның б. э. к. байлыгы белән дә кызыклы. Халыкара аренага һун урдалары (әсәрдәге сөннәр) калкып чыга; аларның хәрәкәте регионндагы этно-социаль үзгәрешләргә зур йогынты ясый, күп кенә борылышларга сәбәпче була. Һуннарның роле бу җирләрдә генә чикләнми, соңрак Европага да үтеп чыга.

Нурихан Фәттахның һуннар тормышын яктырткан әсәр иҗат итүе очраклы хәл түгел, әлбәттә. Биредә элегрәк язылган «Әтил суы ака торур» романы һәм аның бәхетле язмышы да үзенең эчке йогынтысын ясагандыр. Чөнки болгар бабаларыбызның борынгы һуннарга турыдан-туры бәйләнеше бар — Төньяк Кавказ, Дон, Азов буйларында «Бөек Болгар» дип аталган кабиләләр союзы барлыкка килгәнче (безнең эраның VI гасыр ахыры), Кубрат хан чорына тикле күп гасырлар элек болгарлар һуннар кабилә берләшмәсе составына кергәннәр. Ул чор чыганакларында һәм бераз соңрак, борынгы Византия тарихчылары Прокопий, Агафий һәм Менандр язмаларында, алар утригур һәм контригур кабиләләре буларак билгеле.

Һуннар үзләре — составына төрле кабиләләр кергән, этник яктан шактый чуар булган берләшмәнең үзәген тәшкил итүчеләр һәм бу берләшмә тулысынча аларның исеме белән аталган. Ул башлыча төркиләрдән, шулай ук монголлардан һ. б. халыклардан торган. Берләшмәдә хакимлелек иткән һуннарның да, башкаларның да бу бердәмлеккә ихтыяҗлары бигрәк тә сугыш куркынычы алдыннан сизелерлек көчәйгән. Әсәрдә дә вакыйгалар шушы кысада яктыртыла.

Шул ук вакытта, югары катлау вәкилләрендә бердәмлеккә карата мөнәсәбәтнең төрлечә булуы да чагыла. Бу җәһәттән Исәнтәй һәм Албуга образларының бирелеше, Сырга бикә белән Тутыя бикә арасындагы диалог игътибарга лаек.

Әсәрдә шулай ук борынгы һуннардагы сәүдә мөнәсәбәтләренә дә урын бирелгән. Мәсәлән, кыпчакларның сөннәргә затлы тиреләр, эретелгән һәм чүкелгән бакыр, алтын, тимер алып килүләре, ә алмашка йон, ефәк, киндер, тукыма, савыт-саба һ. б. алып китүләре турында телгә алына. Урынлы бу. Әдәбилеккә дә куш була, укучының тарихи фикерләвен баетуга да өлеш кертелә. Ул тирәләрдә яшәгән, көн күргән халыклар, әйтик, Алтай төркиләре, Енисей кыргызлары (борынгы ха-

каслар) һәм шул исәптән әлеге кыпчаклар борын-борынгыдан мәгъдән осталары буларак танылганнар. Мәгъдән эшкәртү, гомумән, һуннарда югары үсешкә ия булган. Урынның тимер һәм бакыр рудаларына бай булуы моның өчен бик ышанычлы нигез. (Мәсәлән, һуннарга караган Түбән Иволгинко шәһәрендә археологик казулар вакытында бик әйбәт сакланган тимер эретү мичләре, шлак һәм әзер продукция калдыклары табылды).

Әйтергә кирәк, һуннарны бары тик рәхимсез сугышчылар итеп кенә күрүчеләр дә, алдынгы цивилизацияләрне җимерүче варварлар итеп караучылар да булды. Аларны монгол яуларына тиңләштерүчеләр дә юк түгел. Дөрес, һуннар күп җирләрне яулаганнар, монголларга кадәр мең еллар чамасы элек алар үтәчәк юлны (нигездә) үткәннәр, алар кебек үк бөтен Европаның котын алганнар. Шулай да бу халыкларның тарихта үз урыннары бар.

Әлеге ике халык турында сүз чыкканда иң элек алар арасындагы охшашлыкларга игътибар итү зарур. Шуларның берсе күчмә терлекчелеккә нигезләнгән җитештерү ысулында чагыла Ә менә бу җитештерү ысулының кайсы һәм нинди чорга туры килүен ачыклау — тарихи үсешне фикерләүдә иң әһәмиятле һәм мәҗбүри адымнарның берсе.

һуннарның хәрәкәте, вакыт-вакыт агрессив юнәлештәге сәясәткә нигезләнүгә дә карамастан, билгеле бер дәрәҗәдә прогрессив әһәмияткә ия. Укучыларның моңа төшенә алулары бик мөһим. Автор әсәр өстендә эшләгәндә бу мәсьәләгә төп игътибарын юнәлткән. һуннарның басып алу походлары кайбер илләрдә (Греция, Рим, Кытай) колбиләүчелек строе хөкем сөргән чорга туры килә. Алар алып барган сугышлар әлеге стройны җимерүдә әһәмиятле роль уйный. Гомумән, һуннарның, бу процесста өлеше зур. Эчтән череп таркалган Кытай колбиләүчелек җәмгыяте һуннарның ешая барган һөҗүмнәре аркасында тәмам җимерелә һәм анда Европага караганда берничә гасыр элек феодаль мөнәсәбәтләр формалаша башлый һәм III—IV гасырларда инде ныгып диярлек урнаша. Безнең эра башында ук көнбатышка хәрәкәт башлаган һун урдалары халыкларның Бөек күчеше башлануына зур этәргеч бирәләр, башка халыкларны кузгатып, бөтен Көньяк Себер, Каспий һәм Кара диңгез буе далаларын үтеп, IV гасыр ахырында (377 елда) Рим империясе чикләренә килеп җитәләр. Башка халыклар белән бергә, Рим колбиләүчелек дәүләтенең җимерелүенә (476 ел) зур өлеш кертәләр. Ниһаять, заманында классик үсеш дәрәҗәсенә ирешкән консерватив строй бәреп төшерелә, Европада феодализм дәверенә киң юл ачыла. Әлеге факторларны күзаллаганда тагын бер кат һун яуларының прогрессив әһәмиятенә төшенергә мөмкин.

Бу романдагы Албуга — тарихи шәхес. Ул шулай ук Модэ исемле һун каганы буларак билгеле. Мәгълүм булганча, Модэ властька әтисе Туман каганны үтерткәннән соң (б. э. к. 209 елда) килә. Әсәрдә бу вакыйга шактый кызыклы гына тасвирланган (390 бит). Нәкъ менә шул Модэ вакытында һуннарның басып алу походлары җәелеп китә дә инде.

Романның бу китабы Туман каганның кытайлардан ачы җиңелү газабы татуыннан башланып китә һәм ахырда Албуга сөннәренең тантаналы җиңүләре белән тәгәлләнә. Әсәр аңлаешлы, гади тел белән язылган. Гомумән, Н. Фәттахның тарихи жанрдагы иҗатына, безгә калса, гадилек һәм үсә барган мавыктыручанлык хас. Гадилектә — даһилык. Балачактан алып «Әтил суы ака торур» романын ничә тапкыр укып чыкканымны төгәл генә әйтә алмыйм. Әмма иманым камил: тарих белән җенләнеп китүемдә шушы әсәрнең дә «гаебе» бар дисәм — һич тә арттыру булмас...

һун җәмгыятендә патриархаль-ыруглык мөнәсәбәтләре көчле булган. Ф. Энгельс билгеләп үткәнчә, ыругның килеп чыгуында гаилә мөнәсәбәтләренең тамырдан үзгәрүе, аерым алганда пуналуаль гаиләнең барлыкка килүе зур роль уйнаган. Кыскача әйткәндә, бу күренешнең асылы — ата-аналар тарафыннан үз балалары арасында үзара никахның катгый тыелуыннан гыйбарәт. Тарихи үсешнең, үзгәрешнең билгеле бер баскычында ике община аерылып чыга: беренчесен хатын-кызлар, ә икенчесен ирләр тәзи. Никах ике общинаның барлык членнары арасында да бара, тик бу ике общинага кергән бертуганнар (ир һәм хатын-кыз) арасында катгый тыела. Шулай итеп, ирләрнең (үз кыз туганын исәпкә кертмичә) уртак хатыннары булган кебек, хатын-кызларның да (үз абыйларыннан башка) уртак ирләре булган. Ф. Энгельс фикеренчә, әлеге гаилә мөнәсәбәтләре Рим һәм Греция (бирегә Кытайны да өстик) колбиләүчелек дәүләтләрен чолгап алган барлык варварларга да хас.

Әйтергә кирәк, Нурихан ага бу мәсьәләне дә игътибарсыз калдырмаган. Укучы өчен бик әһәмиятле белешмә бу, уйландыра торган хәлләр. Әсәрдә күренгәнчә, әлеге тип гаилә мөнәсәбәтләренең калдыклары һәр халыкта да һәм бу халыкның һәр катлавында да көчле булган. Гади халыкка килгәндә, Кондыз картның Сылу кызга ясаган тәкъдиме... («өең иркен, үзең яшь, ырудашың синдә кунар...» — 15 б.) кызыклы. Шуңа ук өстәп, тагын Сылу кызның, ирен каршылаган сыман, Камашка киемнәрен салырга булышуын әйтергә мөмкин (17 б.).

Әйткәнебезчә, югары катлау (сыйныф дип аңларга кирәкми) вәкилләре дә иске гаилә мөнәсәбәтләре калдыкларыннан арына алмаган. Игътибар итик — Елдырым бәк Күрекле бикәгә әнә ничек җавап бирә: «Кияүнең энесе Адай белән кызым Алтын Бөртеккә аерым өй корырбыз, торырлар бергә кияү кайтканчы...» (180 б.) Яки, мәсәлән, Албуганың чин Чунга җавабы: «Туганнарның уртак кызга ир

булуы бездә язык саналмый. Бу безнең борынгы йола». (231 б.)

Этнографик күзлектән караганда, әсәр — борынгы сөннәрнең тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен тасвирлаудан гыйбарәт. Шулардан берсе — үлгәннәргә корбан бирү ритуалы. 25—28 битләрдә сүз Аю-Мамакның ачы язмышы — аның корбанга чалынуы турында бара. Вакыйга шулкадәр оста тасвирланган ки, ирексездән үзеңне тамаша кылучылар арасында хис итәсең. Шунда ук тагын бер кызыклы деталь бар — утка ташланган чыбык, йомычка яки утын агачының үлгән кешене алыштыруы турында сөйләнә. Мөгаен, бу — элегрәк булган мәетне яндырып күмүнең (кремация) сакланып калган бер эзедер. Укучылар шулай ук сөннәрдәге мәет җирләү йоласының үзенчәлекләре белән таныша алалар. Бу шулай ук мөһим, чөнки билгеле бер сәбәпләр аркасында (фәнни стильнең үзгә булуы, тиражның азлыгы h. б.) киң катлау укучыларның бу мәсьәлә буенча махсус әдәбият белән танышу мөмкинлеге аз. Романның азагына җитәрәк, Туман каганны җирләү вакыйгасы тасвирланган. Әлеге процессның һәр детале (җирләү өчен ике катлы бура әзерләү, бит өлгесе h. б.) фәнни яктан — археологик табылдыклар һәм материаллар белән нигезләнә ала.

Археологик материал дигәннән, сурәтләнгән чор турында әлеге фән күзлегеннән дә берничә сүз әйтеп китәргә кирәктер.

Безнең эрага кадәр III гасыр ахыры — II гасыр башында Көньяк Себердә һәм Үзәк Азиядә яшәүче кабиләләрнең тормыш-көнкүрешендә зур үзгәрешләр була. Бу вакытта, югарыда телгә алынганча, һуннарның Модэ (Албуга) җитәкчелегендәге кабиләләр союзы тәмам көчәеп китә. һуннар Үзәк Азияне яулап алалар һәм б. э. к. 205—201 елларда Хакас иңкүлегендә яшәп яткан, утрак терлекчелек һәм игенчелек белән шөгыльләнгән Тагар археологик культурасы кабиләләренә ябырылалар. Нәтиҗәдә, бу кушылудан яңа — Таштык археологик культурасы барлыкка килә. Бу культураның төп үзенчәлекләреннән берсе — мәрхүмнәрне зур курчаклар белән җирләү. Шундый курчаклар, аяк киемнәре һәм кеш бүрекләре күп күләмдә Оглахтино каберлегендә табылды. «Сызгыра торган уклар»да бу йолага кызыклы ишарә бар (394 б.).

Кабилә союзлары (берләшмәләре) оешу — дәүләт барлыкка килүнең иң мөһим баскычларыннан берсе. Ул — социаль тигезсезлек яралгыларының килеп чыгуы белән бергә бара торган процесс. Шул ук вакытта тышкы сугышларның роле дә арткannан-арта бара. Туман каган, аннан соң Албуга җитәкләгән сугышларны чагыштырганда моны истә тотырга кирәк.

Албуга каган алып барган сугышлар азатлык хәрәкәтенең чиген үтеп чыга һәм киләчәктә турыдан-туры, ачыктан-ачык талау һәм баю максатында алып барган сугышларга әйләнеп китә. Автор романның ахырында моны тулысынча ачып биргән. Социаль тигезсезлек үскәннән-үсә бара. Албугага кадәр ук, Иммат картның улы Җидекулга әйткән сүзләрен генә искә төшерик: «...Унбашы булмагае, кирәгем исә мең башы, түбән бәге бул,— син барыбер кара булып калачаксың. Онытгыңмыни шуны?»

Албуга каганның тышкы уңышлары — һун армиясендәге үзгәртеп корулар җимеше. Уклар да үз сүзләрен әйтәләр, каганның кырыс холкы да зур роль уйнаган. (Игътибар итик, Албуга башбаштаклыкны ничек күрә алмый, аяусыз бастыра, ирләренең башларын өзә. Кытай елъязмалары Модэнең ыругбашлар белән булган аңгәмәсен җиткерәләр: Модэ үз ыругбашларыннан киңәш сорады: «Дунху ясак итеп җир сорый. Нихәл итик?» Ыругбашлар: «Җир уңдырышсыз, бирсәк тә була, бирмәскә дә мөмкин»,— дип җавап бирделәр. Модэ ачуланып әйтте: «Җир — дәүләтнең нигезе, аны ничек итеп бирмәк кирәк?!» Шуннан соң ул бирергә диючеләрнең башларын өзде...» (Бичурин И. Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена.— СПб., 1851; П изд. М. —Л., 1950, т.т. I — П.—13 б.). Модэ (Албуга) чорында варислык хокукы ныгып урнаша. Аксакаллар советы тик формаль роль генә уйнаган.

Югарыда телгә алынганча, әсәр кытайларның җиңелүләре белән тәгаллана: «Әйе, җиңелделәр. Хур булдылар. Хәзер инде барыбер түгелмени? Җиңелү, бәлки, чынлыкта җиңүдер әле ул. Һич югы моннан соң инде яуга кумаслар, өйдән, хатыннардан, балалардан аермаслар. Шулкадәр җиңелү хурлыгы татыган патшалар да моннан соң күрәләтә үлемгә атлыгып тормаслар лабаса». Уңышлы финал! Ул дөньябыздагы хәзерге вакыйгаларга, халыкара климатка бик аваздаш, актуаль яңгырый, укучыны искәртә.

Илебез халыкларының тарихка карата булган мөнәсәбәтләре үзгәрүе, җанлануы, үткәннәр белән кызыксынуның көчәюе — чорыбызның яңа үзенчәлеге. Мондый шартларда тарих фәненең һәм әдәбиятның әһәмияте бермә-бер артты. Тарихи әсәр иҗат итү — изге эш, халкыбызга һәм аның тарихына бирелгәнлек билгесе. Аз булса да, безнең үз Дюмаларыбыз бар. Нурихан агага ныклы саулык, иминлек һәм изге эшендә олы уңышлар телибез.

**Илшат ХӘЛИУЛЛИН,**
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият
һәм тарих институтының
кече фәнни хезмәткәре.

**Фәридә Шәрифуллина,**
тарих фәннәре кандидаты.

# КАСЫЙМ ТАТАРЛАРЫ

Урта Идел һәм Урал буе татарлары казанлыларга, мишәрләргә һәм кайбер башка этник төркемнәргә бүленә. Шуларның берсен — иң көнбатыштагысын — касыйм татарлары тәшкил итә. Алар Рязань өлкәсенең Касыйм шәһәрендә һәм шул төбәктәге 17 авылда яши. Көньяк-көнчыгышта, бу төркем урнашкан җирләрдән ерак түгел, мишәр-татар авыллары да бар.

1979 елгы сан алу мәгълүматларына караганда, алар күп түгел — 1040 кеше. Аларның бер өлеше шулай ук илнең төрле шәһәрләрендә — Ленинградта, Мәскәүдә, Рязаньда, Ташкентта яши. Элегрәк касыйм татарлары шактый күбрәк иде. XVIII гасыр ахырында алар 5999 кеше, XIX гасыр ахырында 4764 кеше булган.

Телләре буенча урта диалектның бер сөйләмен тәшкил итсәләр дә, тарихи язмыш касыйм татарларын халкыбызның башка төркемнәре арасында сизелерлек аерган. Аларның формалаша башлавы XV гасыр уртасына, Мәскәү дәүләте территориясендә, Мещера җирендә үзәге Касыйм шәһәре булган татар ханлыгы барлыкка килгән чорга карый. Элек Городец яки Городок Мещерский дип йөртелгән бу шәһәр хан улы Касыйм исеме белән аталган. Касыймга аны князь Василий Темный биргән. 1487 елда рус гаскәрләре Казанга яу чыкканнан соң, мәскәүлеләр Касыйм феодалларын үзләренең хәйләкәр политикасында күндәм корал итеп файдалана башлыйлар. Рус хөкүмәте алар кулы белән Казанны да Мәскәүгә шундый ук бәйлелеккә төшерергә тырыша.

Касыйм ханлыгы ике йөз елдан артык, XVII гасырның соңгы чирегенә кадәр яши. Аның җирләре Касыйм шәһәре тирәсендә 200 чакрымга, Краснослободск, Темников шәһәрләренә кадәр сузыла һәм Касыйм, Елатомск, Шацк, Темников өязләрен эченә ала. Ханлыкның административ чикләре шартлы булган, алар, ихтимал, йомышлы татарларның биләмәләренә бәйле булгандыр. Йомышлылар Рус дәүләтенең тышкы сәясәтендә һәм эчке бурычларын хәл итүдә актив катнашканнар. Касыйм патшалыгының урыны ук касыйм татарларын Рус дәүләтенең Ока елгасы буендагы чикләрен саклауда файдалану өчен бик уңай булган. Татар князьләре һәм казаклары көнчыгыштан һөҗүмнәргә каршы киртә булып торганнар. Йомышлы татарлар отрядларга берләшкән, отрядлардан аерым полклар, кайвакыт зур гаскәр дә оешкан, алар русларның күп кенә хәрби походларында катнашканнар. Мәсәлән, 1534 елда алар рус гаскәрләренең Литвага походында катнашканнар, 1487, 1505, 1551-1552 елларда Казанга, 1555 елда шведлар өстенә, 1557 елда Ливониягә яу барганнар. Моннан тыш рус хөкүмәте татарларны тылмачлар, дипломатик вәкилләр итеп тә файдаланган. Аларны Урдага баручы илчеләр белән озатканнар, кайчакларда грамоталар белән, сөйләшүләр алып бару өчен үзләрен генә дә җибәргәннәр. Хезмәтләре өчен бүләк итеп аларга җир биләмәләре бирелгән, еш кына бу җирләр нәселдән-нәселгә тапшырылган. Җирләргә татарлар төркемләп яки аерым-аерым хуҗа булганнар. Үз чиратында биләмәсе булган йомышлы татар үзе, гаиләсе шуның исәбенә яшәргә, аты, коралы белән походка чыгарга әзер торырга тиеш булган.

Касыйм дәүләте удел тибындагы вассал князьлек тәшкил иткән һәм ханнарның хокукы нык чикләнгән.

Ханлыкның экономикасы Рус дәүләте экономикасы белән тыгыз үрелеп формалашкан, үскән. Хуҗалык эшчәнлегенең нигезен игенчелек тәшкил иткән һәм ул бер үк вакытта малтуар асрау белән бергә барган. Татарлар кыргый кортлар балын җыюдан күп файда күргәннәр, аучылык белән шөгыльләнгәннәр. Елга-күлләр күп булу сәбәпле балыкчылык та шактый роль уйнаган.

Халыкта төрле һөнәрчелекнең дә киң урын алганлыгы мәгълүм. Касыйм остлары тире, йон, металл һәм таш эшкәртүгә бәйле һөнәрләрнең серен белгәннәр. XV-XVI гасырларда алар тарафыннан ясалган патша киемнәрен һәм коралларны хәзерге көндә Дәүләт Тарих

музееның корал палатасында күрергә мөмкин. Ак таштан сарайлар, мәчетләр, мавзолейлар салганнар, аларның кайберләре безнең көннәргәчә сакланган.

Касыйм татарлары эшлекле сәүдәгәр буларак танылганнар. Кайбер өстенлекләрдән дә файдаланганнар, мәсәлән, аларга Россиянең теләсә кайсы төбәгендә сәүдә-предпринимательлек эше алып бару хокукы бирелгән.

Соңрак касыйм татарлары өстенлекләрен югалта башлыйлар. Казан ханлыгы яулап алынгач, Касыйм ханлыгының буфер дәүләт буларак роле кими. 1681 елда, регентша Фатыйма-Солтан вафат булгач, Касыйм ханлыгы бетерелә, ә татарлар турыдан-туры Мәскәү тарафыннан идарә ителә башлый.

Рус хөкүмәте XVIII гасырның беренче яртысында рус булмаган йомышлы кешеләрнең җир биләвен бетерүгә юнәлдерелгән берничә фәрман чыгара. 1713, 1715 елгы фәрманнарда биләмәләре, вотчиналары булган мөселманнарны чукындырырга боерык бирелә, шулай эшләмәгәндә җирләре патшага яки чукынган туганнарына күчә. Йомышлы татарларның бер өлеше (Кастровлар, Ширинскийлар, Тургеневлар һ. б.) христиан диненә күчәргә мәҗбүр була. Соңрак алар рус буржуазиясе составына кереп китәләр.

Касыйм татарларының сәяси һәм социаль-икътисади тарихы үзенчәлекләре аларның этник үсешенә дә эз сала. Күп кенә тикшеренүләрдә аларның килеп чыгуына шактый урын бирелә. Бу темага бәйле мәсьәләләрне мишәр татарлары этногенезы белән тыгыз бәйләп карау дискуссия характеры алды. Галимнәрнең зур өлеше (нигездә революциягә кадәр һәм безнең гасырның егерменче елларында яшәгән галимнәр) — В. В. Вельяминов-Зернов, Г. Н. Әхмәров, В. Н. Гордлевский, Б. А. Куфтин, С. П. Толстов касыйм татарларын мишәрләргә кертәләр һәм (Г. Н. Әхмәровтан башкалары) аларның килеп чыгышында фин-угыр гипотезасын яклыйлар. Кайбер галимнәр (XX гасырның 40-80 нче еллары)— антрополог Т. А. Трофимова, тарихчылар А. Х. Халиков һәм Д. М. Исхаков касыйм татарларын аерым төркем итеп аералар. Тел белгече Л. Т. Мәхмүтова, этнограф Н. И. Воробьев аларны казан татарларына якын куялар. Бу проблеманы тикшерүчеләрнең һәммәсе диярлек касыйм татарларының төрки чыгышы ягында, шул ук вакытта фин-угыр компоненты булу мөмкинлеген дә инкарь итмиләр.

Касыйм ханлыгы урнашкан җирләрдә фин, славян һәм төрки кабиләләре яшәгән. Ул якка иң элек килеп утыручылар фин кабиләләре. Идел буенда һәм Югары Идел белән Ока арасында алардан Дьяков һәм Городец иseme белән йөртелгән шәһәрлекләр калган. Мордва халкы Городец культурасын калдырган кабиләләрнең бер дәвамчысы булып тора. Мордвалар Мещера шәһәрчеге тирәсендәге җирләрдә бик күптәннән яшәп килгән. Алардан калган курган, каберлек эзләре татарлар яшәгән Темгенево, Мунтово, Собакино авыллары тирәсендә хәзер дә сакланып калган.

XVI гасырда мордваларның бер өлеше, касыйм татарларыннан үзләштереп, ислам дине тоткан һәм татарлар белән катышып та киткән булса кирәк. Мордвага якын яңгырашлы кайбер атамалар аларның кайчандыр Касыйм өязендә яшәгәнлеген күрсәтә. Касыйм татарлары арасында әле хәзер дә Ирзин дигән фамилия очрый. Сапаровлар, Минеевлар нәселе мордвадан килә. Шулай ук мариларның да (чирмешләр) эзләре сизелә. Касыйм татарлары составына «мещера» кабиләләре вәкилләре дә (можарлар, мочарлар), дөресрәге, аларның ислам дине тотканнары кергән булса кирәк.

Ниһаять, Рязань җирендә яшәүчеләр борын-борыннан көньяк далаларда яшәүчеләр белән бәйләнеш тотканнар. Кыпчакларның аларга XI гасырда ук үтеп кергәнлеге мәгълүм. Р. Г. Мөхәммәтова «ц» белән сөйләшүче мишәрләрнең борынгы бабалары Кадом өязендә Касыйм ханлыгы төзелгәнче үк яшәгән, алар анда XIII гасыр ахырында — XIV гасыр башында Золотарев шәһәрлеге районыннан (Пенза губернасының көньягында) Алтын Урда халкының ташкынына кереп килгәннәр, дигән фикер әйтә.

Мишәрләрнең этногенезында катнашкан бу төрки компонентлар, күрәсең, касыйм татарларының формалашуында да азмы-күпме роль уйнагандыр. Мишәрләрнең үзләренә килсәк, алар касыйм татарлары арасында бөтенләй эреп-югалып бетмәгән.

Ханзадә Касыйм иртәп килгән дружинаның этник составы мәгълүм түгел, ләкин аларның Алтын Урдадан чыккан төрки телле кабилә вәкилләре булуы ихтимал. Бер кабилә, тел галиме Л. Ш. Арсланов фикеренчә, Кавказдан чыккан яки иберия-кавказ телләре йогынтысын кичергән. Аның Касыйм дружинасына ханзадә «чиркәс җирендә» булганда элагүе мөмкин, XV гасырда бу җирдә төньяк-кавказ этник компоненты урын алып торган. Бу кабиләнең теле төп билгеләре буенча нугай теленә, өлешчә кумык теленә якын.

Касыйм ханлыгына казанлыларның да күпләп күчүе мәгълүм. XVI гасырның беренче яртысында Казан тәхетендә өч тапкыр утырган Шаһгали белән бергә Касыймга аның Казандагы тарафдарлары да килгән. Аларның бер өлешенең 1552 елда Казан ханлыгын яулап алынганнан соң күчкән булуы ихтимал. Татар аксөякләренең ышанычсыз саналган бер өлешен рус хөкүмәте Касыйм ханлыгына сөрә. Хәзергәчә сакланган кайбер шәҗәрәләргә караганда, Акчуриннар, Максутовлар, Борнашевлар, Костровлар һ. б. бабалары Казан ханлыгыннан чыккан.

XV гасырның соңгы чирегендә, XVI гасыр башында Мещера ягында Кырым ханзадә-

ләре Нурдәүләт, Сатылган, Җанайга ияреп килгән кырымлылар күренә. Кырым татарларының бу якта төпләнеп калуы исә элегрәк тә — XIII гасырда да булган. Ширинскийлар һәм Гиреевларның чыгышы шуларга бәйле.

Идел буе татарларының касыйм этник төркеме оешуда нугайлар да катнашкан. Алар Мещерага төрле юллар белән килеп эләккән. Кайберләре нугай сукмакларыннан үткән, чөнки Русь дәүләтенең яудан саклану рәвеше моңа комачаулык итмәгән. Икенчеләре ханнар, ханзадәләр хезмәткә чакырып алган гаскәри төркемнәр белән килгән. Ярославль губернасыннан Мещерага бер төркем нугайлар килеп утырган. Аларның токымында (Алиш, Шегашан, Томтиново авылларында яшәүчеләр) нугай бабалары турындагы риваятьләр әле дә саклана. Тел галимнәре туплаган мәгълүматлар да касыйм татарлары арасында нугай этник компоненты булуы хакында сөйли. Т. А.Трофимова үткәргән антропологик тикшеренүләр Идел буендагы башка татарлар белән чагыштырганда касыйм татарларында монголларга хас билгеләрнең көчлерәк икәнлеген күрсәтте. Бу аларны нугайлар, карагашлар, казакъларга Кыпчак даласының Җучи улусында яшәгән төркемнәргә якынайта.

XVI гасырның икенче яртысыннан ханлыкның сүнә баруына рус хөкүмәтенең йомышлылар катлавын бетерүгә юнәлдергән фәрманнары да сәбәп була. XVII гасыр ахырында һәм XVIII гасырда татар тормышындагы тамырдан үзгәрешләр касыйм татарларының этник үсешенә дә йогынты ясый. Мәсәлән, 1719-1745 елларда Касыйм өязендә татарлар саны 18 процентка кими. Алар көнчыгышка, Идел аръягына һәм Урал ягына кереп утыра башлыйлар. Яңа урында алар, күченеп килгән мишәрләр һәм башка төркемнәргә кушылып, культура-көнкүреш ягыннан үзенчәлекләрен югалталар. Шул ук вакытта касыйм татарларының бер өлеше Петербургка, Мәскәүгә, (Замоскворечьедагы Татар бистәсенә) күчә. Касыйм татарларының күпчелеге рус телен һәм язуын яхшы белә. Бу авыл кешеләренә дә кагыла. Аларның сөйләшендә, бигрәк тә хуҗалык-көнкүрешкә кагылган сүзләрдә, рус алынмалары күп.

XIX гасырда — XX гасыр башында татар халкының төп хуҗалык эшчәнлеген бөртекле ашлык игү, ягъни, игенчелек тәшкил итә. Гадәттә, өч басулы чәчү әйләнеше, пар калдыру ысулы кулланыла. Касыйм татарлары хуҗалыгында элеккечә терлекчелек, умартачылык һаман да өстенлек алып торса да, балыкчылык һәм сунарчылыкка инде артык әһәмият бирелми.

Һөнәрчелекнең тоткан урыны шактый киңәя. XIX гасыр ахырында һөнәрчелек белән крестьян хуҗалыкларының 23 проценты шөгыльләнгән булса, XX гасыр башында инде бу сан 37,1 процентка җитә. Тире, йон эшкәртү киң таралган XX йөз башында һөнәрчеләрнең 4,7 проценты шул эш белән шөгыльләнә. Акча табу өчен читкә, Рәсәйнең төрле шәһәрләренә китүчеләр күп була. XIX гасырның 80 нче елларында ук эшкә яраклы ир-атларның яртысыннан күбрәге (58,3 процент) читкә китеп эшли. Аларның бер өлеше (XX гасыр башында 9,3 проценты чамасы) трактирлар, буфетлар һ. б. тота, башкалары (4,7 процент) официантлар, лакейлар, «барабасызълар, урам себерүчеләр булып эшли. Зур бер төркем (XIX гасыр ахырында 10,7 процент) сәүдә белән шөгыльләнә, башлыча тире-күн, мехлар белән сату итә.

Касыймда Татар бистәсендә XIX гасыр уртасында өяздәге бөтен татарларның 15,2 проценты яши, ә XIX гасыр ахырында 23,6 процент тәшкил итә. XV гасырда татарлар урнашкан Иске посадта кайбер урыннарына ак таш җәелгән киң Хан мәйданы була. Мәйдан буйлап Касыйм ханының һәм аның якыннары — морзалар, бәкләрнең утарлары урнашкан. Сарай каршында ак таштан манаралы мәчет торган. Риваятьләргә караганда, аны 1467 елда ханзадә Касыйм заманында салганнар.

Мәчеттән ерак түгел күп яруслы каравыл манарасы урнашкан. Касыйм манарасының хәрабәләре XVII-XVIII гасырларга кадәр сакланган, Олеарий һәм Витсен гравюраларында алар ачык күренә. Сарай белән янәшәдә Касыйм ханы Шаһгалинең таш мавзолее булган, анда табутлар, төрле бизәкләр, гарәп язулары уелган кабер ташлары сакланган. Шаһгали мавзолее һәм мәчет манарасы XV-XVII гасырлардагы татар архитектурасының иң ачык, матур истәлекләре булып торалар.

Бу корылмалардан бераз арырак, иске татар зиратында 1616 елда салынган Әфганмөхәммәт солтан мавзолее бар. Инде җимерелгән шундый мавзолей тәкыяләрнең берсендә сөембикә күмелгән диган риваять бар.

XIX гасырда Татар бистәсенең торак йортлары барысы да диярлек агачтан булган, гадәти мещан өйләреннән бернәрсәсе белән дә аерылмаган.

XIX гасыр уртасында яшәгән авыл халкы 4638 кеше булып, өяздәге бөтен татарларның 84,8 процентын тәшкил иткән, ә XIX гасырның ахырына алар 76,4 процентка калган. XIX гасыр уртасында аларның 63 авылы, гасыр ахырында 38 авылы булган. Авылларның бер өлеше «Ак аймак»ка, икенчесе «Кара аймак»ка кергән, калганнары «кара зыбыннар» дип йөртелгән. Ак һәм кара якка, яки ике зур бүлеккә аеру төрки халыклар өчен традицион булган.

Ак һәм Кара аймак авыллары, Касыйм шәһәре кебек ук, Ока елгасының сул як ярына урнашкан. Төньяк-көнчыгыштарак урнашкан Ак аймакта биш торак пункт: Подлипки, Торбай, Болотце, Царицыно, Тебеньково исәпләнгән. Алар бөтенесе дә Касыйм өязенең татар

волостена теркәлгән (Тебеньково авылыннан башка «дүрт сала» дигән гомуми исем йөрткән. Касыйм шәһәреннән көньяк көньчыгыштарак урнашкан Кара аймак 50 ләп кечерәк авылны берләштергән. Алар Касыйм өязенең Татар һәм Тау асты волостьларына, Тамбов губернасының Елатом өязендәге Малокусмор волостена кергәннәр.

«Кара зыбыннар» составына Ока елгасының уң як ярындагы сигез авыл кергән. Аларның кайберләре Касыйм шәһәреннән 8-12 чакрым да шул өязнең Бетинск волосте чикләрендә урнашкан. Калганнары (Сәет, Ананьино, Рудаково, Экса, Толстиково авыллары) елга буенча бераз түбәндәрәк, Касыймнан 40 чакрым ераклыкта. Бу авылларның бер өлеше Бетинск волостена, бер өлеше Елатом өязенең Высокая Полена волостена кергән.

Капитализм чорында касыйм татарларының социаль-экономик тормышын иңләп алган тирән үзгәрешләр этник процессларга да көчле йогынты ясый. Күчеп китү тагын да көчәя. Мәсәлән, XX гасыр башына Касыйм районында татарларның саны шактый кимү сизелә. Тормыш итәргә акча юнәтү өчен аларның шактые илнең төрле өлкәләренә китәргә мәҗбүр булалар. Бер өлеше (15 процент чамасы) төрле шәһәрләрдә төпләнеп кала. Мәсәлән, XX гасыр башында байтак касыйм татарларының Петербургка килүе теркәлгән. Зур булмаган төркемнәрнең (һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр булса кирәк) Урта Идел һәм Урал буе авылларына килеп урнашулары мәгълүм. Бу Нижний Новгород, Сембер, Казан, Оренбург губерналарында булган.

Касыймлыларның гомумрәсәй экономик тормышын формалаштыру да киң катнашулары татар халкында промышленностьның төрле тармаклары тагын да үсүгә, иҗтимагый хезмәт бүленеше тирәнәюгә, дәүләтнең аерым районнары белән даими ныклы экономик элемтәләр урнашуга китерә. XIX гасыр ахырында гомуммилли татар әдәби теле формалаша, ул мәдәни элемтәләр киңәюгә һәм ныгытуга этәргеч ясый. Мәктәпләрдә һәм мәдрәсәләрдә укыту шул телдә бара. Укытучылар нигездә Казаннан килә. Касыйм татарлары татар мәгърифәтчеләренең һәм язучыларының иҗатын яхшы беләләр. Аларның китапларын да Казаннан кайтарталар. Касыйм шәһәрендә «Аң», «Чалгы» газеталары чыга.

Октябрь революциясе җиңгәннән соң Касыйм шәһәрендә татар әдәби телендә мәктәпләр эшли, Казаннан басма әдәбият кайтарыла, татар китапханәләре ачыла, театрлар оештырыла.

Соңгы дистә елларда исә касыйм татарларының рус халкына якынаю процессы актив бара. Бергә яшәү (күп кенә татар авылларына күчеп килгән руслар да яши), бергә уку (татарлар белән руслар бер үк мәктәпләрдә, уку йортларында укыйлар), бергә эшләү культура, көнкүреш өлкәләрендә тыгыз элемтәләр урнашуга китерә.

Касыйм татарларына багышланган фәнни дискуссия барышында тикшерелгән үзәк мәсьәләләрнең берсе аларның килеп чыгышына бәйле иде. Ул хәл ителмәгән килеш калды, «касыйм татарлары фин-угырлармы яки төркиләрме, мишәрләрме яки казан татарлары мы» дигән сорауга өзеп җавап бирелмәде. Төрле чыганакларны, касыйм татарларының XIX гасыр уртасы — XX гасыр башындагы традицион матди мәдәниятен анализлау бу юлларның авторына әлеге мәсьәләне берьяклы хәл итү мөмкин түгелдер дип фараз кылырга мөмкинлек бирә. Касыйм татарлары Идел буе татарларының бер төркемен тәшкил итә, аның формалашуы һәм үсүе социаль-территориаль оешма — Касыйм ханлыгы, шунда булган һәм читтән килгән этник гомумилекләрнең бергә үрелеп үсүе шартларында барлыкка килгән. Мещера ягында Касыйм ханлыгы төзелгәнче яшәгән кабиләләр составына фин-угыр кабиләләре — мордвалар, чирмешләр, мещера кергән. Шунда ук төрки телле халыклар да яшәгән, алары мишәрләрнең борынгы бабалары булгандыр. Ә килгән халыклар, кабиләләр Алтын Урдадан, Казаннан, Кырымнан, Әстерханнан, Себердән булган. Касыйм татарларының этник яктан күп кушылмалардан торуы матди мәдәниятләрендә аларның формалашуында актив катнашкан кабиләләр һәм халыкларның мәдәнияте шактый чагылыш табуга китергән. Этнографик мәгълүматларны анализлау казан татарларының матди мәдәнияте белән зур охшашлык булуын күрсәтә, моны башка этнографлар да билгеләп үтә. Бу касыйм татарларының этник тарихында казанлыларның актив катнашуы, Казан белән Касыйм арасында тыгыз мәдәни-экономик элемтәләр булу белән аңлатыла. Әмма касыймлыларның матди мәдәнияте казанлылардан күчерелмә түгел, анда мишәрләргә, татарларның Идел буе һәм Урал ягындагы башка төркемнәренә, бүтән халыкларга тарта торган сыйфатлар да ачык сизелә.

Антропологик яктан касыйм татарлары мөстәкыйль төркем тәшкил итә. Алар үзләрен «Хан кирмән», «Касыйм татарлары» дип атаганнар. Тугандаш булуларын танысалар да, касыйм татарлары үзләрен беркайчан да казан татарлары дип тә, мишәрләр дип тә санамаганнар. Тирәләре исә, үз чиратларында, аларны «Касыйм халкы, көчимләр» дип аерып йөрткәннәр. Руслар аларны XVI гасырда ук мещеряклар, городец яки касыйм татарлары дип атаганнар.

Хәзерге көндә касыйм татарлары, Идел-Урал татарларының компактлы бер төркеме булып калган хәлдә, матди мәдәниятләренең үзенчәлекләрен, туган телләрен, милли үзаңнарын саклыйлар.

# ТАБЫЛДЫК ХАТЛАР НИ СӨЙЛИ?

Китап сөючеләрдән һәркемнең үзе генә яратып укый торган бер төр әдәбияты була. Берәүләргә мажаралы әсәрләр, детектив романнар ошаса, икенчеләр әхлак турындагы хикәяләрне якын күрәләр. Кемдер политика белән кызыксына, кемдер табигать дөньясына гашыйк. Кыскасы, һәркем үзенең уй-холкы, дөньяга карашы, белеме белән аерылып тора. Һәм аларның кулларында төрле жанрдагы китап күрү табигый хәл.

Ә менә эпистоляр повестьларга, аларның эчкерсезлегенә бер генә кеше дә битараф кала алмас, мөгаен, чөнки андый әсәрләр элек-электән халык арасында иң киң таралган стиль — хат стилендә иҗат ителә. Ә хат, белгәнегезчә, иң якын бер генә кешегә атап языла. Анда инде кешенең шатлыгы, кайгысы бар төсмерләре белән калкып чыга. Очрашып сөйләшәсе сүзне телефоннан әйтеп булмаган кебек, хатка язасы бар фикерне, уй-кичерешне дә каршыңда утырган әңгәмәдәшеңә (иң якын булса да) аңлатып бирү кыен бит. Шуңа күрә хат — вакыт узган саен кадере арта гына барган рухи хәзинә ул.

«Казан утлары» журналының 1989 елгы 9 санында басылып чыккан «Табылдык хатлар серe» дигән повесть — яраткан язучыбыз Кояш Тимбикованың иҗаты ни дәрәҗәдә икәнен тагын да яктыртыбрак күрсәтә торган көзге ул. Ялгышмасам, Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ыннан соң, бу — көтеп алган эпистоляр әсәр. Һәм, әйтергә кирәк, уңыш ягыннан да аңардан калышмый шикелле.

Повесть кайсы яклары белән укучыны әсир итә соң? Әйткәнемчә, әсәр эчкерсез һәм ихлас хатлардан тора. Шулар ярдәмендә язучы кеше күңелендәге иң нечкә кылларны тибрәтә алган. Аларның тормышчан яңгыраган самими, садә моңнары укучының күңеленә үтеп керә, сафландыра.

Хатлар ярдәмендә бөтен бер әсәр иҗат итү — икеләтә осталык сорый, минемчә. Әдәби телдә сөйләү өчен дә җаен таба язучы: кайчандыр бергә укыган ике журналист кызның бер-берсенә язган хатларын колакка ятышлы үзгә бер көйгә салып, тормышның моңлы, сагышлы, ирексездән җанга агып керә торган ачы якларын да ачып бирә.

Әсәрнең үзәге, ярыйсы ук каты, бик авырдан ватыла торган дөреслек темасына корылган. Ике журналистка да — Кәшифә белән Гөлләрия — хезмәт юлларын бер үк сукмактан башлыйлар. Ләкин район редакциясендә эшли торган Гөлләрия, Рүзәлнең алдавыч кармагына кабып, яла колы булып кала. Боларга түзә алмыйча, ул яраткан эшен һәм ире Рүзәлне ташларга мәҗбүр була. Аннан соң дәвам иткән сикәлтәле гомер юлларын сез, әсәрнең үзен укып, төшенерсез.

Кәшифә исә шәһәрдә яши. Совет кешесе буларак, үз намусы кушканча эшли ул. Ә дөреслек ярып баручыларның намуслары сөттән пакь, судан саф булса гына дулкын өстендә батмый калырга мөмкин. Кәшифә — шундыйлардан. Һәм үзендә дөреслеккә ахыргача тугрылыклы булып калырга көч таба. Моны түбәндәге мисал белән ачыклап китәргә мөмкин.

Кәшифә, тәзелештә гарипләнгән бер кызның язмышын өйрәнеп, начальникларны фаш итә һәм газетага мәкалә язып китерә. Редактор аның материалын юкка чыгаргач, тагын китә тикшерергә. Бу юлы инде кешенең намусыннан алда йөри торган акча барысының авызын каплап өлгерә һәм дөреслек шиңеп кала. Кеше хәленә «керә белгән» редактор тәҗрибәсез кызга акыл өйрәтә башлый. Кәшифә ул турыда үзенең хатында тәфсилләп болай ди: «Күңелемә һич аңлатып бирә алмаслык тирән җәрәхәт уелды. Эштән китәргә карар кылдым. Гариза яздым, аңа эштән китүемнең төгәл сәбәпләрен дә теркәдем. Кердем редакторга. Укыды. Йөзеннән кан качты, усалланды:

— Нинди мөгез чыгарырга йөрисең син? — дип кычкырып салды.— «Социаль гаделлек!» имеш! Авыл хатыннары кебек, гаделлек эзләп йөрисең, ахмак! Акылыңа кил! Моннан китсәң, сине кем, кая эшкә урнаштыра? Басылып кына эшлә! Шома темалар да бетмәгән. Яз да яз. Каләмең бар, шуңа шөкер ит! Сине урамга сөреп чыгару миңа берни тормый, үзең турында уйла: атаанасы, әллә ничә туганнары, югарыда танышлары барларга да мондый эшләр гел табылмый. Кемең ярдәм итәр? Ялгыз бит син...

Кызганыч, редакторым хаклы иде».

Кояш Тимбикованың шундый уйландыра торган юллары күп очрый әсәрдә. Язучы, менә болай эшләргә кирәк дип, күрсәтеп бирми, ә җәмгыятебездәге борчулы сораулар турында фикер алышырга урын калдыра.

Әлбәттә, әсәрне мәхәббәт утлары җылытмаса, укучыга да нидер җитеп бетмәгән кебек булыр иде. Кайберәүләр бу теманы тапталган дип әйтергә теләсәләр дә, кешелек шикелле үк борынгы, кешелек шикелле үк үлемсез мәхәббәт белән тагын бер кат очрашу, укучы күңеленә якты нурлар гына өстәячәк. «Табылдык хатлар сере»ндәге шул тема Мәхмүтнең Гөлләриягә булган сабыйларча эчкерсез мәхәббәте белән аерылып тора. Бергә уку дәверендә үзенең яратуы турында сөйгәненә бер генә мәртәбә сиздермәсә дә, Себер хәтле Себердән аңа өйләнәм дип кайтуы; Кәшифә сүзләрен игътибарга алмыйча, аны үзен көтеп ятуына ышануы — болар бар да шуны раслый. Повестьның чишелешендә дә Мәхмүтнең шушы ихлас уйларының дөрес түгеллеген Гөлләрия авызыннан ишеткәннән соң нокта куела. Шуннан соң ни булганын, хатын болай сөйли: «Мәгърур имән, гөрселдәп, җиргә ауды дип торам — Мәхмүт чирәмгә сузылып ятты да, үксеп еларга тотынды. Сүгенсен иде, мәсхәрәләсен иде мине! Юк, бер генә ачулы сүз дә чыгармады. Капланды да, өстебезгә ябырылган шомлы тынлыкны каерып ташларга теләгәндәй... «гоһ-гоһ-гоһ» дип үкси бирде».

Шундый сирәк очрый торганнардан була Мәхмүт. Аның үзенчәлекле язмышы да безне нык тетрәндерә.

Әсәр әхлакый яктан тәрбия бирүне дә күз уңында тота. Мәсәлән, Гөлләриянең хатында ул мондый юллар китерә: «Балалар, газета-журналларны күтәреп, каршыга килеп баса: апа, ник болай язылган? Сез бит алай кушмыйсыз, диләр. Җавап табып кара! Алар бит китап, газета-журнал битенә ни язылса, шуңа ихлас ышана. Җанда ышаныч булуы яхшы анысы. Тик соңыннан, шуның ялган булуын белсәләр, ни диярләр?».

Повестьның яхшы яклары белән бергә, минем карашка йомшаграк тоелган бер ягын да билгеләп узасы килә. Әйткәнемчә, үтә дә гади, хискә бирелүчән Мәхмүт Гөлләриягә булган мәхәббәтенә гомеренең соңгы минутынача тугрылыклы кала. Ләкин, Мәхмүтне характерлаган кайбер урыннарда, язучы үзе артыграк хискә бирелеп китә, ахры, кайбер сүзләр, күчәреннән ычкынып китеп, чынбарлыктан — кешене ышандыру орбитасыннан чыгып китәләр. Моны егетнең хатында ачыграк күрергә мөмкин. Ир хатыны турындагы мондый уйларны кем генә уйлый алыр икән: «Сине яратуым ташып чыкканда, аккан күз яшьләренең ләззәтен белсәң иде?» Шуның кебек хисләр тагын очраштыргалый. Бик матур сүзләр, ләкин кем адресына әйтелә бит?

Гомумән, Кояш апа Тимбикова тәрбияви яктан да, мавыктыргыч сюжеты белән дә укучы күңеленә хуш килердәй әсәр иҗат иткән.

**Айдар ВӘЛИУЛЛИН.**
Кукмара районы,
Березняк авылы.

# «КЫЙССАИ ЙОСЫФ» АСЫЛТАШЛАРЫ

Урта гасыр Шәрык шигърияте́ндә асылташлар зур роль уйный. Рүдәки, Хәйям, Сәгъди, Фирдәүси, Низами шигырьләре энҗе һәм мәрҗәннәр, ләгыль һәм якутлар белән «чигелгән». Шота Руставелиның «Юлбарыс тиресе ябынган батыр» поэмасында кырык тугыз мәртәбә энҗе, егерме өч мәртәбә кызыл якут, алты мәртәбә мәрҗән — барысы ике йөз тапкыр төрле-төрле асылташлар телгә алына. Кол Гали дә чама белән шул дәвердә яши һәм иҗат итә. Ул «Кыйссаи Йосыф» дастанын 1212—1233 елларда яза. Автор турында мәгълүматлар безгә бик аз, нигездә, менә шул әсәрдә теркәлгәннәре генә килеп җиткән. Шуңа күрә дастанны тагын да җентеклəбрәк уку һәм аның кайбер урыннарын яңача аңлату Кол Галинең кем булуын аныклый төшәргә мөмкин.

Башта ук өзеп әйтеп куйыйк: дастанда асылташлар җәмгысе утыз алты тапкыр искә алына. 429, 433, 459, 486, 496, 681[1] строфаларда йенҗү-мәрҗан, 171 , 485, 516, 526, 584 (ике тапкыр) строфаларда йенҗү, 360, 488, 864, 1004 (өч тапкыр) строфаларда гәүһәр, 518, 631, 809, 846, 864 строфаларда якут, 21, 171, 484, 496 строфаларда дөрр-ү мәрҗан, 429, 433, 486 строфаларда гәүһәр-йакут, 485, 498 дә мәрҗан, 519 да ләэлеэ-мәрҗан (энҗе-мәрҗан!), 485 тә гакык, 353 тә мөрәссәгъ таҗ, 496 строфада мөнәкъкашь таҗга тап булабыз.

Кол Гали шушылай телгә алган асылташларның хәзерге исемнәре ниндирәк соң?

Ачыклауны ләэлеэ атамасыннан башлыйк. Әбу Рәйхан Бирунинең «Китаб әл-җамаһир фи мәгърифәт әл-җаваһир» («Асылташларны танып-белү буенча мәгълүматлар җыентыгы») (әсәреннән күренгәнчә, ләэлеэ ул — энҗенең гомуми исеме. Әгәр ул ярты мыскалдан (бер мыскал 4,464 граммга тигез) авыррак булса, дөрр-ү дип атала. Энҗенең ваграгы мәрҗән исәпләнә. Мәрҗән сүзенең килеп чыгышы борынгы грекча «маргаритес» һәм латинча «маргарита» сүзләренә барып тоташа. Борынгы Эллада һәм Римдә әлеге мәгънәнне энҗе яки перламутр дип атаганнар. Иранда бу сүз «мург» рәвешенә килә, гарәпләр аны «мурҗ», дип әйтә. Соңга таба ул «мәрҗән» кыяфәтенә керә һәм шул хәлендә безнең заманга килеп җитә.

Бируни Коръәндә хур кызлары хакында: «Алар гүя якут вә мәрҗән»,— дип язылуга игътибар итә. Ягъни, хур кызлары якут кебек пакь, энҗе кебек ак, имеш.

Ләкин гарәпләр вак энҗене генә түгел, янә бер асылташны (буссаз) мәрҗән дип атый. Моның серен ачыклау бик кыен. Энҗе белән мәрҗән (буссаз) бер-берсеннән формасы, төсе һәм бәясе (мәрҗән чыгыштыргысыз дәрәҗәдә арзанрак) белән дә аерыла. Ничек кенә булмасын, «мәрҗән» сүзенең ике мәгъдәнне аңлатуы бик озак дәвам итә. Без моны «Кыйссаи Йосыф» дастанында да күрә алабыз.

Дастанда «дөрр-ү мәрҗан» тезмәсе эре һәм вак энҗеләрне, ягъни, гомумән, энҗене аңлата. Мәсәлен, 171 строфада Кол Гали: «Күктән дөрр-ү мәрҗан, йенҗү йагди», дип, күктән вак һәм эре энҗе явуын белгертә, моны, аныклау өчен, өтердән соң тагын бер мәртәбә энҗе сүзен куллана. Хәзерге татар теленә бу юл: «Энҗе-мәрҗән яуды җиргә яңгыр кебек»,— дип тәрҗемә ителә. «Мәрҗән» сүзе бүгенге әдәби телебездә энҗене белгертмәвен истә тотсак, кызыл яңгыр явуны сурәтләү күңелне шактый шомландыра.

«Ләэлеэ-мәрҗан» тезмәсен вак энҗе дип аңларга кирәк. «Ләэлеэмәрҗандин дүзелмеш дырнакларең»,— ди шагыйрь (519 строфа). Бу юлны укыгач, гүзәлкәйнең энҗедәй тырнаклы нәфис бармаклары күз алдына килә. Хәзерге татар телендә шушы җөмләнең «Энҗемәрҗәндәй тезелгән тырнакларың» дип бирелүе кызыкайның тырнаклары берсе мәрҗәндәй кызыл, икенсесе энҗедәй ак — сәер һәм мәзәк кыяфәттә булуы белән гаҗәпләндерә.

Кол Гали барлык бүтән очракларда мәрҗән сүзен нәкъ менә хәзерге мәгънәсендә куллана. Мисалга, ул 485 строфада «кызыл мәрҗан» дип яза. Чыннан да, энҗе кызыл булмый! 498 строфада Зөләйханың бизәнгечләре: «Айагыгындан мәрҗан хали кушар имди»,— дип тасвирлана. Дөрестән дә, аяк беләзекләре энҗәдән түгел, нәкъ менә мәрҗәннән ясала. Ниһаять, «йенҗү-мәрҗан» сүзтезмәсе, «гәүһәр-якут» тезмә-

[1] Строфалар саны «Кыйссаи Йосыф»ның 1983 елда Казанда дөнья күргән басмасы буенча бирелә.

се кебек үк, асылташларның күмәклек исеме булып тора. Шагыйрь 433 строфада:

*Аг вә атлас, мишк-у ганбәр — җөмлә куйди,*
*Гәүһәр-йакут, йенҗү-мәрҗан буйлә куйди,—*

дип яза. Димәк, ул һич тә ялгызлык исеме мәрҗәнне күздә тотмый.

«Гәүһәр» сүзенең, энҗене белдерү белән бергә, асылташларның күмәклек атамасына әйләнүен дә искәртик. Моны «күзләрендән гәүһәр кеби йашләр акди» дигән 360 строфа да раслый. Шәрыктә күз яшен энҗе образында тасвирлау киң таралган. Әмма аеруча тантаналы очракларда Кол Гали бу сүзләргә киңрәк мәгънәне дә бирә:

*Гәүһәр — таш ул, ләкин һәр таш гәүһәр булмас,*
*Тикмә кеше гәүһәр кадрен аңлый алмас,*
*Бу назымның кадерен һич ахмак белмәс,—*
*Гакыллылар тыңлар, аңлар, белер имди.* (1004 строфа).

Дастанда, кулланылу ягыннан, өченче урында кызыл якут тора. «Йакутә биңзәрсәнең йаңак-ларең» (518 строфа). Шәрыктә урта гасырларда кызыл якут иң кыйммәтле һәм иң яратылган асылташлардан санала. Фирдәүси, Руставели, Низами, Җами, Нәваи поэмаларының һәркайсында бит саен шуның җете кызыл ялкыны дөрли. Югарыда искәрткәнебезчә, ул Коръәнгә дә килеп кергән. Шуңа күрә «Кыйссаи Йосыф»та кызыл якутка очравыбыз гаҗәп түгел. Ә менә энҗе, кызыл якут һәм мәрҗән белән бергә, Кол Гали нииндидер гакыкны телгә алуы серле. 485 строфада:

*Дөрлү-дөрлү терәкләр анда диксүн,*
*Бер нәчә дерәкләри инҗү улсун,*
*Бер нәчә дерәкләри гакык улсун,*
*Бер нәчә-се кызил мәрҗан улсун имди,—*

диелә.

Нәрсә икән соң ул гакык?

Бируни, кыйммәтле асылташлар белән бергә, халык арасында киң таралган арзанлы ташларны да тасвирлый. Алар янәшәсендә гакык әллә кайдан күзгә бәрелеп тора. Үзлеге ягыннан ул данлы асылташлардан калышмый: кварцтай каты, якуттай кызыл, әйбәт эшкәртелә. Бердәнбер кимчелеге — табигатьтә күп очравы.

Гакык йөзек, беләзек, муенсалар җитештерүдә кулланыла. Аңардан уеп мөһер ясыйлар, татар хатын-кызларының яраткан бизәнгече яка чылбырына да тагалар. Мәскәүдәге Дәүләт тарих музеенда XV гасыр татар морзасы хәзинәсеннән (Симферополь) алынган әйберләр саклана. Анда, энҗе муенса белән янәшә, кырык биш гакык төймәдән тезелгән муенса да бар.

Гарәпчә «гакыйк» татарча «гакык»ка бик якын. Рус телендә дә «сердолик»ның синонимы булган «акик» атамасы бар. Татарча исә ике мәгънәгә карата «ахак» атамасы кулланыла. Дөрес, бу мәгъдәннәр асылда бертуганнар — икесе дә кристаллик кварц. Тик аларның берсе катлам-катлам төзелеше, икенчесе бертоташ, ярым үтә күренмәле, кызыл, кызгылт-сары, әфлисун төсендә була. Беренчесен русча — «агат», гарәпчә «йашмун», икенчесен русча «сердолик», гарәпчә «гакыйк» дип атыйлар. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» ахакны «төрле төстәге бернича катламнан гыйбарәт каты минерал» дип таныта. Гакык исә бу сүзлектә теркәлмәгән. Моннан аңлашылганча, ахак сүзе русча «агат», гарәпчә «йашмун» дип атала торган мәгъдәнгә туры килә икән. Икенче минералны белдерер өчен шушы ук сүзне кулланганчы, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ында теркәлгән гакык сүзен саклау (русча «сердолик», гарәпчә «гакыйк») яхшы булыр иде.

Хәзер инде: «Кол Гали энҗе, кызыл якут һәм мәрҗән кебек затлы асылташлар янәшәсенә нигә гап-гади гакыкны куйды икән?» — дигән сорауга җавап бирәсе кала. Бу җәһәттән «Кыйссаи Йосыф» китабында асылташлар кулланылуына игътибар итү кызыклы.

Күренекле немец галиме Герман Банк фикеренчә, асылташлар: мөһер һәм мөһерле йөзек, дин һәм йола әйберләре, медицина кораллары, им-том, нәсел-нәсәп билгеләре, бизәнгечләр ясауда, каты матдәләрне эшкәртүдә, акчаны алыштыруда кулланыла. Кол Гали телгә алган асылташларга да без хәзер менә шушы җәһәттән күз салыйк.

Дастанда мөһер яки мөһерле йөзекнең бөтенләй очрамавы сәер. Югыйсә аны телгә алырга сылтау да, сәбәп тә бар: хакимнәр, биләр, түрәләр, сәүдәгәрләр сату-алу, төрле килешүләр ясый. Ләкин алар бер генә кәгазьне, бер генә битекне дә үзенең шәхси яки мәмләкәт мөһерен сугып расламый, беркетми. Дөрес, Кол Галинең бу җитешсезлеген укучылар артыгы белән төзәтә. Дастанның кулдан-кулга күчеп сакланган кулъязмаларына иясләренең исемнәре күзгә бәрелерлек итеп басылган!

Асылташлар дастанда бүтән яктан бик тулы файдаланыла. Пәйгамбәргә әйләнгән Йосыфның төрмәдән котылуын, мәсәлән, шагыйрь:

*Каршыларга бөтен Мисыр халкы чыкты,*
*Йөзен күреп ул Йосыфның, ләззәт тапты,*
*Алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән җиргә сипте,—*
*Олугъ-кечек күрер өчен йөгерер имди,—*

дип тасвирлый (681 строфа).

Затлы металлар һәм ташлар Йосыфны ходай тәгалә илчесе итеп күрсәткәндә дә эшкә җигелә. Йосыфның ничек итеп пәйгамбәргә әйләнүен күздән кичерик:

*Җәбраил бер ап-ак энҗе алып килде,*
*Йотар өчен Йосыфка ул шуны бирде,*
*Йосыф хикмәт һәм төш юрау гыйльмен белде, —*
*Могҗизалы пәйгамбәр ул булды имди* (584 строфа)

Нәсел-нәсәп билгеләре (мөрәссәгъ таҗ, мөнәкъкашь таҗ) 353 һәм 496 строфаларда очрый. Асылташларны бизәнгеч итеп файдалануга 496 строфа да мисал була ала:

*Зөләйха энҗе-мәрҗәнләп чәчен үрде,*
*Энҗе-мәрҗән аны гаҗәп зиннәтләде,*
*Бизәнеп, ул шул сарайга килеп керде,—*
*Йөз нурыннан сарай эче балкыр имди.*

Туганы белән саубуллашканда, Йосыф аңа үз хәзинәсендәге иң кыйммәтле әйбер — энҗе һәм кызыл якутлар белән бизәлгән алтын җамаяк бүләк итә (864 һәм 864[1] строфалар). Бу җамаякның бәясе дүрт йөз мең алтын, дип билгеләнә. Бүләкнең бүгенге акчага күчерелгән кыйммәтен белү җиңел түгел. Әмма 809 строфадагы мәгълүматлар исәп-хисапны ясарга булыша кебек.

*Аннан соңра Йосыф аңа үгет бирде,*
*Бер беләзек соңып аңа, мә, ал, диде,*
*Ул беләзек кып-кызыл саф якут иде,—*
*Кыйммәте аның мең динар торыр имди.*

Ул заманда алтын динар 4,23 грамм була. Шулай итеп, кызыл якут беләзекнең бәясе 4,23 килограмм алтынга бәрабәр икәнлеген беләбез!

Ниһаять, 485 (энҗе, мәрҗән һәм гакык баганалар) һәм 488 строфаларда асылташларны сарай коруда файдалану тасвирлана.

*Аның эчен җофар белән бизәсеннәр,*
*Түшәмнәргә җәүһәр кандилләр элсеннәр* (488 строфа).

Асылташларны кандилләрдә файдалану яктылык нурларын сындырырга, таркатырга мөмкинлек бирә. Алар оптик призма сыйфатында салават күпере хасил итәләр.

Профессор Г. Банк асылташлар файдалана торган бер өлкәне — сүз сәнгатендә метафоралар куллануны «онытып» калдыра. Кол Галинең шигъри осталыгын раслар өчен югарыда китерелгән мисаллар да җитәр, мөгаен.

Хәзер инде: «Бөек шагыйрь кем булган соң? Болгар дәүләтендә ул нинди урын биләгән?» — дигән сорауны куярга да вакыт җитте. «Кыйссаи Йосыф» китабына язган сүз башында Фазыл Фәсиев ихтимал урын һәм вазифаларны санап чыга да аларның берсенә генә — мөдәррис дәрәҗәсенә туктала. Хаклымы соң ул?

Дастандагы асылташларны тикшерү күрсәткәнчә, Кол Гали алар белән бик еш очрашмаган булса кирәк. Аның бар мәгълүматы китаби рухта яки халык авыз иҗатына гына нигезләнгән. Ул Коръәндәге асылташларны (якут — сигез тапкыр, мәрҗән — унөч тапкыр) һәм халык теленә хас йенҗү-мәрҗан, дөрр-ү мәрҗан, гәүһәр-йакут, ләәлеә-мәрҗан (барысы ундүрт мәртәбә) кебек тотрыклы сүзтезмәләрне еш куллана. Шул ук вакытта Шәрыктәге күп кенә мәшһүр кыйммәтле асылташлар — фирүзә, зөбәрҗәт, ләгыль, лазурит, анар дастанда, гомумән, очрамый. Аның каравы, арзанлы гакык игътибардан бер дә читтә калмый.

Югарыда язылганнар Кол Галинең хан сараеннан да, хәрбиләр һәм сәүдәгәрләр даирәсеннән дә шактый читтә, еракта яшәвен генә расларга мөмкин. Ул китап укый, гади халык белән аралаша. Фәкыйрь бер укымышлы кеше булганлыктан, кулына төшергән бердәнбер асылташы — гакык. Бәлки, бу таш аның йөзеген бизәп торгандыр, ә бәлки, гакыктан кара савыты ясалган булгандыр — мөдәррис Кол Гали шуңа кауры каләмен мана-мана гасырлар буе яшәячәк гүзәл шигырьләрен, дастаннарын язгандыр.

**Спартак ӘХМӘТЕВ,**
геология-минералогия фәннәре кандидаты.

# МОНГОЛ ЯУЛАРЫНА КАДӘРГЕ ЧОРДА БОЛГАР ИЛЕ БЕЛӘН РУСЬ АРАСЫНДА СӘҮДӘ ЭЛЕМТӘЛӘРЕ

Идел буендагы Болгар дәүләте тарихын өйрәнгән галимнәрнең һәркайсы аның иң якын күршеләреннән берсе Русь белән сәяси, экономик һәм мәдәни яктан ныклы элемтә тотканлыгын билгеләп үтмичә калмый. Бу арадашчылыкның бөтен Көнчыгыш Европа тарихы өчен дә әһәмияте гаять зур була.

Төрле элемтәләр арасында галимнәр бигрәк тә экономикага, сәүдәгә кагылышлы булганнарын билгеләп үтәләр. Бу хакта Х. Д. Френ, П. С. Савельев, В. Н. Татищев, Н. М. Карамзин, С. М. Соловьев, В. В. Григорьев, С. М. Шпилевский, В. О. Ключевский, А. Ф. Лихачев һ. б. хезмәтләреннән күп мәгълүмат алырга була.

1878 елда Казан университеты каршында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте төзелү археологик материаллар турындагы мәгълүматларны матбугатта чыгару эшен максатчанрак итеп алып барырга мөмкинлек бирә. Шул исәптән Болгар дәүләте белән Русь арасындагы сәүдә элемтәләре турында сөйли торган материаллар да матбугатта дөнья күрә.

Бөек Октябрьдән соңгы чорда Русь-Болгар элемтәләрен өйрәнүгә Р. Р. Фасмер, А. П. Смирнов, Б. Д. Грепов, Н. Ф. Калинин, Б. А. Рыбаков зур өлеш кертә.

Әйтик, Б. А. Рыбаков хезмәтләрендә Русь белән Болгар дәүләте арасындагы сәүдә элемтәләренең мөһим мәсьәләләре яктыртыла. В. Л. Янин исә ике ил арасындагы акча әйләнешен тикшерә. П. Г. Любимов, М. В. Фехнер, В. П. Даркевич, Г. Ф. Корзухин һ. б. Болгар дәүләтенең Русь белән Шәрык илләре арасындагы сәүдәдә арадаш үзәк роль уйнавына тукталалар. Археологик казу эшләрен киң колач белән алып бару Идел буе Болгар дәүләте белән Русь арасындагы элемтәләр турында гарәп илгизәрләре һәм рус елъязмачылары язып калдырганнарны раслый, сәүдә итү предметларын, сәүдә партнерларын күз алдына китерерлек яңа материаллар да бирә.

Монгол явына кадәрге Болгар дәүләтенең экономик яктан шактый нык үскән феодаль дәүләт булганлыгы хәзер әллә ни бәхәс тудырмый. Экономиканың нигезен авыл хуҗалыгы, һәнәрчелек, терлекчелек, сәүдә һ. б. тәшкил иткән.

Болгар дәүләтенең экономикасында сәүдә зур роль уйный. Аның югары үсеш алуына авыл хуҗалыгында һәм һөнәрчелектә ирешкән уңышлар ныклы этәргеч була. Болгарның Көнчыгыш Европада географик яктан бик уңайлы, зур сәүдә юллары тоташкан җирдә урнашуы аның үз чорындагы Көнчыгыш Европа тарихында мөһим урын тотуына булышлык итә.

Тарихи чыганаклар Болгар дәүләтендә сәүдәнең югары дәрәҗәдә үскән булуы хакында сөйли. Ибне Фазлан болай дип яза: «Алар да (болгарларда) сәүдәгәрләр күп». Сәүдәне үстерү белән дәүләт үзе кызыксына. Ибне Рустәнең хәбәр итүенчә, «мөселман сәүдә кораблары килгәндә алардан пошлина итеп товарларының уннан бер өлешен алалар». Ибне Фазлан бу хәбәрне тагын да ачыклый төшә: «Хәзәр иленнән славяннар иленә кораб килә икән, патша ат менеп килә һәм анда булган нәрсәләрне саный, бөтен булганның уннан бер өлешен ала. Ә инде руслар яки башка берәр кавемнәр коллар белән килә икән, ул чагында патша үзенә һәр ун баштан бер башны ала». Ибне Рустәнең хәбәр итүенә караганда, патша һәр йорттан ала торган ясакның бер формасы «ат һәм башкалар» була. Ибне Фазлан шундый ясак итеп кеш тиресен атый. Безнең уебызча, ясак предметының үзгәрүе халыкара сәүдәдә мехларның зур роль уйнавына бәйле булганды.

Әмма ул чордагы Болгар дәүләте белән Русьның экономикасында сәүдәнең реаль роленә артык зур бәя бирергә кирәк түгелдер. Б. А. Рыбаков болай яза: «Борынгы Русь авылы натураль хуҗалык принципларында яшәгән. Князьләр һәм боярлар үзләрендәге читкә чыгару предметларын (тиреләр, бал, балавыз, коллар) кара халыктан бернинди алмашсыз, ясак яки оброк рәвешендә алганнар. Рус җирләренә кертелгән чит ил әйберләре шәһәр һәм утарларда гына калган, җәмгыятьнең югарыгы феодаль катлавыннан ары китмәгән. Бу чордагы сәүдәне без шәһәрләр һәм хәтта бөтен культу-

ра барлыкка килүнең беренче сәбәбе итеп карарга тиеш түгелбез, ә киресенчә, җирле җәмгыять һәм аның эчке мөмкинлекләре үсү нәтиҗәсе итеп карарга тиешбез».

Рус-болгар сәүдә мөнәсәбәтләренең тарихын ике чорга бүлеп карарга мөмкин һәм бу әлеге илләр тарихында аерылып карала торган чорларга туры килә. Беренче чор X—XI гасырларны, икенчесе XI гасыр ахырыннан XIII гасыр башына, ягъни монгол явына кадәрге вакытларны үз эченә ала.

Гарәп чыганаклары Болгар дәүләте белән Русь арасында тыгыз сәүдә булуын, сәүдә предметларын күрсәтә. Ибне Рустә болай хәбәр итә: «Хәзәрләр болгарлар белән сәүдә итә: шулай ук Русь та аларга үз товарларын китерә. Аларның (ягъни русларның барысы да искә алынган елганың ике як ярында да яшиләр, аларга (ягъни болгарларга) үз товарларын: кеш, ас, тиен тиреләрен һәм башкаларны китерәләр».

Ибне Фазлан да рус сәүдәгәрләренең Болгар дәүләте территориясендә булуын хәбәр итә: «Мин русларны, үз товарлары белән килеп, Итил елгасы буенда урнашкан чакта күрдем». Шуның белән бергә, рус сәүдәгәрләре Болгар иленә үз товарларын сату өчен озакка килгәннәр, чөнки Ибне Фазлан аларның зур агач йортлар салулары турында да яза. Ибне Фазланның рус сәүдәгәренең догасы турында язганнары кызык: «Ул зур сурәт каршына килеп бил бөгә дә әйтә: Ходаем! Мин ерактан килдем, фәлән кадәр кыз, фәлән кадәр баш кеш, фәлән кадәр тире алып килдем, ди, шулай итеп, үзе алып килгән бөтен товарын санап чыга. Аннары әйтә: бу бүләкне сиңа китердем, ди, алып килгән нәрсәсен багана янына куя һәм әйтә: син миңа динарлары һәм дирһәмнәре булган сәүдәгәр китерсәң иде, ул мин теләгән (сатарга) бөтен нәрсәне алсын иде, аңа нәрсә әйтсәм дә, карышмасын иде: аннары ул китә. Сәүдә кыен барса һәм озакка сузылса, ул тагын бүләк алып икенче тапкыр, өченче тапкыр да килә... Еш кына исә аның сәүдәсе җиңел бара (ассызык безнеке — Р. В.), һәм ул сатканнан соң әйтә: ходаем теләгемне үтәде, моның өчен аңа бүләк тиеш»

Ибне Хәүкал «Юллар һәм дәүләтләр китабы»нда Хәзәр иленә китерелә торган бал һәм тиреләр кебек сәүдә предметлары турында сөйли дә, аннары болай дәвам итә: «Бу аларга, кама тиреләре кебек үк, Русь һәм Болгар иленнән китерелә, төрле илләргә чыгарыла һәм алар Болгар, Руслар һәм Куяба илләрендәге төньяк елгаларда гына бар. Әндәлүстә булган Кама тиреләре исә славян илләрендәге елгаларда булганнарның аз өлешен генә тәшкил итә. Бу мехларның күбрәк өлеше һәм иң яхшылары Русь илендә. Моны исә алар (руслар) Болгарда саталар иде...» (ассызык безнеке — Р. В). Шул рәвешле, гарәп чыганакларының һәммәсендә дә X гасырда Русь белән Болгар дәүләте арасында сәүдә элемтәләре тыгыз булу турында хәбәр ителә. Бер үк вакытта Болгар иленең Көнчыгыш белән Көнбатыш арасындагы транзит сәүдәдә арадашчылык итүе басым ясап күрсәтелә. Һәм шунысы игътибарга лаек, Ибне Хордадбехның 854—874 елларга яки, И. Ю. Крачковский фикеренчә, 846—885 елларга нисбәт ителә торган «Юллар һәм дәүләтләр китабы»нда Болгар дәүләтенең андый арадашчы булуы бөтенләй телгә алынмый, гәрчә рус сәүдәгәрләренең Иделдә йөзүе, Рум патшалыгына барып җитүе, Каспий диңгезенә җитеп, аның төрле ярларына төшүе, кайвакыт товарларын дөяләргә төяп Багдадка кадәр китүләре хәбәр ителә.

Елъязмаларда Русь белән Болгар дәүләте арасындагы сәүдә элемтәләре турында байтак искә алына, бу алар арасында тыныч яшәү турында төзелгән килешүләрдә дә чагылыш тапкан. 985 елгы «Повесть временных лет» язмасында политик союз төзелү турында әйтелә.

Бу союз болгар тарихында да, рус тарихында да зур роль уйнаган, ул руслар белән болгарларның тату яшәргә ихлас күңелдән теләвен күрсәтә, дияргә була. Чыннан да, елъязмалардан күренгәнчә, Русь белән Болгар дәүләте арасында тынычлык гасырдан артыкка сузылган. Шушы политик союз, һичшиксез, 1006 елда кул куелган махсус сәүдә килешүендә дә чагылыш тапкандыр.

1006 елгы килешү гамәлдә озак булган, чөнки рус елъязмаларында Русь белән Болгар дәүләте арасындагы сәүдәдә 1008 елга кадәр нинди дә булса регламентлаштырулар барлыгы турында аерып искә алынмый. Бу ике дата арасындагы чорда, 1024 елза Суздаль җирендә ачлык булып, болгарларның ашлык белән ярдәм итүе турында искә алына.

Русь территориясендә феодаль таркаулык көчәю яхшы күршелек мөнәсәбәтләренә дә комачаулык итә башлаган. Әлеге хәл сәүдә мөнәсәбәтләрендә дә чагылыш тапкан, билгеле. Бу вакыйга хакында В. Н. Татищев тәфсилләп яза: «6596 (1088)... Шул ук чорларда Идел һәм Ока буйларында юлбасарлыклар булган һәм сәүдә итүче бик күп болгарларны талаганнар, үтергәннәр. Болгарлар исә князь Олегка һәм аның туганы Ярославка юлбасарлар өстеннән үтенеч белән барганнар. Әмма юлбасарларга чара тапмагач һәм алынган әйберләре кайтарылмагач, көнчыгыштан килеп, Муромны алганнар һәм талаганнар, ә авылларны яндырганнар».

XI гасыр ахырында һәм XII гасыр башында, Владимир-Суздаль князьлеге төзелү

белән, Русь һәм Болгар арасындагы мөнәсәбәтләр икенче этапка керә. Бу чор өчен алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең беркадәр кискенләшүе характерлы. Әмма X—XI гасырларда урнашкан экономик бәйләнешләр, сәүдә мөнәсәбәтләре бөтенләй үк бозылып бетә алмаган, һәм бу чорга караган тарихи чыганаклар Болгар дәүләте белән Русь арасында сәүдәнең дәвам итүе хакында сөйли. Транзит сәүдә үзәге буларак, Болгар дәүләтенең характеры саклана, әмма ул элекке халыкара киңлеген бераз югалта. Болгар һәм Русь территорияләрендә булган Әбу Хәмид әл-Гарнатый болай хәбәр итә: «Славяннар иленә барганда мин, Болгардан чыккач, славяннар елгасы буенча корабта йөзеп бардым... Анда кечкенә мәче кебегрәк кара тиреле җәнлек бар, аны су кеше дип атыйлар. Аның тиресен *Болгарга һәм Саджинга илтәләр* (ассызык безнеке — Р. В.), ә ул шушы елгада була».

Русь елъязмаларында 1120 елга кадәр Болгар дәүләте белән Русь арасында сәүдә мөнәсәбәтләре начараю турында мәгълүматлар юк. 1120 елда Юрий Долгорукийның кайсыдыр бер туганы белән болгарлар өстенә яу чабуы турында хәбәр ителә. Елъязмалар кара-каршы яу чабуларны 1220 елга кадәр дәвам итүен күрсәтә. Әмма сәүдә туктамаган. В. Н. Татищев 1183 елга нисбәт итеп яза: «Русь белән туктаусыз сәүдә итеп торган Идел болгарлары ашлык та, башка төрле товарлар да китерәннәр. Идел һәм Ока буендагы рус шәһәрләрендә сатканнар. 1183 елда Рязань һәм Муром дружиналары (бәлки Владимирның болгарлар белән сәүдәсенә комачауларга теләптер) болгар сәүдәгәрләрен талый. Болгарлар Всеволодтан юлбасарлыкны бетерүен ике тапкыр үтенәләр». Рус князьләренең 1183 елгы зур походына болгарларның Ока елгасында рус сәүдәгәрләрен талавы сәбәп булган — бу факт та сәүдәнең булганлыгы хакында сөйли.

Князь Юрий Всеволодович 1221 елда, Ашлыны алгач, Болгар дәүләтенә янә яу чабарга ниятли, әмма болгарлар аңа өч тапкыр илче җибәрәләр. Шулай итеп кенә князьне ул уеннан баш тартырга күндерәләр. В. Н. Татищев болай яза: «Князь Юрий исә, аларның үтенечләрен тыңлагач, алар белән *этисе заманында төзелгән элекке договорлар нигезендә солых* (ассызык безнеке — Р. В.) төзи. 1229 елда тыныч сәүдә килешүенә кул куела. «Шул вакытта — дип дәвам итә В. Н. Татищев,— болгар князе, Русьта иген бөтенләй уңмавын белеп, бөек князь Юрий Всеволодовичка солых төзү өчен илчеләр җибәрә, бөек князь исә аларны хөрмәтләп каршылый. Һәм ике яктан да илчеләрне, күренекле кешеләрне Русь чигеннән ерак булмаган аерым урынга, Коренев утравына җибәрәләр. Бу кешеләр сәүдәгәрләргә ике якка да товарлар белән иркен йөрергә, пошлинаны һәр шәһәр уставында каралганча түләргә, балыкчыларга ике якка да ызанга кадәрле генә хәрәкәт итәргә, яратышып һәм тыныч яшәргә, әсирләрнең һәммәсен дә азат итәргә, ә ызгыш чыга калганда, ике яктан да судьялар килеп, ызанда хөкем итәргә, дип алты елга килешү төзиләр». Монда һәр шәһәрнең үз сәүдә пошлинасы турында искә алыну да кызык.

Шул рәвешле, XII—XIII гасырлардагы рус елъязмалары, Болгар дәүләте белән Русь арасында мөнәсәбәтләр начараюга карамастан, сәүдәнең дәвам итүе турында сөйлиләр. Болгар дәүләте белән Русь экономикасын күз алдына бастыра торган иң мөһим билге булган сәүдә, күрүебезчә, язма чыганакларда бик аз чагылыш тапкан. Шунлыктан сәүдә элементларын ачуда археологик материалларның ярдәме зур. Әлбәттә, сәүдә предметларының һәммәсе культуралы катлауда сизелерлек эз калдырмаган. Шунлыктан Русь белән Болгар дәүләте арасындагы сәүдәнең предметы, күләме турында гарәп илчеләренең, рус елъязмаларының мәгълүматларын, археология материалларын бөтенесен бергә комплекслы файдаланып кына фикер йөртергә мөмкин.

Монда шунысын да истә тотарга кирәк: Болгар дәүләте, халыкара транзит сәүдә үзәге буларак, Русь иленнән алга таба Шәрык илләренә озатыласы товарларны алып торган. Һәм, үз чиратында, болгарлар бу сәүдәдә, киңрәк итеп алсак, Көнчыгыш белән Көнбатыш арасында, арадашчы булганнар. Кызганычка каршы, гарәп географларының юлъязмаларында, төрле-төрле товарлар аталса да, аларның чыгышы анык билгеләнмәгән. Һәм бу безнең бурычыбызны беркадәр кыенлаштыра.

Руська Болгардан кергән бөтен экспортны ике төркемгә аерырга мөмкин. Беренче төркемгә болгарлар үзләре җитештергән продуктлар — иң элек авыл хуҗалыгы, һөнәрчелек продукциясе керә, икенче төркеме — болгарларның арадашчылыгы белән Русь территориясенә Шәрыктан килә торган товарлар.

Игенчелекнең нык үскән булуы ашлыкны да сәүдә предметы итә. Бу хакта 1024 елгы Тверь елъязмасында, В. Н. Татищев хезмәтендә телгә алына. Әл-Мөкаддәси үзенең язмасында Болгар дәүләтеннән чыгарыла торган товарлар арасында кәҗә, сарык тиреләрен, мөгезле терлекләрне әйтеп үтә. Ибн Фазлан аларның сәүдәгәрләре «төркиләр иленә барып сарыклар алып кайта» дип яза, шунлыктан аларның сарыкларының бер өлеше читтән кайтарылган була. Остеология материаллары Болгар дәүләтендә сарыклар бик күбәеп, авыл хуҗалыгы терлекләренең башка төрләреннән артып китүен күрсәтә.

Болгарда һөнәрчелекнең үсүе һөнәрчеләр эшләгән әйберләрне дә Русь территориясенә чыгаруга юл ача. Болгар күнчеләре бик яхшылап эшкәртелгән күннән сату өчен аяк киемнәре, курткалар, башка әйберләр тегәләр. Русьта да, Урта Азиядәге кебек үк, иң яхшы күнне һәм аяк киемен «болгарый» дип йөрткәннәр. Бу телдә дә чагылыш таба. Әйтик, рус телендәге «тулуп» сүзе дә татар теленнән алынган. Кием-салымның башка өлешләренә карата да шуны әйтергә мөмкин.

Чүлмәкчелектә эшне стандартлаштыру, әйберләрнең сыйфаты югары булу болгар керамикасын Русь территориясендә дә теләп куллануга сәбәп булган. Болгар осталары ясаган савыт-сабалар Владимир, Суздаль, Рязань, Пронск, Муром, Белоозеро, Мәскәү, Звенигород һәм башка шәһәрләрдә табылды. Шунысы игътибарга лаек: бу төбәкләрдә аш савытларыннан тыш, Болгар иленнән ашлык, май, бал һәм башка азык-төлек тутырып китерелгән зур чүлмәкләр дә киң таралган.

Археологик казынулар вакытында Русь территориясендә Болгар һөнәрчеләре ясаган йозаклар, авыл хуҗалыгы кораллары, сугыш коралларының кайбер төрләре, бизәнү әйберләре, сөяктән ясалган әйберләр дә табылды. Болгарлар Руська шулай ук чимал да җибәреп торганнар.

Язма һәм археологик материаллардан күренгәнчә, Руська Болгар дәүләте аша килгән түбәндәге товарлар исемлеген төзергә була: керамика, ефәк, киҗе-мамык һәм йон тукымалар, корал, хуш исле әйберләр, аш тәмләткечләр, сәнгатьчә һөнәрчелек предметлары, пыяла әйберләр, муенсалар, затлы металлар.

Үз чиратында Русь та Болгар дәүләтенә шактый күп товарлар җибәреп торган. Алар илнең эчке базарында да сатылган, Болгар аша Шәрык илләренә дә озатылган. Русьтан көнчыгышка җибәрелә торган товарларга, Болгар товарларын да кертеп, әл-Мөкаддәси түбәндәгечә яза: «Сәүдәгәрләрнең товарларына килсәк, Харәзмнән шулар чыгарыла: кеш, тиен, ас, сусар һәм урман сусары, төлке, кондыз мехлары, кәҗә тиреләре, балавыз, уклар, эре балык, бүрекләр, балык җилеме, балык сөякләре, күн, бал, чикләвекләр, барслар (яки ау этләре), кылычлар, көбә киемнәр, каен агачы, славян коллары, сарыклар, мөгезле терлек. Болар һәммәсе Болгардан китерелә».

Археологик һәм язма чыганакларны бергә кушып, Б. А. Рыбаков Русьтан чыгарыла торган товарларның мондый исемлеген бирә: кондыз, кеш, ас, ак төлке, сусар, төлке, куян, тиен мехлары; кол ирләр һәм хатын-кызлар; бал, балавыз, җитен һәм җитен әйберләр; полотно, көмеш әйберләр, бронза көзгеләр, бизәкле сөяк; кою, ювелирлык һәм керамика һөнәренең кайбер әйберләре, гәрәбә. Бу товарларның бер өлеше Болгарда сатылган, ә башкалары Шәрык илләренә озатылган.

Димәк, Идел буендагы Болгар дәүләте белән Русь арасында тыгыз экономик һәм сәүдә мөнәсәбәтләре даими диярлек яшәп килгән. Татар һәм рус халыклары язмышының тарихи уртаклыгында бу бәйләнешләр әһәмиятле роль уйнаган.

# СИГЕЗЕНЧЕ ДӘРЕС

*Боз һәм кар эреде,*
*Сулар йөгерде,*
*Егълап елгалар*
*Яшьләр түгелде.*
*Көннәр озая,*
*Төннәр кыскара.*
*Бу кайсы вакыт,*
*Иә, әйтеп кара?*

*(Яз көне)*
Габдулла Тукай

Телебезнең үзенчәлеге тагын шунда: җөмлә эчендә сүзләрне бәйләү өчен рус телендәге кебек предлоглар яки приставкалар кулланылмый. Татар телендә җөмләдә сүзләр үзара күбрәк кушымчалар ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән:

Лошадь идет **по дороге** Ат **юлдан** бара (Ат **юл буйлап** бара.)
Мама пришла **с работы** Әни **эштән** кайтты.

Сүзләрне бәйләү өчен *ярдәмлек сүзләр* (бәйлек, теркәгеч), шулай ук күп төрле *ярдәмче сүзләр* (ярдәмче исемнәр, ярдәмче фигыльләр) кулланыла. Телебездә барыннан да бигрәк ярдәмче фигыльләрне күп очратырга мөмкин. Мәсәлән:

Чыгып **китте** — вышел
Килеп **керде** — зашел
Укып **чыктым** — прочитал

Мисаллардан күренгәнчә, бу фигыльләр күбрәк рус телендәге приставкалар урынында кулланыла. Мәсәлән:

сикерде — прыгнул сикереп **төште — спрыгнул**
көлде — смеялся көлеп **җибәрде — засмеялся**
кычкырды — крикнул кычкырып **җибәрде — закричал**

Мондый кушма фигыльләр шулай ук күп кенә башка мәгънә төсмерләрен дә белдерәләр:

Курчак **егыла язды** — кукла чуть не упала.
Әйдә шигырьне **укып карыйк** — Давай попробуем читать стихи.
Шигырьне **сөйләп кара** — Попробуй рассказать стихи.

Кушма фигыльләр безнең сөйләмебезне баета, матурлый торган чара гына түгел, ә алар фикерне төгәл итеп әйтеп бирергә дә ярдәм итәләр. Кайвакыт бер-бер артлы 3-4 фигыль тезелеп килсә дә, безнең телебез өчен гадәти күренеш. Мәсәлән:

Мин керләрне **йөгереп чыгып алып кердем.**

Балагызның сөйләме чыннан да бай һәм матур булсын дисәгез, аларның кушма фигыльләрне уңышлы куллануына да игътибар итегез. Мәсәлән, урынына карап, түбәндәге җөмләләрнең һәр икесен дә кулланырга мөмкин:

Мин савытларны **юдым** — Мин савытларны **юып куйдым.**
Миңа курчакны **бир** — Миңа курчакны **алып бир.**

Без бакчага барабыз — Без бакчага **китеп барабыз.**
Ялгыш сөтне түктем — Ялгыш сөтне **түгеп җибәрдем.**

Бүгенге дәресне торак урыны — өй темасына үткәрик. Түбәндәге яңа сүзләр белән танышырбыз: **өй, ишек, тәрәзә, түшәм, идән, стена, түбә, бүрәнә, авыл, шәһәр.**

1. *Сөйләшеп алыйк:*

— Син кайда яшисең?

— Мин Казанда яшим (Мин Бөгелмә шәһәрендә яшим. Мин Сарман авылында яшим).

— Сезнең өегез кайсы урамда?

— Без Тукай урамында торабыз. Һ. б.

2. *Рәсем буенча эш:* Бу — өй. Бусы аның ишеге, бусы тәрәзәләре. Бу өйнең стенасы. Бусы өйнең түбәсе (Яңа сүзләр берничә мәртәбә кабатлана).

3. *Өй төзү уены.* Бала белән шакмаклардан өй төзелә һәм алда өйрәнгән сүзләр тагын кабатлана. Без өй төзедек. Өйнең стеналары сары, түбәсе кызыл. Бусы ишек һ. б.

Шигырьне укыгыз, эчтәлеген балаларга төшендерегез.

РЕНАТ ХАРИС

### МАТУР ӨЙ

Гөрселдәп җиргә аугач,
Ботаклардан чистаргач,
Кабыгыннан арынгач,
Бүрәнә булды агач.

Төз юан бүрәнәләр
Озыннар һәм авырлар...
КамАЗларга төядек,
Алып кайттык авылга.

Бүрәнәләрне киртләп,
Бурадык нарат бура,
Яшел чирәм өстендә
Сап-сары булып тора.

Акбай йөрде йомышка —
Ташып торды йомычка,
Ә песи булышмады,
Мыштым гына йоклады.

Авылда бүген өмә,
Өмәдән калыйм димә —
Өй салуның эше күп,
Эш күп булгач, кеше күп.

Мүк кыстырып күтәрдек,
Булмады җил үтәрлек.
Әле кыш киләсе бар.
Явасы бар салкын кар...

Акбай һаман булыша —
Чебиләрне куыша:
Йомычка ялгыш тисә,
Чебинең башын тишә.

Песи күләгә тапкан,
Тагын йокларга яткан...
Песи әле кечкенә...
Эшләмичә йөргәнгә
Үсә алмый һич кенә.

Җәйдек сап-сары идән
Озынлыгы ун адым.
Киңлеккә дә ун адым.
Песи биеп карады,
Акбай биеп карады,
Мин сикереп карадым —
Шыгырдарлык булмады.
Түбәсен яптык,
Кәрнизен кактык,
Ишеген куйдык,
Болдырын җыйдык
Буядык...
Юндык...
Нинди матур өй булды!

Шигырьнең эчтәлеге буенча әңгәмә үткәрелә. Балалар эчтәлекне аңлап бетермәсәләр, русча аңлатырга мөмкин. Яңа өйрәнгән: стена, идән, түбә һ. б. сүзләр кабатлана.

*«Кояш кайда» уены.* Көзге белән кояш нуры стенага, түшәмгә, идәнгә юнәлтелә: «Кояш кайда?»

— Түшәмдә, идәндә, тәрәзәдә һ. б.

Фәһимә ХИСАМОВА,
филология фәннәре кандидаты.
Рәшидә БОРҺАНОВА,
методист.

# Нажар Нәҗми

## Татар теле

Туган җирең Идел буе,
Һәр телнең бар туган иле.
Туган җирең кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле.

Ак алъяпкыч бәйләсәләр,
Өзелеп тора кызлар биле.
Кызлар кебек шат чырайлы,
Ачык йөзле татар теле.

Халкың кебек уңган да син,
Хезмәттә син көне-төне,
Ир-егетләреңдәй дәртле,
Гайрәтле син, татар теле.

Фәннән сине аерса да
Гасырларның афәт җиле,
Аксакалларыңдай олпат,
Акыллы син, татар теле.

Ассалар да, киссәләр дә
Үлмәдең син, калдың тере.
Чукындырган чагында да
Чукынмадың, татар теле.

Яндың да син, туңдың да син,
Нишләтмәде язмыш сине.
Дөньяда күп нәрсә күрдең,
Әй, мөкатдәс Тукай теле.

Төрмәләргә дә яптылар
Җәлил белән бергә сине.
Төрмәләрдә дә килмешәк
Булмадың син, татар теле.

Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыктың кире,
Хәтта фашист тегермәне
Тарта алмады анда сине,
Әй син, батыр татар теле!

Кабатланмас үткәннәрең —
Гасырларның яман чире.
Кабатлар сине гасырлар,
Татар теле, дуслык теле.

ناجار نه‌جمی

# تاتار تلی

توغان جیرڭ ایدل بویی ،
هر تلنڭ بار توغان ایلی .
توغان جیرڭ کبك نازلی ،
جردای موڭلی تاتار تلی .

آق آلیاپقچ به‌یله‌سه‌له‌ر ،
اوزولپ تورا قزلار بیلی .
قزلار کبك شات چرایلی
آچق یوزلی تاتار تلی .

حالقڭ کبك اوڭغان دا سین ،
حزمه‌تته سین کونی - تونی ،
ایر- یگتله‌رڭده‌ی ده‌رتلی ،
عه‌یره‌تلی سین تاتار تلی .

فه‌نه‌ن سینی آیرسا دا
عاسرلارنڭ آفه‌ت جیلی ،
آقساقاللارڭدای اولپات ،
آقللی سین ، تاتار تلی .

آسسالاردا ، کیسسه‌له‌رده
اولمه‌دڭ سین ، قالدڭ تری .
چوقندرغان چاغندا دا
چوقنمادڭ ، تاتار تلی .

یاندڭ دا سین ، توڭدڭ دا سین ،
نیشله‌تمه‌دی یازمش سینی .
دنیادا کوپ نه‌رسه کوردڭ ،
ئه‌ی مُقَدَّس توقای تلی .

تۆرمه‌له‌رگه ده یاپتیلار
جه‌لیل بله‌ن برگه سینی .
تۆرمه‌له‌رده ده کیلمشه‌ك
بولمادڭ سین ، تاتار تلی .

زیندانتارنی یاروپ چقتڭ ،
یالقنلانپ چقتڭ کیری .
حه‌تتا فاشیست تگرمه‌نی
تارتا آلمادی آندا سینی ،
ئه‌ی سین ، باتر تاتار تلی !

قاباتلانماس اوتکه‌نه‌رڭ -
عاسرلارنڭ یامان چیری .
قاباتلار سینی عاسرلار ،
تاتار تلی ، دوسلق تلی .

*Журнал өчен текстны* **Җәүдәт МИҢНУЛЛИН** *һәм* **Раиф МӘРДАНОВ** *әзерләде.*

## Резеда Вәлиевага 60 яшь



1983 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы Резеда Тәфкалүн кызы Вәлиева (Хәлилова) 1930 елның 1 маенда Башкортстан АССРның Кыйгы районы Дүшәмбикә авылында туган. 1947 елда Салават районының Каратаулы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Аны 1952 елда тәмамлаганнан соң, ул утыз елдан артык Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә редактор булып эшли.

Резеда Вәлиева, нигездә, балалар шагыйрәсе, нәниләрнең бай күңел дөньясын яратып сурәтләүче автор буларак танылды. «Минем дусларым» исемле беренче китабы 1960 елда дөнья күреп, аннан соң унбиштән артык китабы басылып чыкты. Әсәрләре арасында әкиятләр дә («Зәңгәр алан әкияте»), поэмалар да («Пионерка Гөлназ», «Якты йолдызым», «Ильичка хат», М. Җәлилгә багышланган «Шагыйрь гомере» һ. б.) һәм көйгә салынган җырлар да бар.

Р. Вәлиева тәрҗемә өлкәсендә дә эшли: С. Михалков, Н. Верзилин, Л. Воронкова, В. Тельпуговларның әсәрләре аның тәрҗемәсендә татарча яңгыраш алды, китап булып та басылды.

## Мәгъсум Хуҗинга 60 яшь



Мәгъсум Хәмит улы Хуҗин 1930 елның 15 маенда Татарстанның Саба районы Тенеки авылында колхозчы гаиләсендә туган. 1948 елда Саба урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, башта шул мәктәптә укытучы булып эшли. Аннары аны комсомолның Саба район комитетына секретарь итеп сайлыйлар. 1949—1954 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. 1954—1958 елларда «Татарстан яшьләре» газетасы редакциясендә эшли. 1958 елда М. Хуҗин үз теләге белән Казахстанга китеп, чирәм җирләрне күтәрүдә катнаша. 1959—1969 елларда Саба район газетасында — бүлек мөдире, Арча район газетасында — җаваплы секретарь һәм Балтач район газетасында редактор булып эшли. 1969 елдан 1988 елга кадәр «Чаян» журналында җаваплы секретарь вазыйфаларын башкара.

М. Хуҗин проза жанрында иҗат итә. Беренче хикәяләре көндәлек матбугат битләрендә һәм күмәк җыентыкларда илленче еллар башында ук күренә башлый. 1961 елда аның «Ерганак юл ала», 1966 елда «Хикәяләр», 1973 елда «Курагай атлары», 1978 елда «Авылым урамнары», 1980 елда «Урманлы үр», 1984 елда «Өч каен ышыгы», 1987 елда «Бәхет җире», 1988 елда «Урак өсте болытлары», 1990 елда «Ерактагы кыялар» китаплары дөнья күрде.

М. Хуҗин — 1980 елдан СССР Язучылар союзы члены.

*Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редакциясе юбилярларны кайнар котлыйлар, сәламәтлек һәм иҗат уңышлары телиләр.*

## РСФСР ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ПЛЕНУМЫ

19—20 мартта Мәскәү каласында РСФСР Язучылар берлеге идарәсенең VII пленумы булып үтте. Кереш доклад белән идарәнең сәркатибе Н. Шундик чыкты. Берлекнең яңа Устав проекты белән И. Стрелкова таныштырды.

Фикер алышуларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев тә катнашты һәм чыгыш ясады.

Пленум карары нигезендә Татарстаннан Акъегет (Рөстәм Фәйзуллин), З. Хөснияр, Л. Лерон СССР Язучылар берлеге сафына кабул ителделәр.

## КПСС ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА

27 мартта КПСС өлкә комитеты пленумы булды. Анда Үзәк Комитетының партиянең XXVIII съездына Платформасы, КПСС Уставы проектларын тикшерү барышы турындагы, өлкә партия оешмасында отчет-сайлауларны үткәрү вакыты һәм тәртибе турындагы мәсьәлә каралды.

Фикер алышуларда «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Фәйзуллин да катнашты. Ул үзенең чыгышында республикабызга союздашлык статусы, татар теленә дәүләт теле статусы бирү кирәклегенең мөһим булуын әйтте, әдәбият һәм мәдәният өлкәсендә кичектерми хәл ителергә тиешле шактый мәсьәләләрне билгеләп үтте.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

27 март көнне Татарстан Язучылар берлеге башлангыч партия оешмасының отчет-сайлау җыелышы булды. Доклад белән партоешма секретаре Р. Кәрами чыгыш ясады.

Чыгыш буенча фикер алышуда Г. Бәширов, Р. Мөхәммәдиев, М. Маликова, Р. Мостафин, С. Сабиров, М. Хәбәбуллин, М. Вәлиев, Ә. Гаффар, М. Галиев һ. б. катнашып, башлангыч партия оешмасының үзгәртеп-кору барышындагы эшчәнлегенә бәя бирделәр.

Соңыннан Р. Мөхәммәдиев, Р. Фәйзуллин, Р. Низамиев, М. Шабаев, С. Ибраһимова, Г. Рәхим, Ш. Мостафин, М. Скороходов, Р. Корбанов иптәшләр составында яңа партбюро сайланды. Берлекнең башлангыч партия оешмасы секретаре итеп «Казан утлары» журналының баш редакторы урынбасары Р. Низамиев сайланды.

## КЕМБРИДЖ — КАЗАН

Англиядәге зур булмаган Кембридж каласы Европада үзенең борынгы университеты белән данлыклы. Шулай ук ул дөнья энциклопедия үзәге буларак та таныла. Биредә дөньякүләм исеме булган Халыкара биографик Үзәк эшли.

Күптән түгел бу Халыкара Үзәкнең Генераль директоры доктор Э. Кей күренекле галимебез, филология фәннәре докторы Ә. Кәримуллинга хат белән мөрәҗәгать итте. Хатта Үзәк тарафыннан чыгарылачак өч энциклопедик легатькә аның турында мәкалә урнаштыру өчен рөхсәт бирүен үтенгәннәр.

Мондый шатлыклы хәбәрне Ә. Кәримуллинның гыйльми эшчәнлегенә иң зур бәяләмәләрнең берсе дип аңларга кирәк.

## ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

23 мартта Казанның Актерлар йортында Татарстан Язучылар берлегенең киңәйтелгән пленумы булды. Ул узган ел дөнья күргән әдәби әсәрләр турындагы сөйләшүгә, ягъни әдәби ел йомгакларына багышланды. Аны кереш сүз белән ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев ачты.

Пленумда катнашучылар З. Мансуровның — шигъри әсәрләр, язучы Т. Әйдинең — чәчмә әсәрләр, язучы Л. Леронның — балалар әдәбияты, В. Корчагинның республикабызда яшәп иҗат итүче рус әдипләре иҗатлары турындагы чыгышларын тыңладылар.

Фикер алышуларда язучылар Р. Хисмәтуллин, Н. Әхмәдиев, Ә. Мәхмүдов, Р. Зәйдуллин, Э. Мөэминова, М. Вәлиев, В. Лавришко, С. Шәмси, Р. Мингалим, Ж. Тәрҗеманов, Р. Кәрами һәм башкалар чыгыш ясады.

Татарстан Язучылар берлегенең киңәйтелгән пленумы 14 нче Батыршин сайлау округына ТАССР халык депутатлыгына кандидатлар күрсәтү мәсьәләсен дә карады. Берничә кандидат арасыннан күпчелек тавыш белән ТАССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты Г. Рәхим кандидатурасын күрсәтү турында карар кабул ителде.

## НӘНИЛӘР ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЖУРНАЛ

1 мартта, ниһаять, нәниләр өчен татар телендә «Салават күпере» исемле айлык журналның беренче саны дөнья күрде. Төсле рәсемнәр белән матур итеп бизәлгән бу бүләк «Поинт» дигән совет-фин фирмасы тәэмин иткән сыйфатлы кәгазьдә басылган. Әлегә журналның тиражы — 25 мең данә.

Сабыйларыбызны сөендерүчеләр: баш мөхәррир З. Хөснияр (ул әдәбият сөючеләргә «Таң ата да кич була» исемле китабы белән билгеле), җаваплы сәркатип Р. Корбанов, бүлек мөхәррире Л. Лерон (алар икесе балалар өчен берничә китап авторы), бизәлеш мөхәррире А. Үтәгән (күп еллар «Ялкын» журналында эшләде).

## ТАТАРСТАН КИНОЧЫЛАРЫ СЪЕЗДЫ

27—28 мартта Казан телевидение студиясендә Татарстан киночыларының IV съезды булды. Анда катнашучылар Казан кинохроника студиясендә һәм Казан телевидениесендә эшләнгән документаль фильмнар белән таныштылар. Икенче көнне ТАССР Киночылар берлеге идарәсенең беренче сәркатибе Х. Фәхретдинов, берлекнең ревизия комиссиясе әгъзасы М. Швецов, Е. Алексеева, Н. Сарычева чыгышлары, Казан телевидениесенең телефильмнар редакциясе баш мөхәррире Л. Букштейн һәм Казан кинохроника студиясенең баш мөхәррире В. Пранов информацияләре тыңланды.

ТАССР Киночылар берлеге идарәсенең беренче сәркатибе итеп кинорежиссер Н. Вәлитов сайланды.

## С. СӘЙДӘШЕВКА ҺӘЙКӘЛ САЛУ ФОНДЫНА

16 март көнне Актерлар йортында «Уйныйбыз да, җырлыйбыз да» дигән әдәбимузыкаль кичә үткәрелде. Анда төрле-төрле сәнгать һөнәренә ия булган язучылар чыгыш ясадылар. Программада булган җырлар, биюләр, шигырьләр, көлкеле хикәяләр, гармун һәм курай моңнары тамашачылар күңеленә хуш килде. Кичәне язучы Р. Кәрами алып барды.

Бу әдәби-музыкаль кичәдән җыелган акча С. Сәйдәшевка һәйкәл салу фондына тапшырылачак.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЯҢА ГАЗЕТАЛАР

Март аенда КПССның Татарстан өлкә комитеты, күп кенә партия оешмаларының үтенечен искә алып, татар телендә яңа газеталар чыгару турында карар кабул итте. Түбән Камада моңа кадәр тәрҗемә рәвешендә чыгып килгән «Ленин нурлары» газетасы мөстәкыйльлек статусы алды. Әлмәт спиральҗөйле торбалар коллективы да үз газетасын укыячак. ТАССР Юстиция министрлыгы һәм «Хокук белгече» кооперативы — «Хокук», ә ТАССР Эчке Эшләр министрлыгы «Криминаль хәбәрләр» дигән татарча газета чыгаруны үз өсләренә алдылар.

## ХУШ КИЛӘСЕҢ, НӘҮРУЗ!

21 март көнне Казанның Яшьләр үзәгендә Нәүруз бәйрәме үткәрелде. Бу — төркн халыкларның борын-борыннан килгән кышны озату, язны каршылау бәйрәме. Тантананы тарих фәннәре кандидаты Г. Фәйзрахманов ачты. Аннан соң төрле уеннар, җыр-биюләр башкарылды. Шәһәребезнең югары уку йортларында белем алучы төрки кардәшләребез вәкилләре булган студентлар үзләренең милли сәнгать үрнәкләре белән таныштырдылар.

Нәүруз бәйрәмен оештыруда ВЛКСМның Казан шәһәр комитеты, шәһәр Советы башкарма комитетының мәдәният бүлеге, хуҗалык исәбендәге «Болгар»» берләшмәсе, яшьләр торак комплексының «Ядкарь» театр-студиясе, Татар Иҗтимагый үзәгенең яшьләр бүлеге, ветеринария институты коллективлары башлап йөрде.

* * *

21 март көнне Үзбәкстанда үткәрелгән Нәүруз бәйрәменә Татарстан сәнгать осталары да чакырылды. Концертларда РСФСРның атказанган артисткасы Ә. Авзалова, Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге бүләге лауреаты, җырчы Г. Сафиуллина, «Татарстан яшьләре» газетасының Ф. Кәрим исемендәге республика бүләге лауреаты И. Сафин, З. Билалов, көйләр авторы һәм башкаручы Ф. Мортазин, Татарстанның атказанган артисткасы Р. Мостафина, яшь сәнгать осталары З. Авзалова, Г. Вафина, М. Гомәров һәм башкалар катнашты.

Нәүруз бәйрәмен дуслык һәм туганлык шартларында үткәрүгә Ташкенттагы Татар иҗтимагый үзәге үзеннән зур өлеш кертте.

## «НИЧЕК ЭКСТРЕМИСТ БУЛЫРГА?»

Башкортстанда яшәүче әдип А. Хәлим һәм Ростов кинохроникасы студиясе режиссеры В. Голубниченко март аенда Казанда киң җәмәгатьчелек белән очраштылар. Әлеге очрашулар вакытында А. Хәлимнең 1988 елда «Дружба народов» журналында «Телем минем — дустым минем» дигән мәкаләсенә нигезләнеп төшерелгән «Ничек экстремист булырга?» дигән документаль фильм да күрсәтелде. Фильм Башкортстанда татарлар тупланып яшәгән төбәкләрдәге мәктәпләрдә татар телендә укыту бетерелеп, башкортча укытуга күчү, татарларның паспортларында милләтләрен башкорт итеп яздырту кебек конфликтлы ситуацияне анализлау белән генә чикләнми. Ул тел мәсьәләсенең, халыкның үзаңы, милли мәдәни үсеше, һәр шәхеснең җәмгыятьтәге иҗтимагый-сәяси роле кебек проблемаларны да кузгата.

Фильм режиссерының кыю эшчәнлеген билгеләп:

— Василий Голубниченконың бу эшен урыс интеллигенциясенең батырлыгы дип бәяләргә кирәк,— диде тәнкыйтьче М. Вәлиев очрашуларның берсендә.

Шулай ук режиссерның «Таулар кара башлык астында» исемле икенче фильмы да тамашачыларда зур кызыксыну уятты.

# БҮРӘНӘНЕ САЛЫП БҮРӘНӘГӘ...

Авыл җирлегендә XIX гасырда төзелеп, кайберләре бүгенге көннәргә кадәр сакланып калган ике-өч катлы агач өйләр үзенчәлекле милли архитектурабызның асыл үрнәкләре булып тора. Шунысы кызганыч, кайчандыр бихисап булган бу тарихи кыйммәткә ия йорт-каралтылар төрле сәбәпләр аркасында акрынлап юкка чыга бара. Аларны бик аз санда гына беренчел кыяфәтләрендә сакланган килеш республикабызның Казан арты Олы Мәңгәр (рәсемдә), Кенәр, Әтнә, Мари АССРның Бәрәңге районы (Куян) авылларында күрергә мөмкин.

Казан арты элек-электән, Болгар дәвереннән һәм бигрәк тә Казан ханлыгы вакытында югары сыйныфларының мул һәм җитеш тормышлары, зәвык белән бизәлгән катлы-катлы матур, мәһабәт йорт-җирләре белән танылган төбәк. 1552 елда Явыз Иван гаскәрләренең Казанны алу сугышларында катнашкан князь А. Курбский шул җирләрдән үткәндә күргәннәрен тәэсирләнеп болай дип язып калдырган: «Ул якта... князь-байгураларның утарлары искиткеч гүзәл һәм чын мәгънәсендә шаккаткыч». Ул заман өй-куралары инде күптән юк, ләкин күзәтүчән князь язмаларында бирелгән бәяләмә татар милли архитектурасының XV—XVI гасырларда ук шактый югары дәрәҗәдә үсеш алган булуын дәлилли. Шундый «искиткеч гүзәл» һәм «чын мәгънәсендә шаккаткыч» корылмалар үзләренең төзелеше ягыннан борынгы болгар архитектурасы традицияләренә барып тоташа. Бу традицияләрнең алга таба үсешендә соңрак Казан монументаль архитектурасының йогынтысы да көчле һәм сизелерлек була.

Идел буенда XIX йөз ахырына табан, капитализмның кызу темплар белән үсеш алуы Казан арты авылларында да буржуазиянең ныгуына китерә. Авылларда шәһәрдәгечә катлы өйләр салу тагын да киң таралыш ала. Аларны төзүдә калалардан килгән тәҗрибәле осталар да күп көч куя. Шул рәвешле шәһәр төзелеш архитектурасы өлешчә авыл җирлегенә күчә бара.

Ике катлы өйләрне, гадәттә, хач формасында нык һәм төз бүрәнәләрдән төзегәннәр. Тышкы яктан карaганда, иң элек өйнең алгы ягында уеп-сырлап бизәкләнгән ике кыегы белән чикләнгән өчпочмак рәвешендәге түбә өлеше игътибарны җәлеп итә. Аның астындагы куышлыкта фигуралап юнылган терәкләр белән уратылган балконнары урын ала. Өстәрәк нурларын чәчеп торучы кояш сурәте. Куышлыкның чарлагында махсус тәрәзәләр уела. Биредә кызлар өчен җәйге бүлмә дә эшләгәннәр. Шушы композиция очлаеп яки ярымтүгәрәк булып тәмамланган. Бу төзелеш ысулы борынгы Болгар һәм Казан ханлыгы дәверендәге йорт-каралтыларга бик тә охшаш. Моңа мисал итеп болгар җирендәге «Кара пулат»тагы куышлыкны күрсәтергә мөмкин.

Төп фасадтагы икенче катның өч ягы буйлап сузылган агач терәкле җиңел верандага охшашлы айван ике-өч катлы агач өй архитектурасының икенче үзенчәлегеннән исәпләнә. Бу айван ягында яшел бакча яки агачлыкның мотлак булуы Казан арты татар авылларының милли йөзен тагын да ача төшә. Шунысын да әйтеп үтү урынлы булыр, мондый үзенчәлекле билгеләр Урта Идел һәм Урал буенда яшәүче башка халыклар тормышында чагылыш тапмаган. Дөрес, Урта Азия, Кавказ һәм Кырымда яшәүче төрки кардәшләребезнең дә милли архитектурасында мондый декоратив айваннарның булуы уртак мөнәсәбәтләр барлыгы турында сөйли.

Үткән гасырдан безгә ядкарь булып калган бибәһа бу һәйкәлләр татар милли архитектурасының сәнгати шаһиты буларак халкыбызның мәдәни хәяте тарихын тагын да тулырак итеп, чынбарлыгы белән күзалларга ярдәм итә.

**Йолдыз МӨХӘММӘТШИН**,
тарих фәннәре кандидаты.

**Рөстәм МӨХӘММӘТҖАНОВ** фотосы.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган әдип Әхсән Баянов.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотосы.

## ЖУРНАЛ АЛДЫРУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Журналның брак саны килгән очракта аны газета-журналлар нәшриятының техник контроль бүлегенә җибәрүегезне үтенәбез. Адресы: 420066, Казань, Декабристов, 2, Типография ГЖИ, ОТК.


Редакция журнал җибәрү белән шөгыльләнми.

Әгәр журналның теге яки бу саны килми калса, «Союзпечать»нең җирле бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бу мәсьәлә редакция вәкаләтенә керми.

Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)